# казан утлары

7
ИЮЛЬ - 1970



АЛЕКСАНДР КЛЮЧАРЕВ



ИЛҺАМ ШАКИРОВ

# ТУКАЙ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

## ТАТАРСТАН АССР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫНДА

Тукай исемендәге республика премияләре комитеты утырышы булды. Комитет 1970 елда Г. Тукай исемендәге республика премияләрен музыка өлкәсендә — «Канатлы яшьлек» исемле җырлар җыентыгы һәм татар халык музыка иҗатын җыюда, аны пропагандалауда нәтиҗәле эшләгәнлеге өчен **Александр Сергеевич Ключаревка**, театр һәм музыка-башкару эшчәнлеге өлкәсендә — 1968—1969 елларда «Татар халык җырлары», «Җырларым сиңа, Октябрь» исемле концерт программаларын башкарганы, татар халык җырларын, татар композиторлары әсәрләрен пропагандалаган өчен **Илһам Шакировка** бирү турында карар кабул итте. Татарстан АССР Министрлар Советы Тукай исемендәге республика премияләре комитетының бу карарын раслады.

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

7

ИЮЛЬ

1970

## Бу санда:

ПОВЕСТЬ, ШИГЫРЬЛӘР

Ш. ГАЛИЕВ. Үзем! дисең... Сынатма. Бер мең дүрт йөз унсигез көн... Нюра. Хәтимә апа. Ул фронтка бәхилләшеп китте. Музейда булган хәл. Карт карга. Карыйм да мин... Мәхәббәт һәм биография. Мәңгелектән... Сез тарихның ар башында. Тел очында гына... Күлмәк эченә башак куя идем. Район газетасында эшләгәндә. Күптән яши монда тегермәнче. Кайнар кеше иде. «Уфалланы» тарттым. Үстерим дисең баланы. Биш ел буе. Ай-һай... Шактый еллар... Шигырьләр . . . 3
В. НУРУЛЛИН. Күпер чыкканда. Повесть . . . 10
Г. АФЗАЛ. Гомер китабы. Тирәк. Уйландыра торган чак. Рәсүл Гамзатовтан. Яхшы. Шигырьләр. 43
ЗӨЛФӘТ. Очыш. Шаулый хәтер. Челдерәү. Болык. Кирәкми! Мәңгелек. Мизгел. Синнән еракта... Таныш кышны сагыну. Без генәме! Шигырьләр. 45
Җ. ТӘРҖЕМАНОВ. Лобачевский һәм Халфин. Романнан өзек . . . 50
Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Ышанмагыз, авылдашлар. Йолдыз. Этюд. Миләш. Өмет. Тәнге смена. Шигырьләр . . . 85
Э. МОСТАФИН. Язмыш тәрәзәсе. Көймә. Кичә шат идең. Яралардан аккан канга манып. Кайт, диярсең. Шигырьләр . . . 87
Н. МАДЬЯРОВ. Нинди язмыш. Тартәр җыры. Кайчакта күңел сүрелә. Яшьлек безнә уйната да иде. Җәй буенча. Кояшка эндәште. Шигырьләр. 91

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

В. ГУДКОВА. «Җәй килүнең» сере. Очерк . . . 92
З. ШӘФИГУЛЛИН. Авыл — шәһәр эзеннән. Очерк. 93

ПУБЛИЦИСТИКА

Г. АХУНОВ, М. ЗАРИПОВ. Татарстан — туган йортыбыз . . . 107

КЫЗЫКЛЫ БИОГРАФИЯЛӘР

И. САЛАХОВ. Сикәлтәле сукмаклардан. Очерк . . 117

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Х. ГОСМАН. Тарихчанлык принцибын үзләштерү юлында . . . . . . . . . . . . . . . 128

ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА

Р. СИБӘГАТОВ. Тәрҗемәгә ике караш . . . . . 136

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. БАТУЛЛИН. Хыял дөньясында . . . . . . . . 142
П. СТАРОСТИН. Туган ягыбызның ерак үткәне . 144

Бәләкәй рецензияләр . . . . . . . . . . . . . 145

МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ә. КӘРИМУЛЛИН. Тормышка ашмаган проектлар . 147

ТЕАТР СӘНГАТЕ

И. ИЛЯЛОВА. Яңа үрләргә карап . . . . . . . . 160

СТЕПАН РАЗИН ВОССТАНИЕСЕНӘ 300 ЕЛ

С. АЛИШЕВ. Крестьяннар сугышында татарлар . . 167

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

Г. ФӘЙЗРАХМАНОВ. Пирамидалар илендә . . . 174

ФОЛЬКЛОР

Ф. ӘХМЕТОВА. Керәшен йолалары . . . . . . . 179

ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

Ә. КАЙБЫШЕВ. Казанда беренче татар спектакльләре . . . . . . . . . . . . . . . . 181

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

З. ГОМӘРОВА. Нигә Вәли тиз үсми. Күңелем. Чыланудан качалар. Укып бир. Табышмак. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 183

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Р. ФӘИЗОВ. Могҗиза. Күгәрчен Фазыл. Хикәяләр. 185
Ә. БАЯНОВ. Үкенечкә. Мәхәббәт корбаны. Әтәчләр сугышы. Баганалар. Шигырьләр . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 27/IV-1970 ел. Басарга кул куелды 11/VI-1970 ел. ПФ 09059.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 85046 экз.
Заказ С-270. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казань, Бауман урамы, йорт 19. 1970 ел.

## Шәүкәт Галиев

●

Үзем! дисең,
Үзем булып калыйм, дисең,
Үзлегемне саклыйм, дисең,
Югалтмыйм! дисең.
Нык торасың.
Тик торасың..
Оттырасың!

Үзең булып яшәү сере
Бу тормышта
Үзгәдер лә —
Үзең булып калыйм, дисәң,
Кирәк һаман
Эзләнергә,
Үсәргә һәм
Заман белән бергә
Үзгәрергә,
Үзгәрергә!

### Сынатма

Берәр жиргә жыенганда, әнкәй
Искәрткәне әле исемдә:
— Сынатма —
Кемнеке дигәндә,
Галиулла улы! дисеннәр.

Мин укырга кердем. Әткәйнең дә
Озатуы әле исемдә:
— Сынатма —
Кемнеке дигәндә,
Һидият нәселе! дисеннәр.

Мин шәһәргә киттем. Авылдашлар
Башка нинди киңәш бирсеннәр:
— Сынатма —
Кемнәр бу дигәндә,
Тау ягыннан болар! дисеннәр.

Илләр гизеп сәфәр йөргәндә дә,
Каләм алганда да исемдә:
— Сынатма —
Кемнәр бу дигәндә,
Татарстан улы! дисеннәр.

## Бер мең дүрт йөз унсигез көн...

Бөек Ватан сугышы 1418 көн дәвам итте.

Ябырылып килде өскә
Фашист кыяфәтле үлем.
Сугыш булды өндә, төштә,
Каршы тордык явыз көчкә —
Бер мең дүрт йөз унсигез көн,
Бер мең дүрт йөз унсигез төн!..

Яулап тыныч киләчәкне
Җир шарын шуышып үттек.
Һәр секундта без кан түктек,
Һәр минутта без кан түктек —
Бер мең дүрт йөз унсигез көн,
Бер мең дүрт йөз унсигез төн...

Ул чакта ышанган идек
Соңгы сугыш, соңгысы дип,
Гел уяу булырга куша,
Гел уяу булырга куша —
Бер мең дүрт йөз унсигез көн,
Бер мең дүрт йөз унсигез төн!..

Күңелләрдә һаман яна,
Онытылмый икән бер дә:
Бәгырьләрне телеп яна,
Гомергә төзәлмәс яра —
Бер мең дүрт йөз унсигез көн,
Бер мең дүрт йөз унсигез төн...

## Нюра

Ул сугыштан бала белән кайтты —
Зифа буйлы шәфкать туташы.
Кеше күзләреннән качып булмый,
Тормышның бу, туган, уртасы.

Башын ия дә ул, чәчен чөя,
Чыш-пышлардан нигә куркасы —
Хат җибәреп тора, акча сала
Яшь капитан — кызның атасы.

...Сугыш бетте дигәч, хәбәр килде...
Карточкасын үбеп жылады...
Ә кыз үсте, рәсмен: «папа!» диде,
Ирнен тешләп ана тыңлады.

«Папаң исән! — диде,— кайтыр!» диде,
Эчтән генә йотты күз яшен:
«Кайгымны бер үзем генә белим,
Нарасыем боегып үсмәсен»...

Ә бер көнне дусты хатка язды:
«Капитаның исән ләбаса,
Эз югалтыр өчен генә үзен
Үлгән хәбәр иткән ләбаса.
Яна семья корган...»

...Уен гына
Булды микән бөтен узганнар?!
— Нәрсә булды, әни, ник җылыйсың?
— Әтиең үлгән, диеп, язганнар...

## Хәтимә апа

Ишетелеп тора: өске катта
Тып-тып басып бала йөгерә.
Чырык-чырык килеп туп сикертә,
Җылап алырга да өлгерә.

— Борчыймыйммы?
— Рәхәтләнеп тыңлыйм!
Ә үземә насыйп булмады...
Өч кенә көн торып калдык. Сугыш
Йолкып алды Насыйбулламны...

Хаты да юк, үлгән хәбәре дә.
Күңел һаман көтә, ышана.
Үткен егет иде, кайтыр кебек
Юллар нинди урау булса да...

Япа-ялгыз көн кичерәм шулай,
Тыңлап өстә бала уйнавын...
Тәрбиягә үзем алмак булдым,
Ә аннары кире уйладым.

Кеше әйтте: ирең кайтып керсә,
«Нинди бала?» диеп шикләнер.
Ә аласы калган... Күрер идем,
Инде үсеп буйга җиткәнен.

...Үзе сөйли, үзе оек бәйли,
Оек бәйли күрше баласына.
Ә аннары, ак йон җебе алып,
Шарф башлый Насыйбулласына...

●

Ул фронтка бәхилләшеп китте,
«Кайтып булмас,— диеп,— туганнар...»
Күз яшьләре белән озаттык без...
Ә районнан кире борганнар.

Өч көннән соң кабат чакырдылар.
«Бәхил» сүзен ул да катмады.
«Кайтасың!» дип көлеп озаттык без.
Китте... Ләкин кире кайтмады...

## Музейда булган хәл

Музейда мин бервакыт
Күргән идем бер макет:
Бик фәкыйрь авыл өе
(Нәкъ менә булган көе!).
Шәрә сәкедә түрдә
Агай чабата үрә.
Ә хатыны йон эрли.
Бик үз... Моңсу, җан әрни...

Күрәм, китәм дигәндә —
Вак акчалар идәндә.
Бүгенгеләр көлгәннәр —
Үртәп хәер биргәннәр...

...Ачудан ярсый-ярсый
Абзый чабата ясый!

## Карт карга

Карачкыга килеп кунды
Карт бер карга.
Тәҗрибәле — ашыкмый ул
Каркылдарга.

«Бу карачкы монда тора
Күптән инде,
Без моңарга күнегеп тә
Беткән инде.

Белә идем хуҗасын да
Эшләпәнен,
Күрә идем баш күтәрми
Эшләгәнен,

Хәтерлимен гадәт-холкын,
Торагын да,
Хәзер юк ул. Ә камзулы
Тора монда...

Кума, онык, бакча таптап
Буйдан-буйга,
Йөзгә җиткәч бер ирек бир
Уйланырга!..»

Очып китте салмак кына
Кара карга,
Күпне күргән — ашыкмый ул
Каркылдарга.

●

Карыйм да мин, сеңелем, гаҗәпләнәм —
Бер дә сәбәпсезгә көләсең.
Шундый тыелгысыз шатлык биргәч,
Күңелледер, дөнья, күрәсең.

Иң бәхетле көннәрнең дә әллә
Мәшәкатен генә тояммы?
Артыграктыр, ахры, каш җыерам —
Шуның өчен әле оялдым...

Төрле ягы була бу тормышның,
Кәефсез дә чагы юк түгел...
Җирдә яшәү әмма күңелле эш,
Беркайчан да авыр йөк түгел!

Күңелне дә саклый белү кирәк,
Ирек бирмә артык сызларга.
Инде бер дә дәва табалмасаң,
Кара — көлеп торган кызларга!

## Мәхәббәт һәм биография

Төрле-төрле мәгълүматлар
Саный кеше,
Биографиядә тик сөюен
Язмый кеше.

Ә мәхәббәт хәл итә бит
Язмышларны —
Хыялларны, омтылышлар,
Уңышларны!

Уйладым мин хаксызлыкны
Төзәтергә —
Мәхәббәткә дә бер графа
Күрсәтергә.

Тик нәни эш әверелде
Биграк зурга —
Һәр язганым әйләнә дә
Китә җырга!..

●

Мәңгелектән
Тамчы булып
Мин тамганмын.
Кемдер әле
Тумый калган...
Мин туганмын!

Нәрсә гаҗәп
Кабат китсәм
Мәңгелеккә? —
Бу дөньяда
Булмаганмын
Мин элек тә...

*Кол Галигә*

●

Сез тарихның ар башында,
Безнең урын — бүгендер.
Сез — беренче Гали, әмма
Без соңгысы түгелдер;

Булыр әле зур тарихта
Тагын бик күп алмашлар —
Хис белән, фикер белән дә,
Рух белән дә адашлар!

●

Тел очында гына торган сүзне
Әйтеп бираалмаган чак була,
Авыз тутырып бер сөйләр өчен
Я кыюлык җитми чак кына...

Өлгергән уй барыбер юллар яра —
Кемдер әйтә кирәк сүзләрне.
Кыю сүзне без тапмыйбыз бугай,
Кыюларны таба үзләре!

●

Күлмәк эчена башак куя идем,
Үрмәләп гел йөри иде ул.
Я куеннан үтә, я аркадан —
Әйтерсең лә тере иде ул!

Инде онытылган кебек булгач
(Үгә уйлар көтеп торалар),
Күңелемнең әллә кай төшеннән
Шул башаклар тартел чыгалар.

●

Район газетында эшләгәндә
Җитешелде бөтен тарафка —
Агайларга киңәш бирел тордым,
Өйрәттем мин һәрбер тармакта.

Ул сүзләрем зирәк игенченең
Махра утларында көйрәгән.
Шул төтендә очты беркатлылык —
Агайлардан хәзер өйрәнәм.

●

Күптән яши монда тегермәнче,
Динен, телен инде оныткан.
Әнә тора, күзен кысып үзе,
Кулларына җылы он тоткан.

Дөнья бәясе бер кеше инде,
Мәзәк, шуклык дисәң — Семёнда.
Күнелең дә ап-ак. Буялсаң да
Буялгансың бары син онга.

●

Кайнар кеше иде Гайфулла абый
(Күз алдына карыйм китереп) —
Сикереп торыр да ул әйтер иде
Туры сүзне өзеп, кистереп.

...«Ферма яна!» — диеп атылып чыккан,
Гарасатта аны кем дәшкән?
Шул йөгергән хәлдә яшен суккан,
Җитезлеген, ахры, көнләшкән...

●

«Уфалла»ны тарттым ничә еллар,
Тәртә арасыннан чыкмадым.
Авырлыкны, яман интегүне
Төшләрдә дә күреп йокладым.

Бер ат җитәр иде коткарырга
Шушы газапларның барысыннан!
...Алып кайта шушы уйларымны
Йөз ат көчле җиңел машина...

●

Үстерим дисең баланы
Җил-янгыр тидермичә,
Авырлыкны үзеңә алып —
Аңарга китермичә...

Тигезләп куяр идең дә
Аның барасы юлын —
Ул ничек тормыш таныр да,
Ул нинди кеше булыр?

●

Биш ел буе счет төймәсе тарттым
(Төп эштән соң яздым шигырьләр),
Журналист та булып ел чаптым,
(Төп эштән соң яздым шигырьләр),

«Эш!» — диделәр, эшне сорадылар,
Беркем сорамады тегесен.
Эштән арып кайткач, ялны урлап,
Эшләнгән бу минем төп эшем!

●

Ай-һай, ничек өлгерәсен,
Сөйләп тә җибәрәсен!
Авыз — машинаң белән сип
Гел сүзләр җилгәрәсен.

Үзен сизмисен дә бугай —
Очга бит кибәк кенә,
Ә фикер дигән орлыклар
Төшә бик сирәк кенә...

●

Шактый еллар күрми торганнан соң
Юлытасың берәр танышка.
Кочагыңны җәеп кылма, имеш,
Ни гомерләр үтеп табыш та!

Бер-береңне бүлеп шау киләсең:
— Я, нихәл?
— Шәп!
— Исәнме?
— Исән!
Үзгәргәнбез — төрле кешеләр без,
Шуннан ары сүз дә юк икән...

Вакыйф Нуруллин

# КҮПЕР ЧЫККАНДА

ПОВЕСТЬ

## Сүз башы



Алдан ук әйтеп куям, туган: һәр яктан да үрнәк булырлык дәрәҗәдә ал да гөл түгел минем тормыш. Хәзер хезмәт герое булып, макталып йөргәч тә, син гомер буена шулай әйбәт кенә яшәгән, акыллы гына эшләгән икән бу кеше дип уйлама. Син болай итмәкче буласың, ә дөнья дигәнең, баш бирмәс кырыкмыш тай шикелле, үзе кирәк дип тапкан якка борып ала да китә. Карышып, тезгенен тарткалый башласаң, бер читкә селтәп, авыз-борыныңны җимерергә дә күп сорамый икән кайчакта...

Хәер, барысын да тормышка, башка кешеләргә аударып калдыру да бик үк дөрес булмас. Турысын әйтергә кирәк, үземнең дә чатаклыкларым байтак булды, туган. Кызурак, үзсүзлерәк кеше мин. Әмма шулай да... Тукта, фәлсәфәгә кереп барам түгелме соң әле? Алдан ук үземне акларга җыенам түгелме?.. Юк, болай ярамас! Гаеп миндә күбрәк булганмы, башкалардамы — анысын соңыннан үзең чамаларсың. Фәлсәфәсен үзең чыгарырсың. Сез, яшьләр, андыйга оста хәзер. Аңлы-белемле халык. Ә безгә ныклап торып, теләгәнчә укырга да, уйланырга да вакыт булмады. Заманасы андый түгел иде... Ярый, рас үтенгәнсең икән, сөйлим әле мин сиңа үземнең баштан кичкән кайбер хәлләрне. Тик башта ук килешеп куйыйк: бүлдермә син мине! Күңеленнән кайбер мин сөйли торган хәлләр белән бик үк риза булып бетмәсәң дә, бүлдермә! Бүлдерсәләр, фикерем чуала.

Димәк, килештек шулай.

## I

1946 елның гыйнварында, армия хезмәтеннән кайтып төшкән айда ук, мине үзебезнең «Чулпан» колхозына председатель итеп куйдылар. Сугышка кадәр ике ел чамасы хисапчы булып эшләвемне искә алмаганда, колхоз белән алай зур алыш-бирешле кеше түгел идем. Ә житәкчелек мәсьәләсендә тәжрибәм бөтенләй юк иде. Әнә шул турыда исләренә төшереп:

— Кыстамагыз, иптәшләр, ышанычыгызны аклый алмам. Холкым да бик җиңел. Миннән тәҗрибәлерәк, өлкәнрәк агайлар да бар бит,— дип карышып карасам да, авыл халкы күп сөйләшеп тормады.

— Кыза башласаң — суытырбыз, ялгышсаң — чабуыңнан тартырбыз. Белемең бар — ун класс бетергән, башың эшли — анысын хисапчы чагыңда күрдек! Сине куябыз — бетте китте! — дип, егерме бишенче яшемдә председатель арбасына җиктеләр дә куйдылар.

## 2

Ә ул арба җиңел түгел икән. Ай-һай, зур икән, мәшәкатьле икән аның йөге!

«Хуҗа» булып эшләргә тотынган көнне үк сизенә башладым мин моны. Колхозыбыз кечкенә булганлыктан (нибары кырык өч кенә хуҗалык), бездә бригадир-фәлән юк. Бар эшне председатель алып бара. Өй борынча йөреп, колхозчыларга көн саен эшкә әйтеп чыгу да аның вазифасына керә. Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, беренче эш көнем үк бик җайсыз башланды. Халыкны ындырга, ашлык сугарга җыеп, төрлесен төрле эшкә урнаштырдым да, инде азрак тамак ялгап чыгыйм дип, өйгә кайтып, иртән мичкә тәгәрәтеп киткән бәрәңгеләрне алып ашарга гына утырган идем, борының турсайтып, салам тарттыручы малай килеп җитте.

— Сине ындырга чакырдылар, Өлфәт абый. Сугу машинасының валын әйләндерә торган чарыгы ярылды! — ди.

— Ә ник алай иртүк ярылды соң ул, энем?

Күрәсең, көтелмәгән күңелсез хәбәрне ишеткәч аптырап калганмын инде, югыйсә мондый мәгънәсез сорауны бирмәс идем.

Йодрык кадәр генә булса да, телгә оста икән малай актыгы:

— Без сорап караган идек тә, әйтмәде шул ник ватылганын! Әйдә, Өлфәт абый, тизрәк киен дә баргач үзең сорарсың. Син председатель кеше бит, бәлки, сиңа әйтер! — диде, хәйләкәр елмаеп.

— Мин чарык коючы түгел ләбаса! Булса, амбарда була инде ул, энекәш. Запас частьлар председатель кесәсендә йөрми торгандыр бит, завхоз кулында булырга тиештер ич алар! Галим абыең шуны белми микәнни? — дидем мин, кискен итеп.

Ләкин салам тарттыручының монда да җавабы әзер булып чыкты.

— Амбарда булса, сине борчып йөрер идекмени, Өлфәт абый? Амбарда булмагангә монда җибәрде дә инде мине Галим абый! — диде ул, түгәрәк күзләрен елтыратып.

Утызлап кеше эшсез утырганда тамактан ризык үтәме соң? Салам тарттыручы малайга ияреп, тиз генә ындырга киттем. Халык ындыр табагының читенә ут ягып, шуның тирәсенә җыелышкан. Яшьрәкләр, күрәсең, җылынырга теләптер инде, түгәрәкләнеп тезелгәннәр дә, бияләйләрен атышып, «базар» уйныйлар. Ә барабанга көлтә биреп торучы Галим абый ватылган чарык янында чуала иде. Көн шактый салкын булса да, бүрек колакчыннарын күтәреп куйган, бияләйләре дә җирдә, кар өстендә, ята. Кыяфәте җитди, ачулы иде. Башка чакта гел үзе алдан сүз башлый торган Галим абзый бу юлы миңа бөтенләй игътибар итмәде. Бары тик ачың янына чүгәләп:

— Нишлибез инде, Галим абый? Запасыбыз юкмыни? — дигәч кенә, тирән итеп күрсенде дә:

— Бар иде ул заманында. Узган җәй районның «Сельхозснаб» складында бар иде. Алып куйыйк, кирәге чыгар дип Рәдифкә әйтеп тә караганыем. Тыңламады бит, аксак шайтан. Менә хәзер ике кулсыз калдык инде! — дип җавап бирде.

— Нишләргә, кая барырга киңәш итәсең, Галим абый?

— Районда юк ул, Өлфәт энекәш. Күрше колхозларга барып карасаң гына инде. Бәлки, бирәрсендә булмасмы икән.

Тиз генә ат җигеп, «Алга» колхозына киттем. Аннары «Кызыл урнәккә», аннан «Ватан»га. Әмма берсеннән дә таба алмадым. Озынга сузмыйча гына әйткәндә, бер айга якын эзләдек без ул каһәр төшкән нәрсәне. Карап торырга алай бер дә искитмәле әйбер дә түгел кана үзе: уникe тешле, уртасы тишек, өч-дүрт килолы, гап-гади чуен кисәге генә. Андый чарыкларны үзебезнең механика мастерскоенда да көненә унбишне ясау берни тормый хәзер. Тик кирәкләре генә юк. Ә ул чакта кадерле иде. Чөнки шул булмаса, шартла — сугу машинасын эшләтә алмыйсың! Тәмам гаҗиз итте ул безне. Башка һичкайдан таба алмагач, завхозны чарык коя торган Ч. заводына җибәреп карадым. Атнага якын гомер үткәреп, ул да буш кул белән кайтты. Без продукциябезне аерым колхозларга өләшмибез, разнарядка буенча районнарга гына озатабыз, дип борып җибәргәннәр. Ә разнарядка буенча кайтуын көтә башласаң — колхоз игене яңа уңыш өлгергәнче дә сугылып бетәчәк түгел.

Уйладым-уйладым да, ни булса ул дип, өйне карап торырга бер карчыкны калдырып (ул чакта мин, дию пәрие кебек, бер ялгызым яши идем, чөнки ахмакланып хатыным Сәкинәне аерып җибәрдем...), заводка үзем киттем.

Безнең эше авыл кешесенә завод ихатасына үтү дә сират күперен кичүдән ким түгел икән. Шулай да, алай иттем, болай иттем, тырыша торгач, тәки директорның үзенә барып җиттем бит, туган. Карап торырга күркәм генә ир уртасы кеше икән. Белмим, үзе сугышта булгандырмы, әллә заманга хас модага ияреп кенә алай иткәндерме — өстенә карасу зәңгәр диагональ китель кигән. Өстәлендә яшел фуражкасы ята. Каршылавын да хәйран ягымлы каршылады. Өстәл янында утырган җиреннән генә булса да, кул биреп күреште. Шунда мин, рәхимле бәндәгә охшаган бу, болай булса, шәт, борып чыгармас, дип уйлап алдым да, батыраеп китеп, гозеремне сөйләп бирдем.

Алданрак куанылган икән. Тел төбемне төшенеп алуга, кыяфәте бозылды директорның. Сирәк саргылт кашларына хәтле салынып төште. Күренеп тора, мине кабул итәргә ризалык биргүенә үкенә бу хәзер. Тик сиздермәскә тырыша, мөмкин кадәр сабыр, ягымлы булырга тели:

— Хәлеңне аңлыйм, иптәш председатель,— ди бу миңа,— бик яхшы аңлыйм! Әмма, кызганычка каршы, ярдәм итә алмыйм. Андый нәрсә рөхсәт ителми безгә. Колхозда гына андый алыш-бирешләргә юл куелырга мөмкин. Ә бу колхоз түгел, завод бу! Бездә һәр деталь исәптә, һәр детальнең кая, кайчан озатылырга тиешлеге алдан ук билгеләп куелган.

Кара син аны ничек сөйләнә бит, ә?! Колхоз түгел, имеш! Колхозның синең заводыңнан кай төше ким аның? Яхшылабрак уйлаган кешегә колхоз синең заводыңнан мөһимрәк тә әле. Синең чарыгың бар, ә колхоз икмәк үстерә. Бар, торып кара син икмәксез. Ашап кара чарыгыңны!

Мин шулай уйлап, бик нык ачуланып, әмма ачуымны сиздермәскә азапланып торган арада, директор өстәл тартмасыннан бер папка чыгарып, аның эчендәге кәгазьләр арасыннан берсен тартып алды да,

— Менә, ышанмасаң, үзең кара, иптәш председатель: план буенча, запас частьлар сезнең районга май башларында гына озатылырга тиеш дип дигелгән монда! — дип, мина сузды.

Кәгазьдә, чыннан да, ул әйткәнчә язылган иде. Әмма миңа аннан ни файда? Майга кадәр көтәрлек чамабыз булса, өемдә кеше калдырып, йөз илле километр җиргә ат куып килер идеммени! Язгы чәчүгә башланганчы ничек тә сугып бетерергә кирәк иң безгә игенне! Югыйсә, үреп, әрәм булып бетәчәк ләбаса ул!

— Аңлыйм, иптәш, барысын да бик яхшы аңлыйм, әмма булмагач — булмый инде! — диде директор, һаман үзенекен сукалавын дәвам итеп.

— Юк инде, Вениамин Илларионович, алай ансат кына кайтарып җибәрмәгез инде сез мине! Йөз илле чакрымга ат куып, башта шушында завхоз килде. Ул бер атна йөреп буш кайтты. Инде мин, председатель кеше, үзем килдем. Юлда ике көнем үтте, монда өченче көнем узып бара. Кайтып җитәргә янә ике көн кирәк булачак. Үзем генә түгел, ат тикле ат куып йөрим ләбаса мин! Монда килмәгән булсам, бер атна эчендә ул ат күпме эш эшләгән булыр иде, беләсезме шуны? Дөрес, формаль яктан сез, әлбәттә, хаклы: мине буш кул белән кайтарып җибәрсәгез дә бер сүз әйтүче булмаячак сезгә. Ләкин, зинһар дип әйтәм, сез дә минем хәлемә керергә тырышыгыз. Берәр төрле җаен табыгыз, зинһар!

Директор минем сүзләрне колагына да элмәде бугай: алдында яткан газетаны уку белән мәшгуль иде ул.

— Карагыз әле, Вениамин Илларионович,— дидем мин, аның шулай илтифатсыз булуына хәйран калып.— Тыңлагыз әле, соңгы сүземне генә әйтәм дә китәм аннары.

Директор иренеп кенә башын күтәрде дә, барыбер буш кайтарып җибәрәм бит инде, нигә бу тикле үҗәтләнәсең, дигәнне аңлата торган итеп елмаеп куйды.

Минем йон тагын да ныграк кабарып китте. Бар усаллыгымны җыйдым да, соры-коңгырт күзләренә карап:

— Соңыннан үпкәләштән булмасын, Вениамин Илларионович, шуның өчен башта ук кисәтеп куям: әгәр бүген мине буш борып кайтарсагыз, аллага ышанучы булмасам да, билләһи дип әйтәм, бу хәлне болай гына калдырмаячакмын! — дидем.— Менә күрерсез, болай гына калдырачак түгел мин моны. Моннан кайту белән Мәскәүгә генералиссимусның үзе янына барачакмын! Исе китәр инде синең ише авыл мужигына дип уйламагыз. Бик яхшы белә ул мине. Менә бу орденнарны, Кремльгә чакыртып китереп, үз кулы белән тагып җибәрде ул миңа! — дип, шинелемнең изүен чишеп, күкрәгемдәге Дан орденнарын күрсәттем.

Дөресен әйтим, бу нотыгымның файдасы тияренә үзем дә бик үк ышанып җитмәгән идем. Тик килгән җирдә, ичмаса, бераз ачуымны бушатып, аның да күңеленә азрак шом салып китим дип кенә азаплануым иде. Кайчакта беренче карашка бөтенләй көлке тоелган гап-гади генә сүзләр дә кешегә искиткеч нык тәэсир итә икән, туган. «Үзе такты» дигәнемне ишетүгә колаклары торды директорның. Сирәк, юка чәчләренә тикле кабарып китте, битенә кадәр кызарып чыкты.

— Ярар, ярар, иптәш,— диде ул, каушавын белгертмәскә тырышса да, яшерә алмыйча,— син алай бик каты чәпчемә! Безнең дә үз заданиебез, үз планыбыз бар ләбаса. Һәр колхоз председателе шушылай, синең кебек заводка килеп, низаглашып йөри башласа — кая китә ул аннары?

— Башкаларда минем эшем юк. Минем үз хәлем хәл. Әгәр чарасыз җибәрсәгез, үпкәләштән булмасын! — дидем, директорның пешләп калуын күргәч, батыраеп китеп.

— Ну, ярый алайса,— диде бу, һич тә чигенер чамам булмавын сизенеп.— Ярый, алай бик ерактан да килгән кеше булгач, кагыйдәне бозып булса да...

Шулай диде дә, минут эчендә завод складына шалтыратып, миңа бер чарык биреп җибәрергә кушты.

Ул көнне җир йөзендә миннән дә бәхетле кеше, ихтимал, булмагандыр. Берәү юлдан тапса да игътибар итми китә торган шул чүен кисәге миңа әйтеп бетергесез куаныч китерде. Ә орденнарны «үз кулы белән такты» дип мин аңа аптыраганнан, бүтән чарам калмаганга гына әйткән идем. Тагамы соң инде! Минем ише Дан ордены алучыларның барысына да үзе тагып тора башласа, бүтән эшкә вакыты да калмас иде аның. Тагу түгел, дөньяда Хәкимов Өлфәт исемле бер татар малае барлыгын белми дә торгандыр әле ул... Шулай да ярдәме тиде!

## 3

Председатель итеп мине январь ахырында сайлаганнар иде. Теге хәерсез чарыкны юллап алып кайтканчы февраль үтеп китә язды. Ә сугасы иген дөнья әле. Аны ничек тә тизрәк сугып бетерергә кирәк. Машинага тагын берәр хәл булмаса, ихтимал, апрель урталарына бетереп тә булыр. Көннәр озаюга, җылынуга таба бара. Январь аенда ике көн эшләгәнне хәзер бер көндә башкарырга мөмкин. Мөмкин генә түгел, шулай эшлиләр дә. Халык бик тырыш бездә. Ул яктан шөкер әлегә. Ә менә атлар!.. Ул мескеннәргә карарга да кызганыч. Кабыргаларын ярты чакрымнан санарга мөмкин. Ичмаса, абзарларының да рәте юк. Сугыш елларында ачылып-тишелеп беткән. Түбә саламына кадәр кырык өченче елда колхоз сыерларына азыкка киткән. Узган җәйдә япкан булганнар булуын, әмма хатын-кыз да бала-чага гына япкан түбәнең рәте бик шәптән булып чыкмаган.

Хәзер дә, солы саламы белән бодай саламыннан башка, фураж бирелми атларга. Кама уртасындагы утрауда, безнең авылдан утыз километрда, колхозның илле җиде гектар болыны бар барын. Тик менә өч ел инде, көч җитмәгәнлектән, ул болындагы печән дә чабылмыйча калып килә икән. Аны бу ел ничек тә чабып-җыеп алырга кирәк инде...

Ә атлар арык. Шулай да игенне язгы чәчүгә тикле сугып бетерербез дип уйлыйбыз. Анысына ничек тә түзәләр инде. Әмма шул ук атлар белән язын бөтен колхоз кырын сөреп, чәчеп чыгасы бар бит әле! Дүрт йөз туксан дүрт гектар җирнең өч йөз җитмеш гектарын сөреп чәчәсе бар. Ат башына унөч гектардан артык туры килә. Ә тракторга өметләнергә урын юк. МТСка барып караган идем:

— Сездән зуррак колхозларга да житкерә алмыйбыз әле, бөелга котәргә туры килер, Хәкимов! — диделәр.

Әйтәм бит, бөтен өмет атларда хәзер. Сугышка кадәр язгы чәчүдә эшләргә тиешле атларны, бер ай беркая да җикмичә, шәпләп тәрбияләр, ял иттерәләр иде. Хәзер ял турында әйткән дә юк инде, хәтта рәтле ашау да эләкми аларга. Солысы да бар колхозның, арышы, бодае да бар. Икмәк планы да күптән түләнеп беткән безнең (план тулмаган дип теге директорга чарык бирсен өчен генә әйттем мин). Әйтәм бит, фуражлык кына рәтебез бар. Тик ашатырга ярамый. Чөнки районда планнарын тутырмаган колхозлар бар. Зуррак колхозларның җире сугыш елларында тулысынча чәчелмәгән — көчләре җитмәгән. Ә план — җир исәбеннән. Кыскасы, планны бөтен район тутыруын көтәргә кирәк...

Ут йотып йөргән чакта, барабанга көлтә бирүче Галим абзый бер көнне төшке ял вакытында яныма килде дә:

— Һаман фуражсыз эшләтә торган булсак, тәмам барып чыгачак бит бу атлар! Ни уйлыйсың син, прсидәтел? — ди.

— Мин дә нәкъ синенчә уйлыйм, Галим абзый. Болай барса, эшләр шәп булмаячак безнең,— дим.— Ләкин нишлим соң, фураж ашатырга рөхсәт юк бит.

Галим абзый миңа беркавым карап торды да иплəп кенә сүзгә керешт е:

— Әй, энем-энем!.. Менә безгә бер грамм да фураж бирмәскә кушылган. Ну без крәстиян халкы бит, үзебез дә уйланырга тиешле. Без дә берәр әмәлен табарга тиештер бит бу хикмәтнең! Чак кына булса да, үз башыбызны да эшләтеп карарга ярый торгандыр. Ярый гына түгел, иптәш Ленин безгә шулай кушкан да бит. Әйдә әзрәк үз башыбызны да уйлатып карыйк!

— Ничек итеп, Галим абзый?..

Ул, һич тә икеләнеп тормыйча, әлеп алып китте:

— Ничек итеп дисеңме? Әйтик, менә болай: без һәр көнне көндезге уникедән бергә тикле төшке ялга туктыйбыз, шулай бит?

— Әйе.

— Алай булгач, менә шул: төшке ял вакытында атларны ындырда калдырып, аларга солы ашатсак ничек булыр икән?

— Без бит хәзер солы сукмыйбыз, бодай сугабыз ич, Галим абзый.

— Син анысы өчен бер дә шаккатма, Өлфәт энекәш, анысы бик ансат җайлана торган нәрсә аның, тик синең генә ризалыгың булсын. Син каршы килмәсәң, солыны мамин т сугып алабыз без аны. Ярты сәгать эчендә бөтен калхуз атына бер атна ашарга җитәрлек солы сугып алырга була!

— Сугуын сугарга булыр да, әмма аның өчен безнең баштан сыйпамаслар бит, Галим абзый?

— Ә син башыңнан сыйпаганны көтәсеңме әллә, нанай? Көтмә син аны. Шул ук чакта артык өркеп тә яшәмә. Төптәнрәк уйлап карaганда, атларыбызга фураж ашатырлык кына хакыбыз бар лабаса безнең! Башка калхузларның планы өчен ник без җык күрергә тиеш ди әле? Бер үк төрле мөмкинлекләр бирелгән ич аларга да. Шулай булгач, үзләре өчен үзләре кыймылдасыннар.

— «Берләр — меңнәр өчен, меңнәр — берләр өчен!» — дигән сүз бар бит, Галим абзый! Аны да онытырга ярамый ич!

— Шуның белән рәттән үк «һәркемнән — сәләтенчә, һәркемгә — хезмәтенчә» дигәне дә бар аның, наный. Тотасың икән, һәр икесен дә истә тотарга кирәк! Теләсәң ни эшлә, энем, ну мин иртәгәдән үк атларга солы суктырып ашата башлыйм! Гаепләсәләр — мине гаепләрләр.

Һәм ул, күрәсең, мәсьәләне хәл ителгән санап, минем яннан китеп тә барды.

## 4

Безнең шул сөйләшүдән соң шактый вакыт үтте. Инде игенне сугып бетерергә дә күп калмады. Көнозын эштә булсалар да, төшке ял вакытында солы ашата башлагач, атларга да хәйран гына тән кунып китте. Болай булса, язгы чәчүне ничек тә вакытында ерып чыгарбыз дип эчтән куанып йөри идем. Тик ул куанычымны болыт каплады. Анысы менә болай булды.

Бер дә бер көнне безгә авыл советы йомышчысы — ябык кына, хәлсез генә, шактый олы яшьтәге бер апа — килде дә:

— Райкумнан чалтыраттылар. Хәкимов кичке сәгать биштән дә сунга калмыйча килеп җитсен дип әйттеләр,— диде. Аннары, калын, авыр зәңгәр шәлен чишеп җибәреп, идарәнең ишегe буендагы озын эскәмиягә килеп утырды да сукранырга тотынды.— Әйдә, энем Өлфәт, атыңны тизрәк җик тә, әйләнечрәк булса да, безнең Көрнәле аркылы мине калдыра кит инде син. Бик арыдым, аяк атлар хәлем дә калма-

ды. Монда килгәнче дә таң тишегеннән авыл буйлап кәнсәләргә кеше чакырып йөрдем. Кайсын заем, кайсын ит, кайсын сөт түләве буенча дәштерделәр.

Ат җигеп, юлга чыккач, йомышчы апа тагын зарлана башлады.

— Мин дежур буласы көнне генә көтеп торганнар диярсең: барысына да бүген кирәк, барысы да тизрәк, ди. Иртәгәгә калдырсалар — дөнья бетә диярсең, билләһи. Инде менә монда килергә туры килде. Ичмаса, өемдә кеше юк. Олы кызым урман кисүдә. Кечесе фермыда, төнсез кайтмый.

Мин ябык апаны азрак юатырга тырышып нәрсәдер әйткән булдым.

— Анысы да дөрес инде, Өлфәт энем,— диде ул, шундук минем белән килешеп.— Сезнең эше начальникләргә дә алай бик ансат түгел инде бер уйлаганда. Шулай да менә шушы Мәгышия апаң әйткәнне диярсең, бер дә алай төнгә каршы ук чакырып торырлык тәҗеле эш түгелдер әле!

— Белмим шул, Мәгышия апа.

Икебез дә беркавым сөйләшмичә бардык.

— Карале, Өлфәт энем,— диде аннары Мәгышия апа, мина таба борылып утырып.— Кайчан тәмам рәтләнер икән безнең эше крәстиян тормышы? Сугыш елларында, ярый, сүз әйтмәдек. Анысы бөтен ил белән килгән каза булды. Инде сугыш бетте ләбаса... Әйт әле, энем Өлфәт, типтереп яшәүләрне күрергә тиз насыйп булырмы икән?

— Булыр, Мәгышия апа, булыр! Сабырлык кирәк. Сугыш беткәнгә ел да тулмаган ич әле. Бер ел эчендә барысын да җайлап булмый инде ул. Син үз авылыбыз каланчасыннан карап кына хөкем йөртмә, Мәгышия апа. Фашистлар безнең илдәге ни тикле кешене йортсыз-җирсез калдырды. Ул кешеләрне тораклы иткәнче, җимерек авылларны, шәһәрләрне, завод-фабрикаларны торгызганчы байтак көч түгәргә туры килер әле.

— Колхозлар фәкыйрь булмасын иде дигәннән әйтүем инде. Юкса эшебез кирегә китмәгәе...

— Китмәс, Мәгышия апа. Яхшыруга таба барабыз. Менә күрерсең, танымаслык булып үзгәрер әле безнең авыллар. Хәтереңдәдер, сугыш алды елларында хезмәт көненә бирелгән икмәкне, халык вакытында амбарга барып алмагач, өй борынча ат белән өләшеп йөриләр иде. Куяр урын таба алмый интегә иде колхозчы. Тагын шулай булыр әле, менә күрерсең!

— Ни генә әйттеңие кана!...

Шул рәвешле сөйләшеп, Мәгышия апаны да, шул вакытта үземне дә юатып, өметләндереп бара торгач, Көрнәлегә килеп җиткәнебезне сизми дә калдым. Мәгышия апаны калдырып, ары киткәч, кичкә каршы нигә болай ашыгыч рәвештә чакырдылар икән дип, борчыла, фараз кыла башладым. Бер караганда, алай әллә ни хәвефләнерлек урын да юк шикелле. Колхозның икмәк планы күптән тулган. Артыгын да шактый бирдек инде. Хәзер дә озатып торабыз. Чәчүлек орлыкларыбыз да кирәгенчә әзерләп куелган. Сабан-тырмаларыбыз да ремонтланып бетү алдында тора. Шулай булгач, нигә болай чакырттылар икән?..

Ләкин ашыктырырлык эшләр булган икән шул менә. Ничек кенә булган әле! Башка мәсьәләләрне инде хәл кылып, мине генә көтеп торганнар, ахрысы: килеп керүем булды — райкомның бюро утырышын дәвам итеп, мине тикшерергә керештеләр.

Мәсьәләне тулырак итеп аңлату өчен, башта минем урында эшләп киткән Рәдиф Хәйретдиновның райкомга язган хаты укылды. Ул үзенең, ферма мөдире буларак, көн-төн тырышып эшләвен, колхозны алга җибәрү өчен бар көчен салуын бәйнә-бәйнә аңлатып язган. Аннары, гәрчә аның урынына председатель итеп куйсалар да, Хәкимов Өлфәткә, ягъни миңа, бернинди дә ачуы юклыгын, бу хатны бары тик намус-

лы совет кешесе буларак кына язуын анлаткан да: «Эшли башлавына өч ай тулар-тулмас ук Хәкимов алдау юлына басты,— дигән.— Халык төшкә кайтып киткән арада бодай сугуны туктаттырып, өч тапкыр бер-әр сәгать буена солы суктырды. Ул солыны, үлчәп керемгә алмыйча, ындырда яшереп саклый һәм һәр көн төшке ял вакытында атларга ашата. Районның икмәк заданиесе тулмый торып, бер грамм фураж бирмәскә дигән күрсәтмәне белгән килеш, шушындый җинаятькә барган кешене, минемчә, партиядә тоту турында сүз дә булырга тиеш түгел, иптәшләр! Суд хөкеменә тапшырылырга тиешле эш бу!» дип нәтиҗә ясаган.

Рәдифнең шушы хатын укыганнан соң, судка бирергә дип үк әйтмәсәләр дә, мине шулай ук бик нык гаепләп, тагын өч бюро члены чыгып сөйләде. Аннары миңа сүз бирделәр.

— Минем әйтер сүзем юк! — дидем мин.

Соң нәрсә сөйлим? Мәсьәлә болай да ачык бит. Рәдиф барысын да бәйнә-бәйнә тезеп биргән. Шулай ук гаепне Галим абзыйга аударырга да телем бармый. Чөнки мин солы сугуларын белдем. Тансам — ялганлау була. Ялганларлык булсам, партиягә кереп тә тормаган булыр идем мин. Ә партия сафына мин иң кыен чакта — кырык беренче елның декабрендә, я — илем, я — үлем мәсьәләсе хәл ителгән көннәрдә кергән кеше.

Үзем сөйләмәгәч, сорау бирә башладылар.

— Әйт алайса: иптәш Хәйретдинов язган фактлар дөресме?

— Икесе дөрес, өченчесе миңа мәгълүм түгел.

— Сез моның ярамавын белеп эшләдегезме?

— Мин моны бик кирәк булганга эшләдем!..

Үзең дә чамалыйсыңдыр, туган, ул чаклар өчен гаебем зур иде бит минем. Ни эшләтсәләр дә каршы килә алмас идем. Ләкин мине райкомның беренче секретаре Гадел абый коткарып калды. Ул кызып-ачуланып түгел, җайлап, иплән кенә сөйләп китте. Үзенә кадәр сөйләгән кешеләрне дә алай зурлап хупламады, мине дә бөтенләй бетереп ташламады.

— Иптәш Хәкимовның гаебе зур,— диде аннары.— Күрсәтмә барын белә торып, андый нәрсәгә юл куярга тиеш түгел иде ул. Ләкин монда шуны да искә алырга кирәк: Хәкимов әле яшь, председатель булып эшләвенә нибары өченче ае гына. Колхоз тормышын да тиешенчә белеп житкермәгәндер. Армиядән кайту белән сайлап куйдылар аны. Шулаймы, иптәш Хәкимов?

— Әйе, Гадел Салихович! — дидем мин, аның шушылай минем хәлне аңлап сөйләвенә чиксез куанып.

— Менә шуларны искә алып фикер йөрткәндә, иптәшләр,— дип дәвам итте ул,— Хәкимовны бөтенләй үк этеп егарга кирәк түгелдер. Фронтта да начар сугышмаган иптәш Хәкимов. Ике Дан ордены алуга лаеклы булган кешеләр, районыбызда дип әйтмим, республикабызда да күп түгел әле алар...

Әллә ни таза булмаса да, мәһабәт, сылу гәүдәле, кара бөдрә чәчле, коңгырт-кара күзле, озынчарак кара тут битле бу кешене моңарчы да ике-өч тапкыр күргәнем бар иде. Әмма моңарчы бер дә алай якыннан очрашып сөйләшергә туры килгәне юк иде. Шунлыктан, ни әйтер икән дип, башкалардан битәр аннан шикләнеп утыра идем. Ә ул, күрәсең, минем турыда әллә никадәр мәгълүматлы кеше булып чыкты!..

Бюро миңа каты шелтә бирү белән тәмамланды. Утырышны ябып, бюро членнарын таратканнан соң, Гадел абый мине үз кабинетына алып керде. Ихтимал, үз кайгыма артык тирән чумып утырганмындыр инде, райком секретареның сул кулы протез кул икәнлеген бөтенләй күрмәгән идем. Аңысын кабинетына кереп, каршына утыргач кына абайлап алдым. Шунда ук: «Әһә, димәк, сугышта булган бу кеше.

Димәк, моның белән ачыктан-ачык сөйләшергә дә мөмкин!» дип, эчтән куанып куйдым. Шул ук вакытта, тагын нишләтмәкче була икән бу мине, күрәсең, үземне генә орышырга ниятләнгәндер дип, күңелемә шик тә төште. Әмма Гадел абый сүзне мин бөтенләй башыма да китермәгән яктан башлап китте.

— Кайсы фронтта булдыгыз сез, иптәш Хәкимов? — диде ул.

— Башта Ленинград фронтында, аннары Беренче Белоруссия фронтында булдым.

— Нинди төр гаскәрдә?

— Пехота.

— Кем булып?

— Башта рядовой, аннары сержант. Кырык беренче елның декабреннән башлап, сугыш тәмамланганчы разведчик булып йөрдем.

— Ә Дан орденнарын ни өчен бирделәр?

— Берсен, фашистларның тылына үтеп, корал складларын шартлаткан өчен, берсен дошман дивизиясенең штаб офицерын «тел» итеп алып кайткач.

Секретарь бер сүз дә дәшмичә, тыныч кына тыңлап утырды. Аннары, папиросын кабызды да:

— Димәк, партизанлыкта йөрергә туры килмәде, алайса? — диде.

— Юк, Гадел Салихович. Ә нигә алай дип сорыйсыз әле?

— Нигәме?..— Әйтимме икән, юк микән дигәндәй, ул бераз уйланып торды.— Колхозда партизаннарча эш итә башлагансыз бит! Шуңа күрә әллә сугышта да партизан булдыгызмы дип уйлаган идем. Ә сез разведчик икәнсез.

Аның тел төбен аңлагач, ничектер уңайсызланыбрак калдым. Колакларым кызышып китте. Ни дип җавап бирергә инде моңа?

— Күрәсең, разведкадан калган гадәт буенча шулай эшләнгәндер инде, Гадел Салихович,— дидем мин. Аннары ачыктан-ачык сөйләшүгә күчтем.— Бүтән бернинди чара таба алмагач, шулай яшертен генә, разведчикларча гына эш итмәкче булган идек. Ләкин, бүген күрдем, тыныч тормышта разведка ясау сугыштагы разведкадан хәтәррәк икән. Теләсә ни әйтегез, Гадел Салихович, әмма атларны исән-сау саклап калу өчен эшләнгән эш иде бу. Егерме сигез баш ат белән язын өч йөз дә җитмеш гектар җирне чәчеп-сөреп чыгасы бар бит әле безнең!

— Синең сүзеңдә дә хаклык бар, иптәш Хәкимов. Мин сине бүген шуңа күрә яклап чыктым да. Разведка турында да дөрес сүз әйттең. Ләкин син бер нәрсәне яхшы аңларга тиеш: сугыш вакытында да разведчиклар үзләре теләгәнчә генә хәрәкәт итмиләр бит. Командирлар биргән боерык буенча, план белән йөри алар разведкага. Ә син...

Шактый гыйбрәтле сүзләр сөйләде ул миңа. Җыеп кына әйткәндә, ул сөйләгәннәрдән мин шуны аңладым: миңа, яшь председательгә, киләчәктә ашыгып эш итәргә ярамый. Алдын-артын уйлап кына эш кылырга кирәк. Чөнки бөтен кеше дә минем төсле уйламаска мөмкин. Мөмкин генә түгел, чыннан да шулай ул. Мең кешенең берсе, мисал итеп әйтсәк, миңа кадәр председатель булып эшләгән элеге Рәдиф Хәйретдиновның кайбер мәсьәләләр хакында бөтенләй башкача фикер йөртүе гаҗәпмени?..

Гадел абыйны тыңлагач, дөньялар яктырып, офыкларым киңәеп киткәндәй булды. Югыйсә бюрода утырганда, бигрәк тә Рәдиф хатын укыган вакытта, күңелем тәмам суынган иде колхоздан. Барысына да кул селтәп, бөтенләй авылдан ук чыгып китәр дәрәҗәгә җитеп утырган идем. Чөнки шәхси тормышым җимерелгән иде бит минем. Шушы колхоз тормышы белән мавыгып, үземне-үзем шуның белән юатып кына яши идем. Ә менә Гадел абый белән сөйләшкәннән соң ул ямьсез уйларым бөтенләй онытылды.

Инде чыгып китәм дип торганда гына Гадел абый миңа тагын бер сорау бирде.

— Колхоз эше буенча бер-беребезне аңлаштык шикелле, ә үз хәлләрең ничек соң? Хатының белән малаеңны алып кайтмадыңмы әле? — диде ул.

Мин башта аптырап калдым. Ни өчен дисәң, Гадел абыйның мин председатель булып эшли башлаганнан бирле безнең авылга бер мәртәбә дә килгәне булмады. Шулай ук районга үзем баргач та ул хакта сүз кузгатканы юк иде. Ә ул инде минем семьяның таркалуы хакында да белә икән.

— Сез каян беләсез ул турыда, Гадел Салихович? — дидем мин, кызыксынуымны яшерә алмыйча.

Секретарь елмаеп куйды да:

— Үз районыбыздагы колхоз председательләренең хәлен дә белмәсәм, нинди секретарь булыр идем мин? — диде. Аннары тагын житдиләнде дә җайлап кына дәвам итте.— Кайдан икәне ул кадәр мөһим түгелдер, бәлки, иптәш Хәкимов. Ә менә синең хәлеңне белергә тиеш мин. Сизеп торам, хатыныңны да, улыңны да алып кайтмагансың икән әле. Я, әйт әле миңа: киләчәктә ничек яшәргә уйлыйсың? Нидән килеп чыкты ул низаг? Уйлап-уйлап эшләдеңме, әллә һаман шулай партизаннарча бер кизәнүдә генә эшләп ташладыңмы?

— Әйтүе авыр инде аңысын, Гадел Салихович. Узган эшне искә төшереп тормыйк ла,— дидем мин, ул хакта бер дә сөйлисем килмичә.

— Ихтыярың, иптәш Хәкимов. Шулай да син тагын бер тапкыр уйла әле, ямә! Ир кеше теләсә нинди мәсьәләдә дә егет булып кала белергә тиеш.



### 5

Кайтырга дип атны җигеп чыккач, район урамында яшь кенә бер кыз яныма килде дә:

— Зинһар, алып кайт әле, Өлфәт абый? Төнгә каршы үзем генә җәяү юлга чыгарга куркам, ә куныр каласым килми, иртәгә иртән дәрескә керәсем бар! — диде.

— Кая алып кайтырга соң сезне? Кем сез? — дидем мин, гаҗәпләнеп. Гаҗәпләнми мөмкин түгел, чөнки мин аның кайсы авылныкы булуын да, кем икәнлеген дә белмим. Хәтта моңарчы күргәнем дә юк шикелле иде.

— Мине бер күргән кешеләр онытмый дип йөри идем, ялгышканмын икән! — диде теге кыз, гаҗәеп ягымлы итеп елмаеп һәм йөзенә чак кына үпкәләү билгесе чыгарып.— Биш күреп тә игътибар итмәүчеләр бар икән ич миңа! Көрнәледә укытам мин, Өлфәт абый. Күргәнегез бар бит мине, игътибар итмәдегез микәнни?

— Гафу итегез, әйе шул, күргәнем бар икән шул! — дигән булдым мин, кайда һәм кайчан күргәнемне һич тә хәтерли алмыйча.— Исемегез ничек әле сезнең?

— Гөлүсә дип йөриләр мине, Өлфәт абый. Я, алып кайтасызмы, утырыйммы чанагызга?

— Мин турыдан-туры «Чулпан»га кайтмакчы идем шул, Гөлүсә.

— Шулаймыни? Әллә мин Көрнәле аша кайтасызмы икән дип уйлаган идем,— диде ул, шундук күңелсезләнеп.

— Йомышым юк иде шул анда.

— Ярар инде, алай булгач.

Шулай диде дә ул читкә тайпылды, ә мин кайтыр якка кузгалдым. Аннары башыма шундый уй килде: «Тукта әле, Өлфәт, ни кыланасың син? Өч-дүрт километр әйләнечрәк була дип, кешене ташлап китәргә

ярамый бит инде!» Атны шып туктаттым да артыма әйләнеп карадым. Кыз, нәүмизләнеп, әле һаман юлга карап тора иде.

— Әйдә, Гөлүсә, әйләнеч булса булыр, алып кайтыйм инде алайса!

Ул, тиз генә йөгереп килеп, тәмле хушбуй исләрен аңкытып, чанага менеп утырды. Мин райкомда булган хәлләрдән соң кәефем кырылганга, ә Гөлүсә башта үтенечен кире кагуыма унайсызланган иде булса кирәк — байтак араны икебез дә сүзсез генә үттек. Әмма болай бару да кыен иде, кызның күңелен күтәреп җибәрер өчен генә булса да, нидер әйтергә кирәк иде аңа.

— Сез Көрнәленеке түгел бугай бит, Гөлүсә. Әйтегез әле, кай як суын эчеп үскән чибәр сез? — дидем мин, киеренке тынлыкны бозып.

— Чибәр булсам, бер сүзсез утырткан булыр идегез әле, күрәсең, чибәрлегем чамалыдыр инде.— диде ул, серле елмаеп.— Шулай да комплиментыгыз өчен рәхмәт! Ә туган ягым — Минзәлә, Ык суын эчеп үстем.

Мин аңа текәлебрәк карадым. Чыннан да, бик чибәр иде ул, каһәр. Бигрәк тә иреннәре матур, коңгырт күзләре сөйкемле иде аның. Кай ягы беләндер минем Сәкинәгә дә охшап китә шикелле иде ул.

— Көрнәледә күптәннән эшлисезме инде? — дип сорадым.

— Дүртенче ел инде, Өлфәт абый. Быел укулар беткәч, үзебезнең якка кайтып китәр идем. Туйдырды...

— Эш туйдырдымы, әллә Көрнәледән туйдыгызмы?

— Эш түгел, эшемне яратам мин аныкы. Көрнәледән туйдым. Халкы, бигрәк тә егетләре, грубый.

— Ничек инде алай, сезгә тимиләрдер бит алар?

— Тиюен тимиләр, әмма тынгылык та бирмиләр. Клубка чыгар хәл юк, хәзер тагылырга гына торалар.

— Ә сез берсен дә ярата алмыйсызмыни?

— Юк шул, ярата алмыйм, берсе дә күңелемә ошамый. Ә сез Сәкинәне ярата идегезме, Өлфәт абый?

— Бик ярата идем, Гөлүсә! Сез аны белә идегезмени? — дидем мин, гаҗәпсенеп.

— Бер авыл советында эшлә дә белмә, имеш. Хисапчы чагында бик еш килә иде ул Көрнәлегә. Якын дус ук булмасак та, яхшы таныш идек без аның белән, яшьтәшләр идек.

— Алай булгач, сез миңа абый дияргә тиеш түгел икән. Миннән ике генә яшькә кече иде бит ул.

— Беләм, Өлфәт абый. Ләкин мин сезгә башкача эндәшә алмыйм. Ничектер миннән күп олы шикелле тоеласыз.

— Ихтыярыгыз алайса.

— Сер булмаса, әйтегез әле,— диде ул, беркавым икебез дә тын гына баргач,— Сәкинәне нигә аерып җибәрдегез сез?

— Булды инде, Гөлүсә...

— Сөйләргә теләмисез, димәк?

— Кызыклы хәл түгел ул.

— Ә минем беләсем килә, Өлфәт абый! Үзегез ярата идем дисез, үзегез аерып җибәргәнсез. Яраткан кешене аеру мөмкин микәнни соң?

— Мөмкин икән шул менә. Сез ничек итеп, тәвәккәлләп, төнгә каршы минем белән юлга чыгарга уйладыгыз әле, Гөлүсә? — дидем мин, сүзне икенче якка борырга ниятләп.— Ни әйтсәң дә, ир кеше бит мин, әле утызга да җитмәгән тол ир кеше!

Ул, ялт борылып, миңа сыенып утырды.

— Ә мин сездән курыкмыйм, Өлфәт абый. Куркыныч кешегә охшамагансыз сез. Беренче күрүдә үк әйбәт кеше икәнегезне сизендем.

— Яхшы сүзегез өчен рәхмәт!

Тагын бер кавым сөйләшмичә баргач, Гөлүсә кинәт калтыранып, эх, дип куйды да көтелмәгән бер кискенлек белән:

— Лəкин сез джентльмен түгелсез икəн, Өлфəт абый! — диде.

— Аңламыйм, Гөлүсə, нəрсə əйтмəкче буласыз?

— Хи-хи-хи! — диде ул, кычкырып көлеп.— Унөч километрның ун-берен үттек инде, ə сез əле һаман миннəн туңмыйсыңмы дип сорарга да догадаться итмисез. Толыбыгызны салып бирмəсəгез, һич югында, куенызга сыендырыр идегез, ичмаса! Катып үлəм бит инде.

Ул, чыннан да, хаклы иде. Гаеп миндə.

— Гафу итегез, Гөлүсə, мин шундый гамьсез инде! — дип, толыбым-ны сала башладым. Лəкин ул:

— Юк, юк, кирəкми, Өлфəт абый, менə болай шəбрəк булыр ул! — дип, мине туктатты да, песи баласыдай йомылып кына, толып эченə кереп утырды. Миңа да искиткеч рəхəт булып китте. Җылы иде каһəр-нең тыны! Бер мəлгə тəмам башларны əйлəндереп, күз алларымны караңгылатып җибəрде... Лəкин шунда Сəкинəм күз алдыма килеп басты һəм мин, айнып китеп, үземне тезгенлəп алдым да, теге йомшак песи баласына бер дə исем китмəгəн кыяфəт белəн, күктə җемелдəш-кəн йолдызларга карап бара башладым.

— Минем бүген районга ни өчен килүемне һич сорамыйсыз, Өлфəт абый? — диде Гөлүсə, тагын да ныграк сыена төшеп.

— Йомышыгыз булгандыр инде.

Ул янə кычкырып көлеп җибəрде:

— Бернинди йомышым да юк иде минем, Өлфəт абый!

— Юк иде?

— Əйе, юк иде! — диде ул. Минем гаҗəпсенеп калуымны күргəч, ничектер серле, йомшак итеп пышылдауга күчте.— Бүген сез районга Көрнəле аша киттегез, шулай бит?

— Əйе.

— Менə мин киткəнегезне күреп калдым да җəяүлəп юлыгыздан атладым. Əйлəнеп кайтышлый очрарсыз дип, юри əкрен генə бардым. Лəкин сез озак юандыгыз, ə мин, бара торгач, район үзəгенə үк барып җиттем. Сез кайтырга чыкканда мин яңа килеп җиткəн генə идем əле.

— Я, тəкъсир! Үлмəсəң əллə нилəр ишетерсең бу дөньяда! — дидем мин аптырап һəм аның сүзлəрен уенга борырга тырышып: — Нигə юк-ны сөйлəп торырга инде, Гөлүсə?

— Ə мин чынлап əйтəм, Өлфəт абый. Просто тиле хислəремə буй-сындым да артыгыздан киттем. Һəм бер дə үкенмим. Мин уйлаганга караганда да интересныйрак кеше булып чыктыгыз сез.

— Ташлагыз əле юк сүзне! — дидем мин, күңелемнəн сəер бер рə-хəтлек кичерсəм дə, юри кырыс булырга тырышып.

— Мин гомумəн ялган сөйли белмим, Өлфəт абый! — диде ул, кинəт җитдилəнеп китеп.— Ə мондый мəсьəлəдə алдашуны бөтенлəй күрəл-мим. Нəрсə уйлыйм — шуны əйтəм мин. Чынлап та, мин сезне болай ук интересный кеше дип уйламаган идем. Тиз кабынып китүчəн, шашкын хисле кеше сыманрак тоелган идегез. Ə сез əнə ничек нык ихтыярлы, сабыр кеше булып чыктыгыз. Һəм шуның белəн мине бөтенлəй əсир иттегез бүген.

Бу сүзлəрне ул чын күңеленнəн, күзлəремə туп-туры карап əйтте. Дулкынланудан бит алмалары комач шикелле кызарган, күзлəре оч-кынланып ялтырый иде.

Миңа да бик уңайсыз һəм кыен булып китте. Ихтимал, аның күңелен юатыр өчен генə булса да, йомшак кына итеп, мамык шəленнəн чыгып торган бөтеркə чəчлəреннəн сыйпарга, мин сезгə ышанам, Гөлүсə, игътибарыгызга бик шатмын, диярге кирəк булгандыр. Башта, чыннан да, шулай итмəкче дə булган идем. Лəкин шундук, нигə кыз баланың күңелен омсындырырга, лутчы турысын əйтергə дə бирергə кирəк дигəн уй башыма килде дə, мин аңа юри каты итеп:

— Бала-чага шикелле җыен юк-барны сөйләп тормагыз әле, Гөлүсә! — дидем.

Шулай диюем булды, ул куенымнан ялт итеп атылып чыкты да чанадан сикереп төште.

— Юләрләнмәгез, Гөлүсә, әйдә утырыгыз да кайтыйк матур гына! — дип чакырып карасам да утырмады. Аннары үзем дә чанадан төшеп, күтәреп алып утыртмакчы булган идем. Ләкин ул кыр кәҗәседәй җиңел генә йөгереп китте. Мин аны куып тормадым.

— Ихтыярыгыз алайса! — дидем дә атыма утырып киттем.

Инде Көрнәлегә кайтып җитәргә дә ерак калмаган, утлары җемелдәшеп күренә иде.

Ул, бер сүз дә дәшмичә, баскан җирендә торып калды.

Ике-өч йөз метр киткәч, мин артыма борылып караганда ул җылт-җылт атлап кайтыр якка килә иде инде...

## 6

Әйе, ул көнне мин Гадел абыйга да, шактый сәер сүзләр сөйләгән теге укытучы кыз Гөлүсәгә дә Сәкинәмне ник аерып җибәрүемне аңлатып бирмәдем. Шуңа аңлатмадым, чөнки шәхси тормышым турында үзем дә сөйләргә яратмыйм, башкалар сөйләгәнне дә бик үк өнәп бетермим. Минемчә, андый эшләрне бары тик ике генә кеше: ир белән хатын гына белергә тиеш... Ләкин, шулай икәнлеген яхшы белсәм дә, бу урында мин яшьлек елларымны, беренче мәхәббәтемне, семья хәлләремне сиңа кыскача гына булса да сөйләп бирмичә үтеп китә алмыйм. Алда сөйләячәк вакыйгалар шунсыз аңлашылмаячак, туган. Аңлашылган тәкъдирдә дә тулы булмаячак. Мин сиңа бер нәрсәне дә яшермичә, ничек булган — шул килеш сөйләп бирергә вәгъдә иттем бит. Менә тыңла әле.

Барлык авыл малайлары кебек үк, мин дә җәен каз көтеп, шара уйнап, җиләккә йөреп, ә кышларын чана-чаңгы шуып үстем.

Башка малайларныкы кебек үк, минем дә үз дусларым, үз иптәшләрем булды. Әмма шулар арасында иң якын дустым Рәдиф иде. Кая барсак та, ни кылансак та, без гел аның белән бергә идек. Мине бөтән малайлар кимсетә башласа — ул, аны кимсетә башласалар — мин, берберебезне яклап, теләсә кемгә каршы чыгарга әзер тордык. Әзер генә түгел, сугышкан чакларыбыз да булды.

Һич онытасым юк, без беренче класска укырга керәсе елны, сабан туе көннәрендә, Рәдифләргә Казаннан туганнары кунакка кайтты. Рәдифкә бүләк итеп, уенчык гармун да алып кайтканнар иде. Бер дә бер көнне, шул гармунын тотып урамда уйнап йөргән чагында, бездән өч-дүрт яшькә зуррак Шайтан Вагыйз дигән малай, кая, кубызыңны уйнап карыйм әле дип, сагыз урынына ябышты бит Рәдифкә. Рәдифнең гадәте шундый: гармун тикле гармунын гына түгел, гомумән үз әйберен миннән башка кешегә бирергә яратмый ул. Ә гармунын хәтта миңа да уйнатып караганы юк иде әле. Шулай булгач, ничек уйнатсын ди ул Шайтан Вагыйзгә! Ә Вагыйз китми дә китми. Теле белән Рәдифне юмалый алмагач, куркытырга кереште бу. Алай да эше барып чыкмагач, Рәдифнең гармунын тарта-йолка башлады. Үз дигәненә алай да ирешмәгәч, як-ягына каранып алды да, якын-тирәдә безнең яклы малайлар юклыгын белеп, Рәдифнең эченә тибеп җибәрде. Инде минем дә түземем төкәнгән иде, мин дә Шайтанның ипи шүрлегенә бер менеп төштем. Аннары ул миңа берне ямады. Китте сугыш, китте кычкырыш!..

Эш менә болай булып бетте: каяндыр таяк табып алып, Вагыйз безнең икебезне дә шәп кенә дөмбәсләде дә Рәдифнең гармунын урталай аерып кайтып китте. Хәер, без дә әҗәтле булып калмадык. Берничә

көннән соң, ул һич көтмәгәндә, кулында таягы юк чакта тотып алдык та үзен бик әйбәтләп тукмап җибәрдек.

Мәктәпкә укырга кергәч тә Рәдиф белән бер партада утырып укыдык. Өйгә биреп җибәрелгән мәсьәләләрне дә бергә чишә идек. Беренче классны тәмамлаган елны әти миңа чын гармун алып бирде. Гармун уйнарга да Рәдиф белән бергә өйрәндек. Ул миннән алдарак та өйрәнде әле. Өйрәнүен өйрәнде, тик әллә ни оста гармунчы булып китә алмады. Тора-бара бөтенләй бизде. Ә мин, киресенчә, торган саен күбрәк хиресләнә бардым. Мәктәптә тәнәфес вакытларында да укытучылар гел миңа уйнарга кушалар иде.

Сигезенчедә чакта (дүртне бетергәч, без үзебездән җиде километр ераклыктагы Янтык урта мәктәбендә, фатир торып, укыдык), әти-әниләре туганнарының туена киткәч, безнең класстагы бер кыз аулак өй ясарга булган. Гармун уйный белгәнгә, мине дә чакырды бу. Ә Рәдифне чакырмады. Дустымны калдырып үзем генә бараммы соң инде?

— Рәдифне дә кертерлек булсаң — риза, шунсыз — юк! — дидем мин тегө кызга.

Күрәсең, башка гармунчы табар чамасы булмагандыр, сыкраныбрак кына булса да, ризалашты кыз.

Әйтелгән сәгатенә бардык. Үз авылларыннан да биш-алты малай, җиде-сигез кыз җыелган иде. Артык тавышланмыйча гына (укытучылар сизсә — харап!) мин уйныйм, тегеләр җырлый башлады. Аннары кызып, онытылып киттеләр булса кирәк, шәбрәк, кычкырыбрак җырлашырга тотындылар. Төрле уеннар уйнау китте. Йөзек салыш уйнаганда, үзләренең җаны теләгән кызларын алып, малайлар «кәҗә ябып», «йолдыз санап» та кергәлиләр. Минем дә исәп юк түгел. Миңа да Сәкинә исемле бер кыз ошый. Минем ул кызны моңарчы да күргәләгәнем бар. Алтынчыда, икенче сменада укый ул. Ләкин моңарчы минем аңа әллә ни игътибар иткәнем юк иде. Ә менә бүген әллә ничек бик якын булып китте. Миннән ике класска кечерәк икәнен дә аңлыйм, шулай да нигәдер тиңдәшем шикелле, яшьтән үк бергә үскән шикелле тоела башлады ул. Аның белән бик рәхәтләнеп «йолдыз санап» керер идем дә бит, нихәл итәсең, гармун уйнап утыргач, мин йөзек салыш уенында катнаша алмыйм. Шуңлыктан миңа җәза бирелми. Ә «кәҗә ябарга» җәзага тап булган кешеләр генә чыгарга тиеш.

Рәдифнең эше рәхәт! Әллә юри җәза алырга тырыша инде шунда: Сәкинә белән өч тапкыр «кәҗә ябып» керде бу! Ул, ихтимал, дүртенче мәртәбә дә чыккан булыр иде, тик кинәт бик хәтәр итеп ишек дөбердәтә башладылар. Барыбыз да шып булдык. Чыгып: «Кем ул?» — дип сорарга беребезнең дә йөрәге житми. Син бар да син бар дип, пышынпышын бер-беребезне кыстышып тик торабыз. Ә ишек аның саен ныграк дөберди, тәрәзә рамнарына кадәр дер селкенә. Ниһаять, хуҗа кыз тәвәккәлләп чыгып китте.

— Беттек, балалар! — диде ул, бик тиз генә әйләнеп кереп.— Укытучы Нәҗип абый килгән! Әйдә, тизрәк киенегез дә минем белән өйалдына чыгыгыз! Мин ишекне ачканда ишек артында торып торырсыз да, Нәҗип абый өйгә кереп киткәч, чыгып чабарсыз!

Укуга алай искитәрлек һәвәс түгел иде ул кыз. «Отлично» турында әйткән дә юк инде, «яхшы» билгеләрен дә бик сирәк алгалап килә. Ә менә хәзер, шушындый кыен чакта, барыбыздан да акыллырак, кыюрак булып чыкты! Без нәкъ ул әйткәнчә эшләдек: өйалды ишеге артына посып тордык та, Нәҗип абый пыр тузып өйгә кереп китүгә, атылышып чыгып, урамга сибелдек. Үзебез фатирда тора торган йортның капка төбенә ничек кайтып җиткәнемне сизми дә калдым. Ә Рәдиф күренми иде әле. Миңа аны көтеп тормыйча ярамый: бергә чыгып киттек, бергә кайтып керергә тиешбез. Кышкы суыкта урык-сурык ишек ачып йөргәнне фатир хуҗасы яратмый.

Нәжип абыйдан курыкканлыктан бөтенләй онытып торган икәнмен, капка төбендә Рәдифне көтеп торганда аяк туңа башлаганга арлыбирле йөрергә керешкәч, кылт итеп гармунымны теге кызларда онытып калдырганлыгым исемә төште дә йөрәгем жу итеп китте. Бөтен өметем Рәдифтә иде хәзер. Бәлки, ул алып кайтмасмы? Андый чакта минем шикелле куркып-югалып калмый торган гадәте бар иде аның...

Бик озак көттем мин аны ул кичне. Туңып беттем. Шулай да ул кайтмыйча өйгә кермәдем. Ә эш менә болай булган икән. Безнең белән бергә, башта Рәдиф тә өялдыңа чыккан. Ләкин хуҗа кыз ишекләрен ачып азапланган чакта, гармуныбыз онытылып калуын исенә алган да йөгереп өйгә кире кереп киткән. Гармунны алып чыгып килгәндә исә Нәжип абыйга юлыккан. Ә Нәжип абый Рәдифнең якасыннан ук каптырып:

— Башкаларыгыз кая китте? Кемнәр бар иде? Ничә кеше идегез? — дип сорау алырга тотынган.

Рәдиф башта Янтыктагы үзе белгән зуррак, инде мәктәпне тәмамлап чыккан берничә егетнең һәм кызның исемнәрен әйтеп котылырга тырышып караган. Әмма Нәжип абый, аның ул сүзләренә ышанмыйча, бик каты кыса башлагач, түзмәгән, аулак өйгә килгән укучыларның исемнәрен әйтергә мәҗбүр булган. Тик минем исемне генә әйтмәгән. Гармунны да, үземнеке дип, үз өстенә алган.

Менә шундый иде минем Рәдиф дустым!

Мин үзем дә аның өчен җанымны бирергә әзер идем. Бервакыт шулай мәктәпкә тәкә куыгы алып килде бу. Тәнәфестә өреп тутырып куйды да дәрес башлангач, парта астында торган килеш кенә, шул куык белән шаярып утыра башлады. Боргычлый торгач, ялгыш шартлап китте бит моның куыгы. Шактый каты шартлады ул нәмәстәкәй. Класстагы укучылар гына түгел, хәтта кара такта янына эленгән карта каршында безгә дәрес аңлатып торган укытучыбыз Галия апага тикле сискәнеп китте. Аннары бөтен класс берьюлы кычкырып көлеп җибәрде. Шартлау безнең парта астында булганлыгын Рәдифнең дә, минем дә кызарышып китүебездән үк аңлап алды булса кирәк, Галия апа кулындагы күрсәткеч таягын Рәдифкә төбәде дә:

— Син шартлаттыңмы? — дип, җан ачуы белән кычкырып куйды.

Рәдиф, җавап бирмичә, башын аска иде.

— Бас әле, Хәйретдинов, синнән сорыйм мин!

Рәдиф иренеп кенә басты, әмма җавап бирмәде.

— Я, багана булып катып торма, әйт, син шартлаттыңмы? Нәрсә иде ул? — диде Галия апа, Рәдифнең янына килеп, күзенә керердәй булып.

— Юк, мин шартлатмадым, апа,— диде Рәдиф, елап җибәрер дәрәҗәгә җитеп.

— Димәк, син шартлаттың, Хәкимов? — диде Галия апа. Тавыш да ныграк ачулана төшеп, миңа текәлде.

Нишләмәк кирәк, «мин түгел» дисәм, эш зурга китәчәк. Ахыр чиктә мәсьәлә барыбер ачыкланыр да Рәдифкә бик кыенга туры килер. Болай да географиядән тарта-суза гына «уртача»га укып килә ул. Шартлауның да Рәдиф эше икәнен белсә, Галия апа аңа чиреккә «начар» чыгаруы да бик ихтимал. Болай да ничектер үртәлүчән, юк кына нәрсәгә дә кызып китә торган укытучы ул. Мондый эштән соң ике дә уйлап тормас...

Секунд эчендә шул фикер башыма килде дә, тиз генә торып бастым:

— Гафу итегез, Галия апа, куык минеке иде, ялгыш шартлап китте,— дидем.

Галия апа, чарт иттереп, күрсәткеч таягы белән картага сукты да:

— Бар, югал күземнән, хәзер үк чыгып кит класстан! — дип мине куды... Аннары тәнәфестә укыту мөдире Нәжип абый янына алып кереп

тә нык кына «эшкәрттеләр» үземне. Ләкин мин Рәдифкә сукыр бер тиенлек тә үпкәләмәдем. Иң якын дустыңа ничек үпкәлисең инде?..

Безнең дуслык соңрак, икебез дә үсеп егет булгач бозылды.

7

Ул елны без икебез дә ун классны тәмамлап, колхозда эшли башлаган идек инде. Рәдиф — завхоз, мин — хисапчы. Ул елларда унны бетергән кешеләр бик кадерле иде бит, нигә алай колхозда гына каласы иттегез? диярсең син, бәлки. Минем дә үз хыялым бар иде: авыл хуҗалыгы институтына укырга керергә иде минем исәп. Ләкин хыял бер, чынбарлык бөтенләй башка нәрсә бит ул, туган. Мин унынчыда укыган елны әнием авырый башлады да мин аны ташлап китә алмадым. Дөрес, Рәдиф Казанга барып, педагогия институтына имтихан биреп караган иде караган. Күрәсең, булдыра алмагандыр — имтихан алу вакыты беткәнче үк әйләнеп кайтты да:

— Ун ел укып та бик нык алҗыттым инде, житәр! Колхозда эшләп карарга кирәк бераз,— дигән булып, шыпырт кына завхозлыкка урнашты.

Минем укырга китмәвемнең тагын бер бик житди сәбәбе бар, туган. Ул турыда һич тә сүз кузгатырга исәбем юк иде дә, шулай булса да, яшереп калдыра алмыйм инде мин синнән. Хикмәт шунда, әти бик кызу канлы, бик җиңел холыклы кеше иде безнең. Шунын өстенә нык кына салгалый да иде. Ә салдымы — тавыш чыгара, әнигә бәйләнә, бер дә юкка аны кимсетә башлый. Соңгы елларда бөтенләй азынды бу. Әниннең кыз чагыннан калган, күз карасы кебек итеп саклап торган мамык шәлен дә, хәтта бердәнбер самоварыбызны да каядыр башка авылга илтеп сатып эчеп кайткач һәм шунын өчен әни күз яше белән елап, әрләргә җыена башлагач, карап торган бердәнбер сыерыбызны да житәкләп чыгып китте дә, шул китүеннән җир упкандай юкка чыкты. Исәндерме-юкмы — ул хакта бер нәрсә дә әйтә алмыйм. Хаты да, хәбәре дә юк...

Менә шулай, туган. Әтисез дә калгач, кием-салым, ашау-эчү мәсьәләләре дә шактый кыен булгач, мина институт турындагы хыялларымны онытып торырга туры килде. Әйтмәсәм дә аңлашыла булса кирәк, Рәдиф тә, мин дә ул чакта борыннарыбызга кызлар исе кергән, кызлар дигәндә җәһәннәмнең аргы ягына барып чыгарга әзер торган егетләр идек инде. Кичләрен аулак өйләргә дә йөрибез. Ә үзебез һаман бик дус, бик тату. Беребез ни әйтсә — икенчебез шуңа риза. Гомергә шулай булыр төсле иде. Әмма кешеләр яшьрәк чакта гына шулай әчкерсез булалардыр, ахрысы. Ә олыгая төшкәч күңелләре тупаслана, муртая, дуслык хисләре кими, шәхси омтылышлары өстенлек итә башлый булса кирәк. Икенче төрле итеп әйткәндә, «минеке», «минә» дигән нәрсә алгы планга чыга торгандыр, ахрысы. Шулайдыр, шулай булмаса, кайчакта дус белән дус кына түгел, эне белә абый, ата белән бала үзара алдашуга, ачуланышуга һәм дошманлашуга барып житәр идемени?..

Безнең телгә килешүебез һич тә көтмәгәндә килеп чыкты. Әлеге шул Янтыкта — теге чакта Нәҗип абый туздырып чыгарган аулак өйдә — безнең белән бергә утырган һәм шул ук вакытта ук инде минем күңелгә кереп калган Сәкинә исемле кыз кырыгынчы ел башында авылыбыздагы туганнарына утырмага килде. Кызлар күрмәгән кеше түгел инде мин. Кайберләрен озата кайткалаганым да бар иде. Әмма Сәкинә... Ул хәзер тагын да чибәрләнеп, тагын да сылуланып киткән. Синең, мөгаен, «Все начинается с дороги», «Крепостная актриса», «Коллеги», «Чистые пруды», «День счастья», «Человек, которого я люблю» исемле фильмнарны караганың бардыр. Менә шуларның барысында да Тама-

ра Семина дигән актриса уйный. Төп рольләрне башкара ул. Әйтергә кирәк, бик шәп итеп башкара. Безнең авылга утырмага килгән елны Сәкинә нәкъ шул Тамара төсле чибәр, тыйнак, нәкъ шулай мәхәббәтле иде. Бер сүз белән генә әйткәндә, килгән көнне үк үлеп гашыйк булдым мин аңа. Ничек итсәм итәм, әмма бүген кич барыбер шул кызны озата кайтам дип, күңелемә беркетеп куйдым.

Әмма аңа күңеле төшкән кеше бер мин генә булмаганмын, башка егетләрнең дә ике күзен дүрт иткән икән ул. Алары өчен кайгырмаска да була. Рәдиф белән икәүләп тотынсак, каршы тора алучы булмаячак иде безгә. Тик, кызганычка каршы, Рәдифнең үзенең дә Сәкинәгә һушы киткән булып чыкты, туган! Гел аның тирәсендә сырпалана башлады бу. Йөзек салыш уйнаганда җәзага тап булып, бер тапкыр Сәкинәне «йолдыз санарга» алып чыгып, хәтсез генә озак торып кerделәр. Ә миңа, әлеге шул гармун уйнап утырганлыктан, «җәзалы» уен уйнарга һич тә җай юк. Ну гармунны уйныйм инде аныcы! Җаннарымны биреп тырышам. Сәкинә биегәндә аеруча шәп сайрый гармуным. Талып, тартыша башлаган бармакларым язылып киткәндәй була. Биюен дә бик шәп бии инде малай! Идәнгә түгел, йөрәккә басып бии. Шундый да дәртле, шундый да килештереп биючене күргәнем юк иде әле. Башкаларга да шулай тоела торгандырмы, миңа калса, минем өчен генә шулай оста биидер кебек ул. Ул — биеп, мин — уйнап үзара сөйләшәбез, серләшәбез шикелле тоела. Тик ничек итеп чынлап торып сөйләшергә соң үзе белән?..

Аулак өйдән таралышыр вакыт якынлашкач, әйдә бер тартып керик әле дигән булып, мин Рәдифне өялдына алып чыктым да:

— Нәрсә, Сәкинәңне озатырга исәбең бармы әллә? — дип сорадым.

— Әбизәтелне озатам!

— Суфиян үпкәләмәсме соң?

Хикмәт шунда, шул көннәрдә авылыбызның Суфия исемле кызын сөйләштергәләп йөри башлаган иде ул. Әйтүенә караганда, чын-чынлап ук ярата да. Ләкин минем теге соравыма һич тә исе китмәде Рәдифнең:

— Һәй, таптың сүз! — диде ул, кычкырып көлеп. — Суфия моның янында дүртенче сорт кына ич ул. Аннары тагы беркая да китми бит ул Суфия, Сәкинә кайтып киткәч тә монда кала.

— Калуын када да бит, соңыннан ул сиңа үпкәләсә, сөйләшергә теләмәсә?

— Үпкәләсә — үпкә бәлеше пешереп ашар!

— Туктале, кызма әле син, Рәдиф. Суфиян бик чибәр, бик акыллы бит! Гел чикерткә шикелле сикергәләп йөрмә инде! Ә Сәкинәне бүген мин озатыйммы әллә дигән идем. Янтыкта аулак өйдә утырган елдан бирле яратып йөрим бит мин аны. Тик сүз катарга гына моңарчы йөрәгем җитмәгән иде.

— Юк, Өлфәт, әйдә, алай мәтәштермә инде син, яме! Дуслыкны бозма. Мин озатам аны бүген. Минем дә бик күптәннән күз төшеп йөри инде аңа. Әгәр арага керсәң — дуслык бетте дип уйла!

Нишләтәсең инде аны? Шулай да:

— Дус итсәң — юл куй миңа, Рәдиф? — дип тагын бер кат үтенеп карадым каравын.

Әмма Рәдиф күп сөйләшеп тормады.

— Әйткән-бетте! Булмагач — булмый, Өлфәт! — диде дә кереп үк китте.

Ул кичне дә, икенче, өченче кичне дә Сәкинәне Рәдиф озата барды. Әмма, яшьләрнең сөйләвенә караганда, кыз белән уртак тел таба алмаган иде әле. Шуннан ары минем дә кан кызып китте Рәдифкә. Шулай булмый хәле юк, чөнки Сәкинә безнең авылга гомергә килмәгән, торса — атна-ун көн торыр. Санаулы көн бик тиз үтә бит ул. Ә Рәдиф инде өч

көн вакытны алды. Дусын дус та, ахыр чиктә, бездә дә күңел дигән нәрсә бар бит!..

Шулай уйладым да, дүртенче кичне аулак өйгә баргач, әле уеннар башланганчы ук, Рәдифне өялдына алып чыктым һәм гомеремдә беренче мәртәбә, төрпә итеп:

— Я, ничек соң, егет, кунак кызы белән эшләр җайланамы? — дидем.

Рәдиф теш арасыннан гына черт иттереп төкереп куйды.

— Сиңа аны белү бик кирәкме?

— Әйе, кирәк.

— Алайса әйтәм: көндердем мин аны, малай!

— Мәтәштермә син, Рәдиф. Мине ахмакка санама! Сөешергә түгел, сөйләшергә дә теләмәгән Сәкинә синең белән!

— Шымчылык итеп, күзәтеп йөрдеңмени?

— Юк, мин үзем күзәтмәдем, ләкин барысын да беләм: әйттеләр.

— Ярый, алайса, дус кеше буларак, дөресен әйтим: бик үҗәт нәрсә булып чыкты ул кыз. Һич кенә дә якын бара торган түгел. Ну шулай да бүген тагын бер тапкыр озатып карыйм әле. Килешә алмасак, иманын укытам мин аның!

— Юк инде, Рәдиф, өч тапкыр барып карадың — җитте! Өчтән ары көч була ул. Бүген миңа юл куй инде син, яме?

— Папрубый барырга!

— Барсам нишләтерсең?

— Анысын соңыннан күрерсең!

— Өркетмә, яме, синнән курка торган күлмәгем күптән тузды инде!..

## 8

Тартышка китсә көч белән алдыра алмаячагын үзе дә сизенде булса кирәк (шаярып көрәшеп уйнаган вакытларда гел мин ега идем аны), өялдында сөйләшкәндә шактый нык әтәчләнсә дә, теге кичне Рәдиф миңа комачаулап, бәйләнеп йөрмәде.

Сәкинәне ничек озата кайтуымны, капка төпләрендә ниләр сөйләшүебезне сөйләп тормыйм, туган. Андый изге нәрсәне, минемчә, үзара сөйләшкән егет белән кыз гына белергә тиеш. Тик шуны гына искәртеп китмәкче булам: картлар әйтмешли, чәчләребез чәчкә бәйләнеп үк туган булганбыз, күрәсең: Сәкинә белән шул ук кичтә аңлашып, сөешеп киттек без.

Бер атна торды ул безнең авылда. Соңыннан да, җае чыккан саен, я мин Янтыкка барып, яисә ул безнең авылга килеп, очраша башладык. Хатлар язышып та серләшәбез. Аннары, көтә торгач, сабан туе да килеп җитте. Алдан сөйләшү буенча, Сәкинә бәйрәмдә безнең авылга килергә тиеш иде. Безнең авылның урманы бик якын, ындыр артыннан ук башлана. Сабан туен һәр ел шунда үткәрәләр. Бик матур аланлык бар безнең анда. Коенырга теләгән кешегә көмеш сулы зур гына күле дә якын гына. Элек шунда бер рус баеның дачасы булган. Билгеле, хәзер анда бернинди дача юк: революция елларында авыл халкы бөтенесен яндырган — капитализмның духы да калмасын, янәсе... Духы, чыннан да юк. Ә менә аланы белән күле калган. Исән булсам, шул аланда колхозчылар өчен ял йорты салдырырга әле исәп. Нык итеп, бүрәнәдән эшләтергә уйлыйм. Кыш көне дә торырлык булсын. Авыл халкының җәй көне ял итеп йөрергә вакыты булмый аның. Ә менә кыш көне була. Кышын да бик шәп ул алан. Әллә кайдагы курортларга барып йөргәнче, үз курортыбызда рәхәтләнерләр, ичмаса! Колхозның анлык кына хәле бар хәзер...

Ярый, монысы анын киләчәк эше. Мин сиңа үткән хәлләрне сөйли идем бит әле.

Сүзендә торды Сәкинә — килде сабан туена. Икебез дә бик нык сагынышканбыз икән, очрашкач ук, үзебез дә сизмәстән, сукмак буйлап урман эченә кереп киттек. Аны күргәнче сөйләшеп сүзебез бетмәс төсле иде. Ә менә хәзер, очрашып икәүдән икәү генә бара башлагач, бөтенләй телсез калдым. Һич кенә дә юньле сүз килми телгә! Әнисенең сәламәтлеге хакында, ничек һәм кемнәр белән безнең авылга килүе турында сораштым да шуның белән сүзем бетте. Ул да дәшми, минем дә тел әйләнми. Әкрен генә атлыйбыз да атлыйбыз. Ләкин болай бару ничектер кыен. Аптырагач, мин чәчәк җыярга тотындым һәм Сәкинәгә бер кочак чәчәк җыеп бирдем. Ул, рәхмәт әйтеп, чәчәкләрне кулына алды да сокланып күкрәгенә кысты. Ә мин, ни эшләвемне үзем дә белештермичә, Сәкинәнең сылулыгына сокланып, исереп китеп, чәчәкләре белән бергә аны кочып алдым...

Бу минем аны гомеремдә беренче тапкыр үбүем иде. Шунда без бер-беребезне мәңге ташлашмаска сүз куештык. Аннары кайтыр якка — сабан туе бара торган аланга таба киттек. Бу минутларда миннән дә бәхетле кеше, белмим, булдымы икән?!

Тик ул бәхетебез озакка бармады. Аланга килеп җитәбез дигәндә генә, Казаннан үзләренә кунакка кайткан туган тиешле бер егетне ияртеп, кинәт каршыбызга Рәдиф килеп чыкты. Кыяфәтләреннән үк күренеп тора — икесе дә бераз салмышлар. Миңа бәйләнергә чамалый болар. Сүзне Рәдиф башлады. Алар юлыбызга аркылы төшкәч, читләтеп үтеп китмәкче идек, Рәдиф җиңемнән тартып туктатты да, йөзенә ачуны китерә торган мыскыллы кыяфәт чыгарып:

— Я инде, бик алай ашыкмагыз, нурлы йөзләрегезне туйганчы бер күреп калыйк инде,— диде. Карашы нурсызланган зур яшькелт күзләрен, гаҗәпләнгән булып, Сәкинәгә текәде. Сәкинә бер дә исе китмичә йөзен читкә боргач, авызын бәлчәйтеп куйды да:

— Ярар инде, чибәр кыз, боргаланма инде, кыш көне утырмага килгән чагыңда бер дә болай кыланмаган идең бит! — дип, үбәргә итенә башлады.

Моннан соң да түзеп торырга һич тә мөмкин түгел иде. Рәдифнең кулларын читкә кактым да, нык кына итеп, үзен этеп җибәрдем. Шул арада, арттан килеп, Казан егете минем колакка берне тартты. Әллә көтелмәгәндә китереп сукканга, әллә берәр каты әйбер белән ордымы икән — бер мәлгә күз алларым караңгыланып китте. Шулай да бик тиз өнемә килдем һәм:

— Бар, Сәкинә, йөгер! — дидем дә, кизәнеп торып теге егетнең танавына мин дә берне салдым. Үзе шулай йомшак буынлы булгангадырмы, әллә җан ачуым белән мин бик нык эләктергәнменме — мәтәлеп үк китте егет.

Мин Рәдиф тә шулай кулын ходка җибәрер дип көткән идем. Бәйләнеп тә эш майтара алмам дип шүрләгәндерме, әллә сабан туеннан соң тагын бергә эшләргә туры киләчәген исенә төшерепме икән, анысы миңа кагылмады. Ул тимәгәч, мин дә кул күтәреп тормадым. Тиз генә Сәкинә артыннан китеп бардым.

Бер-ике көн үпкәләшеп, бер-беребезне күрмәмешкә салышып йөрсәк тә, сабан туе үтүгә Рәдиф белән очраша, сөйләшә башладык. Ни әйтсәң дә, беребез завхоз, беребез хисапчы идек бит!

Мин шуның белән мәсьәлә ачыкланды, арабыз өзелде бугай дип, тәмам тынычланган идем. Рәдиф үзе дә бер дә алай ачуын сиздермәгән булды. Ләкин ул җай чыкканны гына көтеп йөргән икән. Анысы ничек булганын соңыннан аңлатырмын, хәзер Сәкинә белән ничек кавышуыбыз хакында тагын берничә авыз сүз әйтеп китим әле мин сиңа, туган.

## 9

Ул килүендә Сәкинә безнең авылда ике көн торды. Өченче көнне кичкә каршы озата киттем мин аны. Теләсәм, ат җигеп илтергә дә булыр иде, билгеле. Әмма җиде километр ара ат белән барганда бик тиз узыла бит ул. Ә минем Сәкинәне, биш кенә минутка булса да, янымда озаграк тотасым килде. Шуна күрә җәяүләп кенә озатырга булдым. Иркенләп, бер дә ашыкмыйча бардык без ул көнне. Юл буендагы эрәмәлеккә тукталып, җиләк тә ашадык, чәчәкләр җыеп, мин аңа тәкыя да үреп бирдем. Рәхәтләнеп сөйләштек, туйганчы көлештек. Янтык күренә башлагач та, аерылыша алмыйча, шактый вакыт берберебезгә карап, сүзсез генә сөйләшеп тордык. Бары шуннан соң гына, хатлар язышып торырга сүз куешып, ниһаять, аерылыштык. Ул гаҗәеп матур аяклары белән җинел генә атлап, бер кулына чәчәкләр, икенчесенә косынкасын тотып, басу капкаларыннан кереп киткәнче, мин аңа сокланып, хәйран калып һәм кул болгап тордым...

Их, бу дөнья! Нигә кеше гомерендә бер генә тапкыр була икән андый кадерле минутлар? Бер-ике сәгатькә генә булса да, нигә кире кайтарып булмый икән андый бәхетле чакларны! Әгәр шулай мөмкин булса, Сәкинәне һич икеләнүсез борып алып кайтыр идем мин. Алып кайтыр идем дә, шул ук сәгатьтә авыл советына барып, язылышыр идек. Үзе дә моңа каршы килмәс иде ул, минемчә. Аерылышканда мин аңа, шаярып кына:

— Ә мин сине җибәрмим, Сәкинә. Күтәрәм дә үзебезгә алып кайтам! — дигәч:

— Әйдә, булдыра алсаң — мин каршы түгел! — дигән иде ләбаса. Дөрес, ул да шаярып әйткәндер әйтүен. Әмма шаярудан чынга күчәргә әллә ни күп кирәк түгел бит. Ярата иде ул мине, үлеп ярата иде. Һичбер арттырусыз әйтәм, әгәр шул көнне тәвәккәлләп, чынлап торып тотынсам, кайтыр иде ул минем белән. Әгәр шул көнне аны алып кайткан булсам, ак сакаллы карт буласы икәнмен мин: бер ел бергә яшәп каласы икәнбез! Ләкин юк, үткәнне кире кайтару мөмкин түгел шул!..

## 10

Кырык беренче ел башында Сәкинә тагын утырмага килде. Бу юлы безнең арага керүче булмады. Рәдиф инде кисәтелгән, авылның бүтән егетләре шулай ук безнең яратышуыбызны белә иде. Шулай да бер көнне аулак өйдә кич утырганда «кәҗә ябарга» алып чыккан аны Рәдиф. (Ул көнне мин колхоз отчеты белән районга барып кич утырырга кайтып җитә алмаган идем.) Ләкин элеккечә үк сагызланмаган ул. Төрле юк-бар турында лыгырданып торган да:

— Син чынлап та яратасыңмы шул чыпчык йомыркасы төсле сипкелле, сары кашлы Өлфәтне? — дип кенә сораган.

Сәкинә дә каушап калмаган.

— Чынлап яратам, Рәдиф! Сипкелле булса да, узган ел сабан туенда теге Казан егете белән икегезне ике якка сибеп китте ич ул! — дип җавап биргән.

Шуннан авызы томаланган тегенең. Үз алдына нидер мыгырданып, тәмәкесен кабызган да, аулак өйгә кереп тә тормыйча, кайтып киткән.

Сәкинәнең җавабы бик җиткән дип санадым мин. Ул хакта Рәдифкә бөтенләй сүз катмадым. Нишләтим соң, сипкелле булгач — сипкелле инде мин. Кашым гына түгел, чәчем дә сары, бакыр төслерәк. Дөресен генә әйткәндә, Рәдифнең дә әллә ни мактанырлыгы юк инде кана. Төсбит, буй-сын шәп, әлбәттә. Ул яктан тел тидереп булмый. Ә менә аягының рәте юк. Өченче ел сугу машинасының маховигы тирәсендә шаярып утырган чагында барабанны маховик белән тоташтыра торган каеш

астына аягын ялгыш кыстырып, бәлагә тарган иде ул. Шуннан соң аягының тубыктан түбән ягы тәмам эштән чыгып калды. Хәзер бик нык аксап йөри. Ул аягына фабрикада тегелгән ботинка да, күн итек тә кия алмый. Фабрика итеген боздыртып, үзенә җайлаштырып, Галим абзыйдан тектереп кенә киярга мәҗбүр. Алай да юньләп йөри алмый әле. Иярле атка атланып барган кеше сыман, бер батып, бер калкып кына йөри. Менә шул кеше синнән сипкелле, сары чәчле дип көлеп йөргәч, кәефең кырылмый нишләр?..

Шулай итеп, ул килүендә бер атна торды Сәкинә безнең авылда. Бер атна буена һәр кичне озата кайттым мин аны. Әмма санаулы көннәр бик тиз үтә шул, каһәр. Тәмам ияләшеп, үзләшеп җиткәндә генә:

— Иртәгә мин китәм инде, Әлфәт,— диде Сәкинә.

— Юк, Сәкинә, беркая җибәрмим мин сине. Риза булсаң да, булмасаң да, алам да калам!

Мин аны чынлап әйткән идем. Сәкинәм, җан кисәгем, дерт итеп куркып китте. Беркавым тәмам аптырап, ни әйтергә дә белмичә торды. Бары шуннан соң гына:

— Юк, Әлфәт, алай куырма әле син мине,— диде.— Без бик яшь бит. Мин яңа гына унсигезгә чыктым. Аннары әниең терелеп китсә, сине армия хезмәтенә дә алып куюлары бар. Бер кавышкач, ике ел аерым торулары бик кыен диләр ич!

Шулай дигәч, мин каршы килә алмадым.

— Алай-болай армиягә алып куйсалар, мин хезмәт итеп кайтканчы көтәрсеңме соң, матурым? Берәрсенә күзең төшеп, башың әйләнеп китмәсме икән? — дип кенә сорадым.

— Борчылма, бәгырем, көтәрмен. Ике ел гомер күпмени ул? Син кайтканда да егермедә генә булам бит әле мин! — диде ул.

Аннары тагын сабан туе җитте. Бу ел да Сәкинә бәйрәмгә безнен авылга килде. Нигә гел ул гына килә, нигә син бер дә бармадың, дип гаҗәпләнмә, туган. Хикмәте бар аның. Янтык егетләре кунак егетләрне бик үк өнәп бетермиләр. Нигәдер тар күңеллеләр. Менә шуңа күрә андый болгавыр чакта — сабан туе көннәрендә Янтык егетләре миңа да бәйләнмәсен өчен, Сәкинә үзе безгә килә торган иде.

Бу ел да, нәкъ былтыргыча, сабан туе барган аланда озак тукталып тормастан, очрашкач ук урманга кереп китеп, чәчәкләр җыеп йөрдек. Тик бу юлы әйтер сүз таба алмыйча, гаҗизләнмәдем инде мин. Хәзер без бер-беребезгә туганнардай якын идек, үз идек. Сөйләшеп сүзебез бетмәде. Авылга тәмам күз бәйләнгәч кенә кайттык. Ә икенче көнне мин аны тагын авыллары күренә башлаганчы озата бардым. Тагын шулай ук басу капкасыннан кереп киткәнче кул болгап, карап тордым.

Кырык беренче елның унсигезенче июне иде бу.

Ә дүрт көннән соң безнең авылга шомлы хәбәр килде. Башка кешеләр үзләрен ничек хис иткәндер, анысын әйтә алмыйм. Әмма мин үзем, сугыш башланганын ишеткәч, беркавымга өнсезләнеп калдым. Күк йөзләре караңгыланып киткәндәй булды. Юк, сугышка алырлар да шунда үлеп калырмын дип, үзем өчен хафаланмадым! Минемише егетләр дә сакламагач, кем саклар ул туган илне? Әнием өчен, Сәкинә өчен кайгырдым мин ул минутларда. Мин исән-имин әйләнеп кайта алмасам, алар нишләр? Ахыр чиктә, Сәкинә әле яшь, таза, чибәр. Башта бик нык өзгәләнсә дә, соңыннан сүрелер, бүтән кешене, бәлки миннән яхшыраkны да табар. Ә менә әни... Сырхаулы бит ул. Бер көн аякта йөрсә, ике көн түшәктә ята. Сызламаган җирем юк, ди. Врачларга да күрсәтеп караган идем үзен. Ләкин авыруын тәгаен генә ачыклый да, терелтә дә алмадылар. Шул әти имгәтеп бетергәндер инде бичараны. Ул китеп олакканнан бирле авырый әнием. Мин дә киткәч — ул нишләр? Менә хикмәт нәрсәдә!..

Өч-дүрт көн эчендә авылның бөтен ир-егетләрен дип әйтерлек сугышка алып бетерделәр. Егерме җидесенә иртәнге сәгать тугызга район военкоматына килеп җитәргә кушып, егерме алтынчы июньдә миңа да язу килде. Үзем белән бер атналык азык-төлек, кашык һәм кружка да алып килергә әйтелгән иде ул язуда. Димәк, эни савыкканны көтеп тормыйлар, мине дә хәзер үк алалар? Ә Рәдифкә андый язу юк. Кылмаячак та аңар андый язу. Аның ише аксак белән нишләсеннәр? Ә мине, сипкелле, сары чәчле булсам да, алачаклар мена...

Колхозның исәп-хисап эшләрен тиз генә бүтән кешегә тапшырдым да, үзебезгә чыбык очы тиешле Хәерниса апага биштәр капчыгы әзерли торырга кушып (әни үзе булдыра алырлык түгел, ул көннәрдә бик нык әзлегеп ята иде), озын-озын уйлап тормастан, Янтыкка Сәкинә янына киттем.

Туп-туры өйләренә барып кердем. Әнисе Саҗидә исемле икәнлеген белсәм дә, үзен күргәнем юк иде әле. Бик житез, мөлаем һәм минем әнигә караганда шактый яшь, егәрле хатын икән. Кем син, төнгә каршы нишләп йөрисен, дип тә төпченеп тормады. Сәкинә кирәк иде миңа, дигәч:

— Суга гына киткәние, хәзер кайтып җитәр, энем, утырып тор! — дип, түр якларына кертеп утыртты да үзе самовар куярга керешге.

Биш-ун минуттан Сәкинә дә кайтып керде. Заманы шундый иде бит, ни өчен килүемне Сәкинә кыяфәтемнән үк аңлап алды булса кирәк, бер дә алай аптырап калмады. Болай да алсу йөзе тагын ныграк кызарып китте дә беркавым сүз әйтә алмыйча карап торды. Аннары мин аңа, әйдә, урамга чыгыйк әле, әйтәсе сүзем бар иде дигәнне аңлатып, ым кактым һәм без су буена төшеп киттек.

Башта инеш буенда, болынлыкта шактый озак сөйләшеп йөрдек. Көлешкән, шаярышкан булсак та, икебез дә борчулы, сагышлы идек. Бу очрашуыбызның соңгы очрашу булырга мөмкин икәнлеген тоеп тору җаныбызны тырный. Аннары без су буендагы тал төбендә бер-беребезгә сыенышып, сүзсез генә уйланып, моңланып утырдык. Искиткеч җылы һәм якты кич иде ул. Күктә ай балкып тора, йолдызлар җемелдәшә. Янтык этләре сирәк-мирәк өреп куя, бакалар бакылдашып ала, таллар арасында кошлар чыркылдаша. Шуннан башка берниндй тавыш юк. Ә бит хәзер кайдадыр сугыш, үтереш бара. Дөнья янгыратып туплар шартлый, бомбалар ярыла, кешеләр үлә. Иртәгәдән мин дә шул мәхшәргә китәчәкмен...

— Ничек уйлыйсың, Сәкинә, исән-сау әйләнеп кайтырга язармы икән миңа?

— Кайтырсың, Өлфәт! Кайтырга тиеш син, бәгырем! Синсез мин нишлим ди аннары?

— Әйтүем шушы, Сәкинә, алай-болай мин кайта алмасам, үлү хәбәрем килсә дә, шул хәбәрдән соң бер елсыз кияүгә чыкма!

— Юкны сөйләмә, бәгырем! Синнән башка беркем дә кирәкми миңа!

Шулай диде дә, күкрәгемә башын куеп, сулкылдап елый башлады. Минем күздән дә яшь бәреп чыкты. Бераздан Сәкинә елавыннан туктады, күзләрен мөлдерәтеп миңа карады да әйтте:

— Әгәр чын-чынлап яратасың икән — калдырма мине Өлфәт, алып кайт үзең белән!

Мин аптырап, бер мәлгә каушап калдым. Минем өчен көтелмәгән бәхет иде бу. Ахыр чиктә, мин дә яшь егет бит! Минем дә, бер генә тапкыр булса да, сөйгәнем белән бергә булып каласым килә. Ләкин мин бу турыда аңа әйтергә кыймаган идем, күңелен рәнҗетермен, үпкәләтермен дип уйлаган идем. Инде менә ул үзе тәкъдим ясады. Нишләргә соң миңа хәзер?

— Мин әйләнеп кайта алмасам, үкенмәссеңме соң, Сәкинә? Бер төн өчен тол хатын исемен күтәреп йөрергә туры киләчәк бит сиңа!

— Булсын, Өлфәт! Теләсә нәрсә булсын. Мин барысына да риза! Ике-өч кенә, бер генә сәгать булса да, синең белән булып каласым килә минем. Башка берни дә кирәк түгел миңа!

Мин ни дип әйтергә дә белмәдем. Сәкинәне кысып кочаклаган килеш, күзләренә карап, өннән чыгып утыра бирдем. Шул арада Сәкинә, әлеге сүзләрен әйткәнгә үзен үзе битәрләгән сыман итеп:

— Ярар алайса, кирәкми! — дип елап җибәрде. Аннары тиз генә сикереп торды да, битен кулы белән каплап, кайтыр якка йөгереп китте.

Мәсьәләне шул ук минутта хәл итәргә кирәк иде. Аны кызганам дип, артыннан бармыйча, мин я шунда тал төбендә утырып калырга һәм сөйгәнемне мәңгегә югалтырга тиеш. Яисә куып җитәргә дә, син минеке бәгырем дип, килен итеп авылга, әни янына алып кайтырга тиеш. Мин соңгысын сайладым...

Ә иртән, сугышка китеп барышлый авыл советына — Көрнәлегә кагылып, язылышып чыктык.

Мин кайтканчы үз авылыгызда, әниең янында яшәп торсаң да ярый дип, мәсьәләне Сәкинәнең үз ихтыярына куйган идем. Әмма ул, минем авыру әниемне ялгыз калдырырга теләмәде, бездә — әни янында торып калырга булды.

## 11

Сугыш булгач, бигрәк тә разведчик кешегә, төрле чак туры килә. Егермешәр көн, берәр ай буена хат язып салырга мөмкинлек тимәгән вакытлар да булгалады. Ләкин ник бер үпкәләп карасын Сәкинә! Киресенчә, һәр хатында мине юатып, өметләндереп яза иде. Аның хатларын уку — үзе бер гомер була торган иде миңа!

Белмим, нинди изге, сабыр җан булгандыр ул. Инде әйткәнемчә, эти бөтен кием-салымны, бөтен мал-туарны сатып киткәнлектән, безнең тормыш болай да ташка үлчим генә иде бит. Шуның өстенә, мин сугышка китеп баргач, әнинең хәле тагын да авырая төшкән. Тора-бара ул бөтенләй аяктан калган, гел урын өстендә генә ята башлаган. Ләкин Сәкинә ул турыда миңа бер тапкыр да язмады. Мине борчыйсы килмәгән, терелер дип өмет иткән ул. Үз әнисе кебек итеп тәрбияләгән әнине. Чана белән тартып алып барып, район врачларына да күрсәтеп караган. Ләкин әни барыбер савыга алмаган, хәле һаман начарлана барган һәм ул кырык икенче елның уникизенче февралендә мәрхүм булган.

Бары шуннан соң гына Сәкинә дөресен язды миңа. Әле дә хәтеремдә, хатын менә шушы сүзләр белән тәмамлаган иде: «Бeләм, бәгырем, бу хәбәрне ишетү авыр булыр сиңа. Миңа да бик читен, бик күңелсез әни булмагач. Амбар хәтле өйдә бер башым торып калдым бит. Бернинди киңәшчем, сердәшчем юк. Әни барда кайгымны да, шатлыгымны да аның белән уртаклаша идем. Үзе эшли алмаса да, акыллы киңәшләре, тәмле сүзе белән ярдәм итә, күңелне күтәрә иде. Аннары ул миңа бик зур иптәш булды. Ә хәзер мин бер үзем калдым. Үз әнием, кайт Янтыкка, Өлфәт әйләнеп кайтканчы бергә торып торырбыз, дип әйтә әйтүен. Ә мин кайтырга теләмим, өегезне ятим итеп калдырасым килми, тәрәзәләрен кадаклап китәргә кулым бармый. Ничек тә син кайтканчы түзәрмен әле, Өлфәт. Аның каравы, син кайткач гөрләтеп яшәрбез. Бездән дә бәхетле кешеләр булмас ул чакта! Ә хәзергә сабыр итик. Син дә артык борчылма. Нишлисең бит, терелә алмады әни. Гомере шулай кыска булгандыр инде.

Ярый, хәзергә сау булып тор. Дошманнарны тизрәк җиңеп кайт! Тагын бер кабат һавадагы йолдызлар санынча сиңа сәлам озатып, исән-сау кайтуыңны көтеп, Сәкинәң».

Менә шулай итеп юатып язды ул миңа. Ә шул хатыннан соң бер-ике ай үткәч, улыбыз тууын хәбәр итеп, мине тагын да ныграк хәйранга калдырды. Син аның сабырлыгын, тыйнаклыгын гына күр әле, туган: бер дә шапырынмыйча, гадәти нәрсә турында гына сүз баргандай итеп: «Мин монда чишмәдән нәкъ сиңа охшаган сары чәчле, яшькелт-зәңгәр күзле бер кечкенә генә малай алып кайткан идем, Өлфәт. Киңәш ит әле, аңа нинди исем кушыйк икән? Синнән хат килгәнче исем кушмый торам. Озак көттермә, малаеңны зарыктырма, яме»,— дип хат язды. Шуңарчы йөкле булуын да хәбәр итмәгән иде ул миңа. Яшьлеге, тәҗрибәсезлеге аркасындадыр инде, әллә исән-имин таба алам, әллә юк дип, миңа язмыйча яшереп йөргән. Шундый да сабыр, шундый да түземле булырга кирәк бит, ә!

Мин малайга Ирек дип исем кушарга әйтеп яздым. Дөньяда иректән дә кадерле нәрсә юк, минемчә...

Тәки сүзендә торды Сәкинә: мин сугыштан кайтканчы безнең өйдә яшәде. Тик менә мин кайткач...

## 12

Ул көннәр исемә төшсә, йөрәгем өшеп, тыным кысылып куя. Авыр миңа ул турыда сөйләү, бик авыр, туган. Әмма бөтен эшне үзем бозып ташладым. Үзем ахмак булдым. Соңгы елларда нәселдәшлек хакында, үсемлекләргә дә, адәм балаларына да кайбер сыйфатларның нәселдән нәселгә күчүе турында бик күп язалар. Дөрес булырга тиеш ул нәрсә. Әти бик дуамал иде безнең. Аның шул гадәте миңа да күчкән булса кирәк. Югыйсә минем ул юләрлек кайдан килсен икән?..

Менә болай булды ул хәл, туган. Инде белгәнеңчә, мин сугыштан кырык алтынчы ел башында кайттым. Минем урынга калган бер яшь кенә кыз хисапчылык эшен юньләп алып бара алмагач, кырык икенче елда аның урынына Сәкинәне куйганнар һәм ул әле дә шул эшендә эшли иде. Ә Ирек инде зур, дүрт яшен тутырып килә. Кайтып кергән шәпкә ул миннән ятсынып торды. Шулай булмый хәле дә юк, чөнки ул мине гомерендә бер тапкыр да күрмәгән иде бит әле. Ләкин аның ятсынуы озакка бармады. Әнисе:

— Менә, улым, бу шул кеше, синең әтиең бит инде бу! — дип минем фронттан җибәргән фоторәсемемне күрсәткәч, бер миңа, бер рәсемгә карап торды һәм:

— Чынлап син минем әтимени, абый? — дип сорады.

Мин:

— Әйе, улым, чынлап синең әтиең мин! — дигәч, ура кычкырып, муеныма килеп асылынды. Шатлыгымнан түбәгә менеп, дөнья яңгыратып кычкыргандай булдым мин ул көнне! Андый хәлне үз башыннан кичергән кеше генә аңларга мөмкин. Тик мин берәүнең дә ул хәлгә дучар булуын теләмим. Кешеләр үз балаларын дүрт яшькә җиткәч кенә түгел, туган көннән үк күреп, үз күз алларында үстерергә тиешләр! Мин шулай дип уйлыйм.

Кайтып төшкәннән икенче көнендә үк мине туган-тумачалар, дусишләр кунакка дәшә башлады. Башка җирдә, белмим, ничектер, әмма бездә гадәт шундый: читтә йөреп кайткан кешене якын туганнары гына түгел, аз гына чыбык очы тиешлеләренә тикле өйләренә чакырып кунак итәләр. Борыннан килгән ул гадәт хәзер дә шулай дәвам итә...

Кайтуыма атна-ун көн үткәч, урамнан тотып алып кына булса да, Рәдиф тә:

— Әйдә, Өлфәт, чәй эчеп, рәхәтләнеп бер сөйләшеп утырыйк әле! — дип үзләренә алып керде.

Чәй эчеп чыгарбыз дип кенә алып керсә дә, әнисе пилмәнгә хәтле пешереп куйган, «мәйләре» дә мулдан иде. Мин моңа артык гаҗәпләнмәдем. Ник дисәң, Рәдиф кырык беренче елның сентябреннән бирле колхоз председателе булып эшли икән. Нигә аның пилмәнлек кенә рәте булмасын, ди. Сугышка кадәр теләсә кем, теләсә кайчан пешерә иде бит аны. Рәдифнең әнисе Мәсрүрә апа безне якты чырай, ачык йөз белән каршылады. Килеп керүебезгә үк өстәлгә аш-суын китереп утыртты. Ә үзе, барып кайтасы җирем барые, дигән булып, каядыр чыгып китте.

Башта без тыныч кына, төрле вак-төяк нәрсәләр хакында гына сөйләшеп утырдык. Стаканнарны күтәреп куйгач, икебезнең дә телләребез чишелеп китте. Рәдиф минем орденнарны, медальләрне берәм-берәм тотып карады да:

— Биш ел буе ут эчендә йөрүең бушка китмәгән икән, Өлфәт дус, шәп! — дип мактап алды. Бераз нидер уйланып утыргач, тагын сүз башлады.— Ә мин менә аяк аркасында сугышка бара алмадым. Ну мин аңа әнә очы хәтле дә үкенмим. Канса кансов, бөтен кешегә дә мылтык тотып сугышырга димәгән бит! Мылтыксыз сугышучылар да бик күп кирәк булды бу сугышта. Мин үзем, мәсәлән, мылтыксыз сугыштым. Кайберләрен, башкаларга сабак булсын дип, хәтта утыртырга да туры килде. Ну миңа барыбер орден бирмәделәр. Ни хәтле тырышып та ярап булмады халыкка. Бик яхшы сизеп торам: быелгы отчет-сайлау җыелышында прсидәтеллектән алырга җыеналар мине. Менә сиңа орден!

— Күрәсең, орденлык эш майтара алмагансың инде, Рәдиф. Бер дә элә-танагы калмаган бит, малай, хуҗалыкның: кая карасаң да ачык та тишек, нигә тотынсаң — шул юк. Хәтта эшкә ярарлык һәр атка җигеп йөрерлек берәр чана да калмаган диләр бит.

Рәдиф чыраен сытып, кашларын җыерды. Кабаланып стаканындагы аракысын эчеп куйды. Аннары ни өчендер үзалдына елмайды да:

— Дөрес, Өлфәт, бик дөрес әйткәннәр! — диде.— Тагын да дөресрәк итеп әйткәндә, ике атка бер чана да калмады безнең хәзер.

— Нигә алай булды соң ул, Рәдиф?

— Нигәме?.. Анысы турында мин сиңа отчет биреп тора алмыйм инде. Отчетлардан районга бирә-бирә дә гарык булып беткән. Нигә икәнен үзең эшли башлагач чамаларсың әле. Минем урынга сине куймак булалар ди бит!

— Кемнәр?

— Кем булсын, халык, әлбәттә!

— Шулаймыни? Ә миңа әле бу турыда беркем бер сүз әйткәне юк.

— Әйтерләр әле, җыелышта әйтерләр. Ничек соң, сайласалар эшләр исәбең бармы?

— Ни дип тә әйтә алмыйм, Рәдиф. Чөнки минем бу турыда синнән беренче ишетүем. Ә синең үзеңнең эшлисең киләме соң?

— Дөресен генә әйткәндә, килә, Өлфәт, бик килә! Бу урынымнан төшеп, бүтән эштә эшләүне мин күз алдыма да китерә алмыйм. Әмма белеп торам: очырачаклар мине прсидәтеллектән... Ә син әле уйлаганым юк дисең алайса? Уйларга кирәк, Өлфәт дус, бик кирәк сиңа бу турыда уйларга!

— Нигә тумаган тайның билен сындырып, юкка баш ватарга ди әле миңа?

— Тайны инде туган дип исәплә, ә билен сындыру мәсьәләсендә мин сиңа шуны әйтергә тиешмен: сындырсаң, минем билне, үзеңнең яшьтәшеңнең, дустыңның билен сындырачаксың, Өлфәт!

— Моны ничек аңларга инде? Куркытып куюмы, әллә ниндидер үтенечме?

— Теләсәң ничек аңла, ләкин аңла, Өлфәт! Аң-ла-а!

Шуннан соң миңа ризыкның тәме, табынның яме бетте. Чөнки аңлашылды: Рәдиф мине кисәтеп кую өчен чакырган икән. Хәзер инде сүз озайтып утырудан барыбер мәгънә чыкмаслыгын сизенеп, сый-хөрмәте өчен Рәдифкә рәхмәт әйттем дә өйгә кайтырга кузгалдым. «Аңла!» дигәннән соң терсәге белән өстәлгә таянып, башын иеп уйга калган Рәдиф мин ишекләрен ачып чыгып баргaнда кинәт сикереп торды да, тиле кеше сыман ямьсез итеп, шаркылдап көлә башлады. Мин, аптырап, ачкан ишекне япмыйча тукталып калдым:

— Нишлисең, Рәдиф?

Минем сорауны бөтенләй ишетмәгәндәй, ул тагын берәр минут чамасы шулай шаркылдап торды. Аннары бераз тыйлыга төште дә:

— Яп әле ишекне дә кил монда! — диде.

Мин янына килгәч, күзләрен елтыратып, бик зур сер әйткән кешедәй колагыма үрелеп, пышылдарга тотынды:

— Үземнән үзем көләм мин, Өлфәт дус! Соң инде сиңа шул сүзләрне әйтеп ялынып торырга тиешле кешемени мин? Син бит минем үтенечне барыбер колагыңа да алмаячаксың. Канса кансов, минем урынга сине булмаса, башка кешене куячаклар, ә мине барыбер чөеп ыргытачаклар быел. Әйдә, чөйсәләр чөйсеннәр инде, үкенерлек түгел: дүрт елдан артык дөньясын шауллатып яшәдем! Башкасы турында әйткән дә юк, мин эчкән аракыны җыеп барсаң, анысы гына да кечерәк бер күл булыр иде. И «теге» якның да кимен куймадым. Дус итеп сиңа гына әйтәм, яшь, чибәр хатын-кызларга да кулым тигәләде!

— Булмагандыр ла?..

— Ә? Булмагандыр дисеңме?.. Ха-ха-ха-ха! Ул миңа ышанмый торган була бит әле! Әгәр алай шикләнәсең икән, кайткач Сәкинәңнән сора әнә.

— Бу ни дигән сүз, Рәдиф? Минем Сәкинә белән дә булдым дип әйтергә теләвең түгелдер бит?

Рәдиф мыскыллы елмаеп куйды:

— Бигрәк беркатлы кеше инде син, Өлфәт! Күңелеңә авыр алма, малай...

Башта артык исем китмичә утырган булсам да, тегенең соңгы сүзләреннән соң минем эчкә дә корт керде бит, туган. Башымнан хәтта, әллә, сикереп торып, ботарлап ташлыйм микән үзен, дигән уй да йөгереп үтте. Ләкин, түземемне җыеп, тыелып калдым һәм тагын бер мәртәбә:

— Алдашмыйсыңмы, малай? Шушы сүзләреңне расларлык берәр дәлилең бармы? — дип сорадым.

Ул тагын кычкырып көлеп куйды да:

— Андый эшләрнең дәлиле каламыни, юләр! — диде.— Дәлиле юк, ә миңа шаһит кирәк булса — бар, анысы булыр!

— Кем ул?

Рәдиф җавап бирергә ашыкмады, никтер уйга калып, маңгаен ышкып тора башлады.

— Мин җавап көтәм, Рәдиф: кем ул шаһит? — дидем мин, тәкатьсезләнеп.

— Син көтәсең дә бит, ә мин әйтергә теләмәсәм?

— «А»сын әйткән икәнсең, «Б»сын да әйт! Я сүзләрең ялган икәнлеген таны да хәзер үк гафу үтен! Югыйсә...

— Ул кадәр үк чапаланма син! — диде Рәдиф, минем кыза башлавыма бер дә алай исе китмичә.— Әгәр синең өчен ул кеше бик алай важный икән, әйтәм алайса: Хафиз карттан сорарга мужыш әнә!

— Иртәгә аек баштан да шушы сүзләреңне кабатларсыңмы, Рәдиф?

— Ә хәзер син мине исерек дип уйлыйсынмы? Икебезгә бер яртыны да эчеп бетермәдек бит әле без. Чепуха бит бу минем өчен! Бер үземә бер яртыдан да кызмача гына булып йөрим мин. Каяле...

Рәдиф шкафларындагы шешәгә үреләә башлагач, мин түзеп тора алмадым:

— Җитте, агайне, бик шәп сыйладың! — дидем дә, мәсьәләне бүген үк ачыкламакчы булып, Хафиз картларга киттем. Ләкин ул өйдә юк иде.

— Атна башында үк районда торучы малаебызга кунакка дип киткәние, шуннан бирле кайтканы юк әле, олан,— диде карчыгы.

Үзең дә чамалыйсыңдыр, туган, минем кәефнең рәте-чираты сүтелгән иде инде. Рәдиф сүзләренә бөтенләй үк ышанып җитмәгән идем җитүен. Шулай да Сәкинәм белән башка көннәрдәгечә якын итеп, үз итеп сөйләшү булмады. Үзем никадәр сиздермәскә теләсәм дә, Сәкинә барыбер минем хәлне сизенде.

— Нишләдең син, Өлфәт? Нигә болай сонга калдың, кайда шушылай алыштырып җибәрделәр сине? — диде ул, бик нык хәвефләнеп.

— Мин бүген Рәдифләрдә булдым, аракы эчтек, сезнең ничек итеп сугыш елларында бергәләп колхозны җитәкләп алып баруыгыз турында сөйләшеп утырдык! — дидем мин. «Бергәләп» сүзенә басым ясап әйттем. Аннары, нишләр икән дип, Сәкинәнең йөзенә карадым. Берәр төрле кырын эше булган булса, кинәт коелып төшәргә тиеш иде ул. Коелып үк төшмәде Сәкинә, әмма секунд эчендә дерт итеп, сискәнепкызарып китте. Тик ул үзен бик тиз кулга алды һәм, бер дә алай шаккатмыйча гына:

— Күңелгә килгән нәрсә алга килми калмый шул. Болай сонгаргач, күңелем шикләнгән иде аны, тәки шул аксак шайтан янында булгансың икән! — диде дә кече якка кереп китте.

Шуннан ары ул да дәшмәде, мин дә сүз озайтып тормадым. Минем Рәдифләрдә булганны ишеткәч дерт итеп китсә дә һәм аның шул дерт итеп китүе Рәдиф сүзләрен раслау сыман булып тоелса да, Хафиз карт белән сөйләшеп, мәсьәләне тулысынча ачыкламыйча, эшне зурга җибәрмәскә булдым.

Ул төнне мин керфек тә какмадым, туган. Колагымда һаман Рәдифнең «күңеленә авыр алма...» дигән сүзләре яңгырап торды, күз алдымнан мең кабат Сәкинәнең миңа таныш булган тормышы һәм гадәт-холыклары чагылып үтте. Ләкин аны гаепләрлек бер генә нәрсә дә юк иде минем күңелдә. «Димәк, булмаган андый нәрсә. Димәк, шикләнергә урын юк, Сәкинә андый кабахәтлеккә бармагандыр, Рәдиф ялган сөйлидер», дип үземне үзем тынычландырырга никадәр тырышсам да, шик-шөбһәне тәки башымнан куып чыгара алмадым. Шуның өстенә, шомлы күңелне тагын да шомландырып төн буе җил улады, буран котырды. Аптырагач, мин санарга керештем. Ләкин аның да файдасы тимәде. Миңгә кадәр санап та йокыга китә алмагач, әле таң беленә генә башлаган булса да, торып киендем дә башта капка төпләрен көрәдем, аннары мал-туар асларын җыештырып, аларның ашарларына салдым. Алай да вакыт бик акрын үткәч, бабай заманыннан ук калган һәм гел ботактан гына торган утын түмәркәләрен ярырга тотындым. Ә колакта гел Рәдиф сүзләре яңгырый һәм мин Хафиз карт белән булачак сөйләшүне күз алдыма китерергә тырыша идем.

Хафиз карт... Үзебездә генә түгел, тирә-як авылларда да бик мөхтәрәм, бик гадел кеше санала иде ул. Туган-тумачалары бәла-казага юлыккан адәмнәр, әҗерен үзе сорап алмый, ни бирсәң шуңа риза дип, «Корьән» яки «ясин» чыгартырга гел шул Хафиз абзыйны чакыра торганнар иде...

Шулай төрлечә уйланып һәм эш белән мавыгып, ничек кирәк алай, сәгать уңберләрне житкердем дә, кайтып җитмәде микән дип, тагын

Хафиз картларга бардым. Юк, кайтмаган иде әле. Әмма карчыгы Мәрьямниса абыстай бу юлы мине шактый тынычландырып җибәрде:

— Бүген базар көн бит, олан. Шәт, район базарына китүчеләр булмый калмагандыр әле, шулар атына утырып кайтыр дип торам мин аны,— диде.

Вакытны ничек үткәрергә, җанымны кая куярга белмичә аптырагач, өйгә кайтып, әмма өйгә кереп тормыйча гына, егет чактан калган чаңгыларны тезмәдән эзләп табып кидем дә урманга киттем. Ара-тирә ишетелеп куйган тукран тукылдатуларын искә алмаганда, кышкы урманда сихри тынлык хөкем сөрә иде.

Яшел ботакларына ак кар кунган мәһабәт чыршыларга, зифа каеннарга, инде кышның яртысы үтеп барса да, яфраклары әле һаман коелып бетмәгән иманнәргә, кызлар муенындагы мәрҗән шикелле булып, сирәк-мирәк очрап куйган кып-кызыл миләшләргә сокланып карап йөри торгач, үзем дә сизмәстән, сабан түе аланына килеп чыкканмын. Ак юрганга төренеп йоклап яткан ул алан кышын да гаҗәеп матур иде. Аның өстендәге шул ак юрганын ачып карасаң, хәзер дә бөтен тирә якка хуш ис — җиләк һәм чәчәкләр исе таралыр төсле иде...

Заманында Сәкинә белән менә шушы аланда очрашып, әнә теге — кояш чыгышына таба киткән сукмак буйлап әчкәре кереп, чәчәкләр җыеп йөргән идек бит инде без. Һәм ул чакларда дөнья гел шулай чәчәктән генә торыр, без һәрвакыт шулай шат һәм бәхетле булырбыз кебек иде... Ә менә хәзер... Бүген кич ни буласын әйтүе дә кыен... Әй, бу Рәдифне дә әйтер идем инде... Нигә гел генә миңа килеп кагыла соң әле аның хикмәтләре?..

Мин урманнан әйләнеп чыкканда, Хафиз карт инде кайткан, иләмсез зур гәүдәсе белән бөтен өйне тутырып, чәй эчеп утыра иде. Тиз генә урыныннан кубып, каршыма килеп күреште дә:

— Әйдә, батыр, әйдә, мактап җөрисең икән әле, әзер табынга туры килдең! — дип, өстемне салырга кыстый башлады. Чәйләр эчеп ук утырырга һич тә ниятем булмаса да, карт:

— Аштан олы булмыйлар, наный, ярамый алай! Аннары әллә кемгә килеп кермәгән лабаса, сөннәт бабаң лабаса мин синең! — дип, авыз ачарга да ирек бирмичә кыстый башлагач, карышып торырга мөмкин булмады. Шул ук вакытта табын янында Сәкинә белән Рәдиф мәсьәләсен ачыкларга да ничектер җайлырак булыр төсле тоелган иде. Тик менә карчыгы Мәрьямниса абыстай алдында андый четрекле мәсьәләне ничек кузгатып җибәрермен дип кенә борчылган идем. Әллә чыннан да изге кеше булып, шул уйларымны сизенеп алды инде: мин шинелемне сала торган арада Хафиз карт Мәрьямниса абыстайны тиз генә кече якка алып кереп, аңа нидер пышылдады да тегесе шундук киенеп каядыр чыгып китте.

Табын янына килеп утыруга, Хафиз картның иңенә кулымны куеп, күзләренә карадым да:

— Бер дә алдашмыйча гына, дөп-дөресен генә әйт әле, сөннәт бабай: мин сугышта чакта минем Сәкинә Рәдиф белән чуалдымы-юкмы? — дидем.

Хафиз карт, минем сүзне бөтенләй ишетмәгән сыман, башта иләп кенә, өреп суыта-суыта гына бер стакан чәй эчте. Чәен эчеп бетергәч тә, күзләрен самовар борынына текәп, байтак ара дәшми утырды. Бары шуннан соң гына:

— Болай үзең шикләнеп кенә бирдеңме бу сорауны, наный? Әллә берәрсеннән берәр төрле сүз ишетепме? — диде.

— Үземдә бернинди дә шик туганы юк иде, кеше әйтте, Хафиз абзый. Әмма мин бүтән беркем сүзенә дә ышанмыйм, мин бары тик синең сүзенә генә ышаначакмын!

Хафиз карт никтер каушап калгандай булды: башта моңарчы кыпкызыл булган йөзе агарып китте, аннары уң кашы тартышып куйды. Ләкин бу хәл озакка бармады, ул менә болай дип җавап бирде:

— Гомеремдә бер генә мәртәбә нахак сүз әйткәнем булса да, тәвәккәлләп бу юлы тагын бер тапкыр әйтерием: «җук» диярием мин сиңа, наный! Әмма ләкин җитмешкә җитеп әйтмәгән нахак сүзне бер бүген генә әйтә алмыйм инде. Хак сүз әйткәннәр сиңа, наный: чуалды Сәкинәң Рәдиф белән, чуалганнарын үз күзем белән күрдем.

— Кайда һәм кайчан күрдең? — дидем мин, Хафиз картның авызына керердәй булып.

— Кая, алай ук сабырсызланма әле! — диде ул, йөзен читкә борып. Аннары бик гадәти хәбәр җиткергәндәй иплән кенә: — Нигә миңа алай ямьсез карыйсың? Мин алар артыннан шымчылык итеп йөрмәгән ләбаса! Кырык өченче елның җәендә урманда зелпе тамыры җыеп йөргәндә ялгыш кына өсләренә килеп чыктым, наный,— диде.

Шулай итеп, минем соңгы өметем дә өзелде. Кинәт күз алларым караңгыланып китте һәм аяк астымдагы җир чайкалып куйгандай булды. Шактый вакыт телсез-өнсез калып торганнан соң, кинәт бер явыз ерткычка әйләндем дә, бар ачуымны Сәкинәдән алырга булып, өйгә кайтып киттем.

Мин кайтып кергәндә Сәкинә улыбыз Иректне сөеп, аның белән сөйләшеп утыра иде. Мин өстемне чишенә башлагач:

— Менә, улым, безгә әйтмичә генә иртүк каядыр чыгып югалган әтиебез дә әйләнеп кайткан! Әйдәле, сорыйк әле үзеннән: кайда булды икән, ниләр эшләп йөрде икән? Яле, бер үбеп ал әле үзен безгә әйтмичә шулай озак йөреп кайткан өчен! — дип, көлә-көлә сөйләнеп, Иректне күтәреп яныма килде. Килде дә шундук өркеп-аптырап читкә тайпылды.

— Бәй, нишләдең син, Өлфәт? — диде ул, минем сөзәргә җыенган үгез кебек каш астымнан карап торуыма шаккатып.— Йөзеңнең бөтен нуры качкан бит синең!

Бер сүз дә дәшмәдем. Бөтен ачуымны берьюлы аңлатып бирердәй сүз таба алмадым. Ни әйтсәм дә аз булыр төсле тоелды. Шуңа дәшмәскә булдым. Кайчакта дәшмичә орышу да сүз белән ачуланудан ныграк тәэсир итә бит кешегә. Сәкинәгә дә шулай тәэсир итте:

— Я инде, газаплама, Өлфәт,— диде ул, тагын да ныграк хафага төшеп.— Әйт инде ичмаса, нигә болай усалланып кайттың? Берәрсе белән бәйләнештеңме әллә?

— Кит каршымнан! — дидем мин, бар көчемә акырып.— Чекрәеп торма, кара елан!

Башта Ирек куркып елап җибәрде, аннары Сәкинәнең күзләреннән мөлдерәп яшь ага башлады. Миңа да ничектер оят, уңайсыз булып китте. Хәтта, әллә икесен дә кочып алып, юатыйм микән, дигән уй да башымнан йөгереп үтте. Ләкин бу бик аз вакыт эчендә, секундның бер өлешендә генә булып алды. Мин яңадан ярсыган арысланга әверелдем. Иректне елавыннан туктатырга азапланган Сәкинә каршына килеп, баланы тагын куркытмас өчен акрын, әмма нәфрәтле итеп:

— Я, сөйләп күрсәт әле: мин юкта Рәдиф белән ничек типтердең? — дидем.

Бу сүзләремнән соң Сәкинә тәмам өнсез калыр дип көткән идем. Ә ул аз гына гаҗәпсенеп, сөйкемле кара күзләрен миңа текәп торды да, кинәт ачылып китеп, көлеп җибәрде һәм болай диде:

— Төсең-битең бик куркыныч булып кайтып кергәч, әллә чыннан да берәр төрле хәвефле эш булганмы дип торам. Баксаң-күрсәң, бөтенләй юк өчен хәсрәтләнеп йөрисең икән, Өлфәт! Нигә тузга язмаган нәрсәгә ышанып йөрисең, күнче күбәләгем! Арыслandай ирем була торып, шул йолкыш белән бәйләнергә башыма тай типмәгән ич минем!

Мин аның бу сүзләрен игътибарга алыр дәрәҗәдән узган идем инде.

— Әһә! Син әле шулаймы? Авызыңны ыржайтып, көлеп торасыңмы? — дип алып торып киттем шуннан, алып торып киттем, туган — чыдасаң чыда, чыдамасаң юк!

Сәкинә, җан кисәгем, шунда да артык хафаланмады. Хәтта мин, тәмам чыгырымнан чыгып:

— Бар, үзең дә, малаең да, хәзер үк күземнән югалыгыз! Минем өйдә бүтән эзегез булмасын! — дип акырган чагымда да сабырлыгын җуймады ул. Шунда да иплəп кенә җайларга-көйләргә тырышып карады мине:

— Алай ук тузынма әле, Өлфәт! Андый ниятем булса, башта ук Рәдиф белән йөргән булыр идем. Үзең беләсең бит, Өлфәт җаным, кыз чагымда ук сиңа кадәр ул йөрде иң минем арттан. Яшермим, син сугышка киткәч тә бер тапкыр сүз катып караган иде ул. Ләкин мин аны якын да китермәдем. «Тагын шушы турыда авыз ачасы булсаң — бөтен районга фаш итәм мин сине!» дигәч, тирәмдә дә килгәне булмады. Соң үзең уйлап кара инде: сиңа хыянәт итәрлек булсам, башта авыру әниең белән, аннары яшь балам белән чиләнеп, шушы өйдә шушылай ялгыз яшәр идеммени мин? Әнием янына, үзебезнең авылга кайтып китмәс идеммени?

— Ярый, анысы шулай да булсын ди. Ә нигә соң шул Рәдифнең сүзләрен гомерендә бер мәртәбә дә ялган сөйләмәгән Хафиз карт раслап тора икән? Ул гадел картның миндә нинди ачуы бар икән, ә? Син менә шушы сорауга җавап бир? — дидем мин, бу дәлилем белән Сәкинәне тәмам фаш итмәкче булып.

Ләкин ул монда да артык шаккатмады. Бары:

— Инде шаһитен дә тапканмыни? Әйт әле, ичмасам, Хафиз картны ни дип котыртты икән, анысы нәрсәләр сөйләде? — дип кенә сорады.

— Онытkан булсаң, исеңә төшерәм алайса, — дидем мин, аның һаман шулай киреләнеп, танып азаплануына җен ачуларым чыгып. — Кырык өченче елны урманда зелпе тамыры җыеп йөргәндә яныгызга килеп чыккан ул сезнең! Хәтерлисеңме?

Сәкинә бер сүз дә әйтмәде. Ул тораташтай катып калган иде.

— Хәтерлисеңме? — дип акырдым мин, шартлап ярылыр хәлгә җитеп. — Хәтереңә төшерә алмасаң, әйдә, Хафиз абзыйның өенә барып, тагын бер кат сорашыйк! Ул барысын да аерым-ачык итеп аңлатып бирер.

Түземлелекнең дә бер чиге була торгандыр, ахрысы. Моңарчы бер дә ачуланмаска, ничек тә миңа мәсьәләне аңлатырга тырышып азапланган Сәкинәм, соңгы сүзләремне ишеткәч:

— Әй, раббым, бар икән күрәсе көннәрем! — диде дә, кинәт сыгылып төшеп еларга тотынды. Ана кушылып, моңарчы әнисе алдында утырган Ирек тә шыңшый башлады.

Мин Ирек бераз тынычланганны көтеп тордым да, ниһаять, мәсьәлә ачыкланган һәм мин җиңүче булып калган сыман итеп, теш арасыннан гына:

— Күрәсе көннәреңне хәзер түгел, алданрак уйлыйлар аны! — дидем.

Шуннан соң да берничә минут елап утырганнан ары, Сәкинә кинәт горур гына итеп башын күтәрде дә күз яшьләрен сөртеп алды һәм, миңа туп-туры карап:

— Теләсәң нәрсә уйла, Өлфәт, ләкин минем синең каршында тырнак очы кадәр дә гаебем юк. Үтерсәң дә синең ул Хафиз картың каршына бармыйм мин. Дөресен әйтмәячәген белеп торам мин аның! — диде.

— Булмаганны сөйләп торма — барыбер ышандыра алмассың! Бар, яхшы чакта күземнән югалыгыз! Үзең дә, малаең да!

— Ә мин сина аны елап сорасаң да бирәчәк түгел! — диде дә Сәкинә башта Иrekне киендерде. Аннары үзе киенде һәм:

— Ярый, Өлфәт, хуш! Шушы сүзләреңне ишетер өчен биш елга якын көтеп торганмын икән мин сине, рәхмәт! — диде дә малайны күтәреп чыгып китте.

Хатын-кыздан болай ансат кына котылып булмый торгандыр ул, мин бераз суынганчы күршегә генә кереп киткәндер, берәр сәгатьтән үк әйләнеп чыгарлар әле дип уйлаган идем. Инде күз бәйләнә башлаган булуга да карамастан, Сәкинә Иrekне күтәреп Янтыкка, әнисе янына ук кайтып киткән булып чыкты. Мин артларыннан бармадым. Болай шома гына кайтып киткән икән, димәк, үз хәлен үзе белгәндер, гаебе булмаса, алай тиз генә бирешмәс иде, дип уйладым. Шуңа бармадым. Дию пәрие шикелле, өйдә бер үзем яши башладым. Күршекүләннәр, дус-ишләр килеп тә, юләрләнеп йөрмә, бар алып кайт, дип үгетләп караганнар иде. Ләкин берсен дә тыңламадым, чыгымчы ат шикелле тәрәлдем дә каттым...

Сәкинә киткәнгә өч атна тулган көнне колхозның отчет-сайлау җыелышы булды. Рәдифне председательлектән азат итеп, аның урынына мине сайладылар. Аны Сәкинә урынына хисапчы итеп куймакчылар иде дә, мин риза булмадым.

— Рәдифне хисапчы итәсе булсагыз, мин председательлектән баш тартам, иптәшләр! — дигәч, килештеләр. Аксаклыгын искә алып, аны ферма мөдире итеп куйдылар. Анысына каршы килмәдем.

Шулай итеп, без — ике тәкә башы — бер казанда кайный башладык. Гөнаһсы кирәкми, ферма мөдире вазифасын әйбәт кенә үтәргә тотынды Рәдиф. Әчүен дә киметтe. Барлы-юклы бер ай эчендә фермадагы хәлләрне шактый гына җайга сала башлады. Ә менә мине аның урынына председатель итеп куйганнан соң үзенең тар күңелендә туган яман көнчелеген тәки җинә алмаган икән ул. Инде әйткәнемчә, атларга фураж ашатканны да районга ул җиткергән булып чыкты.

## 13

Райкомда шелтә биреп кайтарганнан соң, берәр вәкил җибәреп, кәнүшнәгә ташып куйган солыны үлчәп амбарга салдыртырлар дип көткән идем. Ләкин, ни хикмәттер, беркем дә килмәде. Солы хакында да бүтән сүз кузгаткан кеше булмады. Беткән баш беткән инде, мин дөньяда иң кадерле кешеләремне — улым белән Сәкинәмне югалттым, шуннан да артык югалту булырга мөмкин түгел, ни эшләтсәләр дә эшләтерләр дип, тагын шактый солы суктырып куйдым һәм атларга көн саен дүртәр кило солы ашата башладык...

Шулай итеп, безнең атлар язгы чәчүгә чыкканда шактый көр иде. Эшең уң булганда «мин» дип мактанып алырга да ярый дип, ялгышмасам, Каюм Насыйри әйткән бугай. Мина да бу урында әзрәк мактанып алырга ярый торгандыр.

Ул елны районда язгы чәчүне иң алдан тәгәлләгән колхоз — безнең «Чулпан» булды. Бик алай зурдан кубып булмаса да (чөнки минем өстә шелтә тора бит әле), район газетасына да язып чыктылар.

Чәчүләр беткәч бар халыкны кушып, сугыш елларында түгелмичә яткан ферма тиресләрен түгә башладык. Яңа ат абзарын төзү өчен саман кирпеч сугарга тотындык. Шул арада печән өсте дә килеп житте. Аны әрәм-шәрәм итмичә җыеп алырга кирәк иде. Ә ул ансат эш түгел. Искәртеп киткән идем бугай инде, безнең колхоз җирендә бер гектар да печәнлек болын юк. Печәнлегебез авылдан утыз километрда безнең Кама уртасындагы бер утрауда. Шунлыктан анда көн саен барып-кайтып йөрү мөмкин түгел. Бер баргач, печәнне чабып-өеп бетергәнче

шунда торырга туры килә. Шулай ук колхозчыларның да барысын җибәрә алмыйсың. Ялгызакларны, мәсәлән, ничек итеп йорт-җирен калдырып җибәрмәк кирәк? Карт-корыны җибәрүдән фәтва юк. Печән чабу — авыр эш. Аны теләсә кем булдыра алмый. Җитмәсә авылның ныклап эшләрдәй ир-атлары да бармак белән генә санарлык. Күбесе сугыштан кайта алмыйча ятып калды...

Бик тырышканнан соң да әле печәнгә барырдай нибары унике хатын һәм өч бөртек ир заты җыелды. Ә чабасы печәнебез илле җиде гектар! Печән чапкычыбыз да юк ичмаса. Барын бар ул, ләкин ватык. Ни эзләп тә һичкайдан запчасть таба алмадым.

Уйладым-уйладым да, әлеге унике хатын-кызны һәм өч бөртек ирне ияртеп, шул халыкның барысына бер атнага җитәрлек азык-төлек төяп, болынга үзем киттем. Халыкка ышанмаудан түгел. Халык бик гадел, эшчән безнең. Ләкин, сынаганым бар, «хуҗа» үзе эшләгәндә эш бөтенләй башкача, яхшырак бара инде ул.

Сугышка кадәр, баһадирдай ир-егетләр бар вакытта, ул илле җиде гектар болынны дүрт-биш көн эчендә егып сала торганнар иде. Ә бу ел без бер атна маташып та нибары егерме өч гектарын гына чаба алдык. Бердән, печәне бик калын, эченә керсә, ат күренми. Икенчедән, ни әйтсәң дә, печән чабу хатын-кыз эше түгел бит инде ул. Тагын бер хикмәте бар: ашауның юне юк. Дөрес, токмачлы куе ашын туйганчы ашарга була, икмәге дә бирелә. Әмма печән чапкан кешегә алар гына әллә ни зур куәт кертә алмый шул. Шулай булгач, кешеләрне куырып, ашыктырып та булмый.

Тиешле көнне безгә тагын бер атналык азык китерделәр. Ул көн үзенә күрә бер бәйрәм шикелле булды. Колхоздан җибәргән ризыклар өстенә, өйдә калган туган-тумачалары печәнчеләрнең кайсына җиләк, кайсына каймак-май, кайсына чәй әйберләре җибәргәннәр иде. Ә миңа бер нәрсә юк. Сәкинәм булса, ул да берәр әйбер җибәргән булыр иде дә соң, ни хәл итәсең...

Бик кыен булды миңа ул көнне. Күңелем тулып, күземә яшьләр килде. Әйбер килмәгәнгә түгел! Печәнчеләр мине үземә җибәргәннән дә болайрак сыйлады ул көнне. Ялгызлык, таянычым, көтәр кешем булмау өзгәләде күңелемне. Ашым — аш, эшем — эш булмады.

Безгә азык алып килгән кеше кайтырга җыена башлагач, әйтәсе сүзем барые сиңа дип, Галим абзый мине читкәрәк алып китте дә:

— Теләсәң нишлә, энем, болай булса, бу печәнне уракка төшкәнче җыйтарып чыга алмыйбыз без! — диде.

— Ник алай дисең, Галим абзый?

— Ник икәне күз алдында бит, Өлфәт энем: тагын бер грамм да ит алып килмәгәннәр ләбаса! Ә син үгез суеп китерәләр дип әйткән иең!

Әйе, печән чаба башлаган көнне ашның «коры» икәнлеген күргәч, сугышка кадәр печәнчеләргә көненә берәр кадак ит ашата торганнарые, хәзер андый гадәт юкмыни, председатель, дип бер теленә шайтан төкергәне, уенын-чынын бергә кушып, миңа төрттереп куйган иде. Ә мин, шаярып:

— Гафу итегез инде, туганнар, онытып җибәргәнмен шул. Юлга кузгалып киткәндә генә искә төште ул нәрсә. Әмма артык хафаланмагыз, алдагы атнада алып килерләр, колхозның нәсел үгезен суеп китерергә кушып киттем! — дип җавап биргән идем. Галим абзыйның шул сүзне искә төшерүе иде.

— Уйнап кына әйткән идем бит мин аны, Галим абзый,— дидем мин, түзә алмыйча көлеп җибәреп.— Нәсел үгезен суярга ярыймы соң инде? Сыерларыгыз кысыр калса, үзегез үк мине каргаячаксыз бит аннары!

Ләкин Галим абзыйның бер дә исе китмәде:

— Ә безгә ни әбизәтелне үгез, безгә тана ите дә ярый, энем!

— Яравын ярар да ул, Галим абзый, ләкин барысы да исәптә бит алар. Бөтен ил буенча терлек арттыру өчен көрәш барган вакытта, карап торган уналты баш тананың да берсен суйсак, колагымнан асып куймаслармы икән соң мине?

— Ә син асмый торган итеп эшлә!

— Алай итеп буламы икән соң?

— Була, энем Өлфәт, бик була! Тик әзрәк башыңны эшләтергә генә кирәк.

— Мәсәлән?

— Әйтик болай: безнең авылның көтүе иртә-кич авыл буендагы күпер аша үтеп йөриме?

— Йөри, шуннан?

— Шуннан шулай: күпердән чыкканда, такта арасына кысылып, берәр тананың аягы сынарга мөмкинме?

— Мөмкинен мөмкин дә, тик моңарчы андый хәлнең булганы юк ич әле.

— Булмаса — булыр! Менә болай тора эш, энем: давай, син мина шушы безгә ризык китергән атка утырып кайтып килергә рөхсәт ит әле, яме? Калган ягын мин үзем чамалармын аның. Хәзер бер тананы кызганмасак, кышын йөзе белән кайтачак ул!

Бер уйлаганда Галим абзый сүзендә дә хаклык юк түгел. Дөрес сайрый ул: печәнчеләрне арурак ашатып, печәнне яңгырлар киткәнче, ныклап торып урак урырга керешкәнче чабып-өеп кайтсак, бик шәп булыр иде! Узган кыштагы шикелле, колхоз терлекләренә нәрсә ашатыйк икән дип, баш ватып тормас идек аннары. Ләкин...

— Бернинди законга да сыя торган эш түгел бит бу, Галим абзый!

— Сыймаса — сыяр, син һич кенә дә аптырама аның өчен! — диде Галим абзый, гел үз сүзен куәтләп.— Сыйдырырбыз аны, сыя торган итеп эшләрбез. Закун гына түгел, шайтан үзе дә бәйләнә алмаслык итеп эшлим мин аны. Менә шул Галим абыеңң әйткәние диярсең, эшлим. Булдымы?

Мин: «Юк, Галим абзый, ярамас ул алай! Тиктомалга кайтып китүеңә печәнчеләр дә гаҗәпләнер» дип әйтмәкче булып авызымны ачкан идем, әмма яшь чагында читтә йөреп шомарып беткән һәм шул шомалыгы, үткенлеге, тәвәккәллеге аркасында «әйтсә эшли» кушаматы алган Галим абзый мине тыңлап тормады: кинәт сыгылып төшеп, эчен тотты да инде кайтып китәргә торган азык-төлек китерүченең арбасына барып ауды.

— Әйдә, сенелем, ку тизрәк атыңны! Үләм ату, эчем бик каты авырта! Һич тә тәкатем юк, әйдә, район больнисенә калдыра китәрсең мине!

Ул моны шундый илереп, чын авыру кеше сыман итеп әйтте, хәтта аны мин үзем дә кызганып куйдым. Шаярма, Галим абзый, төш арбадан, диярга теләсәм дә телем әйләнмәде. Ул арада алар атларын чаптырып китеп тә бардылар.

*(Ахыры киләсе санда)*

## Гамил Афзал

### Гомер китабы

Егермедә үсәм, дисен,
Дошман килсә килсен, дисен,
Утны-суны кичәм, дисен,
Дәртле йөрәк исән, дисен.
  Ә еллар бара тора,
  Елгалар ага тора.
Кырык яшьтә булам, дисен,
Торткан җирдән борам, дисен,
Ташны ташка орам, дисен,
Хуҗаларча торам, дисен.
  Ә җилләр исә тора,
  Малайлар үсә тора.

Алтмыш адым бардым, дисен,
Ташлы юлга тардым, дисен,
Тешем белән, түшем белән
Бураэналар ярдым, дисен.
  Ә еллар бара тора,
  Елгалар ага тора.
Әле миңа сиксән, дисен,
Сындырырмын типсәм, дисен,
Карчыгым да исән, дисен,
Тагын әзрәк үсәм, дисен.
  Ә җилләр исә тора,
  Оныклар үсә тора.

### Тирәк

Алкаланып аккан су буенда
Җиргә кирәк булып,
Мин утырам ап-ак ай нурында
Ялгыз тирәк булып.

Язлар буе шаулый кошлар түе
Җылы оя үреп,
Мин утырам язлар, көзләр буе
Тәмле төшләр күреп.

Җир астыннан, тамырларга тиеп,
Серле сулар ага,
Баш очымда көмеш нурлар сибеп,
Шат йолдызлар яна.

Ыгы-зыгы килгән шау-шулардан,
Таш юллардан ерак,
Мин утырам тып-тын басулардан
Изге илһам сорап.

Мин башымны чайкап җилгә җиллим
Җилле төннәр буе,
Мин хәйләне, явызлыкны белмим,
Мин табигать улы.

## Уйландыра торган чак

Шаулап исә,
Шомлы исә көзге җилләр,
Агачлардан берән-саран яфрак өзә.
Соры болыт сарыла да җир йөзенә,
Вак иләктән,
Вак иләктән яңгыр сибә.

Шыксыз калган басуларда, болыннарда
Сызгыра тик,
Сызгыра тик көзге җилләр.
Кипкән әрем сабаклары моңаялар:
Кая китте якты көннәр,
Җылы көннәр!

Тезелеп-тезелеп
Кошлар китә җылы якка.
Кырлар сары, урман сары, үлән сары,
Балигъ булган, акыл кергән табигатькә,
Уйландыра,
Моңландыра торган чагы.

## Рәсүл Гамзатовтан

Балыклар йөзә
агымга каршы,
Бөркетләр оча
давылга каршы;
Намусы кушса,
шагыйрьләр чыга
Бер үзе
бөтен дөньяга каршы.

## Яхшы

Ярларыннан ташый-ташый сулар акты.
Ташу үтте.
Ярларына сулар кайтты.
Ташу үтте.
Үзәннәргә комнар ятты.
Таңнар атты.
Үлән чыкты.
Офык якты.
Урманнарда сайрар кошлар канат какты.
Кызыл гөлләр, зәңгәр гөлләр чәчәк атты.
Һава татлы.
Сулар татлы.
Уйлар татлы.
Күңелләрдә кинә юк инә чаклы.
Мәңге ябык капкаларны зиһен ачты,
Томан булып торган уйлар чыңга ашты.
Хыял чиксез,
Күкләр биек,
Сулар тирән;
Очу яхшы,
йөзү яхшы,
көлү яхшы.

## Зөлфәт

### Очыш

И, җанның даулы мизгеле!
Зур болытлар астында
Нокта кадәрле бер кошчык
Аска оча таш сыман!

Мамык сыман күтәрелә!
Бөтерелә бушлыкта...
Күкне иңләп очкан чакта
Бәрелмәсме офыкка?!

### Шаулый хәтер...

Туй күлмәге кигән ап-ак шомырт
Сикереп чыга инде бакчадан,
Сикермә, дип, иңнәреннән тоткан,
Һич җибәрми аны сак чаган.
Шаулый хәтер шушы шомырт
сыман,
Һаман шаулый җанны җылытып:
Күптән инде, шул бакчада бер кыз
Ак яулыгын китте онытып.
Сискәндердек, төн йокысын бүлдек
Борма-борма агым суларның,
Вәгъдә биргән будык сылуларга,
Төшләренә кердек шуларның.
Сөю сүзләренең иң көчлесе
Тибрәнгәндер безнең телләрдә —
Тик чәчәкләр мәңге шауламыйлар,
Сибеләләр икән җилләрдә...
Тел бистәсе усак, күптән инде,
Тик без генә әйткән сүзләрне,
Тик без генә йөргән сукмакларны,
Тик без генә күргән эзләрне
Бүтән егетләргә әйтеп салган,
Пышылдаган бүтән кызларга.
Һаман шулай инде... Кыз кешене
Үстерәләрмени тузларга?
Яшь егетләр шуңа таң аттыра
Кочагында кызны җылытып.
Әнә берсе тагын ак яулыгын
Шул бакчада киткән онытып.
Сибелергә генә тора шомырт
Уйнак җилләр килеп кагылса,
Сикерәсе хәзер урам якка —
Тотып алыр егет табылса!

## Челдерәү

Су буенда ат эчертә матур кыз,
Яшел ярда сары күнле ияр бар.
Ат сыртыннан ашып үскән яшел тал,
Шул яшел таллар артында кемнәр бар?

— Эч, йолдыз кашка!
Чөмер-чөмер-чөмери!

Чылтыр-чылтыр җиз йөгәнме
челдери?
Йөгән тотып кемгә насыйп кыз тора?
Ат сискәнә, ат пошкыра, кемнәр бар?
Нинди егет тал артыннан сызгыра?

— Эч, йолдыз кашка!
Чөмер-чөмер-чөмери!

Чылтыр-чылтыр җиз йөгән шул
челдери,
Тал артыннан чая егет сызгыра.
Сискәнмә, ат, йөгән тотып янында
Шул егеткә насыйп булыр кыз тора.

— Эч, йолдыз кашка!
Чөмер-чөмер-чөмери!

Йөгән түгел, килер туйның
Кыңгыравы челдери...

## Болын

Монда, имеш, яулар җир селкеткән,
Юк ителгән, имеш, халыклар,
Җир астында калган иске нигез,
Талир тәңкә, көмеш савытлар...
Төкерми дә вакыт! — Юа, күмә —
Эзләп кара җилне даладан!
Безнең язмышларны сулар юган,
Туфрак күмгән, ялкын ялаган.
Шушы кырдан мәгърур ханнар үткән,
Кабиләләр үткән, күченеп,
Бүген анда «Алга» колхозының
Ат көтүе йөри чемченеп.
Сабан туйлар гөрелтесе сеңеп,
Бик тирәндә калган нигездә,
Алмачуар бия, койрык селкеп,
Тыныч кына колын имезә.
Вакыт күмгән, һаман күмә тора,
Ул куймаган әле көрәген.
...Нигезләрдә яткан авыр ташлар
Кысылгандай
кысыл, йөрәгем.
Бу төбәктә кайсы кабиләләр,
Нинди утлар ягып җылынган? —
Мин ял итәм —
яңа гасыр улы! —
Болонья плащым җәеп болынга...

## Кирәкми!

Елыйсың. Нигә еларга?
Елама, кирәк түгел!
Юкса бит ир егеттә дә
Шау тимер йөрәк түгел.
Беләм, әйе, ялгышканбыз —
Ак һәм кара буталган.
Безгә тиешле учактан
Чит кешеләр ут алган.
Назлар кире кайтсалар да,
Язлар кайтмас кабаттан.

Без гене́ме үз канатын
Давылларда канаткан?
Ялгышканда көлгәнбез бит,
Елмайганбыз бит әле!
Хәзер дә көлик, капланып,
Күз яшьләре үтәли...
Елыйсың... Нигә еларга?
Елама, кирәк түгел!
Миндә дә бит шау тимердән
Ясалган йөрәк түгел!

## Мәңгелек

Иңнәрендә уйный икән
һаман шул ук пар толым...
Шул ук оялчан елмаю...
Шул ук сәер тартыну...
һаман жырлар ярата сын,
Жырларын мина таныш,
Жырлаган саен аларга
Өстәлә бара сагыш.
Жырлама син ул жырларны,
Тын гына Ыкка кара,
Ык төбеннән, яшьлек сыман,
Болытлар агып бара.
Аяк астында болытлар —
Көзге Ык көзге сыман...
Болытларга тиеп булмый:
Яшьлектәй изге сыман!
Без дә шул болыт шикелле
Агабыз да агабыз,
Бер көн килгәч жир өстенә
Тамчы булып тамабыз.
Беребез тама гөлләргә,
Беребез тама ташка...
...Ак болытка әверелеп
Очабыз яңабаштан.
Бөтенесе кабатлана!
Кабаттан тетрәнерләр
Нәкъ синекедәй толымнар
Кемнендер иңнәрендә.
Аерылырбыз без галәмнең
Ниндидер почмагында —
Мин, бәлки, төтен булырмын
Кемнендер учагында...
Син сагышлы бер жыр булып
Жаннарга кагылганда,
Таратырлар мине жилләр,
Таң нуры кабынганда.
Учак янындагы егет
Сөйгәненә читкә сөйләр:
— Күзеңә төтен керә бит,
Күзләреңне йом, юләр!..

...Син исә читкә китмәссен,
Танырсың, бәлки, мине,
Әйтерсең:
— Ул бит шулкадәр
Мине яраткан иде...
...ул бит шулкадәр
...мине яраткан иде!
...Шул ук оялчан елмаю,
Шул ук сәер тартыну.
Иңнәреңдә уйный икән
Һаман шул ук пар толым.

## Мизгел

Йолдызлар...
Безнең учактан
Шаулап очкын бөркелеп
Күкнең зәңгәр гөмбәзенә
Ябышып калган кебек.
Шундый тынлык...
«Шылт!» — итсәң дә
Барысы җуелыр кебек,
Очкыннар, күктән ычкынып,
Җиргә коелыр кебек.

Яфракларга шыбыр-шыбыр
Коелыр сыман йолдыз —
Шуннан куркып бугай яфрак
Астына керде кондыз.
Көмеш дуга ясады да
Тукталып калды чуртан...
Шундый мизгел! Идел яры.
Учак яна. Учак бары...
Утын ташларга куркам.
Әй, җиһан...

## Синнән еракта...

*Хәрби дәфтәрдән*

Кай җиренә кагылсаң да,
Бу җан гел яра бугай.
Июньнең соңгы кояшы
Баеп та бара бугай...
Үләндәге тамчыларга
Кагылыр өчен мәллә
Каенның яшел чуклары
Җиргәчә иелгәннәр.

Ап-ак каен кәүсәсенә
Яшел куләгә төшкән.
Пар булып күтәрелимме
Каен шаулаган төштән?
Җемелдәшеп каеннарның
Чуклары арасыннан
Яңгыр тамчылары түгел —
Сагыну тама сыман...

## Таныш кышны сагыну

Урачәгә ауган көртләр булып
Күкелемә кергән бу урман.
Йолдыз сугыла карлы ябалдашка.
Эңгер-меңгер инде куерган.
Түштән карга бата җирән кашка.
— Әйдә, малкай, юлны карап бар!
...Юл бирәм дип гуя читкә чыгып,
Көрткә чумып кала наратлар.
Кичке буран сырындының чәчен
Җилфердәтә алан иңеннән.

Әй, илкәем... Серле юлларында
Бер юлаучың бит мин... юк, үлмәм!
Икеләтә мин сау-сәламәтмен,
Мин яшим тиң туган ягымда.
Эремичә һаман сакланырлар
Кар көртләрең кайнар җачымда!
Сикереп чыга таллар сырындыны
Ат артыннан ничек өлгерә?
Шук малайлар сыман үрәчәгә
Ябышырга теләп йөгерә...
Алдыр, малкай, алдыралмас булсаң,
Урман юлларында дулама!
Булгач булсын, җиз кыңгырау итеп
Бәйлик мәллә айны дугага?
Алдыр, әйдә! Әгәр сусап китсәң,
Авыл егетедәй зур имән
Чөңгерер дә су эчерер сиңа
Җидегән йолдыз чүмече белән.
Без юлларда җилдерербез әле
Җанда олы сөю тынганчы...
Төйик аны йөрәк чанасына
Бастырыклар шартлап сынганчы!

## Без генәме?

Без генәме шашып яратканбыз?
Безне дә бит шашып сөйделәр.
Җаннарга да сагыш кына түгел,
Күпме кирәк шатлык өйделәр.
Эт сикерә иде өскә һаулап
Капка ачып кергән һәр чакта —
Этен ала идек пычакка да,
Кызын ала идек кочакка.
Көз түгел бит, яшел тупылларны
Без саргайта идек аларны!
Толымнарга охшатып без иштек
Беләк юанлыгы талларны.
Сукмакларга инде яфрак яуды,
Тупыллар да ауды давылда.
Гармун бакасына ятлар баса,
Бүтән җырлар хәзер авылда...
Ача идек урыс капкаларны!
Ачылдылар алар, ачылды...
Толымнар да хәтта сүтелделәр,
Тәңкәләр дә хәтта чәчелде...
...Урыс капкаларны киереп ачып
Туйлар керде шушы өйләргә.
Безгә калды бары кызыгырга,
Безгә калды бары сөйләргә...
Хәзер исә без сөйлибез инде:
— Да! Безне бит шашып сөйделәр!
Кирәк чакта җаңга шатлык яуды...
Кирәк чакта сагыш өйделәр...
Онытылмас була белделәр...

# ҖӘВАД ТӘРҖЕМАНОВКА 50 ЯШЬ



Беренче китап — шау-шулы һәм бәхетле, моңлы һәм хәсрәтле, бик гади һәм серле зур тормышка алып киткән беренче юлдаш ул. Соңыннан бик күп китаплар укыла, шул китапларның геройлары белән бик күп йокысыз төннәр үткәрәсең, ләкин онытылмыйча, гомереңбуе синең белән яши торганнары алай күп булмый. Һәм менә шулар арасында, һичшиксез, бала чакта укыган беренче китап һәм аның геройлары да яши.

Соңгы елларда әдәбиятка килеп, инде үз сүзен ишеттергән, укучысын тапкан, исеме билгеле булган язучыларның бик күбесенең беренче китаплары «Күбәләк — җилбәзәк», «Койрык турында боерык», «Ачкыч һәм баскыч» шикелле китаплар булгандыр бәлки. Алардан элегрәк яза башлап, сугыштан соңгы елларда әдәбиятка килгән язучыларның да яраткан китаплары «Әни сүзе», «Судан табылган хат», «Кояшлы иртә» һ. б. лар иде.

Шулай итеп, Җәвад Тәрҗеманов берничә буын укучыга табигать, тормыш серләреннән беренче мәгълүматларга бай, уку өчен кызыклы китаплар биргән язучы. Аның 1938 елдан башлап соңгы көннәргә кадәр чыккан китаплары инде кырыктан артты. Күп кенә әсәрләре тәрҗемә ителеп, Мәскәү һәм Казан нәшриятларында рус телендә дә басылды. Ә Җәвадның үзенә бары тик илле генә яшь әле.

«Һәр язучы, бик еш кына үзенең ихтыярыннан тыш та, әсәрләрендә билгеле бер дәрәҗәдә үзен сурәтли», ди бөек немец язучысы В. Гете.

Чыннан да, менә ун еллар инде химия-технология институтында катлаулы машиналар турында студентларга лекцияләр укып, семинарлар үткәреп йөргән техник фәннәр кандидаты Җәвад үз иҗатында һаман бала күңелле саф, самими. Ул үзенең геройлары кебек җиңел сөякле, җитез, һәрвакыт шат күңелле, көләч. Кешеләрдә, табигатьтә бары тик балалар гына күрә белгән сыйфатларны табып, нәкъ аларча итеп әйтеп бирә.

Авыр жанрларның берсе — балалар әдәбиятында эшли башлаган Җәвад Тәрҗеманов соңгы елларда зурлар өчен дә язарга тотынды. Күп еллар буе фән өлкәсендә эшләү, бөек математик Н. И. Лобачевский тормышыннан бай материал туплау нәтиҗәсендә ул «Лобачевскийның яшьлеге» дигән романын бастыра. Хәзер шушы романның икенче кисәге булган «Көмеш дага» әсәрен тәмамлау алдында тора. (Без бу санда шул әсәрдән өзек бирәбез.) Шуннан соң автор «Солдат хатлары» дигән повесть өчен материал туплый, опера һәм балет театры өчен либретто язарга әзерләнә.

Казан шәһәренең 13 нче урта мәктәбендә Һади Такташ оештырган әдәбият түгәрәгендә катнашып, Фатих Кәрим, Абдулла Алишлардан беренче сабакларны алган Җәвад Тәрҗеманов үзенең илле еллыгын әнә шулай зур күләмле әсәрләр язып каршылый. Журналыбыз укучылары, каләмдәш дуслары аңар тагын да зур иҗат уңышлары һәм сәламәтлек телиләр.

# ЛОБАЧЕВСКИЙ
# ҺӘМ ХӘЛФИН



*(«Көмеш дага» исемле тарихи романнан өзек)*



1819 елнын җәй азагында такыр юлдан почта атларына утырып Лобачевский Казанга кайтып килә иде. Иске тарантас, тәгәрмәчләре сикәлтәгә эләккән саен, биле авырткан карт төсле, ыңгырашып куя. Атлар ялкау гына юырталар, каеш чыбыркы аларны куркытмый. Хәер, кучерның ара-тирә селтәнгәләп алуы да, аларны ашыктырудан бигрәк, сыртларына кунган бәйләнчек кигәвеннәрне куу өчен генә.

Лобачевский тарантасының япмасын төшерергә кушты. Көн эссе һәм юл ялыктыргыч булуга карамастан, аның кәефе яхшы күренә. Ул кымыздан кайтып килә. Оренбург далаларында кымыз эчеп, күкертле суларда коенып дәвалангач, аның сәламәтлеге әйбәтләнеп китте. Соңгы елда авыруы көчәеп, ул юньләп эшли дә алмаган иде, менә хәзер кайтып җитү белән яраткан эшенә тотынырга хыяллана.

Олы юл иксез-чиксез басуларны икегә ярып бара. Бу ел бик уңдырышлы булды: кая карама еш-еш тезелгән чүмәләләр. Олы юлның ике ягыннан да көлтә төялгән олаулар агыла, олау башында кайтучы яшүсмерләрнең шатлыклы җырлары еракларга тарала. Анда-санда урылып бетмәгән җирләр һәм ай-уракларын җитез йөртүче ак яулыклы хатын-кызлар күренгәли.

Тарантасның җиңелчә генә чайкалып баруы, авыр йөк төялгән арбаларның тәгәрмәчләре шыгырдавы, эссе кояш нурында чикерткәләр чыңлавы, еракган ишетелгән җыр авазларына кушылып, юлчыны хезмәтнең авырлыгын онытырга мәҗбүр итә, табигатьнең юмартлыгына һәм байлыгына сокландыра, күңелендә ләззәтләнү тойгысы уята...

Лобачевский көтмәгәндә генә яттан шигырь укып җибәрде:

Ләззәт өсти табигатьнең чагылышы,
Янгырый кош-кортның шат тавышы!
Мул уңышны безгә көз китерә,
Патшага да, бөҗәккә дә ризык бирә...

Кузлада утырган егерме яшьләр тирәсендәге егет җәһәт кенә аңа табан борылды.

— Нишләвең бу? — диде аңа Лобачевский, гаҗәпләнеп.

— Кызык кеше сез, барин,— дип җавап кайтарды кучер һәм, үз тавышына үзе колак салган сыман, акрын гына шигырьдәге сүзләрне кабатлады:— патшага да, бөҗәккә дә...

— Якташыбыз Державин шулай язган,— диде Лобачевский, бераз җанлана төшеп.— Акыллы егет син, Иван. Яхшы белән яманны аера беләсең. Һәр кешедә булмый ул андый сыйфат. Син менә томана галимнәрне генә алып кара. Алар мондый шигырьнең кыйммәтен күрә белмиләр. Ә син һәммәсенә игътибар итәсең, шуңлыктан синең белән сөйләшүе күңелле. Болай бит ул, Иван: син дә, кош та, патша да, шулай ук бөҗәк тә — һәммәсе дә күзгә күренми торган материядән хасил булган. Шагыйрь һәм философ Лукреций борын заманда ук шулай дип өйрәткән.— Лобачевский алга табан иелде һәм, дәртләнеп, яттан сөйләргә кереште:

...әйберләрнең нидән торуын күрмәгәч,
Минем сүзгә ышанмыйча карама син.
Без күрмәгән җисемнәрнең барлыгына
Күнәрсең син, минем сүзне тыңлагачтын,
...каян нинди ис килгәнне күрмәсәк тә,
Ис тоя бит һәрчак безнең борыныбыз.
Эссе белән салкынны да күрәлмибез,
Тавышны да шулай ук без тоталмыйбыз.
Ләкин болар һәммәсе дә матди нәрсә:
Әгәр алар чынбарлыкта булмасалар
(Сизү-сизелү фәкать матди җисемгә хас),
Хәрәкәткә килмәс иде бу әгъзалар.
Дым саркыта киемебезгә диңгез буе,
Киптерә аны, өстә килеш, кояшлы көн;
Тик без дымны һичбер вакыт күрәлмибез,
Эссе чакта кояш нурын күрмәгән күк.
Димәктер ки, су бөртеге нык ваклана,
Шуңа аны безнең күзләр күрә алмый...

Лобачевский яңадан, иплән, арка терәп утырды.

— Шагыйрьнең шулай тирән мәгънәле әйтүе искиткеч түгелмени, ә бит ул моннан бик күп заманнар элек, Гайсә пәйгамбәр туганчы ук яшәгән!

— Гайсә пәйгамбәр туганчы?!.— дип кабатлады кучер, гаҗәпләнеп.— Барын да аңлап бетермәсәм дә, бик шома язылган шул. Тыңлавы күңелле!

Николай Иванович елмаеп куйды, ләкин латинчадан рус теленә үзе тәрҗемә итүен әйтмәде. Берникадәр вакыт шулай онытылып уйлап утырганнан соң, ул яңадан дәртләнеп сүзгә кереште:

— Гаҗәеп нәрсәләр күп ул дөньяда, Иван. Кымызда туйганчы укыдым, хәзер гел сөйлисе генә килеп тора. Әле хәзергә кадәр кешенең табигатькә булган мөнәсәбәтен һәм табигатьтә тоткан урынын яхшылап белмиләр. Материянең килеп чыгуын да аңлатучы юк...

Лобачевский кинәт сүздән туктап, ерактан ишетелгән авазларга колак салды.

— Дөньядагы барлык әйберне без табигать дип атарга тиешбез,— диде Лобачевский, сүзен дәвам итеп.— Табигатьта иң камил, иң җитлеккән җан иясе — кеше. Аны табигать үзе тудырган. Минемчә, табигатьнең серләрен ачуда Гайсәнең ике тиенлек тә файдасы тимәячәк. Бу өлкәдә бердәнбер көч — кеше үзе. Табигатьне өйрәнергә, аның серләренә төшенергә фәкать кеше генә сәләтле. Әйтик, менә мин акылым белән, зиһенем белән бөтен галәмне, очсыз-кырыйсыз күк киңлеген, еракларда чекрәеп карап торган йолдызларны кочарга телим...

Дилбегәнең бушап калганын тоеп, атлар адымнарын акрынайтканнан-акрынайта барып, бөтенләй туктар хәлгә җиттеләр.

Кучерның исә, тыңлый торгач, маңгаена тир бәреп чыкты. Ниһаять, ул авыр итеп көрсенеп куйды:

— Гафу итегез, барин, без бит надан халык, андый эшләр безгә караңгы, аны ходай үзе генә белә,— диде, чукынып алды һәм, атларына карап утырып, дилбегәне тартты да чөңгереп куйды.

Лобачевский, үзенең уйларына бирелеп, дәшми генә барды. Онытылып киткәнгә, ул инде хәзер тирә-ягындагы матурлыкны да күрми иде.

Ә юл чаба да чаба; әле шактый вакыт бормаланып бара, әле ук шикелле алга сузыла. Урылган басулар һәм эскертләр инде ерактa калды, аларны таулар һәм урманнар алмаштырды.

Көтмәгәндә кояшның кызуы кимеп, салкынча җил исә башлады. Күк йөзен болыт каплады. Еракта коеп яңгыр яуганы күренде.

Лобачевский тарантасның япмасын күтәрергә кушмакчы гына булган иде, болытлар, кинәт куерган кебек, кинәт кенә тарала да башлады, һәм алда салават күпере, аллы-яшелле матур тасма булып, күк белән җирне тоташтырды. Бу хәл Николай Ивановичның башында яңа

фикерләр уятты. Державинның «Салават күпере» шигырендәге сүзләрне хәтерләтте:

Карангыга нур сип...

Матур әйтелгән. Лобачевский бу сүзләрне күңеленнән сокланып кабатлый, тик ул моның белән тулысынча килешә генә алмый: салават күпере кыска гына вакыт эчендә балкып ала да эзсез югала. Кеше исә гомер буена халык бәхете өчен яшәргә тиеш. Әйе, әйе! Коры сүз генә түгел бу. Әнә кырмыскалар белән бал кортларын алып кара. Алар һәммәсе бергә яшиләр, тырыш хезмәтләре белән үзләре яшәгән ояга өлеш кертәләр. Әгәр шуларның берсен генә аерып алсаң, ул җан иясенең көче беткән шикелле тоела, кызганыч булып кала. Ә менә үзе кебекләр белән бергә, зур бердәм гаиләдә яшәгән вакытта безне таң калдыра... Кешеләрдә берләшү теләге кайчан туар икән? Алар кайчан, бал кортлары һәм кырмыскалар кебек, үзара органик бәйләнешкә керерләр икән?.. Мин ышанам: киләчәктә шулай булыр. Кешелек дөньясының киләчәге якты һәм гүзәл. Моңа ирешү өчен фән гаҗәеп зур өлеш кертәчәк. Ләкин фәннең колачы киңәергә, санаулы галимнәр даирәсеннән чыгып, җәмгыятьнең барлык катлауларын да үз эченә алырга тиеш. Фәннең изге максаты кешелек дөньясын камилләштерү, табигатьнең хуҗасы булу өчен һәркемгә шартлар тудыру бит. Ул, Лобачевский, әнә шундый фәнне иҗат итәчәк. Һәркем белемле булгач, галәмнең асылына төшенү дә җиңеләләшер...

Николай Иванович тирән итеп сулу алды. Аның уйлары, юл шикелле үк, туктый белмичә, алга йөгерә. Тик кайбер вакыт, сикәлтәгә эләккән тәгәрмәч кебек, бер урында әйләнеп торгандай була да тагын алга омтыла.

...Әйе шул, математика фәненең бүгенге казанышлары кеше акылының шундый зур хакыйкатьне аңлый алуы турында сөйли. Математика белемгә турыдан-туры юл ачты. Геометрия нигезләрен үзгәртеп кору зарурлыгы да фәннең тәүге төшенчәләренә ачыклык кертү максатыннан килеп чыкты. Ләкин...

Тройка кинәт юлдан читкә борылып туктагач, Николай Ивановичның уйлары бүленеп калды. Ул күзен ачты. Каршыларына ат менгән ирләр һәм хатын-кызлар килә иде. Бу якларда яшәүче дворяннар кәеф-сафа кылып йөриләр, күрәсең. Шул тирәдә утарлары бардыр. Карадан киенгән зифа амазонкаларның иярдә шундый оста утыруларына Лобачевский сокланып карап торды. Әнә бер унҗиде яшьләрдәге кыз, көләкөлә, үзе белән янәшә барган ханымга нәрсәдер сөйли. Үзенә текәп караганны тоеп, ул тиз генә башын борып, юл читендәге тарантастагы кешегә елмаюлы карап ташлады һәм юлдашына таба борылды. Әдәпсезлек күрсәтүеннән оялып, Николай Иванович та башын түбән иде. Ә кыз аның ягына тагын бер күз сирпеп алды, тик шунда ук тезгенен тартып, тарантас яныннан атын чаптырып үтеп тә китте. Мөгаен, теге ханым берәр сүз әйткәндер инде. Җил хушбуй исе китергәч, Лобачевский авыр сулап куйды.

Кучер исә, чыбыркысын һавада болгап:

— На-а, карлыгачлар! — дип кычкырды да атларын юлга чыгарды.

Николай Иванович, битен сөртергә теләп, венгерка кесәсеннән дүрткә бөкләнгән ефәк кулъяулыгын алды. Тыныч кына елмаеп куйды: кулъяулыкның бер читенә матур хәрефләр белән «Lise» дип кызның исеме чигелгән иде.

— Manu propria [1],— диде Николай Иванович үз алдына.— Лиза... Аның төсе...

---

[1] Үз кулы белән (лат.)

Гүя Лобачевский уяу көе төш күрә иде, аның фикерләре кирегә, үткәнгә — Оренбург даласына, күкертле суга әйләнеп кайтты. Әле генә ат өстендә елмаеп очып узган амазонка шикелле үк зифа буйлы, матур кыз. Елмаюы шундый мөлаем, ә күзләре зәп-зәңгәр. Лизаның әнисе ревматизмнан дәвалана — күкертле ванналарда коена. Бәхетле минутлар бик тә кыска тоела, һәм Николай Ивановичның китәр көне дә якынлаша. Алар террасада соңгы тапкыр очрашалар. Егет беренче мәртәбә кыюлык күрсәтеп, кызның кулын тота. Гәрчә бармаклары калтырап куйса да, кыз кулын тартып алмый.

— Монда үткәргән көннәрне сез искә төшерерсезме соң? — ди егет акрын гына.

Лиза җавапны шактый көттереп бирә.

— Сезгә нигә ул? — ди, күтәрелеп карарга да кыймыйча.— Сез бит минем белән һәрвакыт фән турында гына сөйләштегез... Башка нәрсә кызыктырмый да, күрәсең...

— Миңа моны бер мәртәбә әйткәннәр иде инде,— дип куя Лобачевский сузып кына.— Хәер, ул чакта мин гашыйк та булган идем шикелле... Кыз гына тик... Әллә инде әти-әниләре каршы торганга шулай килеп чыкты...

Лиза акрын гына кулын тарта башлый, Николайның шунда җибәрмәскә батырлыгы җитми.

— Искә төшерүе авырмыни?! — дип сорап куя кыз.

— Авыр да кебек, түгел дә кебек,— ди Лобачевский уйчан гына.— Без бит бер-беребезне бик аз белә идек. Ихтимал, безнең мәхәббәт дигәнебез фәкать хыял гына булгандыр. Дворян нәселеннән килсәм, һич югы, бай булсам, өйләнә алыр идем. Тик миндә аларның берсе дә юк иде. Ә аның гыйшкы артык кыска гомерле булып чыкты.

Лиза эндәшми, кулын күкрәгенә, косынка эченә яшерә. Болай иткәндә аның кыяфәте бигрәк тә мөлаем күренә. Лобачевский терраса буйлап йөренә башлый.

— Кыска гомерле булды шул,— дип кабатлый ул кискен итеп.— Димәк, ялгышканмын. Җәзасын үзем күрдем. Байлык эстәү, шөһрәткә һәм чингә омтылу... Болар берсе дә минем өчен түгел. Минем үз омтылышым, үз максатым бар, һәм шул миңа ләззәт бирә. Миңа булган мәхәббәт максат юлымда тоткарлык ясамасын, киресенчә, алга этәргеч бирсен иде!

— Ә мин...— дип башлый кыз һәм шунда ук тынып кала.

Николай Иванович, йөрүдән туктап, аңа текәлә. Кызның йөзе ап-ак. Егылып китүдән курыккан сыман, терраса култыксасына тотынган. «Ярата, күрәсең... Ничек ярата икән соң? Анна шикелле генә булса...»

— Мадемуазель Лиза, кичә сез maman'ыгыз әйткәнне ишеттегезме? Профессормы ул, түгелме, разночинец кына булмасын, дип әйткәндә, кемне күздә тотты икән?..

Лобачевскийның тавышы рәхимсез яңгырый. Ләкин аның горурлыгы кызга кимсетү сүзләре әйтергә ирек бирми. Димәк, шушы минутта ул бәхетле гаилә кору турындагы хыялы белән икенче мәртәбә хушлаша. Димәк, барып чыкмады... Өмете өзелде... Лизаның күтәрелеп карарга да куркып, эндәшми торуы, косынка почмагын бер бөтереп, бер сүтеп торган житез бармаклары нәкъ шул турыда сөйли...

Тарантасның сул тәгәрмәче шактый тирән чокырга эләгеп, Лобачевский чак кына егылып төшми калды. Ул, кинәт йокыдан уянган кеше төсле, як-ягына каранды һәм, бераз тынычлангач, француз хушбуе исе килгән кулъяулыкны тагын бер кабат битенә китерде, шуннан соң гына саклык белән венгерка кесәсенә салып куйды. Терраса култыксасына аның өчен куеп калдырганмы ул кулъяулыгын, юкмы — белеп булмый.

— Разночинец...— дип үз алдына кабатлады Лобачевский, мыскыллы елмаеп.

— Нәрсә, барин? — диде кучер һәм ана борылып карады. Бер кулында ситсы янчык, икенчесендә яна төреп бетергән тәмәке.— Барин, безнең тәмәкедән җирәнмәссезме? Тартып карыйсызмы әллә?

Лобачевский башта аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңламады һәм кырыс итеп:

— Нәрсә? — дип сорады, тик Иванның коты алынып, янчыгын тизрәк яшерүен күргәч, көлемсерәп куйды:— Җирәнүен җирәнмим дә бит, Иван, тартмыйм шул мин. Сиңа да ташларга кирәк. Зарардан башка аның бер нәрсәсе юк бит.

— Юк шул,— дип җавап кайтарды кучер, җанланып китеп. Янчыгын ул куенына яшерде.— Тормыш басканнан гына тартыла. Бер төреп тартасың да, җиңеләеп киткән төсле тоела.

Николай Иванович авыр истәлекләрдән арынырга теләп кайта иде инде. Юк кына сөйләшү дә аның күңелен тынычландырды. Бәлки, ул әйләнә-тирәсенә бөтенләй күз салмыйча ялгыш эшлидер? Бәлки, фәлсәфәгә бирелмичә, кешенең эчке кичерешләрен аңларга тырышып карарга кирәктер? Әйтик, менә карап торышка гап-гади бу егетнең тавышында ара-тирә яңгырап киткән ачу каян килә, сәбәбе нәрсә? Тормыш аны кайчан рәнҗеткән?

Кучер үзе дә күңелен бушатуга каршы килмәде, һәммәсен сөйләп бирде. Аның атасы Оренбургта вак сәүдәгәр булган, кибет тоткан. Беркатлылыгы, тиз ышанучанлыгы аркасында ростовщик моны кәкре каенга терәткән. Кибетләрен тартып алганнар, гаиләләрен урамга куып чыгарганнар. Ата кеше возчик булып эшкә ялланган. Тик шундый зур фаҗигадән соң озак яши алмаган, вафат булган. Атасы урынына олы улы калган һәм шуннан бирле алты җанны туйдырып килә икән...

Аларның сүзләре киселеп калды. Юл читеннән тезелешеп атлап барган хатыннар күренде. Һәрберсенең башында ак яулык, аркасында капчык, капчык бавына өр-яңа чабата асылган, ә үзләре ялан аяк. Тарантас куып җиткәч, алар туктап баш иделәр һәм шуннан соң юлларын дәвам иттеләр.

Лобачевский кучерга атлатып кына барырга кушты һәм таякка таянып, бик читенлек белән атлап барган карчыктан:

— Кайларга юл тотасыз? Кайсы яктан киләсез? — дип сорады.

— Глуховканыкылар без,— диде карчык, авыр итеп тын алып һәм башындагы яулык почмагы белән битләрен сөрткәләп.— Казанга гыйбадәт кылырга баруыбыз.

— Кайгы дигәнен нишләтми кешене! — дип, кучер уфтанып башын чайкап куйды.— Мондый эсседә әлсерәп барырлык булгач, язмыштан инде ул, язмыштан,— диде һәм хатыннарга карап:— Алла ярдәм бирсен! — дип кычкырды. Аннары чыбыркысын болгап алды, өшәнгән атлар теләр-теләмәс кенә адымнарын кызулаттылар.

Шулай итеп, хатыннарны узып киттеләр, кучер белән дә сүз ялганмады. Ләкин болай сөйләшми генә артык озак барырга туры килмәде, Лобачевскийның игътибарын икенче бер нәрсә тартты. Казан ягыннан житәкләшеп килүче ялан аяклы кыз һәм чал чәчле карт күренде. Картның озын гәүдәсе ябыклыктан тагын да озынрак, килбәтсезрәк булып күренә, ә башы, нечкә муены тотып тора алмагандай, бер якка салынган. Ул аякларын көчкә өстерәп килә һәм, кыз булмаса, егылып китәр иде сыман.

Лобачевский атларны туктатырга кушты да тарантастан сикереп төште.

— Бабакай, исәнме! Кайсы яклардан? — диде.

— Ерактан без, барин...— диде карт, сулышы буылып.— Алтмыш чакрым кайтасы әле... Хәлсезлек йөдәтә...

— Авырыйсыңмы әллә? — дип кайгыртучанлык күрсәтте Лобачевский.

— Күкрәк бетте,— диде карт һәм сөякчел бармаклары белән күкрәген тотты.— Сызлый да тора... атларга һич ирек бирми... Дүртенче ай инде җәфа чигәм...

— Нәрсә булды? Салкын тидердеңме әллә?

Карт башын чайкады.

— Юк, барин. Мич чыгару минем һөнәр... Авылыбызда чиркәү салдылар... Юеш чакка туры килдем, яз көненә... Аяк таеп китте дә... түбәдән бүрәнә өстенә күкрәк белән... килеп тә төштем.

— Кайгы дигәнең агач башыннан йөрми шул,— диде кучер, йөрәге әрнеп.— Шул чагында ук шәһәргә килеп табибка күренәсең калган.

— Килдем, килдем... Теге ниегездә булдым... Кара инде хәтердән чыккан.

— Университеттамы? — диде Лобачевский.

— Шунда булдым, барин, әле шуннан кайтып килүем...— диде карт, уфтанып.— Больницына салмадылар, урын юк, имеш...

— Көтәсең калган урын бушаганны,— диде кучер.

— Көтәргә иде үземнең дә исәп, тиз генә бушамас, дип куркыттылар... Ашамый торып булмый бит... Авылга кайтып китәргә ниятләдек.

Лобачевский сораштыруын дәвам итте:

— Улың-кызың юкмы соң анда?

— Бар иде, улым бар иде... Менә бу баланың атасы,— диде карт, башы белән кызга ымлап.

Шунда гына Лобачевский кыз ягына текәп карады. Унике-унөч яшьләрендә, киләчәктә зифа буйлы кыз булырга чамалый. Алтын чәчле, күк күзле, төскә-биткә дә матур гына. Ә өстендә ямаулы киндер күлмәк. «Гади халыкны килбәтсез була дип, кимсетеп карау бер дә килешми,— дигән фикер килде Лобачевскийның башына.— Чибәрлек ягыннан бая ат өстендә үтеп киткән бай кызыннан яки Лизадан киммени? Дөрес тәрбия биреп, киендереп җибәрсәң, дөньяда иң матур кыз булыр иде. Тик аны тиздән тормыш авырлыгы басачак, матурлыгын юкка чыгарачак, изәчәк...»

— Улым күптән җан тәслим кылган, ахры,— диде карт, авыр итеп тын ала-ала:— Француз сугышына киткәннән бирле хаты-хәбәре юк... Килен дә үлеп китте... Йорт-җиребез генә дә калмады...

— Хәзер кайда яшәп ятасыз соң?

— Күршедә, өйдәш булдык... Көчем бар чакта кулдан килгәнне эшли торган идем, хәзер... анысы да... Фәкыйрь кешеләр алар, бик фәкыйрь... Каткан ипи дә сирәк эләгә... Бар икән күрәселәребез... Ходай шулай кушкандыр инде, ходайга каршы барып булмый...

— Бабай, без болай итик: хәзер сез икегез дә тарантаска утырыгыз да мин сезне университет больницасына алып кайтыйм,— диде Лобачевский, дәртләнеп.

— Рәхмәт төшсен, барин... Шундый зур изгелек...— дип сөйләнде карт, нәрсә эшләргә дә белмичә, тик Лобачевский аңа озак уйларга юл калдырмады:

— Нәрсә инде катып калдыгыз? Кичкә чаклы кайтып җитәргә кирәк. Тизрәк утырыгыз.

Карт белән кыз бер-берсенә карашып алдылар, тик урыннарыннан кузгалмадылар. Шунда карт билгеле бер карарга килеп, башын селкеп сөйләргә кереште:

— Рәхмәт төшсен, барин, бик зур рәхмәт... Бармыйк инде без...

Тынлык урнашты. Лобачевский, тәкъдимен кабул итмәүгә сәерсенеп:

— Ни өчен бармыйсыз? — диде һәм кызга мөрәҗәгать итте:— Чибәркәй, бәлки син әйтерсең? Исемең ничек синең? — Ул кызның башыннан сыйпады.

— Маша,— диде кыз һәм аңа күтәрелеп карады. Бит алмаларын алсуландырып, бу чит кешене ничектер үз итеп, аңлатырга кереште: —

Бармыйк инде... Бабай белән безнең анда котны алдылар, сезнең шәһәрдә.

— Берәр төрле куркыныч нәрсә күрдегезме?

— Больница янындагы олы урамда ул халык җыелды, халык! Бер баштан икенче башка чабыпмы чабалар. Татарлар үкереп-үкереп елый, городовойлар җикеренә...

Кыз битенә төшкән чәчен артка ташлады һәм сүзен дәвам итте:

— Ул халык! Ул халык — олы урамны шыгрым тутырганнар...

— Биш табут куйганнар,— дип эләктереп алды карт.— Ә табутларында мәет түгел... башка нәрсә ята, ди...

— Юкны сөйләмә әле, картлач,— диде Лобачевский, тавышын күтәреп.— Юньләбрәк әйт, нәрсә күмәләр, кемне күмәләр?

— Алла үзе генә белә инде анысын... Ачуланма, зинһар, барин, белеп житкермәдем шул... ләгънәт төшкерләре, городовойлар куып җибәрде... Кешедән ишеткәнне генә сөйлибез... Башка вакыт барырбыз инде... Рәхмәт, барин.

Лобачевский бераз уйланып торды һәм кучерына таба борылып:

— Иван, ку әйдә атларыңны! — диде һәм, нәрсәдер исенә төшеп, кузгалмый торырга ишарәләде.— Күпме акчаң бар, миңа биреп тор әле, Казанга кайткач түләрмен.

Кучер аңа гаҗәпсенеп карап куйды, тик шунда ук куеныннан киндер янчык тартып чыгарды, каударлана-каударлана бавын чиште һәм, андагы вак акчаны учына бушатып, ашыкмыйча гына, ипләп кенә санарга тотынды.

Лобачевский түземсезлек белән аның санап бетергәнен көтте. Аннары ул, акчаны алып, шуның янына үз янчыгыннан да бушатты һәм барын бергә картка сузды.

— Мә, дәваланырга ярар,— диде Николай Иванович ягымлы тавыш белән.— Ал, ал!.. Ә син, чибәркәй, бабаңны университетка алып барырсың. Туп-туры миңа килегез...— Ул кесәсеннән куен дәфтәре чыгарып, шуңа берничә сүз язды һәм кызга шул язуны тоттырды.— Менә бу язу мине табарга ярдәм итәр. Килерсезме?

— Килербез,— диде кыз акрын гына тавыш белән һәм елмаеп куйды. Шул вакыт аның бабасы, ничек итеп рәхмәт әйтергә белмәгәч, Лобачевскийның алдына тезләнде. Кыз да аныңча эшләде.

— Барин... галиҗәнап... мәрхәмәт иясе! — дип күз яшьләре белән көйләргә тотынды карт.— Сезне ходай тәгалә үзе юлыктырган инде!..

— Торыгыз хәзер үк, торыгыз! — диде Лобачевский, аңа торырга булышып.— Кирәкмәгәнне эшлисез...

Бер минуттан ул инде тарантасына менеп утырды.

— Сау бул, бабай! Хуш, чибәркәй! — дип, утырган килеш, саубуллашты һәм кузгалырга кушты. Аның йөзендә яңа борчылу, яңа хафалану чалынган төсле тоелды.

— На-а, карлыгачлар! — дип, кучер оста гына итеп чыбыркы белән берне төшереп тә алды.— Мәрхәмәт иясен алып кайтасыз, тизрәк кыймылдагыз!

Арыган атлар аңа карап кына юыртырга ашыкмадылар. Казан янындагы соңгы үргә менеп җиткәнче, кучерга әле шактый еш чыбыркысын уйнатырга туры килде.

Үр сыртында Лобачевский тарантаска торып басты. Аның күз алдында, иксез-чиксез булып, тал куаклыгы һәм вак каенлыклар каплаган яшел үзән җәелеп ята. Аргы, урта һәм бирге Кабан күлләре — гүя үзара тасмалар белән тоташтырылган көзгеләр. Бирге Кабанның бер ягында Архангельский һәм Суконный бистәләре, икенче ягында исә — Яңа бистә, бик зур сабын заводы. Мәчет айлары һәм чиркәү тәреләре кояшта җемелди.

— Иван, чак кына туктап тор,— дип, Лобачевский тарантастан барган килеш сикереп төште.— Күр, нинди матурлык! Шәһәребез чыннан да түбән җиргә утырган шул. Казан димәсәң Казан...

Кинәт Воскресенский монастырьда чаң суктылар, һәм Казан өстенә моңлы гүләү таралды. Бу тавышка ияреп Спасо-Преображенский, Ивановский, Богородицкий монастырьларның бакыр батырлары тавыш бирде, кафедраль соборның һәм барлык чиркәүләрнең чаңнары кушылды. Чаң тавышлары бөтен күк йөзен каплап алды һәм куркынып һавага күтәрелгән чәүкә тавышларын күмеп китте.

— Аллага шөкер, кайтып җиттек,— диде кучер һәм, башыннан картузын салып, киң колач белән чукынып алды.

Кинәт Воскресенский монастырьның капкасы ике якка ачылып китте, һәм аннан алтынланган авыр карета килеп чыкты. Алты ат җигелгән, алтысы да кара туры, симез атлар, капкадан чыгуга, биегән төсле җиңел генә юыртып киттеләр. Биек кузлада немец кафтаны һәм өчпочмаклы эшләпә киеп кукыраеп утырган кучерга озын саплы чыбыркысын баш өстендә болгарга да туры килмәде. Карета алдыннан тантаналы кыяфәт белән яшел япанча кигән, атка атланган ике ир бара. Берсе зур саклык белән генә архиепископның мантиясен, икенчесе таягын тоткан иде.

«Архиепископ Амвросий гыйбадәт кылдырырга китте»,— дип уйлап алды Лобачевский һәм шунда ук университеттагы серле күмүне хәтерләде. Башта ул андый хәбәргә ышанмаган иде. Менә хәзер бөтен шәһәр чиркәүләрендә чаң сукканын үз колагы белән ишеткәч һәм архиепископның каретасын үз күзе белән күргәч, шикләнә калды. Бу чаклы тантана белән кемне күмәләр икән?

Лобачевский тиз генә тарантасына сикереп менеп утырды да кучерга боерык бирде:

— Ку әйдә, Иван!

Дугадагы шөлдер тоныкк кына чыңлап куйды, атлар тиздән ялга туктаячакларын сизделәр, күрәсең, шактый җитез юырта башладылар. Менә Оренбург тракты Егорьевский урамга әйләнде, һәм алар шәһәрнең үзәгенә якынлаштылар. Тәбәнәк агач өйләр өстеннән сукно фабрикасының таш бинапары калкып күренде. Кызыл кирпеч диварлары һәм тимер рәшәткә куелган тәрәзәләре белән ул бинапар төрмәгә охшап, анда эшләүче крепостнойларның авыр шартларда яшәвен һәрвакыт хәтергә төшереп тора иде.

Лобачевский кучерын ничек кенә ашыктырмасын, урам буйлап агылучы экипажлар һәм җәяүле халык алга чыгарга мөмкинлек бирмәде, башкалар белән бергә барырга мәҗбүр итте. Шәһәрнең үзәгенә бистәләрдән һәм якын тирәдәге авыллардан халык агыла. Монда руслар һәм татарлар да, ирләр һәм хатыннар да, шулай ук кызык күрергә яратучы бала-чага да бар. Зур магазиннар, кечкенә кибетләр һәм кабакларның берсе дә сәүдә итми, һәммәсе бикле. Төрле телдәге сөйләшүләргә караганда халыкның нәрсәгәдер бик нык дулкынланганын аңларга мөмкин иде, тик моның сәбәбе Лобачевскийга һаман әле сер булып кала бирде.

Кара болытлар кояшны томалап, шәһәр өстенә гүя кара япан бөркәделәр.

Үзәккә якынлашкан саен, халык арта, урамнар тыгызлана барды. Болакның Кабанга кушылган җирендәге Татар күпере ягыннан, сабан туена ашыккан сыман, төркем-төркем булып һөнәрчеләр, шәкертләр, Печән базары әһелләре килгәне күренде. Ак мәчетнең манарасыннан азан әйткән ишетелде.

Университет алдындагы мәйданны солдатлар уратып алган, тройка үтәрлек түгел иде. Моны күреп, тәмам түземе беткән Лобачевский тарантасыннан төште һәм халык арасыннан дини җыр ишетелгән якка үтте. Университет ишек алдыннан табутлар күтәреп ашыкмыйча гына

урамга чыгып килгән мәет күмүчеләр күренде, чиркәү хорының җыры әрмачык булып ишетелде. Иң алдан өерләре белән руханилар атлый. Алар артыннан ак коленкор ябылган, кәрән тәстәге биш табут килә...

Ни өчен веноклар юк икән? Венок тасмаларыннан укып бу серле табутларда кемнәрнең мәетләре ятканны белергә мөмкин булыр иде...

Табутлар артыннан кемнәр килгәнне яхшырак күрергә теләп, Николай Иванович алгарак чыкты. Беренче булып университетның яңа ректоры профессор Солнцев һәм аның белән янәшә кырыс кыяфәтле чит бер әфәнде — зур түрә килә, алардан соң, бераз ара калдырып, укытучылар, студентлар, гимназистлар һәм күренекле шәһәр кешеләре атлый. Гади халык исә аларга юл бирү өчен өй тирәләренә сыенган. Мәет күмүчеләр Арча кырындагы рус зиратына таба юл алдылар. Күңелсез тынлыкны фәкать чиркәү хоры һәм чаң тавышлары гына боза иде...

— Нинди нәрсә булды әле бу? — дип, Лобачевский үз алдына сөйләнеп куйды һәм шул вакыт якында гына кемнеңдер:

— Николай Иванович! — дип эндәшкәнен ишетте.

Лобачевский борылып карарга өлгермәде, кемдер аны беләгеннән кысып тотты.

— Әйдәгез, бераз читкәрәк,— диде.

Шатлыгыннан Лобачевский чак кына кычкырып җибәрмәде: култыклап алган кеше аны гимназиядә укыткан, хәзер исә университетта татар теле буенча адъюнкт дәрәҗәсенә күтәрелгән Ибраһим Хәлфин иде.

— Читкә чыгыйк,— дип кабатлады Хәлфин һәм Лобачевскийны бер читкә тартты.

Ибраһим Хәлфин һәрвакыттагыча ыспай киенгән, өстендәге соры костюмы һәм җәйге эшләпәсе аны яшәртеп күрсәтә, ләкин бүген аның бик нык кәефе киткән иде.

— Ибраһим Исхакович, нәрсә булды соң? Кемнәрне күмәләр?

Җавап урынына башта Хәлфин күңелсез итеп көлемсерәп куйды, аннары һәр сүзенә басым ясап:

— Скелетларны күмәләр,— диде.— Анатомия кабинетыннан, скелет заводыннан җыя торгач әнә, күрәсез, биш табутны тутырганнар, ниһаять.

— Скелет күмәләр?! — диде Лобачевский, гаҗәпләнеп.— Шаяртасыз, ахры.

— Артык шауламагыз,— дип кисәтте аны Хәлфин һәм аңлатырга кереште:— Казан уку-укыту округының яңа попечителе Михаил Леонтьевич Магницкий галиҗәнаплары боерыгы буенча күмәләр. Быел яз көне ул безнең университетны карап йөргәндә сез авырый идегез шикелле. Шул вакытны ул: «Ходай тәгалә үз кыяфәтенә охшатып яраткан кешене анатомик препарат сыйфатында кулланып бәддога алырсыз»,— дигән иде. Бүген менә шул боерыкны үтәү йөзеннән моңа кадәр студентларга фән өйрәнү өчен хезмәт иткән сөякләрне гүргә күмәргә булдылар.

— Солнцев нәрсә карый соң, Солнцев? Ни өчен ул аларны саклап калмаган? Ректор кешегә каршы торырга кирәк иде!

Хәлфин тагын мәсхәрәле көлемсерәде, тик инде Лобачевскийның йөзендә ризасызлык күреп, ягымлы итеп иңбашыннан алды.

— Николай Иванович, тынычланыгыз. Хәзер безнең университетның баш начальнигы директор дип атала һәм бу яңа вазифаны Александр Павлович Владимирский галиҗәнаплары...

— Бу хурлыклы процессиянең башында баручы теге эре кыяфәтле бәндәме?

Хәлфин аңа җавап бирергә өлгермәде, алар янында татарча:

— Балам җаным!.. Улымны бирегез!..— дип ялварып кычкырган тавыш ишетелде.

Бөкресе чыгып, җиргә чүккән бер мескен карчык, солдатлар арасыннан үтеп, табутларга якынлашмакчы булды. Аның җыерчык баскан

йөзе, сәләмә киеме, кайгыдан өзгәләнүе хәтта солдатларның да йөрәгенә мәрхәмәт сулышы өрде, күрәсең: алар аны үткәрмиләр, шулай да карчыкка сак мөгамәлә күрсәтәләр. Ләкин мескен карчыкның аларда эше юк, ул әледән-әле солдатлар өстенә җилеп килә, үзе һаман җан ачысы белән бер үк сүзләрне кабатлый:

— Балам... Балакаем...

Лобачевский шул тирәдәге чалмалы кешедән татарчалатып:

— Ни булды? — дип сорады.

Тегесе ачу катыш:

— Улының җанын шайтанга саткан,— диде һәм читкә борылды.

Ибраһим Хәлфин, татар картларыннан сорашып, мәсьәләне ачыклады һәм Лобачевскийга аңлатып бирде:

— Карчыкның улы университет больницасында үлгән икән. Фәкыйрьлеге аркасында күмә алмаган, шуннан мәетне анатомия театрына тапшырганнар. Хәзер инде карчык, улымның сөякләрен рус зиратына күмсәләр, ахирәттә күрешә алмабыз, дип уфтана...

Бөкресе чыккан мескен карчыкны кызганудан Лобачевскийның йөрәге телгәләнде. Ул үзенең көчсезлеген, карчыкка ярдәм итә алмавын тоеп, башын аска игән, йодрыкларын йомарлаган килеш басып торды.

Хәлфин аңа ягымлы гына кагылып алды, тонык тавыш белән:

— Нык булырга кирәк, дустым, киләчәктә әллә ниләр күребез әле,— дип үгетләде.— Миннән калмагыз,— дип әйдәде.

Лобачевский, кая барганын абайлап тормыйча, аның артыннан атлады. Парадный ишеккә җитәрәк моннан икс ел элек нәкъ шул урында университетка турылыклы булырга ант иткәне хәтеренә төште. Броннерның актык мәртәбә күрешкәндәге сүзләрен хәтерләде: «Россиягә хәзер фән кирәкми, бәлки монархияне саклап калу өчен дин кирәк, аллага ышандыру кирәк», дигән иде ул. Бу чаклы алдан күрә белер икән!..

Киң баскычтан сөйләшми генә икенче катка мендeләр, караңгы коридорга керделәр. Хәлфин бер аудитория ишеген ачты һәм:

— Әйдәгез, бирегә керик әле, Николай Иванович,— дип, Лобачевскийга тәкъдим итте. Тege карышмады.

Таныш аудитория. Кыйммәтле кызыл агачтан уеп эшләнгән таныш кафедра. Тик аның маңгаена алтын йөгерткән славян хәрефләре белән нәрсә язып куйганнар соң?

— «В злохудожну душу не внидет премудрость»[1],— дип укыды Лобачевский һәм, үзен-үзе тыя алмыйча, ярсып кычкырып җибәрде:— Шайтан белсен, нәрсәдер бу! Башка аудиторияләрдә дә шундый хәлме, әллә бер минем өчен генә язылганмы?

— Бөтенесендә шул хәл,— диде Хәлфин, һәм аның тавышы калтырап китте.— Магницкий карашынча, студентлар алла сүзен тиешенчә белеп җиткермиләр. Шуңа күрә священное писание билгеләнгән сәгатьләрендә генә укытылмаячак, бәлки өстәмә рәвештә...

Лобачевский кинәт йөрүдән туктады, кафедрага текәлде, ләкин шунда ук кул селтәп:

— Әйдә, сөйләгез,— диде һәм, кафедрага күтәрелеп карарга да җирәнгән сыман, башын аска иеп, эре-эре адымнар белән йөренүен дәвам итте.

— Өстәмә рәвештә аудиторияләрдә өйрәтергә кушылды,— дип сүзен дәвам итте Ибраһим агай.— Дин сабагы кафедрасы булдырылды. Аңа житәкчелек итәргә Спасо-Преображенский монастырьның настоятеле архимандрит Феофанны чакырдылар.

— Тагын ниләр бар? — дип кызыксынды Лобачевский, йөрүендә дәвам итеп.

— Тагынмы? Бетсен философия, яшәсен дин сабагы! Безнең азиат типографиясенә, попечитель әмере белән, евангелиене татар телендә

[1] Явыз җанга гыйлем инмәс.

халык арасына тарату эше йөкләнде. Дәүләт цензоры буларак миңа мәшәкать артты.— Хәлфиннең йөзендә кызганыч елмаю чагылды.— Тагын Магницкий туган ил әдәбиятын сөючеләр җәмгыятен, мәрхүм профессорыбыз Ибраһимов оештырып калдырган җәмгыятьне буарга җыена. Хәзер аның урынына Россия дини җәмгыятенең Казан бүлеге оештырыла...

— Университет түгел бу, рухка богау сала торган монастырь,— диде Лобачевский, ишеткәннәренә йомгак ясаган сыман итеп.— Миңа монда бөркү була башлады. Әйдәгез, чыгыйк тизрәк.

Хәлфин килеп аны дусларча кочаклап алды, һәм алар берничә минут, кафедрадан читкә карап, эскәмиядә утырып тордылар.

— Моның белән генә дә бетми шул әле, дустым,— диде Хәлфин һәм авыр итеп көрсенеп куйды.— Магницкий әмере белән, директор махсус комитет оештырды. Аның бурычы безнең китапханәдәге Фонвизин, Вольтер, Дидерота[1], Снелль, Лубкин һәм башкаларның зарарлы әсәрләрен сайлап алып утка ягу. Комитет әгъзалары итеп Кондырев, Дунаев, сез...

— Булмас! — дип куйды Лобачевский, гайрәтләнеп, һәм урыныннан сикереп торды.— Булмас! Мин...

— Хәзер булмый торган нәрсә юк инде ул,— диде Ибраһим ага.— Тавышланып без беркемне дә җиңә алмаячакбыз, уйлап эш итәргә кирәк, ашыкмыйча... Иң кадерле китапларны, безнең типографиядә басылган корьән дигән булып, моннан алып чыгарга да яшерергә...

— Кая яшерергә?

— Минем өйгә илтербез,— диде Хәлфин гади генә.— Юк, рәхмәте миңа түгел, профессор Дунаевка тиешле. Аның башында туган фикер. Чит телдәгеләрен сайлап алу сезгә йөкләтелә.

— Бик шәп. Хәзер үк тотынам. Хәзер үк.

Лобачевскийның тыныч кына, эшчән кыяфәттә сөйләшүен күреп, Хәлфин канәгать булды.

— Хәзер инде сез, әлбәттә, акыллы эш йөртәчәксез. Әйдәгез, тагын бер яңалык күрсәтим үзегезгә. Элекке карцер хәзер «гөнаһлы бәндәләр бүлмәсе» дип атала...

Магницкий хәтта карцерны да күздән ычкындырмаган. Кайчандыр Коля Лобачевский утырган тимер рәшәткәле тар бүлмәнең стенасына зур картина эленгән. «Ахырзаман», янәсе. Гөнаһлы кешеләрне әлмәкләргә асып куйганнар; кызыл башлы, кәкре мөгезле, озын койрыклы җеннәр, биешә-биешә, аларны утта кыздыралар... Картина, бу дөньяда төзәлмәсәң, җәһәннәмдә сине шул көтә, дигән мәгънәне аңлата иде.

Карцерда, ниндидер шуклык эшләгән өчен, инде дүртенче тәүлеген икмәк һәм су белән генә тукланып, казна исәбенә укучы студент Горбунов утыра икән. Владимирский боерыгын үтәп, егеткә иске күлмәк, мужик кафтаны һәм чабата кигезгәннәр. Янәсе, тәүбә итмәсәң, бөлгенлеккә төшәчәгеңне белеп тор.

Бу студент белән бер курста укучылар һәр көн иртән, лекцияләр алдыннан, аның җанын коткаруны сорап, чиркәүдә гыйбадәт кылалар икән. Александр ата көн саен Горбуновка үгет-нәсихәт бирә, саф һавага чыгарттыра, ләкин моның өчен төнлә кеше йөрмәгән вакытны сайлый, ди...

Мондый «яңалыкларны» тыңлаганда Лобачевскийның йөрәге кысылып, әрнеп типте. Аның күз алдыннан гимназиядә укыган еллары, студент чаклары үтте. Кайчандыр шау-гөр килгән залларда һәм коридорда хәзер кабер тынлыгы хөкем сөрә. Аңа хәтта көек исе килгән төсле тоелды. Әле күптән түгел генә монда яшьлек дәрте ташып тора иде бит!.. Иң тирән, иң катлаулы философик мәсьәләләрне хәл итүдән

[1] Дидро.

курыкмаучы акыл иялəре, сез кайда?.. Киләчəктə сезне тагын нилəр көтə, шуны белəсезме?..

Бер аудиториянең ишеге янында Лобачевскийны инвалид каравылчы куып җитте.

— Профессор əфəнде, сезне Оренбурдан утыртып кайткан возчик күрергə тели.

Николай Иванович ялт итеп аңа табан борылды.

— Возчик? Һай, онытып җибəргəнмен бит! — диде ул, борчылып.— Аңарга акча бирəсем бар... Мин хəзер!

Лобачевский баскычтан йөгереп диярлек төшеп китте.

Кичен Лобачевский университетның төп китапханəсендə үткəрде. Китаплар һəм кульъязмалар өем-өем булып шкафларда, киштəлəрдə, буялмаган өстəл өслəрендə яталар.

Китапларга каталог төзелмəгəн, вак-төяк исемлеклəрдəн башка нəрсə юк, ə инде алар буенча бер китапны да табарга мөмкин түгел иде. Соңгы вакытта китапханəдə эшлəгəн профессор Сторль кинəт кенə үлеп киткəч, аның урынына яңа кеше билгелəргə өлгермəгəннəр иде. Мондагы тəртипсезлек Николай Ивановичны моннан бер ай элек борчыган булса, хəзер инде, киресенчə, сөендерде генə. Иң кыйммəтле китапларны һəм кульъязмаларны коткарып калырга мөмкин булачак, тикшергəн очракта да бер нəрсəнең очына чыга алмаячаклар иде.

Лобачевский зур хөрмəт белəн авыр күн тышлы фолиантларны ачыпачып карады. Борынгы заманда һəм урта гасырларда яшəгəн философлар... Аристотель, Лукреций, Лукиан, Джордано Бруно... Бу галимнəрнең хезмəтлəре аңа элек-электəн яхшы таныш иде, хəзер исə, һəлак итү куркынычы тугач, бигрəк тə якын булдылар. Математика, астрономия, механика, физика, философия. Гасырлар дəверендə тупланган гыйлем. Дөньядагы бөтен нəрсəне белергə, үзлəштерергə, киләчəк буыннарны шуңа өйрəтергə омтылган күпме акыл иясенең шатлыгы һəм аянычы, йокысыз төннəре менə шушы авыр фолиантларга тупланган. Шуларны кемнəрдер ансат кына утка яксын, имеш!..

Беренче чиратта коткарып калырга тиеш саналган хезмəтлəрне аерааера, Лобачевский вакыт үткəнне сизми дə калды. Ул үзенең фатирына таң атканда гына кайтып керде. Өй эчендə күңелсез тынлык хөкем сөрə иде. Əнисе Макарьевка киткəн җиреннəн кайтып житмəгəн. Энесе Алексей, технология кафедрасында адъюнкт буларак, Урал заводларына визитациягə җибəрелгəн иде. Симонов, күзəтче астроном сыйфатында, «Восток» һəм «Мирный» суднолары белəн, Лазарев һəм Беллинсгаузен командалыгында, дөнья тирəли сəяхəт итеп йөри. Мондагы дин əһеллəренең кыргыйлыгы аның башына да килми булыр! Иң акыллы кеше Броннер иде: 1817 нче елның көзендə үк отпуск алып Швейцариягə китеп барды. Хəзер, əлбəттə, кайтмаячак...

Лобачевский салкын бүлмəлəрне йөреп чыкты һəм тəрəзə янында туктап калды. Тышта яктырып килə, ə Николай Ивановичның тирəягында караңгылык, күңелсезлек хөкем сөрə. Аның күңел бушатырлык һəм юатырлык кешесе юк. Ялгыз, япа-ялгыз...

Хəер, ялгызлыкның да төрле чагы була икəн. Менə җəйге ял алдыннан гына, Симонов ерак сəяхəткə чыгып киткəч, астрономия фəнен укыту һəм обсерваториягə җитəкчелек итү эше Лобачевскийга йөклəтелгəн иде. Телескоп янында ялгызың калганда бөтен галəмне уч төбендə тотасың, нинди кыю фикерлəр килə башыңа!.. Ə хəзер бөтенлəй башка ялгызлык. Упкын төсле бушлык.

Ул чакта Лобачевскийга фəн политикадан өстен, хəтта бөтен тормыштан өстен булып күренгəн иде. Галимнəр исə, тау башындагы бөркетлəр кебек, мəгърур ялгызлыкта яшəргə тиешлəр, һəм алар телəсə

нинди әйбер турында кыю фикер йөртергә хаклы, дип уйлаган иде. Университет диварлары галимнәрне көндәлек мәшәкатьләрдән саклый торган крепость стеналары булып тоелган иде... Ә хәзер...

Хәзер университетның ул диварлары, әкияттәге мәрҗән сарай шикелле, чәлпәрәмә килде. Казан университетында башланган бу вәхшилек кара динчеләрнең томаналыгын, искегә ябышып ятарга теләвен, алдынгы фәнне буарга тырышуын чагылдыра түгелме?..

Николай Иванович, тәрәзә яныннан китеп, бүлмә буйлап кискен адымнар белән йөрергә тотынды. Бу минутта аның мие күз иярмәс тизлек белән эшли иде. Университеттагы вәхшилек гүя арткы планга күчте, ләкин чынында исә нәкъ әнә шул вәхшилек олы дөньяга күзне ачып карарга, акны карадан аера белергә өйрәтте. Әйе, дөньяда бертуктаусыз канлы көрәш бара — караңгылык белән яктылык арасында аяусыз көрәш бара. Борынгы Европаны әледән-әле көчле җир тетрәүләр дер селкетә. Француз революциясенең туплары тынып өлгермәде, Испаниядә көрәш башланды, Италиядә карбонарийлар күтәрелеп чыкты. Пруссиядәге реакцион режим ризасызлык тудырды һәм шуның нәтиҗәсендә «Изге союз»ны[1] яклап лаф оручы Коцебу студент Карл Занд тарафыннан үтерелде. Рус халкы да, күрәсең, йокыдан уяна башлады. Чугуевта хәрби халык баш күтәрде. Дон буенда — крестьян восстаниесе. Безнең Казанда да халык тик ятмый: сукно фабрикасында эшләүче крепостнойлар ирек даулый. Халык яктыга омтыла шул. Петербургта әнә Пушкин дигән шагыйрь, халык фикерен чагылдырып, үткен-үткен шигырьләр иҗат итә. Ул безнең Державин — Нәрбиковның шәкерте, имеш, дигән сүзләр дә йөри. Ә бит аның «Ирек» одасы телдән төшми:

Тетрәгез! Дөньяның тираннары,
Гамьсез, җинел язмыш уллары!
Ә сез күтәрелегез батырланып,
Җирнең кимсетелгән коллары!

Лобачевский уйга калып, аянычлы бер тавыш белән үз алдына сөйләнеп куйды:

Россиягә нинди юл белән барырга икән соң? Илнең бәхетле киләчәге өчен көрәш мәйданы кайда булыр икән? Аудиториядә көтеп ятаргамы, әллә көрәш юлына басаргамы?

Кулын болгый-болгый сөйләгәндә, аның кулы камыш креслога тиеп китте. Шуннан ул, карамыйча гына, креслога утырды. Иртәнге тынлыкта аның игътибарын җәлеп итәрлек әйбер булмады, һәм ул, креслога утыргач та, бер үк нәрсә турында уйлавын дәвам итте.

«Ярый, китәргә урын да табылсын, ди. Ләкин гыйлемнән башка гына җиргә яктылык иңә аламы? Ә университет — гыйлем учагы. Юк, һич китәргә ярамый. Минем урыным монда, университетта!..»

Казна исәбенә укырга кергәндә Лобачевский алты ел укытучы булып эшләргә вәгъдә биргән иде, шул вәгъдәсен үтәде. Сүзендә торды. Карт профессор Бартельс математиканы акрынлап аңа тапшырып бетерде диярлек: башта тригонометрияне бирде, аннары конус кисемнәр турындагы фәнне һәм аналитик геометрияне, тора-бара дифференциал һәм интеграл хисаплауны тапшырды. Профессор Реннер үлгәннән соң тагын бер курс өстәлде. Симонов сәяхәткә чыгып киткәч — тагын... Димәк, Лобачевский сүзендә торды, вәгъдәсен үтәде.

Николай Иванович иркен сулу алды һәм креслосын язу өстәленә якынрак китерде. Үткәнне хәтергә төшереп кенә файда чыкмас, хәзергесен кайгыртырга кирәк. Иртәгәдән лекцияләре башлана. Рус телендә

[1] Европада башланган революциягә каршы көрәшү өчен, иң реакцион өч илнең — Австрия, Пруссия, Россиянең монархлары бергә берләшеп, «Изге союз» төзиләр. Ахырдан ул союзга Европаның башка дәүләтләре дә кушыла. «Изге союз»ның башында рус императоры Александр I була.

һәм чит телләрдә чыккан ничаклы китапларны карыйсы бар. Студентларга иң кирәклесен генә — каймагын җыеп кына аңлатырга кирәк.

Язу өстәлендә төрле телләрдәге китаплар, журналлар, дәфтәрләр, вак хәрефләр белән чуарланган табаклы кәгазьләр. Биек шәмдәлләргә утыртылган шәмнәр яныи беткән диярлек. Лобачевский өстәлен күздән кичергәч, тәнендәге арыганлыкны бетерү өчен, бер селтәнеп алды. Шуннан эшкә тотынды.

Кереш лекциянен планын төзеп кенә өлгергән иде, урам яктан:

— Су сатам, су-у-у! Кабан суы! — дигән тавыш ишетелде.

Николай Иванович креслосыннан кисәк кенә сикереп торды һәм ишеккә юнәлде.

Салкын су белән юынгач, ул гүя бөтенләй икенче кешегә әйләнде. Төн буе керфек какмый эшләгәне онытылды.

* * *

Күпме газаплы эзләнүләрдән соң Николай Лобачевский моңарчы беркем күрмәгән, беркем ишетмәгән «Яңа дөнья»га [1] — неевклид геометриясенә якынлашты. Аның юлына дәһшәтле томан пәрдәсе корган нәрсә Евклидның бишенче постулаты булды. Томан артыннан чак беленерлек булып ерак җирләр күренде һәм бер үк вакытта шик тә тудырды, күңелне дә үзенә тартып торды. Максатка ирешү авырлашкан саен, Лобачевский аңа ныграк ашкынды.

Даһи кешегә бөек ачыш ясавы берни тормый, дип уйлаучылар да юк түгел. Очраклы рәвештә агачтан өзелеп төшкән алма, янәсе, Ньютонга тарту көче законын ачып биргән. Чынында исә мондый ачыш бик күп эзләнүләр нәтиҗәсе. Алманың ботактан өзелеп төшкәнен кемнәр генә күзәтеп тормаган, тик аларның берсе дә мәшһүр законны ача алмаган. Мондый фикер ничек итеп башыңа килде? — дип сорагач, Ньютон: «Гомерем буе шуны уйладым бит»,— дигән, имеш.

Лобачевский да нәкъ шундый хәлне кичерә.

Гадәттәге көннәрнең берсендә ул, иртән торып юынганда, моңа кадәр озак еллар буе аның башыннан чыкмый йөргән: «Ни өчен?» — дигән сорауга җавап яшендәй балкып китә. Әйе, бишенче постулат иреклә рәвештә алынган гипотеза гына, ягъни безне чолгап алган өч үлчәмле пространствоның үзлекләре турында беркадәр ихтималлыгы булган фараз итү генә, менә ни өчен ул геометрик чаралар ярдәмендә исбатлана алмый. Аның дөреслеген фәкать тәҗрибә юлы белән генә, табигатьнен үзенә мөрәҗәгать итеп кенә ачыкларга мөмкин. «Мәңге яшәүче нигезләр»нең асылы шул. Бишенче постулат башка аксиомаларга бәйсез рәвештә туган. Хәзер инде аның фәннең ике өлешен механик рәвештә бүлеп торган ызан гына түгел икәнлеген, ә бәлки фәннең тармаклану ноктасы булуын һәм шушы ноктадан бик күп тармаклы һәм шул исәптән төп Евклид геометриясен дә эченә алучы яңа геометрия үсеп китүен ачасы гына калган иде.

Ниһаять, Лобачевскийның башында гадәттән тыш кыю фикер туа. Әгәр Евклидның параллель турылар аксиомасын шартлы төстә алынган фараз итү дип кенә карыйбыз икән, димәк, аның урынына менә мондый гомумирәк постулат тәкъдим итәргә була: яссылыкта туры сызыктан читтә бирелгән нокта аша ул туры белән кисешми торган, ягъни аңа параллель булган ике, өч, ун, йөз, гомумән исәпсез күп туры сызыклар үткәрергә мөмкин. Бу постулатка һәм калган аксиомаларга нигезләп, логик юл белән — бер-бер артлы фикер йөртүләр һәм исбат итүләр ярдәмендә — яңа, моңа кадәр билгеле булмаган неевклид геометриясен төзи алабыз.

[1] Атаклы француз галиме Таннери Н. И. Лобачевскийны Яңа дөньяны, ягъни Американы ачкан Колумбка тиңли.

Ньютон алмасымы бу? Очраклы хәлме? Әллә инде озак еллар буена эзләнүләрнең логик нәтиҗәсеме? Шул чорда җыелып килгән акыл энергиясенең нинди дә булса этәргеч ярдәмендә гөлт итеп кабынып китүеме? Ихтимал, моны Лобачевский үзе дә аермачык сиземли алмагандыр.

Күгелҗем кәгазь табагына бер-бер артлы яңа теоремалар тезелеп китә. Лобачевский, өстәленнән аерылмыйча, яза да яза. Кеше акылына сыймый торган хәл бит: вак-вак энҗе хәрефләр күбәйгән саен, логик эзлеклелек саклаңган яңа геометрик система ачыклана бара. Нәтиҗәләрнең төпле булуы ягыннан бу система бөек грекның «Нигезләр»еннән бер дә ким түгел. Әмма бу яңа дөнья моңа кадәр күнегелгән геометрик чынбарлыктан, җир белән күк аерылган кебек, аерылып тора. Бала вакытында ул шулай, күзләрен зур итеп ачкан хәлдә, тын алырга да куркып, Сережа абыйсының әкиятләрен тыңлый-тыңлый, хыял дөньясына чума торган иде...

Лобачевский креслога аркасын терәп утырды; яза-яза оеган бармаклары бушап, каурый каләм өстәлгә төшеп китте. Бүлмәдә һава җитмичә, тын кысыла башлады.

Димәк, мәсьәлә хәл кылынды! Бишенче постулат үзенең серен икемең ел саклаган булган. Менә хәзер ул сер ачылды — хәзер генә, шушы кулы белән ул моңа кадәр беркем белмәгән дөньяны гәүдәләндерде.

Лобачевский өстәлдә таралып яткан кәгазьләрен җыеп, кинәт кенә читкә этәрде. Юк, ашыгырга ярамый. Хакыйкать дигән нәрсә бар бит әле. Меңнәрчә ел дәверендә кешеләр тормыш сабагын ала килгәннәр — туры сызык кисентеләре белән почмаклар арасындагы үзара мөнәсәбәтне үзләштергәннәр. Евклид, ниһаять, барлык мәгълүматны бергә туплап, безгә күренгән дөньяга шактый тәңгәл килә торган геометрик система эшләп чыгарган.

— Безгә күренгән дөнья...— дип кабатлады Лобачевскийның иреннәре, әмма тавышы чыкмады.

Уйларының дөреслегенә дәлилләр эзләгән төсле, утырган җиреннән сикереп торып, тәрәзә янына килде һәм пәрдәне ачып җибәрде. Караңгы күк гөмбәзендә йолдызлар җемелдәшә иде.

— Космос...— диде ул, пышылдап кына. Аннары чак кына алга иелеп, маңгаен салкын пыялага тигезде. Аңа рәхәт булып китте.

— Космос серләр хәзинәсе ул. Анда кайсыбызның геометриясе хакимлек итә икән? Евклидныкымы, әллә... минекеме? Логик фикер йөртүгә аларның берсе дә каршы килми бит. Шулай булгач, критерийны каян эзләргә һәм ничек табарга соң?

Кыршылып беткән каурыйны читкә ташлап, ул алдан әзерләп куелган каләмнәрнең берсен ала һәм тиз генә карага мана. Язып тутырмый калган соңгы табакка бик ашыгып мондый юлларны өсти:

«Табигатьтән сорарга кирәк! Барлык хакыйкать шунда саклана, һәм безнең сорауларыбызга ул, һичшиксез, җавап бирер».

Каурый каләм читкә оча, өстәл кырыендагы китапка төшеп аны пычрата. Лобачевский берни сизми утыра. Сул кулы белән башына таянган килеш, ул соңгы юлларга текәлгән. Тик ул язуны күрәме, юкмы — анысы билгесез.

Пәрдәсе ачык тәрәзәгә акрынлап кына яктылык үрмәли. Башта ул сизелер-сизелмәс кенә була, бераздан көчәя барып, өстәл янында иелеп утырган кешене караңгыдан аралап ала. Өстәлдәге кәгазь дә аермачык күренә: анда башка юллар өстәлмәгән.

Шуннан соң берничә көн рәттән Лобачевский икеләнеп йөрде. Ул үзенең эшен төгәл итеп башкарды, әмма туктаусыз рәвештә эчке тавышка колак салды, төнлә язып куйган сүзләре күңеленнән китмәде: «Табигатьтән сорарга кирәк!..»

Лəкин параллель сызыклар турындагы аксиоманы тəҗрибə ысулы белəн сынап карау мөмкин түгел: параллель нурларның чиклəнмəгəн бушлыкта кисешмичə генə дəвам итүен кем күргəн? Шул ук вакытта, бишенче постулатны дөрес дип карыйбыз икəн, нинди генə өчпочмакның да эчке почмаклар суммасы ике туры почмакка тигез. Əгəр дə бу яңа геометрия дөрес икəн, өчпочмакның почмаклар суммасы үзгəрүчəн була. Өчпочмак зурайган саен, аның почмаклар суммасы да 180° тан кими барачак...

Аның хəтеренə күңелле походлар — геодезиядəн үткəрелгəн практик дəреслəр килде. Нинди генə өчпочмаклар үлчəп карамадылар алар! Лобачевский кашларын җыерды. Иң зурларында да почмаклар суммасы ике туры почмакка тигез булды. Тик менə безнең күзгə һəм үлчəү приборларына ышанырга ярыймы икəн? Аннары бит əле...

— Өчпочмак зурайган саен, аның почмаклар суммасы...

Аның күз алдыннан караңгы күк гөмбəзендə җемелдəгəн йолдызлар китми. Шунда, ерак космоста, түгелме икəн моның сере? Əгəр дə җир өстендəге өчпочмак урынына космик өчпочмакны үлчəп карасак?

Тиздəн бу хыялны гамəлгə ашыру мөмкинлеге туды: Лобачевский астрономик обсерваториягə хуҗа булып алды. Обсерватория өчен урынны профессор Литтров үзе сайлаган һəм университетның ботаника бакчасындагы калку җиргə салдырган иде. Зур залның тəрəзəлəре дүрт якка да карый. Гөмбəз итеп эшлəнгəн түбəдə меридиан буйлап ярык калдырылган. Авыр оптик приборлар нигездəн үсеп менгəн таш баганалар башына куелган,— идəннең селкенүе һич тəэсир итəрлек түгел. Обсерватория алдында тагын кечкенə генə бер бина булып, анысының түбəсе əйлəнеп йөри һəм параллактик машина ярдəмендə күзəтүлəр алып бару өчен бик уңай иде.

Обсерватория эшендə Лобачевский электəн үк катнашып килде. 1815 нче елда яңа приборлар кайткач та, аны монда дусты Симонов чакырды. Иван Михайлович Симонов ул вакытны Олберс ачкан кометаны өйрəнə һəм шуңа күзəтүлəр алып бара иде. Профессор Литтров җитəкчелек итте.

Литтровның Казаннан киткəненə байтак вакыт үтте инде. Аның урынында Симонов. Лəкин Иван Михайлович ике ел дөнья гизеп кайткаңнан соң университетта озак эшлəмəде — 1823 нче елның язында астрономиядəн һəм физикадан кирəкле инструментлар алып кайту максаты белəн чит илгə командировкага китеп барды. Тиз арада гайбəте дə чыгып өлгерде: янəсе, дөнья гизгəндə аңарга чит иллəр нык игътибар иткəн булган, янəсе, хəзер инде ул Россия Колумбы буларак үзен күрсəтеп йөриячəк. Аның белəн бергə физика профессоры Купфер да китте. Алар барында гəрчə кайчакларда астрономиядəн һəм физикадан укыткаласа да, ничектер, Лобачевский үзен ул фəннəрдə кунак итеп кенə сизə иде. Хəзер исə аңа, саф математика профессорына, чын мəгънəсендə астрономга əйлəнергə һəм обсерваториянең хуҗасы булырга туры килде.

Ниһаять, аңарга хыялын тормышка ашырырга — зур сынау үткəрергə мөмкинлек туды. Моның өчен Җирдə урын җитми, ул космик өчпочмакны үлчəячəк!

Ə нигез итеп нəрсəне алырга? Җир орбитасының диаметрын алырга кирəк! Өчпочмакның түбəсе ролен ерактагы берəр йолдыз — Сириус яки Ригель үтəр. Əнə шундый зур өчпочмакның почмаклар суммасы ике туры почмактан кимрəк чыгармы, юкмы? Күпмегə ким булыр икəн?

Николай Иванович көндез университет эшлəреннəн бушый алмавына да кайгырмады — төнлə эзлəнде, төнлə баш ватты. Гаҗəеп тəҗрибəнең һəр детален вагына-төягенə кадəр кабат-кабат уйлады. Монда инде кайсы əһəмиятле, кайсы əһəмиятсез дип торып булмый: чылбыр буыннары кебек, һəммəсе дə кирəкле. Хəтеренə ышанып җитмичə, Лобачев-

ский саннарны бер-бер артлы кәгазьгә төшерде. Яктылык аберрациясен дә, Җирнең, «хәрәкәтсез» йолдызның һәм гомумән, Кояш системасының йөрешен дә исәпләп бетерде шикелле. Башлап җибәрергә вакыт җиткәндер. Тик менә... Лобачевскийның киң маңгаена янадан-яңа җыерчыклар өстәлде. Астрономия приборлары төп-төгәл күрсәтә алмаячак бит әле, ул бәладән ничек котылырга? Шуның хикмәтен эзләп тагын күпме йокысыз төннәр үтте! Хәер, Николай Иванович менә артык кайгырмады: дәртле кешедән йокы болай да качучан була бит ул.

Менә йолдызның параллаксын, ягъни Җир диаметры белән нинди почмак тәшкил итүен белү өчен беренче билгене дә ясады. Хәзер инде көтәргә генә кала. Нәкъ ярты елдан Җир үз орбитасының икенче ягында — диаметрының аргы башында булачак. Шунда Лобачевский тагын бер билге ясар. Ярты ел — шактый гомер бит. Уйларын уртаклашыр дусты да юк, ичмасам. Аның йөрәк серен белмәгән кешеләр яшь профессорның табигатендә бертөрле дә үзгәреш сизмәделәр. Ул һәрвакыт тыйнак, хезмәтен һәрвакыт төгәл башкарды. Буш сәгатьләрендә исә хыял дулкыннарында тибрәнде. Балыкка барса — калкавычын хәтердән чыгарды. Урманда булса — җыйган гөмбәсен куак төбендә онытып калдырды. Казанда ул онытылып йөрмәгән бер генә урам да калмагандыр.

Прасковья Александровна улының күңелендә ниндидер авыр көрәш баргanлыгын сизде, тик комачауларга тырышмады. Чөнки ана мәхәббәте ул турыда сүз кузгатырга кушмады. Обсерваториядә төн буе йолдызлар күзәтеп янсә балыкта йөреп кайткан улын һәрвакыт якты йөз белән каршылады. Әнисеннән күргән бу хөрмәтне Лобачевский озак еллар сагынып искә ала торган булды. Аяк тавышын ишетеп, әнисенең еш кына күзендәге яшьне сөртүе аның өчен, әлбәттә, сер булып калды. Лобачевский үзенең күңелендәге газаплы уйларны уртаклашмады: ана хәзер астрономияне белүче кеше белән фән турында сөйләшүдән бигрәк, әнкәсенең нурлы йөзен күрүе һәм ягымлы тавышын ишетүе кирәк иде.

Ярты ел әнә шулай үтте. Мәңге хәрәкәт итүче Җир үз орбитасының икенче ягына җитте. Ул диаметр космик өчпочмакның нигезе булып хезмәт итте. Шул ук йолдызга бу ноктадан билге ясап, табигатьтән җавап алыр чак җитте. Лобачевский тәҗрибә ясарга кереште һәм дөньясын онытты.

Тәҗрибә эшләнеп беткәч, ул тиз генә акылын җыя алмый торды. Обсерватория залының ачык тәрәзәсеннән җил бәрә. Сәгать артыннан сәгатьләр үтә. Йолдыз артыннан йолдызлар калка... Шуларның берсеннән Лобачевский җавап көткән иде — җавап булмады. Космик өчпочмакның почмаклар суммасы нәкъ 180° түгел түгелен, шулай да аерма кечкенә — үлчәү приборларының төгәл эшләмәвеннән генә килеп чыккандыр... Күк үзенең серен ачарга теләми, күрәсең. Лобачевский билгесез дөньяга әнә шундый авыр юл белән, озаклап килде. Җитәм, җитәм дигәндә — уңышсызлыкка дучар булды...

Лобачевский акылын туплап, үзен кулга алды һәм аның иреннәре: «Ялгыш үлчәү бәласе... Ялгыш үлчәү бәласе...» — дип пышылдаудан туктады.

Тәрәзә яныннан китеп, зал буенча йөренде, аннары янадан тәрәзә каршына килеп басты. Әнә генә ул Ригель. Гади күзгә кечкенә генә йолдыз булып күренә, чынында исә гаҗәеп зур ут шары. Әгәр ялгыш үлчәү бәласе булмаса?..

Бу төндә Прасковья Александровна улын юкка гына көтеп утырды. Обсерваториядә ут бер сүнде, бер кабынды. Тәрәзәдән зал буйлап помышып йөрүче кешенең шәүләсен күрергә мөмкин иде. Ана күңеле Николашасының эше уңмаганын, шуна тоткарланганын сизенде. Ул кабат-кабат кухняга чыкты, анда улына дип пешереп куйган ашын җылытты.

...Акрын гына ишек шыгырдаган тавышка уянып күзен ачса, бүлмә эче яктырып киткән. Прасковья Александровна, харап булдым дигән сыман, дерт итеп сискәнеп куйды һәм урындыгыннан торды.

— Кара инде, Николаша, йоклап киткәнмен ләбаса!.. Ашың суынгандыр, хәзер...— Ләкин шул вакыт улына күтәрелеп карады һәм түзмәде, йөрәге әрнеп:— Николаша, бер дә үзеңне саклый белмисең, бөтенләй чырайсыз калгансың,— дип әйтеп куйды.

Лобачевский тиз генә җавап бирмәде. Ул башын иеп, гамьсез бер кыяфәттә басып тора иде.

— Николаша,— дип кабатлады Прасковья Александровна һәм, борчылып, улының җиңенә кагылды.— Нишләвең инде?

Лобачевский кинәт башын күтәрде, йөзе бераз алсуланып китте. Ул ягымлы елмаеп әнкәсен кочаклап алды.

— Әнием, зинһар, борчылмагыз. Ялгыш улчәү бәласе... Нәрсә сөйлим! Гафу итегез... Кичке ашны иртән ашау күңеллерәк була бит. Төн озын йокламадыгызмени?

Ләкин елмайган итеп кенә әни кешене алдап булмый икән. Прасковья Александровна гәрчә тыныч тавыш белән:

— Син нәрсә, Николаша! Йокладым, төш күрә-күрә йокладым. Хәзер иртәнге аш китерәм,— дисә дә, икенче якка борылгач, авыр көрсенеп куйды.

Уңышсыз чыккан тәҗрибәдән соң Лобачевский тиз генә аякка баса алмады. Хәзер инде ул төннәрен обсерваториядә торган саен ешрак үткәрә торган булды. Ул ялварып үтенгәч, андый чакта әнисе йокларга ятты, аны көтеп утырмады. Ләкин ана кешенең күзенә йокы кермәде: улының үз-үзен тотышы аны тирән борчуга салды. Кайгыны ул ялгызы кичерде, беркемгә дә сөйләргә йөрәге җитмәде.

Обсерваториядә әллә нинди инструментлар һәм приборлар янында булу Николай Ивановичка күкнең бөек серләренә күз салырга ярдәм итә иде, күрәсең. Кичтән әзерләп куйган каурыйлары еш кына тузып бетә, аның каравы, язган табаклары артканнан арта бара иде.

«Димәк, безнең тәҗрибәбез гадәти геометриянең бөтен исәпләүләрен дөрескә чыгара һәм аның нигезләренә исбатланган дип карарга мөмкинлек тудыра...— Лобачевский әнә шулай дип язды.— Хәлбуки яңа геометрия безнең хыялыбызда яши ала... Алынган өчпочмагыбыз җитәрлек дәрәҗәдә зур идеме соң?..

Хыялыбызда бушлыкны чиксез дәвам иттерә алуны исәпкә кертмәгәндә дә, табигать безгә шундый ерак араны күрсәтәдер ки, алар белән чагыштырганда Җиребездән хәрәкәтсез йолдызларга кадәр ара да бөтенләй кечерәеп, югалып кала Ихтимал, неевклид геометриясе безгә күренми торган иксез-чиксезлектә гамәлгә аша булыр?..»

— Ничек исбат итәргә?

Әнә шул сүзләрне үз алдына кабатлый торгач, Лобачевскийның бөтен игътибары бер тирәгә тупланды. Еш кына ул, хыялга чумып, бар дөньясын онытып тора да кинәт сискәнеп куя, мин кайда соң? — дигән кыяфәт белән як-ягына карана башлый. Аның мондый сәер гадәте күпләрне гаҗәпкә калдыра. Бер шәкерте бу турыда: «Дворяннар җыелышы залы кебек зур җирдә дә ул, колоннага сөялеп, уйга кала, күз алдында нәрсәләр эшләнгәнен гүя күрми дә, ишетми дә иде»,— дип яза.

Аның бу халәтен университет башында торучы түрәләр дә күрәләр, әлбәттә. Профессорга шикләнеп карау өчен шул җитә кала. Гомумән шикле кеше бит бу Лобачевский дигәннәре: элек-электән чиркәүгә юньләп йөрми, түрәләргә артык баш бирми, законнарны ничек тели, шулай аңлата, хәзер инде бигрәк тә — чынбарлыктан ваз кичеп, нинди дер ярамаган, тыелган нәрсә турында фикер йөртә шикелле...

Түрәләрнең йөзендәге ризасызлык тойгысын күреп, Лобачевскийдан коллегалары да акрынлап кына читләшә бардылар. Лобачевскийга-ни

өчен шундый караш булуын тикшереп, баш ватып тормадылар, үзләре турында гына уйлап, түрәләргә ничек тә ярарга тырыштылар. Ә тегеләргә һәркемнең буйсынуы, үтәдән-үтә күренеп торуы һәм тырышып хезмәт итүе генә кирәк тә, чөнки андый шартларда тыныч яшәргә мөмкин.

Ә Лобачевский һаман шикле була килде, тирә-юненә, ичмасам, аз гына да игътибар итмәде. Аның уйларын, кичерешләрен, сөйләгән очракта да, коллегалары барыбер аңларга теләмәячәкләр һәм аңлый алмаячаклар иде. Николай Иванович та үз алдына Евклид белән бәхәсләште, моңа кадәр изге саналган фән нигезләренә тәнкыйть күзе белән карады, фәнне ачыкларга, баетырга теләде. Хыялы белән галәмнең иксез-чиксез киңлекләренә очып, ниндидер ят йолдызларга, чит йолдызларга кагылып-кагылып киткән төсле тоелды. Һәм шуннан чынбарлыкка, иске дөньяга кайтып төшүе аның өчен аеруча зур газап тудырды. Коточкыч наданлык, томаналык хорафатлары аның фикерен буарга, кол итәргә теләде. Галәм төзелешенең яңа законнарына якынлашкан галим үзе укыта торган аудиториядә алтын хәрефләр белән кафедрага язылган: «Явыз җанга белем иңмәс», дигән дини сүзләрне генә очратты.

Уенда бишенче постулат булды, ә колак төбендә ара-тирә Никольскийның: «Шуләй итеп, әфәнделәр, ходай тагәләнең ярдәме белән бу ике өчпочмак үзара тигез була...» дип төчеләнеп сөйләгәне яңгырап киткәндәй тоелды.

Бөек ачыш ясаган чакта ул ерак йолдызлар белән серләште, ә университетта... һаман бер балык башын чәйнәп тордылар: «Аллаһе тагәләне ярат, чиркәүгә йөр!.. Дингә баш ор, буйсын... Ходай тагәлә яктылык ул. Акыл вә зиһен, көч вә байлык ходай кулындадыр; кешенең бар белгәне ошбу яктылык чыганагыннан киләдер, башлангычыбыз буларак без шуңа омтылырга тиешбез... Күкләр ходай тагәләгә, аның кылган эшләренә мәрхәбә җырлый. Астрономиянең максаты әнә шундый...»

Лобачевский менә ни өчен ялгыз иде. Аның туктаусыз рәвештә уйлануын йөзеннән күрергә мөмкин. Кашы һәрвакыт җыерылган булыр, күз карашы гүя аның үзенә генә мәгълүм нәрсәләргә юнәлгән булыр. Ул үз эченә бикләнеп яшәргә мәҗбүр иткелде һәм сөйләшергә теләүчеләр белән дә артык сүз куертып тормады. Хәзергә аңа гына ачылган бөек хакыйкатьне барыбер аңламаячаклар. Күңелендәгене сөйләп биргән очракта, аңарга теләктәшлек күрсәтүчеләр дә хәтта: «Җирдә рәхәт яшәп булганда, ни өчен йолдызларга омтыласың әле син?» — диячәкләр. «Ходай үзенең бетмәс-төкәнмәс зирәклеге белән кешеләрдән яшерүне кирәк тапкан икән, табигатьнең ул серләрен белергә омтылу гөнаһ түгелмени?»

Лобачевский беркем белән аралашмады, торган саен ныграк эшенә чумды, бөтен гомерен шуңа багышлады. Ләкин ул үзенең фәнни ачышын игълан итәргә ашыкмады. Фән өлкәсендә шулкадәр кыю адым ясагач, бу яңа геометрияне кабат-кабат тикшереп, бер төрле хатасын, кимчелеген дә калдырмаска кирәк. Бөек хакыйкатьне кешелек дөньясына ачып бирү эшенә Лобачевский бик җитди карады. Ул туктаусыз эшләде, эзләнде.

Киеренке хезмәт аның сәламәтлегенә, әлбәттә, ничек тә булса тәэсир итәргә тиеш иде. Лобачевский түшәккә егылды.

Авыру гәрчә күңелле нәрсә булмаса да, аның файдасы тими калмады. Тәнне хәлсезләтеп ташлап, ул арыган башка бераз эшләми торырга, ял итәргә мөмкинлек тудырды. Лобачевский тиз генә аякка баса алмады, һәм аның шундый хәлдә булуына Прасковья Александровна артык пошынмады. Улы көннәр буе өйдә торгач, аларның аралары тагын якынайды, Макарьевта яшәгән чактагы кебек, бер-берсен яхшы аңлый һәм уртак тел таба башладылар. Әнисенең кыюсыз гына шаяр-

тып әйткән сүзләренә улы нәкъ бала вакыттагыча мөлаем елмаеп җавап кайтарды, һәм акрынлап аның күз карашы йомшарды, мангаендагы тирән җыерчыклар язылا барды.

Ниһаять, Лобачевский савыга башлады. Тик инде ул өй тирәсендә йөрергә чыкканда әнкәсенә карышмады: нечкәреп калган муенына мамык шарфны ураттырды. Әнисе үзен бик бәхетле сизде. Менә ни өчен врачның җылы сүзләре дә аны сискәнеп һәм агарынып китәргә мәҗбүр итте.

— Николай Иванович, иртәгә университетка тәвәккәлләп бара аласыз,— диде врач.— Ләкин яңадан Эскулап кулына эләгергә теләмәсәгез, зинһар, сакланып йөрегез,— дип кисәтте.

Лобачевский хафага калган әнисенә, арык иннәрен кочып, ягымлы тавыш белән:

— Кайгырмагыз, әнием, сезнең тырышуыгыз аркасында мин сәламәтләнеп кенә калмадым, бәлки акылга да утырдым шикелле,— диде.

— Акылга утыруың шиклерәк шул, Николаша,— диде ана, көрсенеп.— Тагын төннәр буе обсерваториядә ятарсың дип куркам.

— Вакытында кайтыр,— диде врач, сүзгә катнашып, һәм Лобачевскийга усал кыяфәт белән бармак янады:— Ишеттегезме, Николай Иванович?

— Баш өсте,— дип җавап кайтарды Лобачевский, җитди булырга тырышып.— Әнием, улыгыз бүгеннән башлап акыл белән эш итәргә, сезнең сүздән чыкмаска вәгъдә бирә.

— Урамга мамык шарф урап чыга торган бул,— диде Прасковья Александровна, врачны тулысынча үз ягына аударырга теләп.

— Әлбәттә, әлбәттә,— диде врач, көлемсерәп.— Сезгә тыныч йокылар, төпле акыл телим, Николай Иванович.

Ниһаять, эшкә барыр чак та җитте. Ул көнне бераз салкынча иде. Лобачевский болдырда туктап калды. Нинди саф кышкы һава! Акрын гына кар бөртекләре төшә. Лобачевский кулын алга сузды — берсе аның кара перчаткасына кунды. Яхшырак күренергә теләгән төсле, икенчеләре аның янәшәсенә төште.

— Нинди матурлар! — дип куйды Лобачевский, сокланып.

Ул кар бөртекләрен берәм-берәм күздән кичерә иде. Һәрберсенең үз формасы, үз бизәге бар. Шул ук вакытта һәммәсе алты почмаклы. Бишлеләре дә, җиделеләре дә юк. Ни өчен алай икән? Табигатьнең атомнарны шулай урнаштыруы нәрсәдән килә икән?

Лобачевский, бизәкле кар бөртекләреннән күзен ала алмыйча, болдырга төште.

Университетка барып кергәнен ул сизми дә калды. Вестибюльдән караңгы коридорга борылды. Кары эрегән перчаткасын салып, кесәсенә тыкты. Уйланып бара торгач, минералогия кабинетына үтте.

Музейны 1817 нче елда профессор Броннер оештырып җибәргән иде. Аның минераллар коллекциясе музейга нигез ташы булып яткан иде.

Лобачевский бүлмә уртасында туктап калды һәм як-ягына каранды. Стеналарга идәннән алып түшәмгә кадәр стеллаж эшләнгән, аның киштәләренә, чүбек яки йомычка түшәлеп, минераллар куелган һәм кайда нәрсә ятканын күрсәтә торган ярлыклар ябыштырылган.

— Алексей нинди ярата иде бит! — дип сөйләнеп куйды Лобачевский үз алдына.— Себердән утыз алты ящик төяп кайткан иде... Шуларның һәммәсен ташлап китсен инде... Кая китте бит әле — Осокинның сукно фабрикасына управляющий булып!..— Лобачевский, көрсенеп, башын чайкады.

Университет советы шуннан кабинетны аңа тапшырды. Николай Иванович вакытлыча риза булды. Энесе әйләнеп кайтыр дип өметләнде ул.

Эшләргә тыныч биредә. Комачауламыйлар... Әнә коридордан аяк

тавышлары ишетелде. Монда керерме? Юк, аргы башка үтте. Янә тып-тын булып калды.

Лобачевский, бер киштә янына килеп, караштыра башлады. Тау хрустале. Аның кристаллары үтәдән-үтә күренә, алты почмаклы пирамидалар кебек очлаеп тора. Шунда ук яшел каймалы шәмәхә слюда кыерчыклары. Янәшәдә үк искиткеч бүлып укмашкан куе яшел төстәге малахит ята. Менә известняк кисәгендә күзгә-күз булып зәңгәр целестин оялары ялтырый. Арырак — җилпәзә кебек инәләрен төрле якка җәйгән алсу турмалин. Профессор, үзе дә сизмәстән, бер генә тәрәзәдән төшкән тонык яктылыкта җемелдәшкән төрле төстәге минералларга сокланып карап торды. Әнә кварц — гүя ул үз эченә кечерәк кенә бер болытны яшергән. Бакыр купоросының күгелҗем кристаллары — нәкъ менә кыйшайган кублар. Монда кубларның тигез пәм төзләре дә бар. Уенчык итеп эшләнгән диярсең. Су тамчысы шикелле үтә күренә. Лобачевский уйга калып, ул кубикларны яктыга китереп, әйләндереп-әйләндереп карады.

— Тоз, аш тозы. Төрле шартларда үсүләренә карамастан, кристалл формалары бер үк төсле. Бу охшашлык нәрсәдән килә? Пространствоның геометрик формалары материянең физик үзлекләренә бәйле булудан түгелме?

Лобачевский кристалларның икесен дә киштәгә куйды һәм янадан тәрәзәгә табан атлады. Карандаш алып, куен дәфтәренә тиз-тиз генә түбәндәге юлларны язып куйды:

«...Тышкы сызыкларының — кабырга, почмак, кырларының — төгәл булуыннан чыгып, без кристалларда атомнар геометрик законнар нигезендә, ягъни тигез рәтләр тәшкил итеп урнашкан диган фикергә киләбез».

Куен дәфтәрен кесәсенә яшергәч тә эле, башы эшләүдән туктамады. Кар бөртекләре турында уйлану нәтиҗәсендә генә кабинетка килеп керсә дә, ул яна фикерен тикшермичә калдыра алмады.

Николай Иванович киштәдән алынган минераллар янына өстәлгә кристаллография буенча кулланманы да куйды. Кулына почмаклар үлчи торган прибор һәм линейка алды. Җир астында меңнәрчә ел яткан тау хрусталенә зарар китерүдән курыккан сыман, нечкә бармаклары белән сакланып кына эш итте.

Сәгатьләр үтә торды, бер-бер артлы төрле минераллар үлчәнде. Ялтыравык сары кубиклы пиритны, күк төсендәге целестин ромбаларын, ап-ак кальцитның гаҗәеп матур ромбоэдрларын, җемелдәп торган алты кырлы зөбәрҗәт призмаларын үлчәү нәтиҗәсендә көтелмәгән җавап килеп чыкты: бер матдәнең кристаллындагы яссылыклар арасындагы тиндәш почмаклар тигез булалар. Ул кристаллар нинди дә булса кысынкы шартларда үскән очракта форма ягыннан төрле булулары ихтимал, тик шунда да тиндәш почмаклар тигезлекләрен югалтмыйлар.

«Димәк, кырларның почмакларга бәйле икәнлеген табигать үзе раслый...»

Әле генә минераллар үлчәгәндә кулы калтырамаган иде, менә хәзер, язганда, калтырый башлады. Күңеле тыныч түгеллекне күрсәтеп, юллары да бик үк туры чыкмады.

Ишек шыгырдап ачылып китте, һәм өстенә кама тун кигән Хәлфин килеп керде.

— Сәлам галимгә! — диде ул, кәрә-кәрә үк.— Ишекне шакыдым, шакыдым — һич җавап бирмисез. Шуннан менә рөхсәтсез генә...

Лобачевскийның кулыннан карандашы төшеп китте һәм ул сикереп торып, ике кулын алга сузып, каршы атлады. Хәлфиннең салкында кызарган кара тут йөзе белән чагыштырганда Лобачевский бигрәк чырайсыз күренә иде.

— Ибраһим Исхакович! Нинди шатлык! Ничек эзләп таба алдыгыз?

— Каравылчы әйтте. Кулына текәлеп караган көе, шунда кереп китте, диде. Нәрсә язылган иде ул кулыгызга?

— Бик күп кызыклы нәрсәләр язылган иде. Ахырдан сөйләрмен. Башта сез сөйләгез. Хәләл җефетегез, балаларыгыз таза-саулармы?

— Рәхмәт, бик яхшы,— диде Хәлфин, татарчалатып.— Өйдән катгый әмер биреп җибәрделәр, сездән башка бусагадан кертмәячәкләр. Бичара илчегә мәрхәмәт кылуыгызны ялварып сорыймын.

Хәлфин тунының төймәләрен ычкындырды һәм Лобачевский куйган урындыкка утырды.

— Әле сезгә сугылган идем. Прасковья Александровна еламый гына инде, мескенкәем. Авырган арада бераз тынычланган сыман булган иде, бүген менә кулымнан ычкынды: мамык шарфын да урамый качкан, дип зарлана.

Хәлфин елмаеп күзен кысты һәм кесәсеннән мамык шарф чыгарып:

— Әйдәгез, киенегез,— диде.

— Кулымнан ычкынды, дип зарланамыни? — Лобачевскийның кырыс йөзенә елмаю чыкты.— Яковкин да өнәп бетерми иде шул. «Син, Лобачевский, юлбасар булырга тугансың»,— дип әйтә торган иде. Өйдә утыра алмыйм шул, юк шул, Ибраһим Исхакович!

— Бу хөҗрәдә үзегезгә нинди шөгыль таптыгыз, дустым?

— Геометрия, әлбәттә,— диде Лобачевский, өстәл өстендә яткан минералларны күрсәтеп.

— Шаяртасыз түгелме? — диде Хәлфин, гаҗәпкә бирелеп.— Ялгышмасам, кристалларны минералогия фәне өйрәнә шикелле. Аннары билгеле бер дәрәҗәдә — химия. Математиканың моңа нинди катнашы бар?

— Ә сез Ломоносовның сүзләрен хәтерегездән чыгармагыз. «Әгәр химия чын-чыннан фән булырга теләсә, ул сизгер һәм сак геометриядән сорашырга тиеш»,— дигән бит. Сизгер дигән. Бик дөрес әйткән. Бүген миңа менә бу җансыз минералларның телен төшендереп бирүче дә шул геометрия булды.

Профессорның нечкә бармаклары өстәлдә яткан ташка сузылды, аны яратып, сыйпап куйды.

— Шушы кристалларның һәрберсендә хәзергә без белмәгән бөек законнар, табигать законнары ята. Галим өчен зөбәрҗәт белән аш тозы бер үк дәрәҗәдә кыйммәтле, чөнки һәр кристаллның үзенә генә хас геометрик төсмерләве була. Һәм бу очраклы нәрсә түгел, физик төзелешеннән килә. Матдәнең физик һәм геометрик үзенчәлекләре бер бөтен тәшкил итә, аларны аерып карарга мөмкин түгел. Шуннан соң да геометрик үзенчәлек мәсьәләсен өйрәнергә кирәкми дип карау дөрес булырмы?

Дулкынланып сөйли торгач, Лобачевскийның йөзе алсуланып китте, авыру диярлеге калмады.

Хәлфин аның сөйләгәнен зур игътибар белән тыңлады; я дустының йөзенә, я кулындагы зәңгәр целестинга карады.

— Бу турыда минем бертөрле дә мәгълүматым юк иде,— дип сөйләнде ул кыюсыз гына.— Хәзер менә... Рәхмәт инде, Николай Иванович. Минем өчен бөтенләй ят дөньяны ачып бирдегез. Әмма бу минераллар турында соңгы сөйләшүебез булмасын иде. Я раббем! Сәгать ике тулган. Күпме вакытыгызны алганымны сизми дә калганмын.

— Юк, алай түгел,— диде Лобачевский, башын чайкап. Ул саклык белән генә җем-җем килгән кристаллны киштәдәге оясына урнаштырды.— Рәхмәт сезгә... Үземне дус күргән кеше белән сөйләшеп утырасы килгән иде.— Аның тавышы акрынайды, калтырап киткән төсле булды.— Минем тормыш юлымда андый кешеләр күп очрамады... Рәхмәт... Кичен сезгә барып чыгармын. Хәзер гафу үтенергә тиешмен: лекция укыйсым бар.

— Менә яхшы булыр. Бик яхшы,— дип, Хәлфин шатланып урыныннан кузгалды.— Өйдәгеләр сезне сагынып беттеләр инде. Шушы көннәрдә сарык суйдык, тутырма ясадык — телегезне йотарсыз. Тагын менә... кияү егете өчен пилмән белән махсус өчпочмак пешерәсе бар. Тегенди-мондый өчпочмак түгел, неевклид өчпочмагы,— диде ул, хәйләкәр елмаеп.

Лобачевскийның кулын каты кысып, ул ишеккә юнәлде, тик бусагада тукталып калды.

— Куна килегез, Николай Иванович. Иртә таңнан балыкка барырбыз. Якшәмбедә булса да геометриягезне онытып торырсыз,— диде һәм гадәттәгечә татарчалатып хушлашты:— Сау булыгыз!

Хәлфин житез генә атлап чыгып киткәч, Лобачевский бераз вакыт елмаеп колак салып торды. Коридорда аяк тавышлары тәмам ишетелми башлагач кына, минералларны йомшак ояларына урнаштырды, китаплар һәм приборлар шкафын бикләде. Пальтосын кигәндә, Хәлфин урындык башына элеп калдырган мамык шарфны күреп, тагын елмайды.

— Рәхмәт, әнием! — дип куйды ул акрын гына тавыш белән һәм шарфны тырышып-тырышып муенына урады...

Көнозын баш ватканнан соң, арыган булуына да карамастан, Лобачевский турылыклы дусты Хәлфин өенә бик теләп барырга уйлады. Шуларга барып ара-тирә ял итеп кайткалый ул. Башка вакытын эшләп уздыра. Фән белән шөгыльләнә, лекцияләргә әзерләнә. Үз фәннәреннән тыш әле тагын чит илләргә командировкага киткән профессорлар өчен дә укый; физика-математика факультетының деканы; төзү эшләре һәм нәшрият комитетларының башында тора; профессор Дунаев авыру сәбәпле, Казан уку һәм укыту округы идарәсенең даими заседателе дә. Алгебра дәресләрен язарга таң белән торып утыра һәм ике-өч сәгать дәртләнеп кенә эшләп ала. Житмәсә тагын, өйдәге хуҗалык эшләре дә аның җилкәсендә... Университет квартирасында яшәү кыенлашкач, берәүнең өенә күченгәннәр иде,— анда да бик мәшәкатьле булып чыкты. Энесе Алексей, бөтенләй чит кеше төсле, английский клубта ашап-эчеп йөри...

Лобачевский бу турыда Хәлфиннәргә барганда уйлады. Хәлфиннәр нәселләре белән мәгърифәтчеләр булганнар. Бабалары Сәгыйть Петр патша әмере белән төзелгән Адмиралтейство конторасында тылмач булып эшләгән («Татар бистәләренең депутаты» дип йөрткәннәр), аннан Казан гимназиясендә уналты ел буена шәрык телләре укыткан [1]. Уллары Исмәгыйл белән Исхак та шул ук гимназиядә 15 ел укытканнар. Хәзер исә, 1800 нче елдан башлап, Исхакның улы Ибраһим да укыту эшенә керешә [2]. Беренче Азия типографиясенә цензорлык итә. Университетта шәрык телләре һәм әдәбияты адъюнкт-профессоры. Бер үк вакытта гимназиядә укыта. Аның үзенең кече уллары да шунда укыйлар. Олылары инде белем алып, зыялы булганнар. Аның хәтта җәмәгате дә укымышлы ханым иде. Өйдә француз гувернантка тоталар. 1820 нче елларда Казан университеты каршында татар гимназиясе ачу мәсьәләсе кузгатылгач, Ибраһим Исхакович яңа мәктәп өчен кирәк булган уку әсбаплары әзерләүгә, гимназия курсларында укыла торган дәреслекләрне татарчага тәрҗемә итүгә керешкән иде. Ләкин Магницкий бу эшне бөтенләйгә туктатты.

Хәер, Хәлфиннәр белән Лобачевскийның аеруча нык дуслашып китүенә Магницкийның файдасы да тиде. Аның тарафыннан «зарарлы» дип бәяләнгән һәм утка ягарга хөкем ителгән китапларны Хәлфиннәр өенә

---

[1] «Азбука татарского языка» (1774), «Русча-татарча лөгать» (1785), «Краткая грамматика» (1785), «Татарский словарь» (1785) һәм башка китапларны язган.

[2] Ул да шактый гына китаплар язган; шулар арасында: «Азбука и грамматика татарского языка» (1809), «Хрестоматия» (соңгысы өчен аңа император бриллиант кашлы йөзек бүләк иткән).

икәү бергә ташыдылар. Хәзер инде бер сөйләшә башласалар, төн уртасы җиткәнне дә сизмиләр. Бу өйдә җырга, музыкага хөрмәт белән карыйлар, матур әдәбиятны күп укыйлар. Чәйдән башка нәрсә эчмичә, шулай матур итеп күңел ача белүләренә Лобачевский һәрвакыт сокланып карый һәм үзе дә уен-көлкегә бик теләп катнаша торган иде. Тик менә авыруы гына бераз вакытка ул йорттан мәхрүм итте. Ихтимал, шуңа күрәдер, бүген Лобачевский тизрәк барып җитәргә ашкынды.

Ләкин каршы искән көчле җил аңа кызу барырга ирек бирмәде, энә очыдай кар бөртекләрен битенә китереп бәрә-бәрә, башын читкә борырга мәҗбүр итте. Әле иртән генә шул кар бөртекләренең камиллегенә сокланып барган иде бит. Юк, монда яка күтәреп кенә эш чыкмаячак, «барабыз»га утырырга туры килер.

Балык базары мәйданында буш чанага утыргач, татар абзые, пар атның дилбегәсен тарткалап:

— Кая барабыз, кенәз? — диде.

— Иске Бистәгә, Ибраһим Хәлфиннәргә,— дип җавап кайтарды Лобачевский, битен якасы белән томалап.

— Әйдә, кузгалыгыз, малкайлар! — Абзый чыбыркысын чыжлатып бер селтәп җибәрде, атлар җитез генә элдертеп алып киттеләр. Болак аркылы салынган Татар күперен чыккач та, Кабан күле буйлап сулга борылдылар. Бераздан атлар Екатеринский[1] урамы белән ике арадагы тыкрыкка килеп керделәр һәм ике катлы йортның капка төбенә туктадылар.

Якында гына ак мәчет. Аның озын манарасыннан ишетелгән кечке азан тавышы, җил белән бергә, тәбәнәк өй түбәләреннән йөгереп үтте.

Лобачевский урам як ишекнең кыңгыравын тартуга, авыр ишек тупсасына чаклы ачылып китте. Хәлфиннең өстендә җилән, башында түбәтәй, ул бер кулына авыр җиз шәмдәл тоткан, икенчесе белән утны җилдән ышыклый.

— Кыңгырау тавышы ишетелүгә, «Николай Иванович килә» дип, Арсланбигебез бөтен өйне аякка бастырды,— дип көлә-көлә сөйләде өй хуҗасы.— Рәхим итегез, кадерле кунагыбыз булыгыз!

Алар иркен алгы бүлмәгә килеп керделәр. Николай Иванович өстеннән пальтосын салып элде һәм шунда ук үзен бер төркем кешеләр арасында күрде.

Кунак, елмаеп, кулын күкрәгенә куйды һәм, хуҗа хатынга үзе белгән татар сүзләрен әйтеп, сәлам бирде. Кара тут йөзле Хәбибҗамал ян бүлмәнең ишеге төбендә мөлаем гына басып тора, яшел ефәк чаршау арасыннан аның ак яулык бәйләгән башы һәм алтын беләзек кигән куллары гына аермачык күренә иде. Гәрчә рус телен начар белсә дә, Лобачевскийның татарча тырышып-тырышып сөйләвенә җавап итеп, русча эндәшергә булды:

— Здоров яхши? — дип елмаеп сорады ул.

— Яхшы,— дип татарча җавап кайтарды кунак һәм башын иеп: — Рәхмәт,— диде.

Хәбибҗамал, аның сулган йөзенә караган килеш, үзенең алсуланып торган бит алмаларын ике яктан кысып:

— Ай-яй, әфәндем! — диде һәм башын селкеп куйды.— Зачем не кушай?

Лобачевский көлә-көлә татар сүзләре эзләде. Шул вакытны әнисенең җилкәсе аша унҗиде яшьлек Гайнулҗамал карады. Европача киенгән сылу кызның башындагы милли калфагы да бик килешә. Калфагына беркеткән бик юка йон шәл үтәли калын кара чәч толымнары күренеп тора. Аның тезгә җиткән толымнары, зифа буе, кара тутлы нәфис йөзе сокланырлык матур иде.

[1] Хәзерге Тукай урамы.

— Charmante! [1] — диде Лобачевский, житкән кыздан күзен ала алмыйча һәм, шаяртып, ана шәрыкча башын иде.

Гайнулҗамалның йөзе тагын да ныграк кызарды һәм, ул, оялчан гына баш иеп җавап биргәч, әнисе белән янәшә басып торган гувернантка мадам де Фуасье артына ышыкланды.

— Ни өчен Николай Ивановичка җавап бирмисең? — дигән булды әтисе, шаяртып.

Хәлфин, шәмен сүндереп, жиз шәмдәлне почмактагы өстәлгә утыртты һәм кызына тагын нәрсәдер әйтергә теләде, әмма нәкъ шул чакта абыйсы артыннан Арсланбик атылып килеп чыкты.

— Николай абый! — диде ул, урамдагы кебек кычкырып.— Николай абый! — Аның энҗе белән чиккән кара түбәтәе такыр башыннан төшеп китте, үзе йөгереп килеп кунакның иелгән муенына асылынды.

— Исәнме, егет, саумы! — диде Лобачевский ягымлы тавыш белән. Малайны күкрәгенә кысып тоткан килеш, ул, иелеп, идәннән түбәтәйне алды.

— Мә, тот, түбәтәең!

Арысланбикнең авызы сизгән шул — кунак абыйсы бервакытта да буш йөрми, хәзер дә әле менә түбәтәйне чикләвек һәм конфет белән ике читеннән тотып, әнисе янына ашыкты. Лобачевский янына оялып кына озын зифа буйлы, яңа казаки һәм кара бәрхет түбәтәй кигән олы малайлары Салих килде. Аның артында уртанчылары — шаян гимназистлар. Шаһингәрәй белән Шаһиәхмәт профессорның игътибарын тартыр өчен, яна мундирларның күкрәкләрен киерә төшеп, әледән-әле шпагаларын рәтләделәр.

Шуннан Хәлфин:

— Ягез, кунак төшерү йоласын шуның белән тәмам итик! — диде һәм, кунакны култыклап алып, агач баскычтан өске өйгә — үзенең кабинетына юнәлде. Гимназист улы Шаһингәрәйгә: — Иптәшләреңне [2] ашарга дәшәрсең,— диде.

Кабинетка кергәч, Николай Иванович йомшак креслога утырды һәм портфеленнән кульязма тартып чыгарды.

— Ибраһим Исхакович,— дип, хуҗага мөраҗәгать итте ул,— сезнең ярдәмегезгә мохтаҗмын. Профессор Эрдман сезгә яхшы мәгълүм «Серләр магазины»н [3] немец теленә тәрҗемә иткән. Мин шул поэманы студентлар өчен уку китабы сыйфатында кулланырга тәкъдим керттем. Шуннан попечитель әмере белән университет Советы профессор Фукс белән икебезгә поэманың тәрҗемәсен тикшереп бәя бирергә кушты. Магницкий фикере буенча, мөселман шагыйре үзенең әсәрендә Инсус Христосны тиешенчә хөрмәтләп искә алмый икән.— Лобачевский ияләрен сикертеп алды.— Оригиналын белмәгәч, мин ул мәсьәлә хакында да, шулай ук тәрҗемәнең сыйфаты хакында да фикер йөртә алмыйм. Ә менә сез, Ибраһим Исхакович, гарәп-фарсы телләрен шәп белү өстенә немецчәне дә...

— Анысы немецчәне белүем sehr mittelmäßig [4].— дип, Хәлфин кунагының сүзен бүлдерде.

— Сез инде кирәгеннән артык тыйнак, Herr Chalfin [5]. Венада басыла

---

[1] Сокландыргыч (франц.).

[2] Хәлфин тәрбиясендә читтән килгән җиде татар малае булып, алар ишек алдындагы кече өйдә яшиләр һәм шуннан гимназиягә укырга йөриләр. Хәлфин аларның үзүләрен ничек тотулары һәм укулары белән даими рәвештә кызыксынып тора. Казан гимназиясендә татар балалары әлек-электән укысалар да, казна хисабына укучы христиан балалары белән бергә ашарга аларның хаклары булмый, ә Магницкий андый карарның төгәл үтәлүен бик тырышып күзәтә.

[3] «Серләр хәзинәсе» — әзербайҗан халкының бөек шагыйре һәм философы Низами Гәнҗәви (1141—1211) әсәре.

[4] Бик уртача, мактанырлык түгел. (Немец.).

[5] Хәлфин әфәнде. (Нем.).

торган «Fundgruben des Orients»[1] журналын укучылар, әйтик, борынгы ярлыкларга биргән аңлатмаларыгызны бик хуплап каршы алдылар,— диде Лобачевский, елмаеп.— Димәк, безгә дә ярдәм күрсәтә аласыз. Немец телендәге менә бу тәрҗемәне фарсыча оригиналы белән чагыштырып чыгарга кирәк. Шуңа өстәп, Ибраһим Исхакович, кайбер фарсы сүзләрен дә аңлатып бирсәгез иде. Мин аларны билгеләп үттем. Әйтик менә...— Профессор кульязманы ачты, андагы исемнәрне укыды:— Мөштәри, Һарут, Зөһрә дигән исемнәр...

— Анысын аңлатуы берни түгел аның. Мөштәри — Юпитер планетасы. Ләкин бу очракта күчермә мәгънәдә алынган: тапкырлык пәйгамбәре булырга тиеш. Һарут белән Марут — фәрештәләр. Ислам әһелләре өйрәтүенә караганда, ул ике фәрештә гөнаһлы адәм балаларына нәфрәт белән караганнар. Ходай тәгалә аларны сынар өчен, кеше сурәтенә кертә дә Җиргә иңдерә. Әмма фәрештәләр бик тиз сынаталар: Җирдә алар Зөһрә исемле бер бик гүзәл кызга икесе дә гашыйк булалар һәм гөнаһка батып бетәләр. Ходай тәгалә, ачуланып, аларны кыямәт көнгә кадәр чыкмаслык итә — төпсез коега сала. Ә менә аларның гөнаһ юлына кереп китүләренә сәбәпче булган Зөһрә чибәр һич тә гаепләнми, чөнки ул ару-пакь кала. Шуннан ул күккә аша, гүзәллектә тиңе юк таң йолдызы, сезнеңчә әйтсәк, Венера планетасы булып кала.

— Карагыз инде, Венера һәрвакытта да, антик легендалардагы төсле, җиңел холыклы булмаган икән бит,— диде Лобачевский, елмаеп.— Менә бит шәрык телләрен белмәү безне нинди бай әдәбияттан мәхрүм итә.

— Ай, рәхмәт, исемә төшердегез! — Хәлфин җитез генә урыныннан торды һәм шүрлектән яшел сафьян тышлы, бераз таушалган кульязма китапны алды.— Китап кибетендә һич уйламаган җирдән менә шуны таптым. Җәләлетдин Руминың «Мәснәви» дигән философик поэмасы. Нинди матур күчереп язганнар! Каллиграфияне тикмәгә генә сәнгать белән бер дәрәҗәгә куймаганнар шул.

Лобачевский ачык китапка күз салды. Озак еллар үтүгә карамастан, язуы бозылмаган, шул килеш сакланган. Николай Иванович соклануын әйтергә дә өлгермәде, Хәлфин китапны үзенә тартты.

— Хәзер мин сезгә кирәкле җирен табам. Тыңлагыз, менә нәрсә дигән:

Офтобе дар яке зарра ниһон,
Ногаһон он зарра бикшояд даһон.
Зарра-зарра гардад афлосу замин,
Пеши он хуршед, чун жаст аз камин.

Лобачевский елмаеп башын чайкады.

— Гафу, гафу, сез фарсыны белмисез бит әле. Мин тагын сезне шаккаттырмакчы булам,— диде Хәлфин, уңайсызланып.— Ярый, хәлдән килсә, тәрҗемә итеп карыйк.

Һәм ул, ачык китаптан күзен дә алмыйча, акрын гына мәгънәсен әйтә башлады:

Һәр атомда бер кояш яшеренгән,
Кисәк кенә ул атомның телгә килүе мөмкин.
Бөтен җирне вак-вак тузан итәр,
Яшеренгән кояш ирекә чыкса әгәр.

— Һәр атомда бер кояш яшеренгән! — дип дәртләнеп кабатлады Лобачевский. Ул урыныннан торып, бүлмә буйлап йөренергә керешге.— Һәр атомда... Кайчан яшәгән ул шагыйрь?

— Алты йөз ел элек. 1207 нче елны Кече Азиядә, Румда туган. Фамилиясен дә шуннан алган.

— Даһиларча алдан күрә белү түгелмени бу? — Николай Иванович

[1] «Шәрык гәүһәрләре». (Нем.).

креслосына кире килеп утырды. Өстәл өстендәге вазадан карандаш алганда вазаны чак кына идәнгә төшереп җибәрмәде.

— Кабатлагыз әле, Ибраһим Исхакович, хәзер үк теркәп куярга кирәк.

Хәлфин, әлбәттә, аның хәлен аңлый иде: тиз-тиз куен дәфтәренә язганын зур кызыксыну белән күзәтеп утырды.

— Кызганычка каршы, мин физик та, философ та булмаганмын. Шулай да бу шигырьнең поэтик нигезендә яткан фәлсәфәнең, фикернең искиткеч олылыгын күңелем белән сизәм.

— Үлемсез фикер! — диде Лобачевский, дәрткә бирелеп.— Бүгенге көнгә кадәр фән өчен дә сер булып килгән күренешләрнең асылын ачарга омтылу — кеше акылы өчен шуннан да олы теләк булыр микән!.. Бу чаклы кыю фикер!..

Ул куен дәфтәренә әле генә язып куйган юлларны яңадан пышылдап кабатлады. Аннары, тыныч кына утырып тора алмыйча, тирән уйга батып, озын һәм тар кабинетның буеннан-буена йөренергә тотынды.

Тынлыкны хуҗа бозды.

— Николай Иванович, без әле ул философ шагыйрь турында кабат сөйләшербез. Һәрхәлдә, ахыр сөйләшүебез булмас кебек. Әмма хәзер бит рамазан ае түгел, ураза тотмыйк, түбән төшик. Анда инде һәммәсе җыелып беткәннәрдер, безне көтеп утыралардыр.

Лобачевский йөрүеннән туктады, чәчен сыпырып алды һәм оялчан кыяфәт белән:

— Гафу үтенәм. Бераз уйга калынган. Әйдәгез! — диде.

Иркен генә ашау-эчү бүлмәсе. Биек тәрәзә төпләрендәге чүлмәкләрдә бальзамин һәм яран гөлләре үсеп утыра. Бер стенада кыйммәтле рамга шамаил язып куелган. Аннан тыш, гәрчә шәригатькә сыеп бетмәсә дә, табигать күренешләрен сурәтләгән картиналар да бар. Ике диван арасында пыяла шкафлар булып, алар эченә матурлап чынаяклар тезелгән.

Озын өстәл тирәсенә чыннан да ир-ат халкы җыелып өлгергән: Хәлфиннең үз уллары һәм аның тәрбиясендәге гимназистлар өй хуҗасы белән кунакны олылап, аяк өсте көтеп алдылар. Шәригать ирләрдән йөз яшерергә кушканлыктан, бүлмәдә хатын-кыз күренмәде.

Лобачевскийны иң түргә, хөрмәтләп, йомшак мендәргә утырттылар. Хуҗа үзе өстәлнең аргы башына утыруны кирәк тапты: аннан аш өендәгеләргә әмер бирергә җайлы иде. Аш-суны олы малае Салих ташып торды. Асрауларны чыгармадылар.

Бу йортта тәмле ашыйлар, күп ашыйлар. Гадәтләре шулай. Башта чәй янына баллы сумсалар, корт, май куела, аннары пилмән, аның артыннан өчпочмак, гөбәдия килә.

Лобачевский бу өйдә үзен бик иркен тота. Гимназистлар да, күрәсең, ияләшеп җиткәннәр — һич тартынмыйлар кебек. Ә инде кадерле кунак белән янәшә утырган Шаһингәрәй — Хәлфиннең гимназист улы — кунакны кыстаудан бушамый.

— Менә монысыннан җитешегез әле, Николай Иванович, каймаклы катыктан... Монысы тозлы карбыз... Юк-юк, сез әле авыз итмәдегез: бозау теле ул... Николай Иванович, безнең халык: «Аш ашка, урыны башка», ди. Барыннан да авыз итәргә кирәк.

Лобачевскийның елмайганын күреп, малай кычкырып көлеп җибәрде. Табын янында нинди әдәпсезлек ул, дигән сыман, әтисе аңа күз кырые белән генә карап куйды. Уңайсыз хәлдән малайны кунак үзе коткарды.

— Ибраһим Исхакович, Шаһингәрәй минем гимназиядә казна исәбенә укыганымны белми икән әле,— диде, аның җилкәсенә кулын салып.— Ниг ъмәттән баш тарта торган кеше түгел мин, Шаһингәрәй. Сезгә килгәч, кыстатып утырмыйм инде: татар ашларын аеруча яратам.

— Алай булгач, минә монысыннан житешегез әле,— диде малай, куанычын кая куярга белмичә, һәм өсте ябык ниндидер мискине аңарга якынрак китерде.

— Юк инде, бүтән урыным калмады,— Лобачевский баш тартырга мәжбүр булды.— Бер стакан катык кына эчәм дә, гәп корып жибәрербез.

— Фән турындамы?

— Әйе, фәнне дә читтә калдырмабыз.

Гимназистлар, ашаудан туктап, аңа таба борылдылар.

— Кичә гимназиягә кергән идем, татар һәм башка милләт малайларының ничек укулары белән кызыксындым. Кызганычка каршы, сезнең халык анда аз укый. Шулай ук, кызганычка каршы, мактанырлык урыныгыз да юк. Икенче бер телдә укуы жиңел түгел икәнен аңлыйм мин. Тик минә шуннан чыгып кайберәүләр: азчылык милләт балалары укуга сәләтсез, дигән нәтижә чыгарсалар, күңелсез булыр. Андый нәтижәне сез чыгарттырмаска тиешсез. Халкыгыз борын-борыннан белемгә омтылган. Аталарыгыз, бабаларыгыз нинди зур кыенлыкларны жиңеп укырга тырышканнар...

Озын жиз шәмдәлләргә утыртылган шәмнәр профессорга карап сүзсез калган яшүсмерләрнең борчулы йөзләренә тоныкк кына якты сипте. Бу сөйләшү аларның хәтерләренә мәңге онытылмаслык булып кереп урнашты.

Табын яныннан дәррәү кузгалдылар. Гимназистлар кече өйгә чыктылар, ә хужалар исә кунак бүлмәсенә, икенче катка мендeләр.

Хәлфиннәрнең бу бүлмәләре кечерәк кенә бер музей төсле иде. Иңе жиргә асылган зиннәтле шәмдәлләр бүлмәне мул итеп яктырталар. Идәнгә зур палас жәелгән, ә стеналарга бизәкле ефәк тотылган. Бер башта шундый ук ефәк чаршау корылган.

Лобачевский стена буена тезелгән шкафлар янына килде. Кызыл агачтан эшләнгән бу биек шкафларда милли музыка кораллары саклана. Хәлфин аларны озак еллар буе жыеп килә. Берәр жирдә сирәк очрый торган уен коралы барын ишетсә, хәзер шунда чыгып китә, ерак дип тормый.

Бу сазларны, кифарларны, кош сөягеннән эшләнгән флейталарны, тыйбелләрне, быргыларны, карнайларны, курайларны, нәккарларны, гөсләләрне, озын һәм кыска смычоклы скрипкаларны Лобачевский һәрвакыт бик рәхәтләнеп күздән кичерә. Шкафлардан читтәрәк заманасына күрә яңа клавесин тора.

— Хәзер дә коллекциягезне тулыландырасыз булыр? — дип кызыксынды Лобачевский.

— Әлбәттә, шулай,— диде Хәлфин һәм дәртләнеп сөйләргә кереште.— Үзем дә читкә чыккалыйм, эзлим, сорашам. Кайчак өйгә үк китереп бирәләр... Бушлай түгел, әлбәттә... Минем бабай скрипканы бит үзе ясаган. Менә нинди шәп нәрсә! — дип, Хәлфин бер шкафтан алтынсу-сары төстәге скрипканы алды.— Бабайның үләр алдыннан ясап калдырган соңгы скрипкасы,— диде ул акрынрак тавыш белән.

Скрипканы сул кулына күчереп, ияы белән смычокка сузылды. Һәм шулвакыт аның нечкә нәфис бармакларының берсендә патша бүләк итеп биргән бриллиант кашлы йөзеге жемелдәп күренеп китте.

— Менә аның яраткан көе,— диде ул уйчан кыяфәт белән.— Борынгы көй...

Смычок кылга юнәләп кагылырга да өлгермәде — скрипка моңлы бер озын көйгә сузып жырлап та жибәрде. Бу көй Лобачевский моңа кадәр ишеткән борынгы көйләрдән ничектер аерылып тора иде. Хәлфин, уйнавына бирелеп китеп, бөтенләй онытылды, еш-еш сулу алды, күзен яшь пәрдәсе томалады. Ниһаять, смычок борынгы скрипканың кылларын соңгы тапкыр сызып алды да, бриллиант кашлы йөзек кигән кулга

ияреп, түбән төште. Ләкин аннан соң да әле шактый вакыт бүлмәдә тынлык сакланды, гүя һәркем үзенең йөрәк тибешен ишетә иде.

Хәлфин беркемгә дәшми, беркая карамый — аның скрипка һәм смычок тоткан куллары хәлсезләнеп салынып төшкән.

Лобачевский беренче булып исенә килде һәм Хәлфинне кысып кочаклап алды.

— Рәхмәт, дустым! Зур рәхмәт! — диде ул, татарча. Аннары дулкынлануын яшерә алмыйча һәм яшерергә дә теләмичә:

— Ибраһим Исхакович, сезнең уйнавыгыз минем кебек корыган-кипкән математикны да әллә нишләтеп җибәрде. Тагын уйнасагыз иде,— дип үтенде.

Хәлфин тирән итеп бер сулап куйды, скрипкасын назлап кына күкрәгенә якынайтты һәм смычок тоткан кулын югары күтәрде. Бу юлы скрипкага ияреп нечкә һәм саф бер тавыш җырлап җибәрде. Көтелмәгән бу матур тавыш кунакны борылып карарга мәҗбүр итте. Яртылаш ачылган чаршау янында ана белән кыз басып торалар. Гайнулҗамал музыка тәэсиренә бирелеп, үзе дә сизмәстән, җырларга керешкән иде. Аның саф тавышы скрипка моңын тагы да гүзәлрәк итте. Көй беткәч, кыз оялып тизрәк чаршау артына яшеренергә теләде, әмма Лобачевский аны туктатып калды:

— Бик матур җырладыгыз, тик барын да аңлап җиткерә алмадым. Сөйләп бирегез әле,— дип үтенде.

— Татар кызының киләчәк караңгы язмышы турында сөйләнә бу җырда,— дип, кызы өчен Хәлфин үзе җавап кайтарды һәм шуннан соң кинәт дәртләнеп башын селкеп алды.— Нәрсә булды соң әле миңа? Хәзер инде берәр күңелле көй уйнарга кирәк. Тыңларга теләгегез бармы? Ягез әле, балалар, «Җизнәкәй»не җырлагыз әле.

Гайнулҗамал белән Салих бер-беренә карашып алдылар һәм, көлешеп, бүлмә уртасына кара-каршы чыгып бастылар. Хәлфин смычогын күтәрде — кунакны таң калдырып, күңелле шаян көй яңгырады. «Җизнәсенә» хәйләле караш ташлап «балдыз» җырлый башлады.

— Тау башында дүрт казык,
Җизнәкәй,
— Тау башында дүрт казык,
Җизнәкәй...

Салих яна чыга башлаган мыегын бөтергән сыман итте, бөеренә таянды һәм җырның дәвамын җырлады:

— Бер үпкәннән юк язык,
Балдызым-ялгызым.

Аннары ул гайрәтләнеп аяк тибеп алды, як-ягына каранды. Башкалар да кушылып, күмәкләшеп аның сүзләрен кабатладылар:

— Бер үпкәннән юк язык,
Балдызым-ялгызым.

Яшьләрнең чын күңелдән кәефләнеп китүе, җырлашуы Лобачевскийга да тәэсир итми калмады. Ул рәхәтләнеп көлде, җырның ләрым сүзләрен хәтта кабатлатып та карады. «Нинди күңелле бит халык көе, бернинди ясалмалылык, фальшь юк»,— дип уйлап алды ул.

«Балдыз», күзләрен уйнатып, «җизнәсенә» бер карап куйды:

— Аякларың ник кәкере,
Җизнәкәй?
— Аякларың ник кәкере,
Җизнәкәй?..

Салих уңайсызланып җавап кайтарды:

— Читек-кәвеш кигәнгә,
Балдызым-ялгызым...

Җыр белән, уен-көлке белән кышкы озын кичнең үткәне сизелми дә калды. Ашау-эчү бүлмәсендә тагын самовар күренде. Чәйдән соң, йоклар алдыннан, шау-гөр килеп саф һавага чыктылар.

Лобачевскийның бик күптәннән бу кадәр тыныч, каты йоклаганы юк иде.

Хәлфин таң атып җиткәнче ук, кулына шәм тотып, йокы бүлмәсенә, кунагын уятырга керде.

— Николай Иванович, сәгать биш тулды. Чын балыкчылар юлдадыр инде, безгә дә кузгалсак ярар.

Лобачевский тиз генә торып утырды. Ишек алдыннан тавышлар ишетелә: анда кирәк-яракларны, азык-төлекне хәзерләү белән мәшгуль иделәр, күрәсең.

Хәлфин бер кулына ялт иткән җиз таз, икенчесенә шундый ук комган тотып керде һәм җылы су белән кунагының битен-кулын юдырды. Ашау-эчү бүлмәсендә инде өстәл өстендә самовар җырлап утыра, мичтә чытырдап коры каен утыны яна — боз каткан тәрәзәләргә алсу шәүлә төшә. Җылы өйдә утырганда, тышта салкын кыш булуына да ышанасы килми иде.

Лобачевский аннан-моннан гына капкалап, тизрәк юлга чыгарга теләде — аның күңелендә хәзер бернинди уйлану яки борчу да калмады.

Алар, икесе дә аякларына җылы киез итекләр, өсләренә бәрән толыплар, башларына колакчын бүрекләр киеп, ишек алдына чыктылар. Болдырга чыгу белән салкын битләрне чеметеп алды, тынны кысты. Лобачевский тирә-ягына күз салды. Төн буе буран котырмаган диярсең. Койма буйларына өелгән көртләр генә ул буранны хәтергә төшереп тора. Болдырдан капкага чаклы киң итеп юл ачылган.

Юлчылар җыенып беткәләгәнче, күк йөзе акрынлап яктыра да башлады. Хәзер инде тимер ишекле таш амбар да, бүрәнәдән өелгән абзарлар да, өсте ябулы кое да гүя берәм-берәм йокыдан уяндылар — караңгылык сөременнән калкынып килеп чыктылар. Ләкин боларның берсе дә Лобачевскийны гаҗәпләндермәде. Аны таңга калдырган нәрсә ачык калдырган капка алдында торучы «экипаж» булды. Озынчарак җиңел чанага... дүрт таза эт җигелгән иде. Алар тартылалар, йөгереп китмәкче булалар, Салих көчкә тыеп тора, сыйпаштыргалап тынычландыра иде.

Хәлфин чана тирәли, әйберләр төшеп калырлык түгелме, нык бәйләнгәнме дип, тикшереп йөрде. Этләр аңа сыена башладылар, түземсезләнеп шыңшыдылар. Алга җигелгән зур ак эт алгы аякларын аның күкрәгенә ук куйды.

— Хәерле иртә, Акбай! — дип, хуҗасы аны башыннан сыйпады.— Хәзер кузгалабыз, дустым...

Кунакны җайлап утырткач, үзе алга килеп утырды һәм:

— Акбай, алга! — дип кычкырды.

Этләр җилдереп алып Кабан күленә таба киттеләр. Алар озын каешка пар-пар итеп бәйләнгәннәр иде. Юл таныш: Казанканың Иделгә койган җиренә тизрәк барып җитәргә кирәк, анда балык ашатачаклар...

Кар бураны туздырып, түшләре белән көрт ерып этләр күлнең ярыннан төштеләр. Кушканны да көтмичә, Акбай чананы Болакка өстерәде.

Тиздән Татар күпере, анда ыгы-зыгы килгән халык — мичкә белән су ташучылар, иртәнге базарга ашыгучы крестьяннар һәм шулай ук шәһәр халкы күренде. Этләр өчен, күрәсең, бу юл таныш иде, алар Болак бозы өстеннән дә очыртып кына бардылар. Кремль турысында Акбай үзе белеп Казанкага борылды.

Бозга туңган баржалар, пароходлар кышкы йокыга талган сыман күренәләр, аларның озын һәм төз мачталарында җил уйный иде.

Көнчыгыш якта, арык өстендә, кызыл сызык сызылды, алтынсу түгәрәк кояш кабынды.

Бистәгә җиткәнче юл тигез барды: төнге буран елга аркылы көртләр өймәгән. Таза, көр этләр бик теләп, ашкынып юырттылар.

— Бик күңелле икән болай баруы! — дип куйды моңа кадәр сөйләшми генә килгән Лобачевский.— Эскимослардан көнләшеп алдым әле. Очырталар гына бит! Әллә инде миңа да этләр асрый башларга?

Хәлфиннең йөзе яктырып китте.

— Мәшәкатьле нәрсә бит,— диде ул.— Өйрәтүе кыен. Минем Салих оста андый эшкә — ул өйрәтте. Безгә шул да җиткән бит, фәкать ешрак балыкка чыгарга гына кирәк.

— Бик рәхәтләнеп. Һәр якшәмбедә чыгарга мөмкин.— Лобачевский шулай да толып якасын күтәрде һәм бүреген батырып киде.— Бер өйрәнеп китсәм...

— Минем күптән чыккан юк, сагынып беттем инде,— дип, Хәлфин дустына таба борыла төште.— Кышын балык чиртәмени? Йоклый ул балык, ашарга да эзләми. Хәзер һәммәсе уянды. Алабугалар, судаклар котә безне. Ачка интегеп беткәннәрдер, бичаралар. Мин нишләдем, кармак бавына кызыл чүпрәк бәйләп куйдым — хәзер алар, һичшиксез, кызыл канат дип алданачаклар. Сезнең кармакка да чүпрәк бәйләдем, кайгырмагыз.

— Рәхмәт,— диде Лобачевский.— Кәефем күтәрелеп китте әле... балык тотмас борын...

Чәрелдәп кычкырган тавышка ул сискәнеп куйды. Яшь кенә татар хатыны көянтәсен, чиләкләрен ташлап, читкә тайпылды. Аның артыннан суга килгән башка хатын-кызлар да йөгерешә башладылар. Акбай моны ошатмады, ырылдап алды. Ләкин суга дип бәкегә килгән хатын-кызлар тамашаның асылын аңлап, балыкчылар артыннан көлешеп калдылар. Лобачевский, елмаеп, аларны күзәтеп барды. Кама бүрекләр, билле туннар һәм бишмәтләр кигән ул хатыннар озын зифа буйлы булып күренделәр. Ап-ак чигүле киез итекләр аеруча матурлык өсти, бәйрәмчә төс бирә иде.

Тиздән балыкчылар кечерәк кенә бер татар авылына — Бишбалтага килеп керделәр. Бу авыл үзенең урманнары белән мәшһүр. Мондагы халык бөтен Идел буен ишкәкле җинел суднолар белән тәэмин итә. Петр I тикмәгә генә Усиядә суднолар төзү өчен верфьләр кордырып җибәрмәгән. Шуннан бирле монда Каспий диңгезе һәм Балтик диңгезе флотларына бомбардир кораблары һәм канонер көймәләре дә, тиз йөрешле фрегатлар да, сугышта житез бритлар һәм люгерлар да, шулай ук транспортер һәм галиотлар да эшләнә. Шул чорда ук канатный һәм пороховой заводлар төзелгән, тире эшкәртү эше башлап җибәрелгән. Кораблар төзү өчен яраклы наратларны кисеп, адмиралтейство тирәли казылган тирән чокырларга салып «тозлыйлар» икән.

Хәлфин үзенең этләрен гаять зур агач каралты янына туктатты. 1767 нче елда Екатерина II Казанга утырып килгән галера — борынгы ишкәкле хәрби судно — шуның эчендә саклана икән. Этләр, тelләрен чыгарып, кар өстенә яттылар.

— Ибраһим Исхакович, кереп карыйк әле,— диде Лобачевский, чанадан төшеп, авыр толыбын сала-сала.— Күптән шуны күрергә хыялланып йөрим.

Ул житез генә иелеп, стенаның ике тактасын кубарып, ике якка этәрде һәм, ярамаган эш эшләгән малайлар кебек, як-ягына карангалап, эчкә кереп тә китте. Ярыклардан төшкән яктыда галераның яшел буявы да, алтын йөгерткән бизәкләре дә, «Тверь» дигән язуы да аермачык күренде. Кысан җирдә булганга, ул гаҗәп зур сыман тоелды. Ике кат-

нын өскесендә әби патша үзенә зал һәм бүлмәләр эшләткән, аскы катта сарай кешеләренә дигән сигез бүлмә. Крепостной ишкәкчеләргә андый хөрмәт тимәгән.

— Николай Иванович,— диде тышта калган Хәлфин, ашыктырып,— миңа этләр яныннан китәргә ярамый, ә вакыт үтә бит...

Тарихи экспонатка соңгы тапкыр күз салып, Лобачевский кергәндәге шикелле үк житезлек белән кире чыкты һәм такталарны иске урынна-рына тартты. Кояш югары күтәрелгән, күзне бик нык чагылдыра иде. Николай Иванович, кесәсеннән трубкасын чыгарып, көйрәтә башлады.

— Утырыгыз инде, Николай Иванович,— дип ашыктырды Хәлфин.— Яхшы урыннардан колак кагарбыз.

Алар чанага утырып, Хәлфин команда бирүгә, кояшта жылынып, хәл жыеп яткан этләр сикерешеп тордылар һәм тагын да юрттырыбрак алып киттеләр. Яр буенда үсеп утырган наратлар, калын кар баскан тармакларын акрын гына селкеткәләп, балыкчыларны озатып калдылар.

Кояш торган саен югарырак сикерде, яңа яуган карга, гомумән, карап булмый башлады. Лобачевскийның талчыккан күзләре яшьлән-де, Хәлфин дә күзен кыскалады. Бер-берсенә эндәшми генә барсалар да, аларның күңелләре тулы шатлык иде.

Боз каплаган елга һәм чана табанының ара-тирә шыгырдап куюы Лобачевскийның уйларын бала чакларына, ерак Нижний Новгородтагы тәбәнәк өйгә алып киттеләр.

Аның уйларын Хәлфин бүлде.

— Ни өчендер боега башладыгыз түгелме, дустым? — диде ул, борылып карамыйча гына.

— Мин боега башладыммы? — дип кайтарып сорады Лобачевский һәм татарча сүз кыстырды:— Ялгышасыз, туганым. Дөрес әйттем ши-келле?.. Күңелемдә фәкать якты уйлар гына. Бала вакыттагы күңелле вакыйгалар искә төште. Шуларга бәйләп сезнең турыда да уйлап ал-дым. Беләсезме, без ни өчен болай дуслашып киттек? Белмисез, әлбәт-тә. Үзем дә менә хәзер генә ул сорауга җавап таптым.

Тавышына карап Хәлфин Лобачевскийның елмайганын аңлады. Алай гына да түгел икән — Лобачевский көлә-көлә сөйләргә кереште:

— Исемегез тылсым көченә ия сезнең. Минем гомердә өченче Ибра-һим сез. Икенчесе шагыйрь һәм математик Ибраһимов булды. Иң бе-ренчесен күрергә туры килмәде, Ибраһим дигән кешенең Нижний Нов-городка нигез салуы турында ишеткәнем генә бар. Тыңлыйсызмы, сөйлимме, Ибраһим турындагы легенданы?

— Минем халык теленә кергән шундый адашым бармыни әле? Хәлфин кисәк кенә борылуга, чана бераз чайкалып куйды һәм бер якка янтайды.

— Хәзер сөйлим, чананы гына әйләндереп капламагыз,— диде Ло-бачевский, шаяртып.— Бик борынгы заманда Кудьма елгасыннан, бол-гар населеннән чыккан минем беренче Ибраһимым. Ока елгасының Иделгә койган урынында, Тукран тавына барып урнашкан. Ул вакытта әле тау башларын куе урман каплаган булган. Урман кисеп, ундүрт улына һәм өч кызына йортлар житкезгән, хәзер Нижний Новгородта ул урында архиерей йорты. Әнә шулай Ибраһим шәһәре барлыкка килгән, ул үзе башлык булган.

— Тагын нәрсә эшләгәннәр? — диде Хәлфин, түземсезләнеп.

— Тагынмы? Суздаль, Муром, Рязань гаскәрләре һөжүм иткәләгән-нәр. Ибраһим, халкы белән бергә, шәһәр тирәсенә ныгытмалар эшләгән. Ә халкы 500 кешегә житкән... Легенда шуннан артыгын сакламаган. Тик миңа шул да житкән иде. Малай чагымда мин яраткан батырыма әллә нинди каһарманлыклар уйлап чыгара, төшемдә дә, өнемдә дә сата-шып бетә торган идем. Казан гимназиясендә укыган чакны мондый бер вакыйга булды.

Фикерен туплаган сыман, Лобачевский бераз вакыт тынып торды. Хәлфин аның сөйләп бетергәнен сабыр гына көтеп утырды.

— Бер вакытны тәмам күнелем бизгән класска килеп керсәм, гимназистлар ыгы-зыгы киләләр. Васнецов дигән укытучыны куганнар, аның урынына Ибраһим дигәне керәчәк икән. Тәнем эссele-суыклы булып китте. «Теге Ибраһим нәселеннән түгел микән?» — дип уйлап алдым. Нәкъ шул вакыт класска яңа укытучы килеп керде. Ул безгә дөньяда ничә төрле халык яшәсә, исеме шул чаклы күп, ә фамилиясе бер генә икәнне әйтте. Юк-бар кеше түгел иде ул. Ә минем күз алдымда легенда героеның оныкларыннан берсе булып гәүдәләнде. Серемне кешегә сөйләмәдем. Яна укытучы минем өчен иң батыр, иң көчле кеше булып китте... Аның әйткән сүзе закон булды. Бервакыт мин Ad Melpomenen шигырен сөйләдем. Ибраһимов бөтен класс алдында мактады үземне: «Лобачевский, сез, һичшиксез, шагыйрь, я математик булырсыз»,— диде. Бу сүзләр мина язмыш тавышы булып ишетелде, дәрт бирде, канат үстерде. Ихтимал, үзем ирешкән уңышлар өчен мин аңа бурычлымын...

Лобачевский уйга калды. Аннары кинәт кенә кулын сузып Хәлфиннең беләген кысты.

— Хәзер минә өченче Ибраһимым,— диде ул.— Сезнең белән булу минем өчен зур бәхет. Гомердә дә мондый турылыклы дустым булганы юк иде...

Лобачевский тынып калды. Хәлфин дә эндәшмәде.

Идел бозына аяк басып, еракта Ослан таулары күренгәч, этләр бердәм туктап калдылар, килеп житүләренә сөенеп, койрыкларын болгарга тотындылар.

Хәлфин чанадан сикереп төшеп, бер сүз дә әйтмичә, Лобачевскийга кулын сузды. Лобачевский чанадан да төшәргә өлгермәгән иде әле. Сүзсез генә шулай кул кысышу аларның күнелләрендәгене әйтеп бетерде шикелле.

— Иске урынны минем «атлар» үземнән яхшырак беләләр,— диде Хәлфин, шактый вакыт дәшми торгач.— Шунда туктарга булдыгызмыни, малкайларым?

Аның шаяртып әйткән сүзләре һәр икесенә җиңеллек китерде. Чананың бауларын чишеп, кирәк-яракларны алдылар.

— Бу турыда Иделнең төбе калкурак,— дип төшендерде Хәлфин.— Март аенда эре-эре алабугалар чыккалый: сулышларына җайлырак урындыр, күрәсең.

Хәлфиннең кулы кулга йокмады: тиз генә этләрен тугарды — алар шунда ук кар өстендә тәгәри башладылар; чанасын ярга якын бер урынга урнаштырды һәм, авыр үткен сөймән алып, бәке тишәргә кереште.

— Ибраһим Исхакович,— диде Лобачевский, кызыгып,— мин дә сөймән белән эш итә белүемне күрсәтим әле, бирегез әле.

Калын каты боз алай тиз бирешмәде, ике бәке тишкәнче сөймән берничә мәртәбә кулдан кулга күчте.

Менә Хәлфин, бәке тирәсен чистартып, җыелма урындыгын куйды һәм тире бияләе белән маңгаеннан тирен сөртте.

— Николай Иванович, сезнең бәкенең дә эше бетте. Хәзер утырсагыз да ярый. Тик, зинһар өчен, толыбыгызның төймәләрен ычкындырмагыз. Биш-ун минуттан җылы җитми башлаячак.

Кармак бауларын сүтеп, һәркем үз бәкесенә иелде. Ак кургаштан коелган балык-блесналар бөтерелә-бөтерелә төпкә чумдылар. Бу тынлыкта кар өстендә йоклап яткан этләрнең тын алулары да ишетелә иде.

Көтмәгәндә Хәлфин кулын югары күтәрде — зур гына алабуга балыгы карда сикерәнә башлады.

— Кулыгыз җиңел булсын, Ибраһим Исхакович,— диде Лобачевский һәм кинәт үзе дә калкынып куйды — бәкедән икенче алабуга килеп чыкты. Гәрчә монысы бераз кечкенәрәк булса да, Николай Ивановичка бик зур булып күренде. Ул балалар кебек шатланды, йөзенә елмаю чыкты.

Болытлар арасына качкан кояш күренде, һәм яңа яуган карның һәр бөртеге якут төсле җемелди башлады. Кинәт кенә Лобачевскийның хәтеренә борынгы шәрык шагыйренең сүзләре килеп төште: «Һәр атомда бер кояш яшеренгән...» Алабуганың өстен көмешсу бәс каплады, тик Лобачевский, туп-туры карап торса да, моны күрмәде. «Нәрсә соң ул атом? Кояш системасына охшамаган микән аның төзелеше? Үзәге Кояш кебек булып, кисәкчәләре планеталар шикелле урнашмаган микән? Планеталар белән Кояш арасындагы кебек, болар арасында да тарту көче яшәмиме икән?..»

Салынып төшкән кулыннан кармак бавы ычкынганны да тоймады: аның уйлары бик еракта иде.

«Ләкин атом эчендә барган үзара мөнәсәбәтләрнең микъдары чиксез кечкенә, Җир белән чагыштырганда нуль дияргә мөмкин... Димәк, безгә мәгълүм механика законнары анда үз көчләрен югалталар... Әгәр атом эчендә Евклид геометриясе дөрес булып чыкмаса... Әгәр анда махсус геометрия, яңа геометрия генә яраса...»

Лобачевский кинәт кенә бөтенләй хәлсезләнде, урындыгыннан көчкә егылып төшмәде, алга иелгән килеш гәүдәсе хәрәкәтсез катып калды.

Хәлфин исә аңа карап елмаеп куйды: «Кара нинди яхшы булды бу! Математик чынлап торып ял итә. Күзен калкавычтан алмый. Күптән монда алып килергә булган».

Дустының яхшы ял итүенә сөенеп, Хәлфин әнә шулай уйлады. Хәер, ул вакытта әле, моннан йөзләрчә ел элек, Лобачевский үзе дә сизмәстән, томан эчендәге кебек кенә, кешелек дөньясының бөек ачышын — атом энергиясен ачу идеясен төсмерләгәндер дип кемнең башына килсен икән...

Лобачевский шактый озак шулай хәрәкәтсез утырды. Балык тотуда аның гүя бөтенләй кайгысы юк иде.

# Фаил Шәфигуллин

## Ышанмагыз, авылдашлар

Читтә тормыш яхшы, диләр,
Ышанмагыз, авылдашлар.
Кызыкмагыз, авылдашлар,
Киткәннәргә авылын ташлап.

Кайда да бер кояш, диләр,
Ышанмагыз, авылдашлар:
Безнең авыл өстендәге
Кояш якты бар кояштан.

## Йолдыз

Иң якты йолдыз атылгач,
Йөрдем мин илдән илгә.
Ятадыр, дидем, сүнмичә,
Бәлки, ул йолдыз җирдә.

Юлымда күрдем матур кыз,
Сорадым: «Синме йолдыз?»
«Әйе, йолдыз, ләкин сиңа
Нур сипмәм»,— диде ул кыз.

Синдер, ахры, йолдыз, дидем,
Баш идем нәфис гөлгә.
Гөл әйтте: «Йолдыз йолдызың,
Тик күзгә кадәр генә».

Күз ташладым килгән юлга,
Кичкәч утлар-сулар мин:
Йолдыз булып балкый иде
Бик еракта туган ил.

## Этюд

Алтын иген шаулый кырда,
Җете зәңгәр күкләр хәзер.
Мондый көндә кешеләрне
Кайгыларга салмыйм әле,—
Дигән сыман посып тора
Тау астында ялгыз кабер...

## Миләш

Алмаларын ташлап йөгерделәр
Алмагачлар,
Җилләр: «Һоп!» дигәч.
Яшел төймәләрен учлап калды
Тау астында моңсу бер миләш.

Кояш иркәләде ул миләшне,
«Чумып торма,— диде,— сагышка;
Бар, бар, йөгер, әле күзгә ерак,—
Төрле хәлләр була чабышта».
Очкан чакта кошлар чөкердәшеп,
Узар икән, диешеп, кем-кемне? —
Көз юлында алмагачлар түгел,
Кызыл чәчле миләш күренде.

## Өмет

Ике нарат үскән таудан
Соңгы карлар эреп ага.
Зурлар көлсәләр дә, сабый
Тартып чыга һәр көн чана.

Ике нарат үскән таудан,
Шул таудагы ялтыр кардан
Күз дә алмый... карый һаман...
Ә кар бер уч кына калган.

Ике нарат үскән таудан
Соңгы карлар эреп ага.
Утызынчы яз тауга карап
Улын көтә ялгыз ана.

## Төнге смена

Цехлар җырлый — имеш, тимер җырлый...
Төннәр буе җырлар агыла.
Алсу утлар — имеш, көләч йөзләр...
Ну, язып та карый шагыйрьләр.
Башың авыр була чуен шардай,
Мондый чакта кешегә җыр тагын!..
Эшче иптәш, син беләсең инде
Төнге сменалар газабын.
Әрсез йокы яшереп кочагына,
Күзләреңә агып керә төн.
Тамырларың, буыннарың йоклый,
Йокламый тик аңың, йөрәгең.
Романтика бар ул һәр җирдә дә,
Әмма ләкин шуны белегез:
Без цехларга төнлә
Җырлар җырлар,
Җырлар тыңлар өчен килмибез.
Унҗиденче елны кабынып киткән
Утлар яна безнең цехларда.
Без аларны әле көне-төне
Сүндермичә тиеш сакларга.

## Эдуард Мостафин

### Язмыш тәрәзәсе

Мен мәртәбә үлдем, мен мәртәбә
Исән калдым тормыш яратып.
Язмыш дигән йортның тәрәзенә
Бер карыйсы булдым кар атып.
...Челпәрәмә килде тәрәзәсе,
Сүнгән уты кабат янмады,
Тәрәзәдән кергән усал җилләр
Идәннәргә ятып аунады.
Калтыранган салкын кулым белән
Ут кабыздым тәрәз төбенә.
Китерер кебек бу төн кемнәрнедер,
Бер могҗиза көттем төн белә.
Ут яктысы сузылып төште җиргә,
Тәрәзәдә шәүләң чагылды.
Уйларымны төн куенына бәреп,
Иннәремә кулың кагылды.
Каз канатымыни, йомшак куллар
Иркәләде матур җыр булып.
Пәрдә тарткан төнге тәрәз сыман
Ике күзен калды йомылып...
Ә урамда айсыз күктән төшеп
Ак кауҗлар җиргә сибелде.
Җил ашыкты никтер, төн үткәнче
Эзләренне карлар себерде.
Могҗизасы белән килде бу төн —
Яңа тәрәз куйдым язмышка.
Ә йөрәгем пышылдады: «Язны
Инде күптән тоям бу кышта».

1969

### Көймә

Көн буена хуҗасын көтә көймә —
Көнләшәдер аккан саллардан.
Тыныч кына тирбәлә ул ярда
Куркәккәен төреп талларга.
...Ташланасы килә давылларга
Акчарлаклар очар тизлектә.
Шул кошлардай талпынасы иде!
Канатларны җәеп киңлектә.

Көтә көймә, бәйдәге эт кебек,
Көннәр буе көтә хуҗасын.
Ярны ташлап давылларга чыкса,
Онытыр иде бәлки нужасын...
Көч алгандай шунда ярсып куя,
Ишкәкләрен җәя канаттай:
Дулкыннарда очып йөрер иде,
Үрләр аша атылган аттай.
...Давыл үтте, тынды дулкыннар да.
Көймә һаман бәйдә, комлыкта.
Тавыш-тынсыз гына давыл көтә,
Киңлек көтә тирән тынлыкта.

1969

●

Көн эчендә никадәре әйбер;
никадәре исләр,
Никадәре төсләр үзгәрә.

*Флусәгә*

Кичә шат иден, ят иден син,
Ә бүген нигәдер сагышлы,
Ә бүген син миңа кадерле —
Чәчеңнән сыйпадым, сөйдем мин.
Ә кичә күңелдә боз иде.
Елгада боз иде бит кичә,—
Ә бүген көймәләр көтүе.
Әй казлар очтылар тезелеп,
Кичәге болытлар шикелле.
Тик кичә мин газап утында
Шигырьләр язалмый тилмердем,
Ә бүген,
Ә бүген күңелдән
Шигырьләр кәрванын кичердем.

1969

●

Яралардан аккан канга манып
ташка яздым.
Каурыемны ташка ташламадым,—
азмы исемсез каберләр җир буйлап сибелгән...
Ташлардан сорамадым.
Каурыемны шатлыкларга манып
җырлар яздым.
Мактап яздым зәңгәр җирем язын,—
азмы башлар кайгыдан түбән иелгән,—
шатлыклар турында яздым.
Каурыемны язмышларга манып
язасы бар.
Баштан кайгы, шатлык узасы бар.
Турылыклы булыйк, каурыем,
кешеләргә
шушы кулны сузасы бар.

1969

## Кайт, диярсең

Әгәр китсәм Байрон иленә,
Бездәгедәй аксыл томандыр.
Томан кызы, кояш төшкәнче,
Салкын чыкта битен югандыр.

Тәрәзәмне каерып җил ача.
Мин киткәндә Тукай иленнән,
— Кайт,— диярсең, Зөһрә, татарча.

Әгәр китсәм Һейне иленә,
Кар өстендә болан эзедер.
Зәңгәр күзле Рейн кызы да
Мәхәббәтен әле эзлидер.

Тәрәзәмне каерып җил ача.
Мин киткәндә Тукай иленнән,
— Кайт,— диярсең, Зөһрә, татарча.

Әгәр китсәм Лорка иленә,
Гитаралар төнлә моңлыдыр.
Испан кызы, кара толымын,
Күз яшеннән генә дымлыдыр.

Тәрәзәмне каерып җил ача.
Мин киткәндә Тукай иленнән,
— Кайт,— диярсең, Зөһрә, татарча.

Әгәр китсәм Данте иленә,
Тауларына болыт кунадыр.
Тау кызы бер карашы белән
Күңелеңә кереп чумадыр.

Тәрәзәмне каерып җил ача.
Мин киткәндә Тукай иленнән,
— Кайт,— диярсең, Зөһрә, татарча.

1969

## Нәҗип Мадьяров

●

Нинди язмыш аны саклагандыр,
Кыш уртасы килеп җитсә дә,
Бер усакның ялгыз бер яфрагы
Өзелмичә калган, кипсә дә.

Җәйдәгечә инде шауламый ул,
Җилләр иссә фәкать сызгыра...
Аерылмаска тырыша агачыннан,
Яшәсә дә бәрелә-сугыла.

●

Тартар жыры, бакаларның хоры —
Ни генә юк төннең куенында!
Атлар көткән кеше кабызганмы? —
Учак яна инеш буенда.

Үсмер чагым үткән шул җирләргә
Тагын карыйм еллар аркылы.
Яна учак чишмә тугаенда,
Ә йөрәктә уйный ялкыны.

●

Кайчакта күнел сүрелә,
Кайчакта ялкынлана,
Кайчакта кайный шашып ул,
Кайчакта салкыная.

Сүрелсен, әмма сүнмәсен,
Суынсын, бозланмасын.
Суынса да, сүрелсә дә
Өметсез сызланмасын.

●

Яшьлек безне уйната да иде,
Җырлата да, уйлата да иде.
Бәхетегез киләчәктә диеп,
Моңайганда юата да иде.

Күп шатлыклар белән очраштык без,
Әмма риза була алмадык.
Яшьлектән дә артык бәхет югын
Тик зурая төшкәч аңладык.

●

Җәй буенча тургай ояларын
Качырып торган каты камыллар
Сабаннарның канат дулкыныннан
Бар да инде күмелеп калдылар.

Ап-ак икмәк биргән кара туфрак
Гүя моңлы көннәр кичерә.
Аккаеннар елак болытларның
Күз яшьләрен эчеп исерә.

●

Кояшка эндәште салават күпере:
— Минем күк син гүзәл булганың юк әле!
Ә кояш болытлар артына күмелде,
Һәм кинәт салават күпере югалды...

**Валентина Гудкова**

# «ҖАЙ КИЛҮНЕҢ» СЕРЕ

ОЧЕРК



Самолет калын болыт катламнарын ертып чыкты да түбәнәя башлады. Стюардесса кыз ягымлы тавыш белән: «Пассажир иптәшләр, безнең самолетыбыз Татарстан башкаласы Казанга якынлаша»,— дип белдерде. Моңа кадәр тын гына килгән, озын буе белән дә, килеш-килбәте белән дә башкалардан аерылыбрак торган бер карт пассажир күзләрен иллюминаторга төбәде. Биредә аңа барысы да яңа, барысы да кызык. Күрәсең, әлеге пассажир бу якларга беренче тапкыр гына килгәндер.

Тәрәзәгә ябырылган карт — Сорбонна университеты профессоры, атаклы француз физигы Кастле иде. Ниһаять, ул электрон-парамагнитлы резонансның мәркәзе булган Казан шәһәрендә. Совет Татарстаны башкаласын физиклар арасында чыннан да шулай атап йөртәләр. Башкалабызның шулай аталырга тулы хокукы бар. Электрон-парамагнитлы резонанс күренешен Казан университетының элекке доценты Е. К. Завойский ачкан. Сорбонна профессоры — Татарстанда шушы ачышны ясауга егерме биш ел тулу уңае белән үткәрелә торган фәнни конференция кунагы.

Моны берәү дә көтмәгән иде. Профессор Кастле пленар утырыштагы үзенең фәнни докладын Идел турында сөйләүдән башлады. Бу бөек елга ярларын, аның суларында коенып үскән талантлы, зирәк акылга ия кешеләрне күрү турында ул күптән хыялланган. Менә хәзер ул, ниһаять, бу зур бәхеткә ирешкән.

— Мин менә Россиянең үзе кебек киң, колач җитмәслек очсыз-кырыйсыз мәһабәт Идел ярларында,— диде ул.— Тау итәгеннән бәреп чыккан кечкенә чишмә үз юлында бик күп инешләрне очрата. Алар юлларын бергәләп дәвам итәләр. Соңында бер ярыннан икенчесе күренми торган зур елгаларга барып кушылалар. Аны тагын да зуррак, көчлерәк, күп сулырак итәләр. Фән өлкәсендә дә шундый хәлләр бик еш очрап тора. Галим ачыш ясый. Үзе ясаган ачышның нинди зур масштаблы булуын беренче чорларда хәтта авторның үзенең дә күреп бетермәве мөмкин. Евгений Константинович Завойский ясаган ачыш белән дә шушы ук хәл булды...

ЭПР — электрон-парамагнитлы резонанс. Әле чирек гасыр элек кенә бу сүз бик аз физиклар өчен таныш иде. Ә хәзер исә матдәләрнең эчке төзелешен тикшергәндә

кулланыла торган бу искиткеч нечкә, сиземле һәм гаять куәтле инструмент гигант күләмнәрдә практик кулланыла башлады.

...1944 ел. Сугыш бара. ЭПР естендә эзләнүче ике галимнең берсе — Семен Александрович Альтшулер да фронтта. Университетның физика кафедрасы доценты Евгений Константинович Завойскийга бу өлкәдә эзләнүләрне үзенә генә алып барырга туры килә. Салкын аудиторияләр, ягылмаган лабораторияләр, боз белән капланган приборлар, аппаратлар. Әмма галимне һич төрле каршылыклар туктатмый. Ул аруталуны белми эшли, тәҗрибәләр ясый, күзәтүләрен чагыштыра, анализлый, эзләнүен дәвам итә. Көннәрдән бер көнне Семен Александрович Альтшулер исеменә хат килеп төшә. Конверт эчендә журнал мәкаләсе. «ЭПР — бар! ЭПР табылды», дип яза коллегасына Е. К. Завойский.

Шушы проблема буенча докторлык диссертациясе яклагач, Е. К. Завойский Казаннан китә. Аны башка эшкә чакыралар. Завойский урынында фронттан кайткан Семен Александрович Альтшулер эшләргә керешә. Ул университетның теоретик һәм экспериментал физика кафедрасы белән җитәкчелек итә. Бу чорда Завойский ясаган ачыш ныклап аякка баса, ныгый, үсә. Шушы ачышның дәвамы булып радиоспектроскопия фәненең Казан мәктәбе барлыкка килә. Бу фән дә, туктаусыз үсә барып, үз чиратында тагын күп тармакларга бүлгәләнә.

Бүген без шушы яңа фән өлкәсендә **үз сүзен** әйткән Казан физикларының берсе турында сөйләмәкче булабыз.

Е. К. Завойский үзенең ачышын ясаган 1944 елның салкын кышында — Максут Зарипов әле мәктәп баласы. Дөньяда ЭПР дигән гаҗәеп серле күренеш бардыр дигән уй аның башына да керми. Максут үзенең классташлары белән йотлыгып немец-фашист илбасарларын тар-мар итү турындагы Советинформбюросы белдерүләрен тыңлый. Бүреген югары чөеп шатлана. Классташлары белән үзләре шефлык иткән госпитальгә барып яралы солдатларга китаплар укый, аларның өйләренә хатлар яза, концертлар куеша. Һәркем кулыннан килгәнен эшли: берсе җырлый, берсе бии, икенчесе кычкырып шигырь сөйли...

Ул көннәрдән соң күп тә үгел, бары егерме биш ел гына узган. Электрон-магнитлы резонанска да егерме биш кенә яшь. 1944 елда аның барлыгы турында башына да китермәгән Максут Зарипов — бүген трибунада. Шушы кыска вакыт эчендә инде ул профессор, физика-математика фәннәре докторы булып җитлегергә өлгергән. Яшь галим Бөтенсоюз конференциясендә радиоспектроскопиянең Казан мәктәбе башкарган эшләр турында доклад ясый. Залда утырган Е. К. Завойскийга да таныш һәм якын бу егет. Алар күптәнге танышлар. Сорбонна профессоры да трибунадагы коллегасын бик игътибар белән тыңлый. Аның йөзе үйчан. Кем белә, бу минутта ул доклад ясаучы Казан галиме белән Гренобльдә, халыкара симпозиумда танышуларын исенә төшереп утыра торгандыр әле...

...Кешегә кырык яшь. Күп тә түгел, аз да түгел, нәкъ чын-чынлап җитлегү чоры.

— Шушы чор эчендә нәрсә, ни кырырга өлгердең? — беренче карашка шактый төксе һәм дорфарак шушындый сорауны кешеләр үз-үзләренә, бигрәк тә галимнәр нәкъ менә шушы яшьтә бирә торганнардыр инде. Җитлегү чоры — иң җаваплы чор. Шагыйрьләр аны юмор белән «ярминкәдән кайту чоры» дип тә йөртәләр.

Максут Зариповка кырык әле тулды гына. Әгәр кешене син студент елларыннан ук белсәң икән, кырык яшь аның өчен күпме, әллә азмы икәнен әйтүе дә кыен. Вакыт дигән рәхимсез нәрсә кайберәүләрне һич кызганмый. Аның йөзен тирән-тирән сызыклар белән буразналап бетерә. Ә Максут исә һаман студент чагындагы төсле ачык һәм мөлаем йөзле. Кара күзләрендә шаян чаткылар уйный. Бу кешегә инде дүрт дистә, ул зур галим, профессор, фәннәр докторы дип һич тә әйтмәссең!

Әйткәнебезчә, бөтенебез өчен авыр булган 1944 елның салкын кышында Максут Зарипов мәктәптә генә укый иде әле. Тәнәфесләрдә онытылып шаярган, тузан күтәреп куышып уйнаган бәдрә чәчле бу малай дәрескә кергәч танымаслык үзгәрә. Аның колагына бер тавыш керми: дөньясын онытып мәсьәләләр чишә.

Югары классларда уку аның өчен аеруча истәлекле булды. Сигезенчедән башлап, Максутларны көчле математик булуы белән Казан педагоглары арасында дан тоткан Галина Юлиановна Гусарская укыта. Аның классын тәмамлаган укучылар хәтта университетның математика факультетына да имтиханнарны тик «бишле» билгеләренә



*Рәсемдә физика-математика фәннәре докторы М. Зарипов (уңда) һәм физика-математика фәннәре кандидаты, доцент Л. Әминов.*

генә биреп керәләр. Максут хәзер дә Галина Юлиановнаны зур ихтирам белән искә ала.

— Ул безне логик фикерләргә, эзлекле рәвештә уйларга, кыенлыклар алдында югалып калмаска, аларны җиңү юлларын икеләнми эзләргә, табарга өйрәтте,— ди ул.— Бу зур педагогтан без фәннәр патшасы — математиканы аңларга, төшенергә, аны үз итәргә өйрәндек. Галина Юлиановнаны университет профессоры Владимир Владимирович Морозов та ихтирам итә иде. Без бу картны үзара «ак сакал» дип йөрдек. Профессор безнең мәктәпкә бик еш килә, кичәләрдә катнаша. Укучыларның математика түгәрәген алып бара, имтиханнарга кереп, тыңлап утыра иде. Галина Юлиановна куйган «өчле» билгесе дә икенче берәүнең «бишле»сенә тора иде. Менә шуның ачык дәлиле: Раис Бухараевның башы «өчтән» чыкмас иде. Без аның белән бергә укыдык. Ә университетка имтиханнарны ул тик «отлично»га гына биреп керде. Хәзер Бухараев — техник фәннәр докторы. Безнең университетның кибернетигы Альберт Сульдин без укыган 2 нче мәктәпне бер елга алданрак бетерде. Ул да шулай ук фәннәр докторы.

Максут белән сөйләшкән чакта, аңардан еш кына: «җай килде» дигән сүзне ишетергә була. Аңа университетта да «җай килә». Җитез егет барысына да өлгерә, Ньютон стипендиясенә лаек була. Җәмәгать эшләреннән дә читләшми, факультетның комсомол бюросы секретаре була.

Максут Зарипов университетка галимнәр фронтлардан үз урыннарына әйләнеп кайткан чорларда керә. Семен Александрович Альтшулер да нәкъ менә шушы чорларда теоретик һәм эксперименталь кафедра белән җитәкчелек итә башлый. Зарипов башта Альтшулерга семинарга языла. Аннары үзенә аспирант итеп алуын үтенә. Максут аның җитәкчелегендә парамагнитлы резонанс белән мавыгып китә.

— Зарипов гаять сәләтле студент иде,— дип сөйли Альтшулер.— Мин моны бик тиз сизендем. Шуның өстенә талантлы да. Тырыш, алдына максат куя белә, шул максаты белән онытылып мавыга белә. Хезмәт сөю, үз-үзеңне кызганмыйча мавыга белү фәнгә хезмәт итәргә җыенган кешенең альфасы һәм омегасы инде ул. Бу

талантлы егеттә мин тагын шундый бик матур сыйфат күрдем: ул үзенең кулыннан килердәй эшкә генә алына. Ә кулыннан килерлеген-килмәслеген ничек сиземли алганлыгы минем өчен дә сер. Табигать тарафыннан бирелгән сизгерлек, талант тыр инде ул. Кыска гына итеп әйткәндә, Максут — бик эшлекле һәм үз дигәнен итүчән егет. Дөрес, безнең көннәрдә аерым кешеләр генә фәнне әйдәп алып бармыйлар. Ләкин аерым галимнең характерындагы матур һәм көчле сыйфатларның теге яки бу мәсьәләләрне хәл иткәндәге роле гаять зур әһәмияткә ия.

Өлкәннәргә ихтирамлы, үзеннән түбәннәргә игътибарлы, әйләнә-тирәсендәге зур һәм кечкенә кешеләрнең холыкларындагы вак җитешсезлекләргә түземлелек һәм, ниһаять, үзе тирәсендә ниндидер бер тыныч ритмга корылган эчкерсез дуслык атмосферасы тудыру — менә болар барысы да профессор Максут Зариповка хас индивидуаль сыйфатлар...

Максут Зарипов кандидатлык диссертациясен 1955 елда яклый. Аның рәсми оппонентлары Александр Михайлович Прохоров һәм Борис Михайлович Козырев булалар.

— Горурланмаслык та түгел,— ди яшь галим үзе бу турыда.— Фән дөньясында исеме бик күпләргә билгеле Прохоров бит ул. Академик, Нобель премиясе лауреаты. Ә Козыревны кемнәр генә белми! СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты, Е. К. Завойскийның фикердәше һәм дусты. Кыскасы, кандидатлык диссертациясен яклаганда миңа шулай ук «бик җай туры килде». Опять повезло, русча әйткәндә!

Дөресен әйтергә кирәк: бер караганда барысы шул бик гади кебек, мәктәптә Максут менә дигән педагоглардан белем ала. Университетта да остазлары менә дигән. Диссертация яклаганда аның оппонентлары — илебезнең танылган физиклары — парамагнитчылары. Егерме биш яшь дигәндә инде ул фәннәр кандидаты. Тиздән аны доцент итеп билгелиләр. Шушылар өстенә яшь галимгә радиоспектроскопия, каты матдәләрнең физикасы кафедрасын оештыру бурычын йөклиләр. Мондый бурыч йөкләүне административ баскыч буйлап югарыга күтәрелү дип күз алдына китерергә мөмкин булыр иде. Ләкин бит Зарипов — администратор түгел, ул университет укытучысы, студентлар белән эш йөртә. Аларга гомуми физика, теоретик механика, атом физикасы буенча курслар укый, практик занятиеләр алып бара. Болар өстенә җәмәгать эшләре дә җитәрлек — коммунист Зарипов университет парткомының фәнни секторы белән җитәкчелек итә. Докторлык диссертациясе өстендә эшләргә дә вакыт таба.

...Без Максут Зариповның тар һәм кысынкы кабинетында утырабыз. Ул шушы кысынкы бүлмә буенча әрле-бирле йөренә.— Зарипов кандидатлыкта кайчаннан бирле утыра бит инде. Докторлык диссертациясен һаман суза. Әллә шулай калырга уйлый микән, дигән сүзләр кергәли иде колакка,— дип сөйли ул.— Мондый сүзләр Евгений Константиновичка да барып җиткән, күрәсең. Ә ул вакыт табып, елга бер генә булса да, Казанга килеп чыккалый. Безне онытып бетерми. «Башкарган эшләрегезне берләштереп докторлык диссертациясе итеп бирегез. Оппонентыгыз үзем булырмын»,— диде ул бер килүендә.

Диссертацияләрне аттестацияләү буенча вәкаләтле комиссия андый диссертацияләрне әллә ни алкышлап каршыламый. Зарипов моны белә иде. Чыннан да, гадәттә докторлык диссертациясен бу характерда якларга яше илледән узган галимнәрнең генә хакы бар, дип исәпләнелә...

1966 елның 13 октябре университетта әеруча истәлекле көннәрнең берсе булды. Бу көнне берничә кеше диссертация яклады. Максут Зарипов диссертациясе барысыннан да тизрәк «якланды». Аңа докторлык диссертациясен яклау өчен нибары бер сәгать ун минут вакыт кирәк булды. Юк вакытын бар итеп Завойский үзе дә килгән иде. Яклауга академик Александр Александрович Галкин да катнашты. Зариповның кандидатлык диссертациясе буенча оппоненты булган профессор Борис Михайлович Козырев соңгы елларда аңа һәр эштә аталарча ярдәм күрсәтеп килде. Докторлык диссертациясе яклаганда да оппонентларның берсе ул булды.

Максут Зарипов уңышларының, аңа һәрвакыт «җай чыгып торуның» сере нәрсәдә соң? Моның сере — егетнең үзендә.

— Мин аны,— ди Борис Михайлович Козырев,— урта буын физикларның иң күренекле вәкилләреннән берсе дип исәплим. Теоретик белән экспериментаторның сирәк очрый торган гибриды ул. Ике очракта да иң югары класслы белгеч, галим. Ә мондый очракка еш тап булмыйсың. Үзенең теориясен тудырган галимнәрнең күбесе аны эксперименталь дәрәҗәгә китереп җиткерә алмыйлар.

Галимнең хезмәте — озак елларга сузыла торган очсыз-кырыйсыз эш ул. Кечкенә генә ачышлар артында меңләгән тәҗрибәләр, сыкап-чагыштырып караулар, уңышсызлыкка очраулар, күңел кайтулар, барысын артка ташлап яңабаштан тотынулар ята. Бу кичерешләрнең берсе дә Максут Зариповны читләтеп үтмиләр. Боларның барысын да аңа да үз җилкәсендә татырга туры килә.

Яңа ачышлар, уңышлар һәм дан менә шундый газаплы юлны үткәч кенә килә. Максут Зариповны хаклы рәвештә кристаллардагы электрон-парамагнитлы резонанс спекторларын уку буенча иң югары квалификацияле белгечләрнең берсе итеп санныйлар.

Фәндә М. Зарипов сайлап алган юнәлеш — иң төп һәм магистраль юнәлешләрнең берсе. Ул фәндә үз сүзен әйтүгә ирешге. Фәнни-техник революцияләрдән торган безнең гасырда галим кеше өчен гаять зур дәрәҗә инде бу. Илебез һәм дөнья күләмендә данга ия булу дигән сүз ул.

Галимнең, нинди проблемалар белән шөгыльләнсә дә, максаты бер: ул үз хезмәтенең практик яктан әһәмияткә ия булуына ирешергә, аны кешеләргә, халкына хезмәт иттерергә тырышырга тиеш. Турысын гына әйкәндә, галим, фәннең кайсы өлкәсендә генә эшләсә дә, үзенең практик файда китерүе белән кадерле. Профессор Зарипов янына кай яклардан гына килмиләр. Мәскәү һәм Томск, Ленинград һәм Новосибирск, Киев һәм Тбилисидан килгән кунаклар барысы кристаллар төзелешен электрон-парамагнитлы резонанс методы белән укырга өйрәнү өчен киләләр. Максут Зарипов җитәкчелек иткән кафедра төрле фәнни-тикшерену институтлары, учреждениеләре белән хуҗалык договорлары, килешүләр төзи, аларның заказларын үти.

Кристалларның спектрларын тикшерү нигә кирәк? Аларның нинди практик кулланышы бар соң?

— Без эшне рубиннан башладык. Кыйммәтле кызыл якут таш ул. Ә физиклар өчен рубин — иң нык, иң каты кристалл. Рубин промышленностьта да киң кулланыла. Тикшеренүләр барышында шул нәрсә ачыкланды: табигый материаллар безгә ярамый икән. Алар составында башка төр чит матдәләр күп. Без кристалларны үзебез «үстерергә» өйрәндек. Сөйләп тә торасы юк, бик кыен, озакка сузыла торган һәм бик мәшәкатьле процесс инде бу. Без баштарак бу хезмәтләребезнең квант-парамагнитлы беренче көчәйткечләрне (мазерларны) һәм оптик-квантлы генераторларны (лазерларны) төзегәндә кирәкләре чыгар дип башыбызга да китермәдек.

Нинди генә эшкә тотынсаң да, җигелеп эшләргә! Студент еллардан ук килгән бу сүзләр Максут Зарипов тормышында гади аксиомага әверелгән. Яшереп-нитеп торасы юк, администраторлык мәшәкатьләре галим кешегә зур комачаулыклар тудыра, аңа колачын җәеп эшләргә ирек бирми. Шуңа күрә үзен декан итеп билгеләүгә М. Зарипов теләр-теләмәс кенә риза була. Университетта физика факультеты иң зур факультетларның берсе. Студентлар гына да анда 1750 кеше. Укытучы-профессорлар өч йөздән артык. Факультетны ел саен өч йөз кеше тәмамлый.

Аудиторияләр, лабораторияләр җитешми. Приборлар берсе өстенә берсе өелгәннәр. Хәер, бу вакытлы хәл. Деканның кысынкы кабинеты тәрәзәсеннән физика факультетының унөч катлы булачак яңа бинасы күренә.

Әнә бер студент имтиханда уңышсызлыкка очраган. Тагын бер кат тапшырып карарга рөхсәт итүне сорап килгән. Декан каршы түгел. Ләкин соңгысы булсын. Бер укытучы командировкадан — югары курс студентлары производство практикасы үтә торган җирдән кайткан. Ул студентларның эшеннән канәгать. Монысы декан өчен дә сөенечле хәбәр. Максут Зариповның йөзе ачылып, күңеле күтәрелеп китте. Ул арада деканга яңа кәгазь сузалар. Монысы нәрсә тагын? Бер студент зачеткасына укытучы булып үзе кул куйган. Нинди оятсыз алдашу: хәтта җинаять. Деканның карары кырыс:

— Куарга. Бу студент белән күп азапландык инде. Бездән калмады...

Бу хәл аны тәмам тетрәтеп җибәрде. Вузларга керү елдан-ел кыенлаша. Зур конкурс үтәргә туры килә. Ә бер кереп урнашкач, шундый кыенлыкларны, сынау-

ларны башыннан кичергәч, укырга гына иде инде. Онытылып, бирелеп укырга иде. Ә кеше нинди оятсыз алдашу юлына баскан. Гаилә гарипсез булмый дип кенә үзеңне юатып булмый бит. Университетта мондыйларга урын булырга тиеш түгел.— Куарга!— деканның карары бер булды.

Бу миһербансызлык түгел. Чынлыкта йомшак характерлы, киң күңелле кеше ул. Шуңа күрә Максут Зариповка мондый карарлар кабул итү авыр һәм кыен булгандыр. Ләкин администраторлык вазифалары аннан кирәк чакта катгый булуны да таләп итә.

— Сез кешеләрдә нинди сыйфатларны аеруча бәялисез? — дип сорагач, Максут Зарипов кыска гына итеп:

— Игътибарлы булуны,— диде.

Җавап мине гаҗәпләндермәде. Чөнки бу сыйфат аның үзенә дә хас. Максут Зарипов башкаларның кайгысын уртаклаша, шатлыклары өчен бергәләп шатлана белә. Ул бөтенләе белән үз эшенә, үз хыялларына чумган галим генә түгел, оештыручы да.

Оештыру көче нәрсәдә соң аның? Зариповка әллә бу сыйфат та табигать тарафыннан бирелгәнме? Минемчә, эш бираэдә башкачарак. Бу сыйфат Максут Зариповның үзенә тапшырылган эшкә югары дәрәҗәдә җаваплылык белән каравына нигезләнгән. Бу турыда ул үзе дә, күптәнге уйларын дәвам иткәндәгечә итеп:

— Барлык кеше дә үзенә тапшырылган эшне намус белән башкарырга тиеш...— диде.

Ул үзе менә шулай булганга күрә дә галим. Зариповка ул сыйфатлар декан Зарипов буларак та зур ярдәм итәләр.

Хәзер ул дүртенче курс студентлары алдында электрон-парамагнитлы резонанс теориясе буенча махсус курс укый. Бу дисциплина буенча әлегә китаплар юк. Профессор Зарипов аларга лекцияләрне үзе төзегән программа буенча укый. Аудиториядә физфак студентларыннан кала педагогия институты студентлары, Мәскәү физика-техника институты, СССР Фәннәр академиясе сотрудниклары, хәтта Польша Халык Республикасыннан стажировкага килгән Болеслав Климашевский да бар.

Мондый деканның башка укытучылардан да үз лекцияләрен фәннең, техниканың соңгы казанышларына таянып карауларын таләп итәргә тулы хокукы бар. Башкача булуы да мөмкин түгел — физика инертлыкны яратмый.

Физик Зариповның язмышы бик гади. Аның тормышында искиткеч бернәрсә дә юк. «Без барыбыз да халык арасыннан чыктык, без — хезмәт семьясы балалары»,— дигән җыр да бар бит әле. Бу сүзләр профессор Зарипов биографиясенә бик тә туры киләләр.

Галим фәнгә ни күләмдә, ни дәрәҗәдә хезмәт итүе белән бәяләнә. Ә профессор Зариповның, күргәнебезчә, фәндә хезмәтләре зур. Шушы кырык ел гомере эчендә ул сигез фәннәр кандидаты әзерләргә өлгергән, яңа кафедра оештырган. Ә кырык яшьлек вакыт — фән дөньясында нәкъ менә баш белән чумып, колач җәеп эшли торган чор бит ул. Кешенең иң дәртле, иң энергияле чагы. Деканлык вазифалары да аңа үз лабораториясенә кереп бикләнмәскә, үз кайгысы белән генә яшәмәскә, тормышка якынрак торырга ярдәм итәләр. Яшь профессордан без яңа фикерләр көтәбез. Ул Ватаныбыз фәнен яңа зирәк ачышлар белән баетыр дип ышанабыз.

Заһит Шәфигуллин

# АВЫЛ—ШӘҺӘР ЭЗЕННӘН...

**Шәһәр белән авыл арасында социаль-экономик һәм культура көнкүреш аермаларын бетерү коммунизм төзелешенең иң бөек нәтиҗәләреннән берсе булачак.**

*КПСС Программасыннан.*

## Исеме—дуслык символы



Колхозлар — Ерак Көнчыгышта да, Себердә дә, тундрада һәм Урта Азия чүлләрендә дә, илебезнең башкаласы Мәскәү янында да дистәләгән еллар буена тамыр җәйгән хуҗалык формасы. Безнең илдә 36 мең 200 колхоз бар икән, шуларның берсе — нәкъ Казан артындагы Шәпшә, Салкын Чишмә, Николаевка, Красный Восток, Бобровка, Горки, Добровка, Сидор дигән татар һәм рус авылларын берләштергәне — «Урак һәм чүкеч» колхозы дип атала. Исеме — совет дәүләтенең гербы символы, илебездәге төп сыйныфлар булган эшче һәм крестьян дуслыгы символы.

Бу — дуслык тарихи. Аның туу чоры 1917 елга карый. Сыйнфый изелүдән, эксплуатациядән котылу максаты, шәһәр белән авыл арасында каршылыкны җимереп, эшче белән крестьянны бер союзга берләштерде. Һәм данлы 1917 елның давыллы Октябрь көннәрендә солдат шинеле кигән крестьяннар, эшчеләр белән бер сафта, большевиклар партиясе җитәкчелегендә, буржуазия һәм алпавытлар интересын яклаган Вакытлы хөкүмәтне алып аттылар да Совет власте урнаштырдылар.

Менә шунда инде крестьянның йөз еллар буена килгән изге хыялы чынбарлыкка әверелде! Элек алпавытлар һәм чиркәүләр карамагында булган 150 миллион десятинадан артык җирнең крестьяннарга күчүе — шуның нәтиҗәсе. Аның 714 меңе хәзерге Татарстан территориясендә яшәүче крестьяннарга өләшенде. Болардан тыш, Казан губернасы крестьяннары ел саен алпавытларга алтын белән 700 мең сум арен-

да түләүдән азат ителделәр. Ә Россия күләмендә 2,5 миллион крестьян җир банкысына алтын белән 3.310,5 миллион сум бурыч түләүдән котылды.

Алтмыш җиде яшьлек пенсионер-колхозчы Сергей Гаврилович Колесников искә алганча, 6 мең гектарга ия булган хәзерге «Урак һәм чүкеч» колхозының да ярты җирен элек Пенегин, Цимбалов кебек алпавытлар биләп торган. Ярлы-ябагай, бөтен тирә-як авыллардан килеп, тамак хакына аларга бил бөккән, җирен арендага алып, ярты уңышын шул ук соры кортларга биргән. Сергей Гавриловичка да 11—12 яшьтән алпавыт атларын көтәргә туры килгән. Бу бәлаләрдән һәм изелүдән коткарганы өчен Сергей Гавриловичның һәм аның кебек башка күп өлкән колхозчыларның эшчеләр сыйныфына һәм Коммунистлар партиясенә рәхмәте зур. һәм аларда урак белән чүкеч дуслыгының беренче җимешләре үк шундый юмарт булуы чиксез шатлык һәм ышаныч тудырган.

Владимир Ильич Ленин бу дуслыкка күп өметләр баглаган, бу дуслыкта яңа социалистик җәмгыятьнең нигезен күргән. «Диктатураның иң югары принцибы,— дип яза ул,— пролетариат җитәкчелек ролен һәм дәүләт властен саклап кала алсын өчен пролетариатның крестьяннар белән союзын ныгыту». (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 32 том, 499 бит.)

Ильич әйткән сүз — аткан ук ул. Бу союз елдан-ел ныгыган.

Шәпшә, Салкын Чишмә һәм башка авылларда яшәүче крестьяннар үзләренә кайтарылган атлы чәчкечләр, атлы ургычлар, ниһаять, беренче «Фордзон» тракторы килгәч тә, авылга җибәрелгән беренче агроном, дәүләттән бирелгән сортлы орлык аша да юлбашчының васыятьләре тормышка ашуын бөтен күңелләре белән тоеп торганнар. Аннары колхозлар оештыруда да Казан эшчеләре кайсы вәкил, кайсы белгеч булып ярдәмгә килгән...

— Ул ярдәмне искә төшереп кенә бетерерлекмени! — ди колхоз партком секретаре Гали Ягъфәров. Секретарь — яше илләргә җитеп килгән, тормышның әчесен-төчесен күргән кеше. Маңгаенда инде буразналар сызылган, өстендәге күн пальтосы 20—30 еллардагы комиссарларны хәтерләтә. Колхоз тормышын, колхоз кешеләрен биш бармагы кебек белә ул. Колхоз тарихы буенча да яхшы ук хәбәрдар. Бүгенге көн турында да, шәһәрнең, ягъни эшчеләр сыйныфының авылга бүгенге ярдәме турында да теләп, рухланып сөйли ул. Сәбәбе гади: бу чын ярдәм. Нәтиҗәсе дә горурлык хисләре уятырлык.

Гали ага сөйләгәндә «серле» кенәгәгә — кесә дәфтәренә күз төшереп ала. Анда — саннар, таблицалар...

Менә аларның кайберләре: «Хәзер безнең колхозда ДТ-54 һәм ДТ-75 тракторлары — 10 данә, көпчәкле тракторлар — 15, комбайннар — 11, автомашиналар — 14. 1933 елда — Биектау МТСы оештырылганда — бөтен районга хезмәт күрсәтүче МТСта техника моннан әзрәк булган... Ә 1929 елда илебез авыл хуҗалыгының энергетик куәтен 18 мең трактор, 21,3 миллион ат тәшкил иткән, ягъни бер крестьян хуҗалыгына берәр ат та туры килмәгән. Димәк, атсыз ярлылар да байтак булган. Хәзер илебез авыл хуҗалыгының трактор паркы 3,6 миллион трактордан гыйбарәт. Бу 54 миллион ат көче дигән сүз. 1913—1917 елларда авыл хуҗалыгында энергетика куәте бер крестьянга ярты ат көче туры килсә, 1967 ел азагына ул уртача 8,8 ат көче булды. Безнең колхозда исә һәр колхозчы кимендә 10 ат көченә ия...»

— Мин экономик мәсьәләләр буенча политинформатор да бит әле. Бу саннар колхозчылар алдында әңгәмәләр ясаганда кирәк була,— дип сүзен дәвам итә Гали ага. Аның фикере һаман шәһәрнең авылга ярдәмен раслауга юнәлдерелгән. Соңгы вакытта колхозга минераль ашламаларның елдан-ел күбрәк кайтарылуына басым ясый ул. Колхоз былтыр дәүләттән 5.770 центнер минераль ашлама алган һәм чәчүлекләргә керткән. Шуңа өстәмә рәвештә 3.400 центнер аммиак сыекчасы сиптергән. Нәтиҗәсе бик тә куанычлы: 1964 елда колхоз гектардан 5,7 центнер иген уңышы җыйган булса, 1965 елда ул 8,8 центнерга, 1966 елда — 10,5, 1968 елда 12,1 центнерга күтәрелгән. Узган ел исә гомер-гомергә каһәрләнгән шушы ярлы келсу туфраклы җирләрдән колхоз тарихында беренче тапкыр гектардан уртача 19,6 центнер уңыш җыеп алынган. Кем белә — урак һәм чүкеч дуслыгы ныгый барган саен, бу кырлар, бу басулар, бу авыллар тагын әллә нинди могҗизалар күрсәтер әле. Һичшиксез, күрсәтер!.. Могҗизалар күрсәтерлек кадрлары да бар колхозның. Өнә СК-4 комбайны белән 200

гектар игенне теземнәргә салып, 310 гектардан 5 мең центнерга якын ашлык суктырган Хәйдәр Гыйләҗевне, шундый ук эш башкарган Ленин орденлы комбайнчы Петр Алексеевич Зюзинны, ДТ-54 тракторы белән 1500 гектар җир эшкәрткән Михаил Егорович Егоров кебекләрне «алтын куллылар» дип юкка гына әйтмиләрдер.

Партком секретаренең өметләре, хыяллары нигезле. Ул КПСС Үзәк Комитетының 1965 елгы март Пленумы җитештерүне туктаусыз арттыру өчен колхозчы крестьяннарга тудырган уңай шартларны, куәтле стимулларны күздә тотып сөйли. Шушы Пленум ич авыл хуҗалыгы продуктларын дәүләткә сатуның 5 елга исәпләнгән стабиль планын булдырырга һәм планнан тыш тапшырылган продуктлар өчен 1,5 чамасы артыграк түләү билгеләргә кирәклеген күрсәтте. Хәер, бу чараның колхозлар экономикасын һәм колхозчыларның материаль тормышын нык яхшыртуга киң мөмкинлекләр бирүе һәркемгә билгеле инде. «Урак һәм чүкеч» колхозы да узган ел бу мөмкинлектән тулы файдаланды. План нигезендә дәүләткә 5.500 центнер ашлык сатып 45 мең сум акча алса, планнан тыш сатылган 7.500 центнерга 90 мең сумлап керемен арттырды. Күрәсез, колхозның 1969 елгы 600 мең сумнан артык акча доходының шактый өлешен алып тора ул. Шуңа күрә төзелешләр алып барырга да рәт бар. Әмма колхозчыларның уй-теләкләрен дә онытмыйк.

## Кичә, бүген, иртәгә

Узган елның көзендә берничә дистә йортлы, яшеллеккә бай Салкын Чишмә авылында булган идем. 69 яшьлек Бари ага Кәримуллин белән сөйләшеп утыру бик күңелле. Атказанган колхозчы ул. Пенсиядә булса да эштән аерылмый. Бүгенге мул тормышны тагын да матуррак итәсе килә аның.

— Их, заманалар...— дип кәрсенеп куя Бари ага вакыт-вакыт. Бу сүзләрне әйткәндә, ихтимал, Салкын Чишмә буенда тамагы икмәккә туймаган әтисен — мәрхүм Кәримулла абзыйны искә төшерә торгандыр. Ул кечкенә чакта әтисе, бәхет эзләп, Донбасс шахталарына да барып эшләгән. Шулай йөри торгач, 40 ка да җитмичә, Октябрьгә чаклы ук дөнья куйган. Атасыз калган Барига нужа шулпасын бик яшьли татырга туры килә. 15 яшьтән авылны ташлап, әтисе эзеннән чыгып китә. Казан предприятиеләрендә хезмәт итә, Донбасска да барып җитә. Ләкин егерменче еллар азагында авылдагы тирән үзгәрешләр Баринның күңелен кабат туган якка тарта. Колхоздагы күмәк хезмәт аңа завод-фабрика тормышын хәтерләтә.

Салкын Чишмә буе гөрләп чәчәк ата. Биредә Бари ага тормыш иптәше Рокыя апа белән бергә 9 бала үстерә.

— Алма агачыннан ерак тәгәрәми, берсеннән-берсе уңган Бари аганың уллары һәм кызлары,— диләр бу колхозда.

Инде күптән семья корып башка чыккан олы улы Фарук — колхоз бригадиры — әтисе кебек үк «Атказанган колхозчы» исемен алган. Кызы Мөнәвәрә — алдынгы сыер савучы, Камил исемле улы — шофер, ә Ильясы — тракторчы. Зөләйхасы — Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап кайткан, хәзер үз колхозында агроном. Бари ага кызларының берсе Кукмарада плащлар тегә, икенчесе — Казанда медсестра.

Бари ага үзенең картлыгы бәхетле чорга туры килүгә шатланып бетә алмый. Тормышы мул. Шлак-бетоннан салып, сары төскә буяп җибәргән, су белән җылыту системасы кертелгән өе һич тә шәһәрдәге квартиралардан калышмый. Өйдә шифоньер, никельле кроватьлар, матур өстәл-урындыклар; яңалыклар белән танышасың килсә, рәхим ит, өй түрендә «Арфа» радиоалгычы, телевизор.

Өй алдына чыксаң, чолан тулы ашлык («40 потлап булыр»,— ди Бари ага), абзар тулы терлек. Бари аганың янындагы уллары Камил белән Ильяс ай саен һәркайсы кимендә 95—100 әр сум, кызы Мөнәвәрә (ул октябрь аенда санаторийга барып кайткан) 80—90 сум акча алып кайтып тора. Бу колхозда механизаторларның һәм терлекчеләрнең уртача эш хакы әнә шундый.

Юк, Бари ага тормышы башкаларныкыннан әллә ни аерылмый. Телевизор турында сүз чыккан икән, ул колхоздагы 240 хуҗалыкның 130 ында бар. Мотоциклы гаиләләр дә кырыклап. Колхозчыларның кием-салымы да шәһәрдәгечә.

Шулай да халык бөтенләй үк канәгать түгел икән. Яшьләрнең күңеле шәһәргә тартыла. Бари абзыйның уллары-кызлары аның сәбәбен болай аңлаталар:

— Көз көне кичләрен күзгә төртсәң күренмәслек караңгы, урамнар пычрак. Бер кая барыр хәл юк. Укыйм дисәң, уку йорты, зуррак китапханәсе дә юк. Эчпошыргыч тынлык монда. Ә яшь күңел шау-шулы, гөрләп торган тормышка омтыла. Кайберләрен шәһәрнең асфальт урамнары, бөтен уңайлыклары булган квартиралар да кызыктыра...

Димәк, байтак кешеләр шәһәрдәге кебек тормыш тели. Бари ага гаиләсенең теләге шәһәргә китү түгел, авылны шәһәр итү.

Партия Программасында да авылның иртәгесе көне — шәһәрне куып җитү. Әмма авылны ничек шәһәр дәрәҗәсенә күтәрергә һәм шәһәр белән авыл арасындагы культура-көнкүреш аерымлыкларын ничек бетерергә?

Теоретик яктан бер нәрсә ачык: авылларны тизрәк берләштерергә! Югыйсә унбиш-егерме йортлы авыл өчен зур һәм матур итеп культура сарае саласыңмы, урта мәктәп төзисеңме? Ашханә булдырасыңмы?..

Мәсьәләне практик яктан хәл итү кыенрак. Әнә моннан ун ел элек инде 8 авыл эшчеләр белән крестьяннар союзы хөрмәтенә «Урак һәм чүкеч» исемен алган бер колхозга берләшсә дә, бер-берсе белән тыгыз экономик элемтәләр урнаштырса да, уртак интереслар белән яшәсә дә, бер идарәгә буйсынса да, сигезе сигез урында тора бирә. Әй комачаулый да соң бу таркаулык! Аннан ничек котылырга кирәк?

Хәер, бу сорауга җавап эзләп кемнәр генә баш ватмады! Авылларны матурландыру, төзекләндерү буенча практик эшләр башкаручылар да аз булмады.

— Ләкин көн тәртибенә байтактан куелган җитди мәсьәләне бөтен ил, бөтен республика күләмендә хәл итүгә бары тик соңгы вакытта гына керешелде,— ди ТАССР Авыл хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш идарәсе начальнигы В. Тимофеев.— Дөресрәге, КПСС Үзәк Комитетының һәм СССР Министрлар Советының «Авылда төзелешне тәртипкә салу» турындагы мәгълүм карары өлгереп җиткән мәсьәләне кузгатып җибәрде, әйтерсең лә, боялеп торган су юлыннан киртәләр алынды.

Әлеге карар нигезендә республикада авыл төзелешен тәртипкә салу буенча КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советы конкрет чаралар эшләде. Игътибарны беренче чиратта районнарның планировка схемасын булдыруга юнәлдерде. Карар практик эш белән ныгытылды. Республиканың проект оешмалары кыска срокта барлык районнар буенча киләчәктә эреләнеп үсәчәк авылларның схемасын төзеделәр. Бу схема нигезендә, мәсәлән, Сарман районында хәзерге 115 авыл урынына 34 поселок һәм авыл булачак. Элек күп кенә авылларда 50 дән 200 гә кадәр кеше яшәсә, эреләндерелгән авылларда яшәүчеләр саны 700 дән ким булмаячак.

Биектау районында да хәзерге 187 поселок һәм авыл урынына 45 торак пункт кына кала. Хәзер барлык колхоз һәм совхозларның үзәк усадьбасы генераль планы эшләнә. Ә Биектау районының безгә таныш «Урак һәм чүкеч» колхозында үзәк усадьба өлгерде инде.


## Беренче карлыгач

Генераль план нигезендә 8 авыл ике урынга — үзәк усадьбага һәм ярдәмче поселокка тупланырга тиеш.

Ләкин әлеге үзәк усадьба — шәһәргә охшаган беренче авыл, ягъни агрошәһәрчек — җиңел генә тумады. Аның нинди булырга тиешлеген уйлап, хыялланып йокысыз төннәрен уздыручылар да аз булмагандыр. Үрнәк авыл планировкасы проектын эшләү буенча игълан ителгән конкурска «Татгипросельхозстрой», «Татколхозпроект» институтлары, Казан төзүче-инженерлар институты һәм Архитекторлар союзы катнашуы мәсьәләгә ни дәрәҗәдә җитди карауны ачык күрсәтми түгелме соң? Дүрт миллион сумга төшкән шәһәр йөз еллар буена шунда утырырга тиеш.

Конкурста Казандагы төзүче-инженерлар институты эшләгән проект кабул ителеп, аңа башка проектларның да иң уңышлы элементлары өстәлде. Нәкъ шул проект нигезендә менә өченче ел үрнәк авыл, дөресрәге, шәһәргә охшаган авыл салына.

Кайда соң ул агрошәһәрчек? Казан — Арча юлы белән барганда, Чыпчык станциясенә җитәрәк, асфальт тасма уңга тармаклана. Шул тармакка борылсагыз, күз алдыгызга агрошәһәрчек панорамасы калкып чыгар. Ул Шәпшинка елгасының сул ягына канат җәйгән. Уң ягында агач йортлар тезелгән, ни бары бер урамлы иске Шәпшә авылы. Гүя аларны бер-берсенә чагыштыру өчен, яңа авылның — коммунизм авылының өстенлеген, матурлыгын күреп бетен халык соклансын өчен шулай янәшә куйганнар.




Уналтышар квартиралы өзер конструкциялэрдән салынган ике йортны һәм бер-ике бинаның нигезен исәпкә алмаганда, моннан ел ярым элек кенә агрошәһәрчек урыны бушлык иде. Бер җәй эчендә яңа шәһәр үсеп чыкты. В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу көненә гөрләтеп әй туйлары уздырдылар.

Агрошәһәрчекнең шулай тиз төзелүе — тагын шул ук урак белән чүкеч дуслыгы нәтиҗәсе ул. Эшчеләр һәм төзүчеләр үрнәк авыл төзүгә теләп алындылар. Бирегә Казандагы кирпеч һәм төзү материаллары заводыннан ак силикат кирпеч һәм тимер-бетон конструкцияләр төялгән йөк автомашиналары кызыл обоз булып агылды. Экскаваторлар килеп фундамент өчен чокырлар, су һәм җылылык трубалары өчен канаулар казыдылар. Жираф шикелле, муеннарын сузып, күчмә краннар килеп басты. Шәпшә авылы тирәсе бервакыт туктаусыз машиналар гөрелтесенә күмелде. Казандагы 1 нче һәм 2 нче төзелеш трестларыннан, «Казаньхимстрой» трестыннан, «Татсельстрой» идарәсеннән махсус бригадалар, күчмә колонналар, «Союзтатгаз», «Средневолжсксельэлектросетстрой», «Связьстрой-4», «Гидроспецстрой» трестлары, ТАССР Министрлар Советы каршындагы юл төзү һәм ремонтлау идарәсе, ТАССР мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгы бергәләп эшне комплекслы тәртиптә киң җәелдерделәр.

Менә инде алар башкарган эш күз алдында. Үрнәк авыл өч өлештән тора дисәк, ялгышмабыз. Асфальт юлдан аңа кергәндә сезне беренче производство биналары каршылар. Сулда, завод корпусларын хәтерләтеп, тимер-бетон конструкцияләрдән корылган яссы түбәле дүрт бина тора. Икесе — сыерлар абзары, алар 200 әр баш сыерга исәпләнгән. Абзарларда хезмәт тулысынча механикалаштырылган. Ә күршедәге ике бина әлеге «сөтбикә»ләрнең уллары һәм кызлары өчен. Аларның һәрберсендә 200 әр бозау үстерелә.

Ферма тирәсендә колхоз председателе Александр Петрович Орловны очратсагыз (ул анда еш була), күп кенә кызыклы мәгълүматлар бирер.

— Бу биналар — сөт фабрикасы,— дияр ул.— 1968 елны да без бер сыердан уртача 3333 килограмм сөт савып, 13.500 центнер сөт җитештердек. Узган ел колхозыбыз

уңганнары — коммунист Фәния Нургалиева, Мөнәвәрә Кәримуллина, Сания Мөхәммәтова, Антонина Матвеева бу күрсәткечләрдән шактый узып та киттеләр. Ит-сөт җитештерү — колхозыбызның төп юнәлеше. Холмогор нәселле сыерлар — чын сөт чишмәсе.

Александр Петрович һәрвакыт эшләпәсен басып киген булыр. Урта буйлы, тулы йөзле. Яше кырыкларда. Уйчан, кырыс күренә. Вакыт-вакыт, үзе аз гына да елмаймыйча, шаярта да белә:

— Монысы — азык кухнясы,— ди ул, ферма янындагы заводныкы кебек озын трубалы кирпечтән салынган бинага күрсәтеп.— Шәһәргә күчкәч, безнең сыерлар да «культуралаштылар». Аларга кырдан кайтарылган саламны шул кее генә ашатам димә. Башта кухняга алып кереп эшкәрт, төмләндер — сөтбикәләр шуннан соң кабул итәләр...

Ферма тирәсендә зур, биек булып калкып торган биналар белән беррәттән күзгә күренми торганнары — цементланган силос траншеялары, 500 тонналы яшелчә саклагыч, тирес саклагыч һ. б. лар тезелеп киткән.


Фермадан уңдарак ике катлы өй биеклегендә кызыл кирпечтән салынган зур-зур тәрәзәле тагын бер бина игътибарны җәлеп итә. Анысы механика мастерское икән. Мастерскойга берьюлы 12 тракторны ремонтка куеп була. Ремонтчы өчен җиһазлар, станоклар җитәрлек. Баһадир кран-балка — бу эштә иң якын ярдәмче.

Мастерской да ялгыз түгел. Аның артында 20 автомашина куярлык гараж, авыл хуҗалыгы машиналары өчен зур сарай тезелә.


Производство зонасын үткәч тә, уңда — административ комплекс, сулда — торак йортлар тезелгән.

Әйдәгез, башта «Урак һәм чүкеч» колхозы кешеләре яши башлаган өйләргә сәяхәт итик. Әлегә йортларның кайсы урамда, нинди номерлы булуына игътибар итмичә, нинди типта (чөнки биредә алар 11 типта) булуларына, нинди уңайлыклар тудырылуына карап фикер йөртү кызыклырак.

Административ комплекс белән торак массив арасында бер шеренгага баскан икешәр катлы алты йортка игътибар итегез. Ул матурлыклары аларның! Үзләре җыйнак. Кечкенә-кечкенә балконнары да бар. Ике катлы бу өй нибары ике гаилә өчен. Берсе — өске, икенчесе — аскы катта дип уйласагыз, ялгышасыз. Һәр семья өске катта да, аскы катта да яши. Бәрәңгесен, яшелчәсен саклау өчен өйнең тагын бер катын хәтерләткән подвал да бар.



*Уңда — балалар комбинаты, уртада — мәктәп, сулда — өч катлы административ үзәк.*



*Менә ул агрошәһәрчектәге ике катлы ике квартиралы уңайлы йортлар*

Беренче каттагы уңайлыклар турында берничә сүз. Монда туалет, ванна бүлмәсе, кухня, кухняда газ плитәсе. Су ташыйсы, су түгәсе дә юк. Газ дигәннәре киленнәрнең уңганлыгын, өлгерлеген бермә-бер арттыра инде. Шушы ук түбән катта ашханә өчен дә бүлмә бар. Кухня белән рәттән генә ул.

Өске катта — зал, балалар бүлмәсе, йокы бүлмәсе. Бар да якты, күңелле. Бу өйләрдә шәһәрдәгедән дә уңайлырак, минемчә.

Хәзер урамнарга күчик. Бер урамның сул ягында бер катлы ике квартиралы йортлар тезелеп киткән. Квартиралар бер-берсеннән яхшы изоляцияләнгән. Берсенең ишеге өйнең бер ягында, икенчесенеке — икенче якта. Верандалары да бар. Һәрберсендә — кухня, ванна, туалет, зал, йокы бүлмәсе. Йорт тирәсе палисадник рәвешендәге тәбәнәк кенә рәшәткә белән әйләндерелгән.

Урамның икенче ягында — бер генә квартиралы бер катлы йортлар тезмәсе. Аларда да шундый ук уңайлыклар.

Авыл кешесе өчен мал-туарсыз, өй артында бакчасыз яшәү — яшәүмени! Үрнәк авыл төзелешендә болар бөтенесе исәпкә алынган. Йортта терлекләргә сарай эшләнгән, өй артында бакча бүленгән. Тиздән анда җиләк-җимеш агачлары шаулап утырыр. Суган, кыяр, помидор үстерү өчен дә урын бар. Аларга суны ерактан ташыйсы түгел, шланг белән генә сиптер!

Дөресен генә әйткәндә, агрошәһәрчекне бизәп торган 156 квартираның кайсына гына керсәң дә күңел куана.

Күңелле яңа ел көннәрендә зур күченү булды бу йортларга. Бәхетле семьялар күчте аларга. Шуларның берсе безгә таныш Бари ага Кәримуллин гаиләсе. Бу гаиләнең шатлыгын әйтеп һәм сөйләп кенә бетерә торганмыни!

Бу авылдан колхозда 9 ел шофер булып эшләүче Зөфәр Гаделшин гаиләсе дә яңа өй туе шатлыгы кичергән. Ул да моны түземсезлек белән көткән иде. Узган көз очрашкан вакытта:

— Шунда күчәм дип, мотоциклыма гараж да ясамыйча торам,— дигән иде.

Менә яңа урында гаражын да өлгертеп куйган инде.

Колхоз механизаторы Әнәс Ахунҗанов та ике бүлмәле квартирага күчеп килгән. Тормыш иптәше Дания белән чөкердәшеп яши Әнәс яңа йортта. Колхоз агрономы Газиз Абдуллин да бер катлы өч бүлмәле особнякка урнашып алган.

Хәер, Салкын Чишмә тулысынча яңа авылга күчеп беткән. Салкын Чишмә инде халык телендә бер истәлек кенә булып калды.

Яңа авылга Шәпшә белән Сидор авылларыннан да 20 семья күчеп килде. Тормыш түгәрәк. Рәхмәт әйтеп яшәргә дә яшәргә генә инде.

Тик ул йортларга күчүчеләр кемгә рәхмәт әйтерләр икән? Алар ни төзүченең, ни проектлаштыручының исемен белмәячәк. Ә бит бу шәһәр, бу йортлар — чын иҗат. Ләкин аның авторы кем? Һәр җырның, шигырьнең яки скульптураның халыкка билгеле авторы булган кебек, рухландыргыч иҗат булып туган агрошәһәр авторларын да халык яхшы белергә тиеш. Аны проектлаштыруга иң зур көч куючыларның берсе — бик лаеклы кеше — Казан төзүче инженерлар институты доценты Иптәш Бикчәнтәев. Торак йортларның стеналарын ак һәм кызыл кирпеч белән аралаштырып — орнаментлап өйгән төзүчеләрне дә нигә анда яшәүчеләр белмәскә тиеш?! Нигә һәр йорт кенәгәсенә: «Бу йортны «Татсельстрой» идарәсенең 729 нчы механикалаштырылган күчмә колоннасыннан (ПМК) РСФСРның атказанган төзүчесе Равил Сәләхетдинов бригадасы төзеде», дип язып куймаска! Шулай ук агач эшләрен РСФСРның атказанган төзүчесе Фәсәх Кыямов бригадасы балта осталары, отделка эшләрен П. Плешакова комплекслы бригадасы членнары башкарганлыгын теркәү дә күңелле булыр иде. Алар биредә авылны үзгәртеп кору буенча Ильич васыятьләрен тормышка ашыруга үзләреннән зур өлеш керттеләр ич!

Ниһаять, без административ комплекска килдек. Мин аны үрнәк авылның иң гүзәл өлеше дияр идем. Монда инде шәһәргә охшаш җанлылык та сизелә хәзер. Төш җитте исә, кешеләр ашханәгә агыла.

Ашханә дигәннәре зур-зур тәрәзәле, соңгы стильдә эшләнгән, теләсә кайсы шәһәр урамын бизи алырлык мәһабәт бина. Залында иңнеләп урындык, өстәлләр. Ак халатлы официанткалар пар бөркеп торган аш өләшә. Агрошәһәрчектәге иң беренче файдалануга тапшырылган объект ул. Төзүчеләр — үзләре аның беренче клиентлары.

Ашханәгә кырын салынганы — алгы яктан бөтен стенасы пыяладан торганы — универмаг. Ашау-эчү әйберләре дисеңме, кием-салым яки тукыма дисеңме, модалы аяк киемнәреме,— теләгәнеңне сайлап ал. «Татсоюз» боларны барыннан да тизрәк китереп өлгертергә тырышкан.

Ашханәдән уң якта — көнкүреш комбинаты. Ул — дүрт катлы сары төстәге бина. «Урак һәм чүкеч» колхозы авыллары тарихында беренче тапкыр буларак, монда кием тегү, чәч алдыру, көнкүреш техникасын, аяк киемнәрен ремонтлау, фотога төшерү буенча күп санлы осталар эшләячәк. Комбинатның бер катында кунак бүлмәсе — гостиница ачылачак.

Кызыгырлык башка нәрсәләр дә бик күп бу шәһәрдә. Бала-чага үстерүче атааналарга иң кирәге — балалар комбинаты. Ул да, нәкъ Казандагы кебек, соңгы стильдә.




*Биредә сез ашханә һәм көнкүреш комбинаты күрәсез.*

90 урынлы, ике катлы бу бинаның стеналары саргылт һәм күк төстә, тәрәзәләренең зурлыгы балаларга кояш нурларын мул вәгъдә итә.

Торак массив янында гына тагын бер гүзәл бина — агрошәһәрчекнең фельдшерлык-акушерлык пункты, бала тудыру йорты.

Балалар комбинаты белән универмаг арасында ак силикат кирпечтән салынган ике катлы 400 урынлы урта мәктәп. Спорт залы, кабинетлары, класс бүлмәләре, китапханәсе — бары да шәһәр мәктәпләрендәгечә.

Әлеге комплекс уртасында өч катлы тагын бер матур бина игътибарны үзенә тарта. Казандагы 1 нче төзү трестының 3 нче һәм 5 нче төзү идарәсе эшчеләре аны бик тиз салды. Күп кенә райком биналарыннан да чибәррәк бу йортта тиздән колхоз идарәсе, авыл советы, элемтә бүлеге урнашты. Белгечләр өчен дә, халыкны культуралы кабул итү өчен дә бүлмәләр җитәрлек бирелә.

Агрошәһәрчектә элекке алпавыт Пенегин урманы да «әшкә җигелә». Ул яңа шәһәрнең ял паркына әверелгән. Аның куенына кертеп зур культура сарае төзелгән. Анда 400 урынлы тамаша залы, түгәрәкләр өчен бүлмәләр, танца мәйданчыгы, китапханә булачак. Бу төзелешне «Казаньхимстрой» төзүчеләре башкарды.

Культура сарае каршында гына су бассейны көзгедәй ялтырап тора. Эссе чакта халык анда су коена. Элек анда чыпчык тезеннән дә су юк иде. Шапшинка елгасы — коры елга ул. «Гидроспецстрой» трестының Н. Нагорный бригадасы, агрошәһәрчекне сулы итү өчен, Шапшинканы 9 метр биеклектә буып, 27 метр озынлыкта плотина корды. Әйе, дамбаның як-якларын цементлап, чын плотинага әверелдергән ул. Бассейнда дулкыннар уйный, тиздән карплар йөзәр.

Бассейннан түбән як та бик нык ямьләнер. Хәзергә чаклы әрекмән һәм кычытканнар үсеп утырган җирләр яңа шәһәрнең спорт корылмалары урыны — стадион итәлә.

Казан автомобиль юллары идарәсе агрошәһәрчек урамнарына һәм тротуарларга 22 мең квадрат метр асфальт җәя. Терлек абзарлары тирәсендә 3 мең квадрат метрга вак таш түшәлә. Һәм яңа авылда — агрошәһәрдә Гөлбикә абыстайлар, Мария түтиләр, язгы-көзге пычракның ни икәнен дә белмичә, асфальт өстеннән читек-кәвештән генә йөрерләр.

Бу көн килде. Ә бит яңа тормыш өчен көрәшнең беренче көннәре авыр, бик тә авыр иде. Ул чакта чыннан да көрәшергә, бу көрәштә аерым кешеләргә гомерләрен дә бирергә туры килде. Андыйлар «Урак һәм чүкеч» колхозында да булды, һәм аларны онытмыйлар. Әнә Шәпшәдә кулакларга каршы көрәштә һәлак булган колхоз төзүче — бригадир Данил Марфинны тирән ихтирам белән телгә алалар. Шәпшәләләр хәзер Марфиннар башлаган эшне Ленин күрсәткән юлдан уңышлы дәвам итүләре белән горурланалар. Бүгенге авылның чәчәк атуында Марфиннарның да өлеше булуы турында әйтәләр. «Урак һәм чүкеч» артеле членнары колхозчыларның III Бөтенсоюз съездында кабул ителгән Үрнәк Уставта бүгенге чәчәк аткан авыл тормышы кагыйдәләре теркәлүен зур канәгатьләнү белән белдерәләр.

**Гариф Ахунов,**
**Марсель Зарипов**

# ТАТАРСТАН — ТУГАН ЙОРТЫБЫЗ[1]

## Юл башы



„Россиянең олы урамы» дип дан алган бөек Иделебез бар. Өно шул бөек елга буена урнашкан автономияле республикаларның иң зурысын — туган-үскән Татарстаныбызны укучыларга ничек тәкъдим итәргә?

Бәлки сүзне нефтьтән башларгадыр? Илебездә табылган нефть хәзинәсенең өчтән бер өлешен Татарстан биреп килә бит.

Бәлки сәгатьтән башлап җибәрү хәерлерәк булыр? Ник дисәң — дөньяның илле өч мәмләкәтендә вакытны безнең сәгатьләргә карап беләләр. Космонавт Герман Титов та, Җир тирәли уникенче мәртәбә әйләнеш ясаганда, вакытны Чистай осталары ясаган сәгать буенча тикшереп торган. Әйе, сәгатьтән башларга мөмкин. Ләкин безгә химиклар үпкәләмәсме? Кайчандыр сабын кайнату, тире иләү, чыпта сугу белән дан казанган Казан губернасы бүген зур Химия иленә әверелә. Кама ярларында гигант Химкомбинат күтәрелә. Бирәдә минераль ашламалар, автомобиль шиннары, үтә нык изопрен каучук җитештереләчәк. Ул чимал базасы — нефть промыселлары, Казанның органик синтез заводы белән берлектә, Европада тиңе булмаган бердәм нефтехимик комплекс тәшкил итәчәк. Бүген әле беренче казыклары гына кагылып яткан, берничә елдан илебезнең иң зур гигантларыннан берсе булып әвереләчәк Чаллы автомобиль заводыннан башларга кирәктер бәлки?

Ә мехлар? Компрессорлар? Кетгут?

Ә Татарстан игенчеләре ел саен ил амбарына сала торган күп миллионлаган пот икмәк?

Әллә сүзне мең еллык культурабыздан башлыйк микән? Әле дә кыйммәтен югалтмаган борынгы шигъри ядкарьдән — Колгалинең «Йосыф кыйссасы»ннан башлап җибәрсәк? Әллә «Шүрәле»дәнме? Тукайның шигъри таланты белән тагын бер баскыч югары күтәрелгән, Фәрит Яруллин музыкасы белән канатланып, Европа сәхнәләрендә урын алган һәм инде Канадага хәтле барып җиткән шушы халык күңеле җәүһәреннән башлау дөресрәк булмасмы?

---

[1] «И кадерле туган як» китабыннан кайбер бүлекләр. Әсәр 1971 елда Татарстан китап нәшриятында тулысынча басылачак.

Әйе, сөйли белеп сөйләсәң, туган-үскән Татарстаныбыз турында сөйләр сүзләр бик күп.

Шулай да бу язмаларны Иделдән башлап җибәрү яхшырак һәм дөресрәк булыр. Чөнки ул илебездәге барлык елгаларның елгасы. Бу тирәдән меңнәрчә чакрым ераклыкта яшәүче Себер кешеләре дә, тормышын үз елгасыннан башка күз алдына китерә алмаган Дон казагы да, Төньяк диңгезләрен аркылыга-буйга үткән Архангельск поморы да аны үз итә, якын күрә. Идел буйларында яшәүче руслар, татарлар, марилар һәм чувашлар турында әйтеп тә торасы юк инде.

Волга! Руслар аны авыз тутырып шулай дип йөртәләр. Татарлар Идел дип зурлыйлар, Иделкәем дип назлап җырлыйлар. Күрәсез, төрлечә атыйлар аны, әмма бердәй ихтирам, бердәй ярату белән телгә алалар. Чөнки без, Идел буенда яшәүчеләр, тормышыбызны аның белән бәйләгәнбез. Гарәпләрне Нилдан, американнарны Миссисипидан, һиндларны Гангтан башка күз алдына китереп булмаган кебек, без дә тормышыбызны Иделдән башка күз алдына китерә алмыйбыз.

Бөек Ленин гомеренең өчтән бер өлешен Идел буенда үткәргән. Владимир Ильич чит илләрдә эмиграциядә яшәгән чагында бөек елганы сагынып искә алган. «Җәен Иделдә нинди хозур!» — дип язган ул хатларының берсендә.

Укучы дусларыбызга алдан ук әйтеп куйыйк, без юл күрсәткеч белешмә язарга җыенмыйбыз. Ник дигәндә, бик иркен итеп, бик җентекләп төзелгән юл күрсәткеч тә ахыр чиктә тормышның тоныкк бер чагылышы гына булып кала. Тагын шул ягы да бар: хәзерге шаулы космос заманында юл күрсәткеч белешмәләр бик тиз искерәләр, кешеләргә булышасы, компос хезмәтен үтисе урында, буташтырып кына бетерәләр.

Шуңа күрә без иң мөһиме хакында — республикабызның тугандаш халыклар семьясында ирешкән гаять зур уңышлары, урман-кырлары, елга-сулары, җир асты байлыклары хакында, ә барыннан да элек, фидакарь хезмәтләре белән җир йөзен бизәүче, туган-үскән илебезнең кадерен белүче, Алексей Максимович Горький сүзләре белән әйткәндә, «зур максатка булган омтылышны киң күңел белән бәйли алучы» батыр йөрәкле якташларыбыз турында сөйләп бирергә телибез.

## Елгаларның елгасы

Каяндыр, Калинин каласының теге ягыннан, бәләкәй генә бер инеш агып чыга. Иелеп карасаң, тоныкк суда маймыч балыкларның елтыр-елтыр җемелдәшкәннәре күренә. Ел саен күпләп килә торган туристлар аны әле атлап та чыга алалар. Әнә шул меңләгән туристлар дөньяга иң кадерле сувенир итеп, инешнең «изге суын» флягаларга, шешәләргә тутыра башлагач: «Ай-һай, тутырып бетермәгәйләре!» — дип, хәвефләнеп тә куясың.

Бу инештә әле без белгән гайрәтле, мул сулы Иделдән берни дә юк. Ул әле үсмер кызны хәтерләтә. Әле яр буе куаклары арасына качып, әле кояшта йөгереп чыгып шаярып йөргән җитез кызыкайны күз алдына китерегез. Идел суының шушы җитез бормаларына, гөлдерәп кенә агып ятуына карыйсың да, юк, бу диңгезгә тикле барып җитә алмас, халык теленә дә кереп җитмәс борын, кайнар кояшта кибеп, коры үзән булып калыр, дип курка башлыйсың.

Юк икән, яшәргә яратылган — яши. Йөзләгән километр җир узгач, елга олысымакланып китә, холкы да җитди-кырысрак була бара, үйчәнләнә. Әлеге шаян-җитез-тиктормас кыз кая китте соң? Буй-сын дисеңме, акыллы сабырлык дисеңме — ул хәзер сине өзлексез мавыктырып, үзенә чакырып тора. Һәм менә инде яр буена тәүге бер каралты — каравылчы өе дә килеп чыкты, әнә шул өйгә таба ботак-сатак төяп, яңа чабылган хуш исле яшел печән төяп, көймә килә. Ниһаять, менә йортлары бер дистәдән артмаган бәләкәй генә бер авыл да яр буена килеп кунаклады.

Тагын бер йөз километрлар узгач, кызыл күзен кыскалап маяк яна, зәңгәр буяулы бәләкәйрәк катер, тырт-тырт килеп, моторын тырылдатып, сөт сатучыларны елга аша алып чыга башлады. Палубадан сөйләшкән тавышлар ишетелә, хатын-кызлар сөтнең бу араларда ни бәя торуы, базар мәшәкатьләреннән котылып, якты күздә өйгә кайтып җитәргә кирәклеге турында гәп саталар.

Менә, ниһаять, беренче пристань. Искереп беткән баржада кыңгыраулы яшел будка тора, балыкчылар анда каклаган балык саталар.

Бу инде — Идел. Елгаларның елгасы, исеме җырларга күчкән, телләрдән төшми сөйләнә торган Идел. Гөлдерәп кенә агып яткан бәләкәй инеш урнына бөек елганың гайрәтле ухылдавын ишетәсең, аның дәһшәтле тавышына буйсынып, яр буена авыллар, калалар, зур һәм бәләкәй елгалар йөгереп киләләр.

Иделнең буе дүрт мең чакрымнан бик аз гына ким. Ул үзенә җиде мең инешнең суын җыйган. Балаларын багучы ана кебек, меңләгән авыл һәм калаларга, олы һәм вак елгаларга сулыш биргән. Теплоход салмак агучы дулкыннарны узып, шау-шулы пристаньнарга килеп туктый һәм син бала чактан ук таныш булган исемнәргә күз йөртеп барасың: Калинин, Ярославль, Горький...

Бу да Идел. Үз гомерендә күпне күргән, күпне кичергән елга, хезмәт кешесенең җилкәсеннән ничәмә албастыны алып ташлап, күкрәк киереп өр-яңа тормыш төзи башлавына шаһит булып аккан елга!

Казаннан арырак китеп, түбәнрәк төшкәч, Идел үзенә Кама суын кабул итеп ала, ә Кама үз нәүбәтендә төньяк сылуы Вятка һәм ямьле Агыйдел суларын алып килә, синең күз алдыңда шундый да зур дәрья җәелә, моның кайдандыр, өч мең чакрымнар ары, кечерәк кенә бер кизләүдән, караңгы җир астыннан бәреп чыккан чишмәдән башланып киткәненә һич кенә дә ышанасың килми башлый.

Ике олы елганың бергә кушылуын күрү бик күңелле. Кама тамагы пристаненнан караганда күзгә берьюлы ике тасма ташлана: каракучкылы — Идел, яктырагы — Кама. Ул тасмалар ике-өч чакрым узганчы янәшә баралар.

Бер сәгать бара теплоход, ике сәгать бара,— елганың яры күренми. Офыкта мачталар, чиксез су киңлегендә акчарлаклар һәм җай гына агып килүче саллар караваны...

Рәхәт бу тирәләрдә, капитаннар бер-берсе яныннан бик иркенләп, хәвеф-хәтәрсез узалар.

Ләкин бу инде тыныч холыклы, моңсу елга түгел. Сигналларга ныгытып колак сал, капитан: вакытың бик аз булса да, сабыр ит, салчы дустыбыз! Шторм башланачагын якындагы гидрометстанция хәбәр иткән икән инде, салыңны сулгарак бор да тыныч бер култыкка кертеп куй, давыл узганны көтеп алырга сабырлыгың житсен. Елга бер ухылдап алып, яшел дулкыннарын ирекка чыгарып җибәрдеме, корыч арканнарыңны җепне өзгән кебек кенә өзеп атачак, бүрәнәләреңне чәлпәрәмә китереп дәрьяга сибәчәк.

Усал да холыклы елга ул Идел! Ә кояшлы аяз көннәрдә син аның тынычлыгына таң каласың. Бигрәк тә иртән. Җилләр ояларына кереп йокыга талгач, Идел дәрьясы таң нурларында иркәләнеп ята, су өстендә дулкын әсәренең эзе дә юк, әйтерсең, ул күптән түгел дулавыннан, шашынуыннан арып-талып, рәхәт ялга чумган. Хәтта елга уртасына ук килеп эләккән яфрак та чыланмый-нитми тыныч кына тирбәлеп ята.

Нинди иркен рәхәтлек! Син колакларны чыңлатырдай тынлык эчендә калгансың. Иделнең матурлыгына хәйран булып, шундый могҗизави матурлыкны тудырган елгага мең-мең рәхмәтләр әйтергә әзер торасың.

Менә бу да Идел, бу да туган җиребез.

Һәм инде син үзеңдә ике көчнең тартыша башлавын тоясың. Юл ни дисәң дә юл инде ул, син аның тизрәк бетүен телисең, көмеш канатлы лайнерларда, җилдәй җитез поездларда, коштай җиңел машиналарда барган кешеләрдән көнләшеп тә куясың. Шул ук вакытта инде туганыңдай якын булып киткән елга белән аерылуы да кыен. Әгәр шунда берәрсе, әйдә, самолетка күчеп утырабыз! — дисә, мөгаен, килешмәс идең.

Идел безнең уй-хисләребезне баета, гайрәте белән сокландыра һәм без үзебезне көчлерәк, канатлырак итеп тоя башлыйбыз. Иделнең әнә шундый хасияте дә бар.

Бәлки моны нәфис сүз белән дә, бик төгәл язылган гыйльми тикшеренүләр аша да аңлатып булмыйдыр, әмма Идел, баласын кайгырткан ана кебек, үз улларының холыкларына юнәлеш бирә. Безнең халкыбызда хезмәт сөю, дусны дус күрү, туган илебезне ярату, киң күңелле һәм батыр йөрәкле булу сыйфатлары бар икән — болар Идел биргән сыйфатлар.

Идел балалары Иделнең изгелеген меңе белән кайтаралар. Алар аның үткәндәге, бүгенге һәм киләчәктәге даннары. Идел үз уллары һәм кызларының каһарманлыкларында, данлы эшләрендә мактала, мактальп кабатлана, чөнки ул аларны аякларына бастырган, аларга очар канат биргән.

Тверь сәүдәгәре Афанасий Никитин европалылардан беренче булып ерак Һиндстанга кадәр барган чакта Идел аша узган. Иделдә Стенька Разин каекларь: чайкалган. Пугач Иделдә атын эчергән. Идел крестьяннар моң-зарын җырлаучы Некрасовны, бунтарь Чернышевскийны тудырган. Идел деньяга Горькийны, Ульяновларны, җир йөзендә беренче хатын-кыз космонавт «Чайка»ны һәм беренче космик семья Валентина белән Андриян Николаевларны бүләк итте.

Идел мәгърифәтче Каюм Насыйрины, беренче татар революционеры Хөсәен Ямашевны үстерде, Тукай һәм Такташ, Җәлил һәм Фатих Кәрим җырларына, Сәйдәш һәм Яруллин моңнарына канат куйды!

Легендар очучы Михаил Девятаевка — батырлыкның үрнәге булган кешегә, тормышы белән үк әкият-легендаларга биргесез замандашыбызга — каерылмас көчле канатларны шулай ук бөек Идел бирде.

## Декабристлар урамыннан Ирек мәйданына хәтле

Туристлар Казанның шау-шулы урамнарыннан юл күрсәткеч белешмә эзлиләр. Музейларга чиратка басалар. Кешеләр Татарстанның борынгы тарихын да, бүгенге яңалыкларын да күз алдына китерергә тырышалар.

Профессор Н. П. Загоскинның 1895 елны басылып чыккан «Казан буйлап сәяхәт» дигән китабы укучыларга менә нинди белешмә бирә:

«...Беренче урында бертуган Крестовниковларның сабын кайнату заводлары, аннары ике пар тегермәнә, 14 күн эшкәртү заводы, 2 аракы заводы, 3 скорняклык заведениесе булыр...»

Революциягә кадәр басылган тагын бер юл күрсәткеч шәһәрнең хәлен тагын да образлырак итеп әйтә: «Астрахань балык патшалыгы булса, Казанны сабын патшалыгы дип атарга мөмкин...»

Әйе, белешмә-сәяхәтнамәләр шактый ук күңелсез картинаны күз алдына бастыралар.

«Шәһәр читендәге аскы урамда, бер-беренә сыенып, тәбәнәк иске өйләр тезелеп киткән: тәрәзәләре кыек, стеналары янтайган; вакытлар узу белән, эштән чыккан бу алачыкларның түбә тишекләренә агач каерысыннан ямаулар салынган, мүк үскән; түбәләр өстендә анда-санда озын колгалы сыерчык оялары тырпаешып торалар; йортларны ярлы халык яши торган шәһәр читләрендәге бердәнбер яшеллек — тузанга баткан кәрлә тирәкләр һәм эт миләше ябалдашлары күләгәләп...

Югарыда, тау башында, ямь-яшел бакчалар эченә күмелгән таш йортлар, күккә ашкынган мәһабәт чиркәү гөмбәзләре күренә, аларның алтын тәреләре кояшка каршы күзләрне чагылдырып җемелди.

Яңгырлар явып узса, аскы урамга шәһәр үзенең пычрагын агыза, көннәр корыга китсә, тузанын сибә — һәм әнә шул гарип чырайлы шөкәтсез өйләр үзләре дә, себереп ташланган чүп көбек, кемнеңдер гайрәтле кулы белән аска тәгәрәтеп төшерелгәндәй тоела иде».

Узган гасырның сиксәненче елларындагы Казан бу. Байлар һәм ярлылар, ачлар һәм туклар Казаны. Һәм моны кемнәндер ишетеп белгән аз мәгълүматлы узгынчы түгел, Казанны үз күзләре белән күргән, аның пекарняларында ипи пешереп, Идел баржаларыннан йөк бушатып яшәгән Алексей Максимович Горький язган.

Революциягә кадәрге Казанны күз алдына китерик дисәк, шулар янына тагын күккә кадак булып кадалган унөч мәчет манарасын, кырык чиркәү колокольнясын, таш мостовойны дөбердәтеп чапкан арбаларны, атлар тартып йөргән трамвайларны, болгап-болгап күккә кара төтен бөркегән завод морҗаларын, пристаньнарда җилфердәгән сәмруг кошлы патша флагларын һәм пристань басмаларында капчыклар авырлыгыннан сыгылып килгән сәләмә киемле грузчикларны кушарга кирәк.

Менә Иделнең югары ягыннан селедка исе сеңгән карсак пароход килеп туктады. Аның мегрәп кенә кычкырткан моңсу тавышы полиция участоклары, монастырьлар, биек агач коймалар, чат башларына баскан хәерчеләр, толчок һәм Печән базары

әһелләрә белән мәш килеп яшәгән шәһәр естеннән яңгырап үтә дә, каядыр болак артларына, бистәләр ягына узып, әкрен генә юкка чыга.

Никадәр чуар һәм моңсу күренешләр!

Һәм менә туристлар бүгенге Казан урамнары буйлап йөриләр. Туристлар дигәнгә ачыклык кертик. Казан портына теплоходлар чит ил кунакларын көн саен китереп кенә торалар. Туристлар — илнең барлык почмакларыннан, дөньяның барлык континентларыннан. Елга вокзалында украиннарның йомшак сөйләмә себерлеләрнең дала сөйләмә белән аралаша, әзәрбәйҗаннар белән грузиннарның кайнарланып кызу-кызу сөйләшкәннәре ишетелеп кала, үзбәк, кыргыз, тәркмәннәрнең эре генә, вәкарь белән генә сөйләшүләре колакка чалына... Ниһаять, Казан урамнарында син төркем-төркем йөргән чуар киемле чит ил кунакларын: инглизләрне, французларны, итальяннарны, японнарны, гарәпләрне, африкалыларны һәм башка илләрнең, башка континентларның вәкилләрен күрәсең. Алар соңгы елларда шундый күп киләләр, Казан хәтта чит ил кунаклары өчен Идел ярына махсус рәвештә халыкара яшьләр лагере төзәргә мәҗбүр булды.

Башта аларның кайберәүләре бик күп нәрсә белгән төсле кыланалар. Татар халкын Батый хан оныклары дип ялгыш ышанганга күрә, әңгәмә вакытында ат өстендә баручы кыргый җайдакларны күрсәтергә телəп, яннарына камчы белән суккандай итенәләр. Аларга кемдер әйткән: имеш, татарлар — кыргый халык, имеш, алар әле дә чи ит ашаудан туктамаганнар.

Ләкин Казанда атна-ун көн торып, шәһәр белән якыннан танышкач, хезмәт ияләренең эшләү, яшәү шартларын күргәч, татар телендә милли опера тыңлагач, балет карагач, язучылар, композиторлар, художниклар белән очрашып сөйләшкәч, бер сүз белән әйткәндә, татар халкының бүгенге, Совет власте елларында ирешкән мәдәни казанышларын үз күзләре белән күреп, үз колаклары белән ишеткәч, аларга элекке «какшамас иманнарыннан» кире чигенергә һәм шактый ук гаҗәпләнергә дә туры килә. Аларны Казанда унбер югары уку йорты, унсигез техникум, СССР Фәннәр академиясенең Казан институтлары булу гаҗәпләндерә, аларны безнең шәһәребез тирәсендәге яшел урманнарга урнашкан пионер лагерьларында ял итеп ятучы меңләгән баланың дөньяга гаҗәеп якты күз белән каравы һәм һәркайсының «җырлый, бии, тартынмыйча шигырь сөйли белүе» гаҗәпләндерә, аларны больницалар һәм андагы түләүсез багу хәйран калдыра. Һәм алар... тагын да күбрәк белергә, тагын да күбрәк күрергә теләп, Казанның аркылысын-буен карарга рөхсәт сорыйлар.

Рәхим итегез, бездә андый чикләүләр юк!

Шундый экскурсияләрнең берсендә, 1969 елны Казанга ике мәртәбә дүртәр-бишәр йөз кеше булып килгән француз яшьләре төркеменә кушылып, без дә башкалабыз буйлап сәяхәткә чыктык. Көннең көн буе шәһәр буйлап йөрдек, автобуска төялеп тә, җәяүләп тә атладык, бер генә тапкыр да блокнотларыбызга тотынмадык, сөйләгәннәрне без хәтеребезгә генә сеңдереп барырга тырыштык.

Ленин районы белән танышуга ярты көн кирәк булып чыкты.

«Казанның иң зур промышленность районы һәм культура үзәге,— диде экскурсовод кыз. Һәм моның үзәк икәненә французлар да ышандылар. Монда самолет ясыйлар. Кинопленка өлгертәләр (илебездә чыга торган фильмнарның яртысы Казан пленкасында басыла!). Моторлар җитештерәләр. Егерменче гасыр тылсымчылары йөзләгән затлы әйберләргә әйләндерә торган полимерлар да шушы районда өзерләнә. Кайчандыр йөгәнсез җилләр генә йөргән, әрәм белән алабута гына үскән Кәҗә бистәсе бу! Исеме генә ни тора! Монда якты буяуларга буялган күп катлы яңа йортлар күп. Монда мәктәпләр, китапханәләр, культура сарайлары, кинотеатрлар күп, урамнар иркен, бакчалар ямь-яшел. Шуларның барысы егерме биш-утыз ел эчендә төзелгән! Алты гасырлык тарихы булган Казан өчен утыз ел нәрсә ул, тузан бөртеге!

Чит ил кунакларын зәңгәр автобус Киров районына алып чыга. Чачен кыска итеп алдырган экскурсовод кыз бу районның татар телендә Бишбалта дип йөртелгәнен, чөнки монда элекке заманда татар һөнәрчеләре күп яшәгәнен аңлата. Адмиралтейская слобода дигән русча исеме Петр патша хәрби кораблләр эшләткән заманнардан калган икәнен әйтә. Кайчандыр Алафузовларны симерткән Җитен комбинаты янынан узабыз. Экскурсовод патша заманында бу фабрикада тез тиңентен су эчендә торып эшләгәннәрен әйтә, хәзер завод эшчеләреннән дәүләт премиясе лауреатлары, ил кү-

ләмендә танылган билгеләр бар. Комбинат янында гына эшчеләрнең Культура сарае.

Бишбалтадан Яңа бистәгә килеп чыктык. Бөтен дөньяга атаклы Казан мехлары шушында эшләнә. Унбер фабрикасы булган, Ленин орденлы Казан мех эшкәртү берләшмәсе елына җиде-сигез миллион сарык тиресен машиналар карыныннан үткәреп, аларга иң затлы төсләр бирә. Комбинат бөтен дөнья күргәзмәсендә алтын медаль яулап алуга иреште.

Экскурсовод Тукай, Ямаш, Сәйдәш урамнарының мәгънәсен аңлата бара. Элекке «Болгар» номерлары дип йөртелгән бина яныннан узганда ул кызыклы бер чагыштыру ясап, чит ил кунакларының исен китерә. Немец халкының бөек шагыйре Һенрих Һейне йортында бәлки булганыгыз бардыр? Аның бүлмәләре егермедән артык. Татар халкының бөек шагыйре, революциягә кадәр үк көнчыгыш халыклары телләренә тәрҗемә ителә башлаган, рус халкының зур әдипләре дә хәбәрдар булган Габдулла Тукай менә шушы йортта сигез... метрлы бүлмәдә яшәгән, аның чүп ташларга почмакта иске бер кәрҗиненнән башка милкәте булмаган.

Казанда борынгы белән бүгенге аралашып, күзгә ташланып тора. Моны французлар да сизеп алдылар. Карыйсың — техниканың соңгы сүзенә корылган яңа цирк, яңа стадион, газонлы иркен урамнар, карыйсың — тыныч кына, аулак кына бер тупик һәм нәкъ әнә шул тупиктагы йортта мәрмәр такта — галим, язучы яки революционер яшәгән.

Шәһәр үзенең данлы узганыннан, аны күтәрә, аның исемен дөньяга илтә торган тарихтан баш тартмый. Даны аның азатлык көрәшендә, революция баррикадаларында корбан булган каһарманнарның һәйкәлләрендә, урамнар, проспектлар исемендә, хөрмәтләп куелган һәм кадерләп саклана торган күп санлы мәрмәр такталарда.

— Восстание урамы...

— Ибраһимов проспекты...

— Декабристлар урамы...

Шәһәрнең үзәге булган Ирек мәйданында, ике ягына ике бөек шагыйрь — Пушкин һәм Тукай — баскан, горурлык белән Муса Җәлил исемен йөртүче Татар дәүләт опера һәм балет театры каршысында автобустан чыктык. Бронзадан койган гаять зур Ленин һәйкәле янына тезелештек. (Шәһәрдә Ленинга куелган һәйкәлләр күп, монысы — иң зурысы.)

Чит ил кунакларына шәһәрне аңлатып йөрүче экскурсовод кыз әйтте:

— Хәтерегездәме, Ленин районында Декабристлар урамын узган идек? Инде менә Ирек мәйданына килеп туктадык. Шәһәрнең әнә шул башыннан Декабристлар килеп кергәннәр, ә менә моннан чыгып киткәннәр. Туп-туры Себергә... Билгеле, ул чакта театрлар да, әлеге өч һәйкәл дә, Казан консерваториясенең әнә теге Концертлар залы да, авиация институты бинасы да булмаган...

Бу төштән Россиянең кайгысын гасырлар буена үзенә җыеп саклаган Себер тракты узган. Моннан декабристларны сөргенгә куганнар. Моннан аларның батыр йөрәкле хатыннары Трубецкая белән Волконская ирләре артыннан Себергә юнәлгәннәр. 1833 елны Казанга Пугачев вакыйгаларын өйрәнергә дип килгән Александр Сергеевич Пушкин Себер трактына күзләрен талдырып озак карап торган. Азатлык җырчысының бөек хыялы, бәлки, шушы юлдан узган декабрист дусларының аяк-кулларын тышаулаган богау чыңнарында булачак революция чаңнарын ишеткәндер...

Казан аркылы Александр Иванович Герценны Пермьга озатканнар. Казанда ул өч көн булган, жандармнар озатуында Казан урамнары буйлап йөргән. Идел аркылы чыкканда батып үлә язган. Казан Герценга «бик авыр тәэсир иткән...»

Аннары рус крестьяннарын кулларына балта алырга чакырган бунтарь Чернышевскийның, народоволецларның, патшага каршы күтәрелгән эшчеләр, крестьяннарның себер китәр чаклары җиткән. Беренче марксист Федосеев, большевиклар Кржижановский, Бабушкин, Ленин...

Бетмәс-төкәнмәс Себер юлы... Унҗиденче елга чаклы, Октябрь туплары гөрселдәгәнче күпме якты гомерне, күпме күз яшьләрен һәм нахакка аккан каннарны үзенә йоткан...

Узган гасыр азакларында Казан турында юл күрсәткеч белешмә язучы Евгений Беловка боларның берсе дә гыйбрәтле булып тоелмаган.

Ни хәл итмәк кирәк — һәркемнең үз каланчасы.

# Беренче марксист

Казанда, елларның һәм зур көрәшләрнең истәлеген безнең көннәргә кадәр китереп җиткерүче изге урыннар бар. Шундый урыннарның берсе — элекке беренче гимназия. Монда Россиянең беренче марксисты Николай Федосеев укыган, хәзер авиация институты студентлары укый. Казанка яры буйлап сузылган аулак урам — Федосеев исемен йөртә. Идел буена Ключище авылы урнашкан — пристаньлы, бакчалы авыл. Николай Федосеев полиция шымчыларыннан качып, шунда барып чыккан, шул авылда өндәмәләр бастырып ятарга уйлаган.

Ләкин өлгермәгән.

Күп нәрсәгә өлгермәгән ул — Россиянең беренче марксисты Федосеев. Кышкы сарайны алучылар сафында барырга өлгермәгән. Кызыл Пресня баррикадаларында сугышырга өлгермәгән. Володя Ульянов белән дә танышып өлгермәгән...

Федосеев патшага һөҗүм ясаган Александр Ульяновның энесе турында ишеткән булган, Володя хакында ихтирам белән: «Акыллы егет, җитди карашлы, төпле. Аның белән якыннанрак танышырга кирәк әле. Файдасы зур булыр»,— дигән.

Үкенечле — өлгерә алмаган.

Володя Ульяновны Казан университетында, студентларның революцион сходкасында ясаган чыгышы өчен, 1887 елның декабрендә кулга алып, Кокушкино авылына сөргенгә озаталар. Озак та үтми, полиция шымчылары Федосеевның да эзенә төшәләр.

Федосеев Казанга иң әйбәт теләкләре белән килә — университетка керер өчен ул гимназия тәмамларга тиеш. Улын өзелеп яратучы, мөлаем табигатьле ана Казанга килеп, үзе квартир таба, үзе квартирны мебель белән бизи, һәм улына: «Укы, Коля. Өйрән, балам»,— ди.

Коля укый, өйрәнә... марксизмга.

Давыллы еллар. Россиядә пролетариат туып килә. Социалистик революциянең җитәкчесе булырга тиешле бу сыйныф революцион тәгълиматка мохтаҗ. Дөньяның беренче коммунистлары Маркс һәм Энгельс тудырган тәгълиматны яңа кешеләр — эшчеләр кулына тапшырырга кирәк.

Көрәшкә күтәрелгән пролетариатның революцион теориясе туу — бу планета биографиясендә үзе бер давер. Россиядә бигрәк тә! Хезмәт иясе халыкның көрәше һәм җиңүе турындагы тәгълимат ач-ялангач илдә, надан Россиядә, ирекле азат тормыш турында хыялланучы Россиядә тизрәк тарала. Маркcның «Капитал»ын башка илләргә караганда Россиядә алданрак тәрҗемә итеп бастыралар.

Гимназист, революционер, марксист Федосеев та ирекле яңа тормыш турында хыяллана. Революцион тәгълиматның үзәге, асылы булган «дөньяны үзгәртеп кору» бурычын һәрбер эшченең, һәрбер крестьянның, һәрбер интеллигентның аңлавын тели ул. Марксист көрәшчеләр җыя, хезмәтчел Россиягә аның очы-кырые күренмәс нужалары турында сөйләп, нужадан котылу әмәлләрен өйрәтә. Тик аңа боларны яшерен рәвештә, инспекторлардан, полициядән, шымчылардан качып эшләргә туры килә.

Көрәштәше Гурий Плетневны каршысына утыртып, өндәмәләрнең дөресме басылган икәнен тикшергән чакта, ул кояш кебек балкый.

— Әйдә, машинаңда бастыр да боларны Алафузовкага илт,— ди ул, карандашын читкә куеп.

Икенче көнне Елга аръягы гөр килә. Жандармнар коймалардан өндәмә умыра, полицейскийлар станок асларына, эшчеләрнең кесәләренә кереп, патшага каршы язуларны эзли башлый.

Күңелдә калганны, уйга сеңгәнне алып ташлап буламыни? Пролетариат аякка баскан, стачкалар, эш ташлаулар гөрләп торган заман. Эшчеләр түгәрәкләргә җыела, кичә генә әле берни белмәгән надан халык, комсызланып Я. Свердловны, Э. Бауманны, С. Кировны, Х. Ямашев, Г. Коләхметов, М. Вахитовны, Казанда революция «ясаучы» башка революционерларны тыңлый.

Дәһшәтле унҗиденче елны Елга аръягы Казанда беренче эшче гвардия төзеде; көзен, Санкт-Петербургта патша тәхетен җимереп төшергәч, Елга аръягы эшчеләре

урамга туплар тәгәрәтеп алып чыктылар да туры наводка белән Казан Кремленә, губернатор сараена гөрселдәттеләр...

Күптән түгел безгә Федосеев һәм аның иптәшләре өндәмәләр тараткан Алафузов заводларында булырга туры килде. Хәзер бу Ленин исемендәге җитен комбинаты. Предприятие үзенең йөз еллыгын үткәрергә әзерләнә иде. Бирегә революцион традицияләрне ихтирам итүче, аларны көннән-көн арттыручы тырыш коллектив эшли.

— Беләсезме, дуслар, революция Казанда бездән башланды,— ди комбинатның партком секретаре Леонид Федорович Павлов.— Федосеев түгәрәкләрен без республикадагы партия оешмасының башы дип саныйбыз. Федосеев бездә беренче номер белән йөртелә.

Беренче марксистик түгәрәкләр оешкан заман елдан-ел ераклаша бара. Вакыт узган саен ул вакыйгаларның зурлыгы ачыграк күренә.

Николай Федосеевка эшләве авырая. Адым саен күзәтү, адым саен эзәрлекләү... Урамнарда аңар тагылып шымчылар йөри, гимназия инспекторлары аның квартирына килеп, бүлмәсендә актарыналар, хуҗа хатыннан өйдәшенең ниләр белән шөгыльләнгәнен төпченәләр, кайчан кайта, яки кемнәр белән кайта? Өйдә ниләр эшли?..

Гимназия башлыклары Федосеевның әтисен Казанга чакырталар. Намуслы тырыш чиновник, улын каршысына утыртып, каушап сөйләнә:

— Патшага каршы барасыңмыни? Алла сакласын, әниеңне онытма.

Юк, әнисен онытмый Федосеев, кызгана да аны, ләкин ни хәл итмәк кирәк, икенең берсен сайлыйсың: я әни, я революция. Үзе сайлаган юлдан кире борылуны Николай Евграфович башына да китерә алмый.

1889 елны Федосеевны кулга алып Казаннан сөрәләр. Ерак төньякка, кыргый тынлык эченә ташлыйлар аны. Үзең турында, тормыш турында, көрәшең турында туйганчы уйланырга була монда.

Николай Федосеев сөргендә һәлак булды. Башка катлау кешесе, интеллигент булып та үзен эшчеләр сыйныфыныкы дип санаган Федосеев эшчеләр сыйныфына ахыргача турылыклы булып калды.

Язучы Алексей Шелестов Россиянең беренче марксисты Николай Евграфович Федосеев турында китап язды. «Төрмә өстендә теллә тәвечләр» дип атала ул. Ни өчен теллә тәвеч? Нигә төрмә өстендә? Чөнки телләтәвеч — ирекле киек кош, төрмә өстендә дип әйтүе шуңа — Федосеев караңгы төрмә казаматларында да үзен ирекле һәм хөр итеп, җир өстеннән биектә очучы итеп тойган. Ә биектән офыклар киңрәк, ераграк булып күренә.

Ерак Шушенское сөргенендә Владимир Ильич коточкыч хәбәр белдергән хат ала — сөрген михнәтләренә түзә алмыйча, Федосеев атылып үлгән. Үкенечле хәл. Ул аның белән очрашу көнен көтә, сөйләшергә, бәхәсләшергә тели, алар бит якташлар, көрәштәшләр, бер-берсен аңларлар, уртак тел тапкан булырлар иде.

Күңеле тетрәнгән Ильич Минусинскига, сөргендәш иптәшләре Старков, Кржижановский янына чаба...

Зур югалту кайгысын уртаклашып, сүзсез калалар.

— Николай Евграфовичның дөньяда булмавына ышанасы килми,— ди Старков.

— Юк, ул безнең белән,— ди Владимир Ильич.— Ул Идел буенда, Россиянең үзәгендә күп кенә марксистлар тәрбияләде. Аларның тормышы — аның тормышы... Халык ирек яулап алгач та ул безнең белән булыр.

Ул безнең белән. Россиянең беренче марксисты Федосеев безнең белән! Аның хакында язылган китапларда ул, легендаларда, безнең күңелләребездә. Безнең тормышыбызда. 167 мең коммунист (республиканың партия оешмасы әнә ничек үсте!) Николай Федосеев башлаган эшне дәвам итүләре белән горурланалар.

## Губернатор йортында өй туе

Безне губернатор йортына чакырдылар.

Октябрьның илле еллык зур юбилее алдыннан булды бу хәл. Шуңа күрә вакыйганың зурлыгы тагын да әһәмиятлерәк төс алды.

Без биек манаралы, коеп эшләнгән капкалы борынгы йортка дулкынланып килеп кердек. Бу көнне республикабызның Сәнгать музее ачылырга тиеш иде.

Бу йортта беренче мартәбә моннан алтмыш еллар элек ей туе ясаганнар икән. Республика үзәк музеенда безгә аны бөтен ваклыклары белән сөйләп бирделәр. Без шуны искә төшердек.

Көн кичкә авышкан. Хезмәт Казаны үз борчулары, үз мәшәкатьләре белән яши. Грузчиклар пристань ягына ашыга. Лавкаларда тук купецлар утыра, олаучылар кабаклар тирәсендә кайнаша... Ә губернатор йортына бер-бер артлы кареталар килеп тора. Парадный ишеге төбендә ян-якка баскан ике сакчы кунакларны каршы алып честь бирәләр, зиннәтле коляскалардан төшкән әфәнделәр котелокларын, фуражкаларын тезәткәләп, хуҗа янына ашыгалар...

Астраханьнан башлап Чебоксарга, Пензадан башлап Уралга тикле хәрби округ белән командалык итүче генерал-губернаторның хәтерен калдырып кара, бар!

Талантлы архитектор, Саратовта университет, Казанда хәзерге Республика үзәк китапханә бинасы төзегән Карл Люфке сарайны хәрби ведомствога тапшырган көннән башлап кичә чиннар бу бинаны бер квартал әйләнеп үтәргә, офицерлар сакчылар торган будканы узган чакта кулларын козырекка куеп, челтәр капкага күз төбәп, строевой адым белән узарга тиеш булганнар. Берәр прапорщик кисәге әлеге кагыйдәне үтәми карасын! Шундук балконнан команда ишетелә:

— Гауптвахтага — марш!

Көннәрдән бер көнне күңел кайтаргыч бу хәлләргә чик куела. Унҗиденче елның мартында баш күтәргән эшчеләр белән солдатлар сарайга бәреп керәләр.

Генерал-губернатор башта үз күзләренә үзе ышанмый тора, аннары шаркылдап көләргә тотына һәм котырынып:

— Ничек җөрьәт иттегез? Вон! Гауптвахтага! — дип акыра.

Хәрби губернаторның соңгы боерыгы була бу. Революцион солдатлар, генерал-губернаторның аркасына мылтык терәп, аны гауптвахтага алып китәләр.

Элекке губернатор йортына без дулкынланып аяк басабыз.

Музей директоры Галина Аркадьевна Могильникова музейның кыскача тарихы белән таныштыра. Боларның башта вәрым кешеләр җыйган картиналар булуын, аннары крайны өйрәнү музеенда вәрым бер зал алып торуларын, инде менә, ниһаять, губернатор йортында бик шәп торак мәйданы алуларын сөйләп бирә. Музейның торак мәйданы — чыннан да бик иркен, андый йорты булу белән, бәлки, илебезнең кайбер борынгырак музейлары да мактана алмыйдыр. Монда живопись, графика, сынлы сәнгать әсәрләреннән ун мең полотно тупланган.

Залдан залга йөрибез.

Үзара шыпырт кына сөйләшкән, көрсенеп куйган авазлар ишетелә. Караучылар сәнгатькә үзләренчә бәя бирәләр.

Залда тын, әкрен генә әйтелгән сүз дә шундук ишетелә.

— Тропинин. Шевченко кебек крепостной булган. Аны да сатып-алып йөрткәннәр.

— Торыр урыны да булмаган... Князь Долгоруков әҗеренә укыган... Еврей дип ике мартәбә Мәскәүдән куганнар...— Монысы табигать тылсымчысы Левитан картиналары янында сөйләшү.

— Репин... Заманында академик Бруни аның «Бурлаклар»ын сәнгатьне мыскыллау дип атаган. Хурлык!

— Менә монысы Крамской!.. Тынгысыз адәм! Академиягә каршы бунт күтәргән, передвижникларны оештырган... Тамак туйдыру бәрабәренә кояз кызлар портретлы ясарга мәҗбүр булган. Коточкыч хәл.

Әйе, шулай булган. Безгә бөек сәнгатьне китереп җиткерүче якты талантлар сатып һәм алып була торган әйбер урынына йөртелгәннәр, байлар тиенене укыганнар, сөргеннәрдә интеккәннәр, ул заманның сәнгать белгечләре таккан мыскыллы исемнәрне күтәреп йөргәннәр, иҗатка һәм тормыш хакыйкатенә турылыклы булу өчен никадәр көрәшкәннәр, сәнгать гәүһәрләрен гасырлар аша безнең көннәргә тикле китереп җиткергәннәр.

Икенче катта Татарстан художниклары, Бөек Октябрьга багышланган күргәзмәгә катнашучылар үз полотноларын куйганнар.

Бәлки, кайберәүләр моны гадәти бер күргәзмә итеп кабул иткәннәрдер, әмма Татарстан художниклары өчен бу барыннан да элек сәнгать бәйрәме иде.

Революциягә кадәр бездә рәсем сәнгате булмаган. Шәригать безнең халыкны рәсем ясаудан тыйган. Бөек Микеланджелло, Рембрант, Ван-гог, Рубенс, Гоген, Саврасов, Репин, Верещагин һәм башка титаннар сәнгать җәүһәрләре тудырган заманда безнең бабаларыбыз художник палитрасының ни икәнен дә белмәгәннәр.

Безнең рәссамнар буяу пумаласына Октябрьдан соң гына тотындылар. Менә бу урында инде «Октябрьдан соң гына» дип әйтү чыннан да дөрес. Озак вакытлар эшләнмәгәнне эшләү өчен, булмаганны булдыру өчен бер үк вакытта укып һәм эшләп, эшләп һәм укып яшәделәр. Хәзер Татарстан художниклары семьясы Россия Федерациясендә иң ишле семьялардан санала. А. Бурлай, Б. Урманче, Н. Кузнецов, В. Маликов, М. Хәйретдинов, Б. Әлменов, И. Әхмәдиев, Дәүләт премиясе лауреатлары Х. Якупов һәм Л. Фәттахов полотноларын һәм скульптураларын Мәскәү күргәзмәләрендә дә, ел саен үткәрелә торган «Зур Идел» күргәзмәләрендә дә беләләр.

Менә хәзер Татарстан рәссамнарының үз йортлары — Сәнгать музее ачылды. Музейның бер залы алар иҗатына багышланган. Мәйданы ягыннан ул музейдагы бүтән барлык әсәрләр алган кадәр мәйданны биләп тора.

Республика художникларының халыкка күрсәтер һәм горурланыр әсәрләре байтак. Әйе, курыкмый әйтәбез — горурланырлык әсәрләре байтак! РСФСРның халык художнигы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Харис Якуповның «Хөкем алдыннан» исемле картинасы яныннан гамьсез генә узып китеп булмый. Урындыкларга фашистлар җәелеп утырган. Каршыларында Муса Җәлил басып тора. Тоткын шагыйрьнең карашында ныклык, тәвәккәллек бар. Фашист офицеры зажигалкадан сигаретына ут кабызып маташа. Бәлки, берничә минуттан палач әнә шул утны шагыйрьнең аяк астына китереп куяр... Буяулар салу техникасында кырыс бердәмлек һәм фашизмның рәхимсезлеген ача торган массив бердәмлек бар. Сәнгать сөючеләрне ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе В. И. Куделькинның нәфис зирәк таланты да шатландыра. Мәснәви Хәйретдинов теләктәшләре хөкеменә «Вахтадан соң» исемле картинасын, озак еллар буе нефтьчеләр белән бергә ерак промыселларда йөреп тудырган һәм «Зур Идел» күргәзмәсендә әйбәт бәя алган картинасын куйган.

А. Хәлиулловның «Отряд китте» дигән кырыс та, кешелекле дә, романтик та картинасын безгә ике пенсионер белән бергә карарга туры килде. Таякка таянган чал чәчле карт картинаны караган чакта үзе кебек үк чал чәчле әбине култыклап басып торды. Әби сумкасыннан әледән-әле кульяулыгы чыгарып, моңсу күзләрен сөрткәләп ала иде.

Без аларның кем икәннәрен сорашмадык. Бәлки, бер урында эшләп, бер үк көнне пенсиягә киткән картлардыр, бәлки, ирле-хатындыр, ә бәлкем, әнә теге дәһшәтле унҗиденче елны бу сарайның хуҗасын җылы урыныннан кузгатып чыгарган революция солдатларыдыр, бәлки, Идел флотилиясендә акчехларга каршы сугышучылардыр, бәлки, алар яралы Ильичка аның туган каласы Семберне аклар кулыннан тартып алып, бүләк иткәннәрдер...

Кем генә булмасыннар, аларның үткәннәре күңелләрендә кабат яңарды, хисләре сафланып киткәндәй булды. Сәнгатьнең бурычы кешеләргә аларның иң әйбәт мизгелләрен кайтарып бирү түгелмени?

Шигырьне сүз белән аңлатып булмаган кебек, картинаны да сүз белән аңлатып булмый. Шигырьне укырга, картинаны карарга кирәк. Тик шул чагында гына рәссам кешеләргә бүләк итәргә теләгән хакыйкатькә төшенеп була.

Без дөнья сәнгатендә якты эз калдырган бөек художниклар белән бергә Татарстан рәссамнарының да халыкка хезмәт итүләрен күреп сөендек. Бөек Октябрьдан соң гына башланса да, инде үз традицияләре туып килә торган бу сәнгатьнең киләчәгенә без бик нык ышанабыз...

Ибраһим Салахов

# СИКӘЛТӘЛЕ СУКМАКЛАРДАН



Иптәш начальник, менә тагын Колчакның бер шымчысын тоттык,— кызылармеец арестантны стена буена бастырып, үзе өстәлгә, начальникка таба атлап туктады, шып иттереп идәнгә мылтыгын төшерде.— Карулаша. Мин большевик, дигән була.

Өстәл артында озын, таза гәүдәле, киң җилкәле ир, Акмәчет ЧКсының председателе утыра. Аның өстендә күн тужурка, башында шундый ук күн фуражка. Козырегы маңгаен каплап борынына хәтле төшкән. Председатель бар гәүдәсе белән өстәлгә иелгән дә бик тырышып нәрсәдер яза — башын да күтәрми. Ишек ачылуын, кешеләр керүен, кызылармеецның ачулы рапортын да ишетми. Кызылармеец, әллә инде суыктан карлыкканга, бер-ике тапкыр йөткереп куйды. Кәгазь язылып бетте. Кул куелды. Председатель ашыкмыйча гына башын күтәрде: җәенке бит, почык борын, калын кара каш астында кысык күзләр. Әүвәле ул кызылармеецка карады. Кызылармеец, мылтыгын тиз генә күкрәгенә тартып, смирно басты. Аннан караш стена буенда торган арестантка күчте. Кашлар тырпаеп күтәрелделәр, күзләр зураеп түгәрәкләнделәр һәм арестантка текәлеп хәрәкәтсез калдылар. Урта буйлы, чандыр гәүдәле, сакал-мыек җибәргән, 35—40 яшь чамасындагы кеше. Өстендә таушалган пиджак, чалбар. Итектән. Башында — алга тартып киелгән иске кепка. Аркасында — капчык. Кулда — таяк. Кыяфәте сәүдәгәр — кырык тартмачы татарга охшый. Әмма... әмма карашы үткен, соргылт күзләр каушаусыз, үз-үзенә ышану белән карыйлар. Сәүдәгәрләргә хас ялагайлану сизелми.

— Исем, фамилияң?

— Сабир Шәрипов.

— Кайдан киләсең? Нишләп йөрисең?

— Мин Күкчәтау совдепы члены. Колчакка пленга эләккән идем. Омскига якынлашканда «Үлем эшелоны»ннан качып, үзебезнекеләрне эзләп бу якка килеп чыктым.

— Нинди задание белән?

— Төшенмим,— Сабир ЧК председателенә сорау белән карады,— кем заданиесе турында сүз бара?

— Кемнеке булсын,— председатель ачулы тавыш белән кычкырып, урыныннан сикереп торды,— Колчакныкы,— шундук кызылармеецка борылып боерды,— хәзер үк төрмәгә алып бар! Кара, качмасын, хәйләкәр күренә!

* * *

— Мене үзебезнеке җиргә килеп җиттем...— Сабир тар, тынчу камерада ишекле-түрле атлап, үз-үзенә аптырашлы сораулар бирде.— Нишләргә соң? Ничек итеп үземнең большевик булуымны танытырга? Акмәчет... Акмәчет... Мин сиңа ышанып, терәк-ярдәм эзләп килеп егылган идем бит. Ә монда...

Кинәт йозак шалтырады. Авыр тимер ишек шыгырдап ачылды. Камерага мылтык-лы ике кызылармеец кереп ишекнең ике ягына бастылар:

— Шпик, давай допроска!

...Бу юлы Сабирны, гадәттәгечә, ЧК йортының югары катына — председатель бүлмәсенә түгел, аскы каттагы, баскыч астындагы бүлмә ишеге төбенә китереп туктаттылар. Ишек өстенә — стенага озынча фанера кадакланган. Анда шәмәхә карандаш белән кәкре-бөкре итеп «Азык-төлек комиссары» дип язылган. Алдан барган конвоир бүлмәгә кереп берничә минут торды да чыккач, бик коры гына:

— Кер! — диде.

Сабир ишекне ачып эчкә керде. Конвой тышта калды.

Озынча бүлмә. Ике як стена буенда урындыклар. Түрдә кызыл комач җәелгән тар гына өстәл. Камыш урындык. Сабир кергәндә бүлмәнең хуҗасы кулын артка куеп тәрәзәгә карап тора иде. Тәбәнәк. Ябык. Өстендәге френче буп-буш — салынып тора. Башы ап-ак, әйтерсең, кырау төшкән. Сабир кереп ишек төбенә туктагач та, тәрәзә төбендәге кеше кузгалмады, борылмады, тәрәзәгә карап торуында дәвам итте. «Нигә мине ЧК председателенә түгел, бу кешегә китерделәр икән? Ул нәрсә уйлый? Мине нәрсә көтә?»

Теге кеше борылып бер-ике атлады да камыш урындыкка утырды — бигрәк кеч-кенә булып калды. Йөзе озынча. Бит сөякләре калкып торалар.

— Утырыгыз, Сабир Шәрипов! — диде ул, кинәт башын күтәреп, тыныч, ачык тавыш белән.— Менә монда, өстәл янынарак.

Сабир өстәл янындагы урындыкка килеп утырды.

— Күкчәтау, Кызыл Яр большевикларыннан кемнәрне беләсез?

— Гаделбик Майотов, Кәрим Сутюшев, Усман Әбдерәшитовлар белән 1907 елдан ук таныш, бергә эшләдем.

— Тагын?

— Соңгы елларда Сәүвалас Сәйфуллин белән таныштым. Кызыл Яр төрмәсендә бергә яттык.

— Хәзер ул кайда?

— Аны да Омск төрмәсеннән качкан дип ишеттем.

— Мм... Акмәчеттә сезне кем белә?

— Мин монда беренче тапкыр... Танышларым юк... Документларымны обыск вакытында алдылар.

— Ие... Кәрим инде юк... Ә Сәкиннең язмышы ревтрибунал кулында.

Сабир сискәнеп китте, әйтерсең лә, өстенә бозлы су сиптеләр.

— Сәкин дә төрмәдәме?

— Мм...— өстәл артындагы кеше башын түбән иеп, ике кулы белән чигәләрен кысты, ап-ак төкләр керпе энәләре кебек күтәрелделәр, Сабир аптырап калды. «Бу хәтле ватылып, борчылып нәрсә уйлый соң бу кеше?»

— Шәрипов,— диде ул, кинәт аягүрә басып, һәм Сабирның күзләренә туп-туры карады да акрын гына, әмма, һәрбер сүзен үлчәгәндәй бүлеп-бүлеп, сөйли башлады.— Болганчык вакыт хәзер. Коры сүзгә генә карап күрмәгән-белмәгән, тикшерелмәгән кешегә ышану — революциягә хыянәт итү... Әмма мин...— ул нәрсәгәдер сәртенгәндәй түбән карап сүзен бүлде. Бераз уйланып торды һәм тагын сүзен башлады,— мин сезгә ышанырга уйлыйм. Әгәр сез, үзегез әйткәнчә, чын большевик булсагыз, безгә булышыгыз.

— Ничек? — Сабир шатлыгыннан сикереп торды.— Мин — хәзер!

— Акмәчет ачыга. Икмәк кирәк. Мин — азык-төлек комиссары. Миңа ярдәм кирәк. Икмәк! Икмәк табарга һәм армияне, халыкны ачлыктан коткарырга кирәк.

— Мин бар көчем белән сезгә булышачакмын, иптәш комиссар.
— Алай булса планыгызны әйтегез, кайдан икмәк табарга була?

Ниһаять, ике ай дигәндә Сабир яңадан Акмәчеткә килде. Бу юлы инде ул, беренче тапкырдагы кебек, таякка таянып, аркага капчык асып, хәер сорап түгел, дүртенче бодай кәрванының башлыгы булып керде. Юлы уңды аның. Продкомиссарның ышанычы акланды. Әмма нинди авыр юл кичелде, күпме хәвеф-хәтәрләр үтелде, нинди җәфалар чигелде? Аны бары Сабир үзе генә белә иде.

Продкомиссар белән киңәшкәннән соң, аның ышанычнамәсы белән Сабир Акмәчет совдепыннан акча һәм берникадәр товар (күн, ситсы, чәй һ. б. вак-төяк) алып, берничә ат-арба белән ком чүлләре аша мең чакрымнан артык юл үтеп, Атбасарга килеп чыкты. Монда инде Колчак гаскәре, Себер казаклары отрядлары мыж килә. Кайда карама, шунда атлы, җәяүле патруль. Атлаган саен документ тикшерү. Аз гына шик төшкән кешене комендатурага озаталар, аннан инде кире юл юк. Сабир Атбасардагы дус-ишләре — приказчик Газиз, Хәмит Сутюшевлар белән очрашып киңәшкәннән соң, Ишим буендагы, икмәккә бай украин авылларына юл тотты. Ул анда, үзен Атбасардагы татар байларының берсе итеп танытып, Колчак армиясенә ярдәм итәргә чакырып, бодай сатып алырга тотынды. Җыелган бодайны ул элек Атбасарга, аннан Сутюшевларның ярдәме белән чүлдәге казакъ авыллары аша Акмәчеткә озатты. Берничә тапкыр ул, Колчак отрядлары кулына төшеп, чак-чак кына «янмады». Бары тәвәккәллек, үзен байбәтчәләрчә эре тота белү аркасында гына иң куркыныч, хәвефле хәлләрдән коткарып алып чыга алды. Шулай тырыша торгач, ул Акмәчеткә башта өч мең поттан артык бодай озатып, соңгы кәрван — мең биш йөз пот бодай, 400 пот он белән кайтты. Нинди зур шатлык! Ул Төркстан җирендә Совет хөкүмәтен ныгыту өчен көрәшүчеләргә үзенең хәл кадәре ярдәмен күрсәтә алды — ачлыктан хәлсезләнгән кызылармеецларга икмәк китерде. Продкомиссар ничек куаныр! Рәхмәт төшкерә, нинди яхшы, акыллы кеше. Ул бит үз язмышын картага куеп, Сабирга ышанычын тапшырды — үлемнән алып калды. Тизрәк, тизрәк әлеге ябык, чандыр гәүдәле кеше белән күрешергә!

Шәрипов бодай, онны продскладка тапшырып расписка алды да совдепка, продкомиссарга йөгерде.

— Ул юк. Ул Ташкентта,— диде аның кабинетында яшь кенә рус егете һәм кабинетта утырган ике кызылармеецка:— Бу кешене хәзер үк төрмәгә алып барыгыз! — дип өстәде.

Берничә көннән соң Сабир Шәриповны, камерадан чыгарып, төрмә начальнигына китерделәр.

— Сезне,— диде төрмә начальнигы,— бик ашыгыч рәвештә Ташкент край ЧКсына чакыралар.— Аннан конвойга борылды.— Хәзер үк вокзалга алып китегез. Машина көтә. Өченче вагон. Комиссар Павловка расписка белән тапшырыгыз.

Менә көтелмәгән шатлык! Ниһаять, шикләнү, шөбһәләнүләр артта калды. Тагын җиң сызганып Совет хөкүмәтен ныгыту эшенә тотынырга мөмкинлек ачылачак. Һичшиксез, Сабирны теге ак чәчле, кечкенә гәүдәле олы күңелле кеше — продкомиссар чакыра торгандыр. Ул бит хәзер Ташкент ЧКсының начальнигы.

Ташкент вокзалына килеп төшү белән үк, Сабир Шәриповны ревтрибуналга алып киттеләр.

— Документларыгыз?

— Юк. Мин Колчак төрмәсеннән качтым. Күкчәтау совдепы члены. 17 елның апреленнән РСДРП(б) да әгъза.

— Сезне монда кем белә?

— Акмәчет совдепының продкомиссары. Фамилиясен... Хәтерләмим. Ул хәзер монда ЧК башлыгы диләр.

— Соңга калдың таянырга. Ул менә сезнең кебек «большевиклар» кулыннан корбан булды. Аның каны арзанга төшмәс.

Сабир ни әйтергә, уйларга белми аптырап-каушап утырганда трибуналның бер

члены — өстәл читендә утырган хәрби киемле, күзлекле кеше Шәриповка туп-туры карап:

— Мин бу кешене беләм. Ул Омскидагы Колчак өлкә комитетының актив члены иде,— диде, күзен дә йоммыйча.

— Расходка! — диде трибунал председателе өстәлдәге укып торган кәгазеннән башын да күтәрмичә.

Үлем камерасы. Иртәгә аны атачаклар.

«Ни өчен? Ни өчен? Мин бит бар гомеремне ярлыларның, гидайларның азатлыгы өчен көрәшкә багышладым. Колчакта тоткын булдым. Кыйналдым, сугылдым. Бирешмәдем. Колчактан качып үзебезнекеләргә килдем. Инде котылдым, дигәндә?! Юк, юк, бу һич мөмкин түгел,— Сабир, тәрәзәсез тар подвалда бертуктаусыз әйләнеп йөреп, ике кулы белән башын кысты.— Бу ни бу? Бу бит — хаксызлык. Нахак! Нахак бәла. Әмма аннан ничек котылырга. Җаным-тәнем белән Совет яклы кеше булуымны ничек исбат итәргә соң?

Гомер, нинди авыр, сикәлтәле сукмаклардан башландың син. Ачлык. Ялангачлык. Ятимлек. Кеше бусагалары. Кимсетүләр һәм хаксызлыкка каршы көрәш юлына чыгу. Хөррият. Җиңү. Шатлык! Һәм... Менә минем гомерем шундый фаҗигале кара үлем белән чикләнәчәкме?!.»

Туктаусыз йөрүдән Сабир арыды. Инде төн. Надзирательнең дә аяк тавышы ишетелми. Йокларга иде. Мондый төндә керфекләргә нинди йокы кунсын. Еракта калган гомере кабатланып тагын күз алдыннан үтте.

Сабир 1880 елны Вятка губернасы, Алабуга өязе, Салуш волосте, Вәрзи авылында ярлы крестьян семьясында дөньяга килә. Әтисе Шәриф авылның «суык аяк»ларыннан берсе була. Язын, боз төшүгә, ул Иж, Кама елгасы буйларындагы пристаньнарда бурлак ләмкесен тарта, сал агыза яки болынчылар артеленә кушыла. Кар төшеп, боз каткач, «суык аяк» авылга кайтып, чыпта сугарга тотына. Аннан тагын «ычкына»...

Хуҗалыкның бар авырлыгы Сабирның анасы җилкәсендә кала. Ул мескен берәүгә урак урып, икенчегә ашлык сугып, кышкы кичләрдә җеп эрләп, киндер сугып өч баласын канат астында тота. Бара-тора зур улы Сабир да кул астына керә башлый — хәзрәтнең мал-туарын карап, шуның хакына кышын мәктәптә укый.

Әмма бу «гыйлем эстәү» озакка бармый, Сабир уникe яшькә җиткәч, әнисен үпкә авыруы алып китә. Ике елдан соң, суык тидереп, Шәриф абзый да дөнья куя. Сабир береннән бере кечкенә ике сеңелесе белән ятим кала.

Авыл халкы үз сөяген читкә чыгарып ташламый. Шәрифне җирләгәч, картлар җыйналып сөйләшәләр дә ятимнәрне өй башына бүлеп «хода ризалыгы» өчен асрарга керешәләр. Сабир бер кыш хәзрәттә ялчы булып эшли дә язын атасының эзенә баса...

Ул Алабуга, Сарапул, Мамадыш, хәтта Казан каласына хәтле барып чыга. Ләкин аны бер җирдә дә якты йөз, җылы сүз каршыламый. Нишләргә соң? Эшли дә, хәер дә сораша. Хәтта... урлаша да.

Менә шушы юл аны 1898 елда Мәкәрҗә ярминкәсенә алып бара. Ул монда Себер бае Фәттах Рамазановны очратып, аңа яллана да Павлодар шәһәренә китә. Мәкәрҗәдә вакытта бай: «Үз улым мисләндә булырсың. Алла боерса, приказчиклыкка өйрәтермен, укытырмын», дисә дә, Павлодарга кайткач, вәгъдәсен оныта. Ул Сабирга тире, йон ташу эшен йөкли. Мәктәп, уку турында сүз дә кузгатмый.

Бер көнне Сабир байның кибетенә килеп йөри торган казакълардан бер хәбәр ишетә:

— Бол каладан 18 чакрым чамасындагы җәйләүдә Нәҗметдин хәзрәт торадыр. Кидәй балаларын укыта. Тамагын, киемен үзе бирә.

Икенче көнне Сабир таңнан тора да җәяүләп Нәҗметдин хәзрәт авылына кача. Инде авылга керәм дигәндә генә, арттан, пар ат җиккән фоэтон куып житеп туктый. Аннан Фәттахның улы Самат Рамазанов һәм городничий Калинский төшеп Сабирны туктаталар.

— Менә бу сукбай,— ди Самат, Сабирның якасыннан тотып,— кибеттән акча урлап качты.

— Бурлык өчен сине мировой судьяга бирергә иде. Но мин йомшак табигатьле кеше,— ди Калинский, өяз управлениесенә килгәч,— ярар, этап белән Русиягә җибәрермен. Сезнең кебек сукбайлардан котылу хәерле. Ә хәзер! — Ул ишек төбендә кылычына таянып утырган, озын кара мыеклы приставка борылып тамагын кыра.— Бу шайтан көчеген арестант өенә җиткер.

Сабир беренче тапкыр төрмәдә. Тәрәзәдә тимер рәшәткә. Ишек бикләнгән. Караңгы. Куркыныч.

Бер тәүлек. Өч тәүлек. Инде бер атна. Ишек ачылмый. Надзиратель бер телем икмәк белән бер савыт су куя да шуның белән тәүлек үтә. Нишләргә? Кайчан этапка чыгарырлар? Ә анда, Рәчәйдә, Сабирны кем көтә?! Кем ишеген ачып, кем бусагасыннан үтә алыр соң ул? Фәттахларның бер тиенենә хыянәт итмәдем. Ә мине бур, диләр. Кайда соң аларның иманнары? Нигә мондый хаксызлык?

«Волчок» тиз генә ачыла да ябыла. Коридорда шау-шу, йөгерү башлана. Йозак шалтырый. Камерага беренче булып өяз начальнигының тылмачы Габдулла Кадыйрбаев йөгереп керә һәм тәрәзә рәшәткәсенә бәйләнгән билбауны пәке белән кисеп җибәрә дә инде буылып күгәрә башлаган Сабирны күтәреп ала.

Сабир һушына килгәч, төрмә чиновникларының берсе — Ольшанский Илья Иванович аны порукага ала. Сабир аның өендә тора башлый — хуҗалык эшләрендә булыша, буш вакытында китап укырга тырыша. Хуҗа да, аның хатыны Доминика да эшкә тырыш, укырга хирес бу «татарчонок»ны яраталар. Көзен Ольшанский Сабирны Павлодар авыл хуҗалыгы мәктәп-пансионына урнаштыра. Монда биш ел укый, 1903 елда Сабир мәктәпне тәмамлый, авыл хуҗалыгы машиналары җайланмалары буенча монтер, столяр һәм китап төпләүче мастер дигән таныклама алып чыга.

Мәктәптә укуның соңгы елында Сабирның дөньяга карашында, рухи дөньясында берникадәр үзгәреш башлана. Сәбәп менә нәрсәдә була. Бу елны Петербургта эсерлар тарафыннан министр Санягин үтерелә. Менә шушы вакыйгада катнашуда гаепләнгән берничә студент Павлодарга сөргенгә җибәрелгән була. Студентлар җәйге каникулга таралган вакытта бу «сәяси»ләр авыл хуҗалыгы мәктәбенең бушап калган классларына урнашалар. Барыр җире булмаган Сабир да мәктәптә тора. Болар танышалар. Сабир студентларга аны-моны табып китерергә булыша, аш-су әзерләүдә ярдәм итә. Тырышлыгы, турылыгы, хыянәтсезлеге белән ул студентларның ышанычын казана. Алар аңа иялешәләр. Бара-тора студентлар Сабирны дөнья хәлләре, азатлык, хаклык өчен көрәшүче кешеләр белән таныштыра башлыйлар.

Билгеле инде, Сабир таныш түгел сүзләр катыштырып сөйләнгән әңгәмәләрнең тирән фикерләрен төшенеп бетә алмый. Әмма алар киләчәктә аның күңелендә шытып чыгар өчен изге, игелекле орлык булалар.

Нәкъ менә шушы елларда казакъ авылларында бер класслы мәктәпләр ачыла башлый. Укытучылар житешмәү сәбәпле, Сабир Шәриповны Чакаган авылына укытучы итеп җибәрәләр. Сабир — укытучы! Өнме, төшме? Ниһаять, хыял чынбарлыкка әйләнде.

Киез өй. Җир идән. Түгәрәк, тәбәнәк җыелма өстәл. Графит такталар. Өстәл тирәсендә тезләнеп утырган балалар.

— Менә бу туп-туры сызылган таяк.— «А», «а» хәрефе дип атала... Алдыгыздагы такталарга сызыгыз. Ашыкмагыз. Тигез итеп...

Менә шулай дәрес башлана.

— Уй-бай,— дип авыл халкы куана,— мөгаллимнең менә дигәне килгән. Инде балаларыбызның күзе ачылды.

Ләкин бу сөенү озакка бармый, авыл кышлауга күчәргә җыенган көзге көннәрнең берсендә балалар укыта торган киез өйгә ике стражник килеп керә.

— Төньяк Себер халык мәктәпләренең директоры приказы буенча,— ди стражникның берсе, кулындагы пакетны ачып,— Чакаган авыл мәктәбе укытучысы Сабир Шәрипов сәяси ышанычсызлыгы өчен эшеннән бушатылып, кулга алына...

Сабир тагын Павлодар төрмәсендә. Бу юлы инде ул качкын түгел, куркынычлы сәяси гаепле. Бик сак, алдын-артын карап кына йөргән иде бит Сабир. Әмма ниндидер явыз күз аны күзәткән, «озын колак» күренмичә шымчылык иткән. Әй шулай да дөнья әле явыз кешеләрдән генә тормый икән. Тагын ярдәмгә Илья Иванович Ольшанский килә — порукага ала.

Менә шуның белән укытучылык карьерасы тәгәлләнә. Сабир кулына балта алып Павлодардан китә. Ул Екатеринбург, Каинск, Омск шәһәрләрендә йорт салып, столяр мастерскойларында эшләп, тамак туйдырып йөргәннән соң, 1905 елның башында бер иптәшенең ярдәме белән, әлек Акмуллада, аннан Атбасар каласында авыл хуҗалыгы машиналары складлы башлыгы булып эшли башлый.

«Канлы якшәмбе»нең зарлы һәм дәһшәтле авазы казакъ далаларына да килеп җитә. Атбасар мещаннары арасында да тынычсызлык сизелә башлый.

— Сабир әфәнде,— ди бер көнне Кәрим Сутюшев, аны базарда очратып,— без монда китапханә һәм клуб ачарга дәгъва күтәреп йөрибез. Вакытыгыз булса, кичкырын безгә кереп чыгар идегез. Монда бик әйбәт, тырыш егетләр бар. Менә Гаделбик Майотов һәм дә Усман Әбдерәшитовлар белән танышырсыз, килегез, көтәбез.

Атбасарда татар-казакъ клубы һәм китапханә ачыла. Клубта әдәби кичәләр үткәрәләр, ара-тирә концертлар, хәтта «театр»лар да куела башлый. Сабирда да сәләт яшеренеп яткан булган икән, бер-ике чыгыштан соң ул Атбасар халкының яраткан җырчысы, артисты булып китә.

Атнасына бер көн киләчәк кичәгә репетиция үткәрелә. Менә шушы репетициядән соң Кәрим Сутюшев һәм сергенгә җибәрелгән эшче — пар тегермәненең механигы Дмитрий Андреевич Ушаков төрле яшерен листовкалар һәм китаплар укыйлар. Сабир аларны тырышып тыңлый, хәтта кайбер китапларны өенә алып кайтып укый башлый.

Атбасардагы мондый дус-ишләр аның күңелен күтәрә, канатландыра һәм аның күзләре дөньяга яңача карый башлыйлар. Күбрәк, күбрәк белергә укырга кирәк!

Әмма... бер көнне кич ул клубтан авырсынып, тыны кысылып кайта. Төндә Сабирның авыз, борыныннан кан китә.

— Сезнең,— ди фельдшер, Сабирны карап, күкрәгенә, аркасына бармагы белән чиертеп-чиертеп тыңлагач, хәл начар. Дөресен әйтәм, хәтәр. Күптәннән яшеренеп килгән чахотка ачылган. Монда сезне дәвалап булмый. Чамагыз да җитмәс... Минем киңәш — авылга китү. Хәзер үк җәйләүгә, казакъ авылына китегез. Анда кымыз эчәрсез, саф һавада йөрерсез. Менә, әфәндем, миннән киңәш шул.

...«Әфәнде» җәйләүгә китәргә мәҗбүр була. Дала кунакчыл, ләкин авыру кешене бушка кемнең ашатып, эчертеп яткызасы килә. Һәр хәлдә, җаеңа ятышлы эш табарга кирәк. Мохтаҗлык эш эзләтә. Ахырында Сабир писарь — тылмач булып ялланырга мәҗбүр була.

Ул Атбасардан ераклашса да, дуслары Кәрим һәм Усман белән элемтәсен өзми — хат язышa. Алар аңа, газета-журналлар белән бергә, төрле сәяси китаплар да җибәреп торалар.

Авылның гидайлары «тылмачны» үтә яхшы күрәләр, бәла-казага очрасалар, байбәтчәләр җәбере түземнән ашып китсә, аңа киләләр — эч серләрен ачалар, ярдәм емет итәләр. Сабир кулыннан килгән кадәр аларга булыша, прошениеләр яза.

Менә шушы чорда инде Сабир казакъ халкының көнкүреше, гореф-гадәте, бигрәк тә гидай казакъларның авыр язмышы белән якыннан таныша.

«Авыруның килүе тиз, китүе авыр», ди казакъ халкы. Сабирның да авыру үпкәсе әле һаман төзәлми. Бигрәк тә көз һәм яз айларында ул аны сөлек булып суыра, түшәккә ега. Җәйләүгә чыгып, ысланган казы салган май кымызы эчә башлагач кына, ул аякадан аякка баса.

1916 ел.

Еллар буена иңгәреп, канлы яшь түгеп, байлар, бияр, чиновниклар камчысы астында сейрәлгән гидай казакъларның түземе чигеннән чыга. Ат тояклары дөбердәвеннән, ак патшага каршы көрәшкә чакырган набат тавышларыннан, кылычлар, сәнгеләр, китмәннәр чыңгылдавыннан дала дер селкенә. Кузгалыш Каспий диңгезе ярларыннан Тянь-Шань тауларына кадәр җәелә. Бары Күкчәтау, Атбасар, Акмулла тирәләреннән генә ун меңнән артык ир егет атка атланып, ни туры килсә шуның белән коралланып, азатлык өчен көрәшкә чыга.

Омск генерал-губернаторы Күкчәтау өязенә генә генерал Ягодкин командасында утыз кавалерия сотнясы, унбер арбача нык кораллаңдырылган пехота ротасы җибәрергә мәҗбүр була. 1916 елның 26 сентябрендә бу җәзалау экспедициясе Кожас җәйләвендә баш күтәрүчеләр отряды белән очрашып сугышка керә. Тәүлектән артыкка сузылган каты сугыштан соң баш күтәрүчеләр Ягодкинның отрядын тар-мар итәләр.

Кыш, суыклар, каты бураннар. Баш күтәрүчеләр үзләренә торак, атларга азык таба алмаганлыктан, Тургай даласына таба чигенә. Бер өлеше Кытайга чыгып китә, ә бер өлеше, Амангильде отрядына кушылып, сугышны Октябрь революциясенә кадәр дәвам иттерә.

Сабир Шәрипов менә бу халык кузгалышын әзерләүче һәм рухландыручы кешеләрнең берсе була.

Февраль революциясен Сабир Күкчәтауда каршылый. Бу елның апрелендә ул Петропавел РСДРП(б) комитетының Күкчәтау бүлеге оешмасында партия сафына алына. Бу көннәрдә Күкчәтауда да сыйнфый көрәш кызганнан-кыза бара. Күкчәтауның атаклы байлары: Усмановлар, Баязитовлар, Моменжановлар вакытлы хөкүмәтне яклап чыкканда, Сабир Шәрипов каладагы казакъ-татар хезмәт ияләрен яңа гына сайланган совдеп тирәсенә туплый һәм большевиклар платформасын якларга чакыра — җыелышларда, митингларда рус, казакъ, татар телләрендә ялкынлы речьләр белән чыга.

Ниһаять, Октябрь революциясе. Сабир Шәрипов, Күкчәтау совдепы президиумы члены буларак, казакъ-татар хезмәт ияләрен Совет хөкүмәтенең декретларын тормышка ашыру өчен көрәшкә туплый башлый. Ул кызыл гвардия отрядлары төзи. Байларның йортларын, малларын конфискацияләп ярлыларга өләшә, клуб, мәктәпләр, халык йортлары ача башлый. Аның җитәкчелегендә татар мәктәпләре өчен мөгаллимнәр әзерләү курслары ачыла. Ул арада Петроград, Мәскәү һәм башка шәһәрләрдәге эшчеләрнең ачыгуы турында хәбәр килә. Сабир, Имәнтау станциясенә барып, Атбасарда вакытта бергә эшләгән дусты, хәзер Имәнтау совдепы председателе Усман Әбдерәшитов һәм башка совдеп членнары белән киңәшә, тирә-яктагы бай станицаларда икмәк әзерләү өчен продотрядлар төзи. Аларга ярдәмгә кызыл гвардия отрядлары оештыра. Озак та үтми, меңләгән пот ашлык төягән олаулар Петропавел станциясенә кузгала.

1918 елның язына хәтле Имәнтаудан Петропавелга йөз мең поттан артык икмәк озатыла. Петропавел совдепының транспорт комиссары Кәрим Сутюшев Имәнтауга — Усман Әбдерәшитовка, Күкчәтауга — Сабир Шәриповка совдеп исеменнән хат җибәреп, Петроград һәм Мәскәү эшчеләренә күрсәткән ярдәмнәре өчен чын пролетарча рәхмәт белдерә...

...Сабир төрмәсе, караңгы, юеш подвалда ишекле-түрле атлый, шулай үткән гомерен күз алдыннан кичерә... Үз-үзе белән, иптәшләре белән сөйләшә. Ара-тирә үз-үзенә сорау бирә. Усман Әбдерәшитов кайда икән хәзер! Кәрим, җан кисәгем Кәрим, син инде юк. Сине вәхшиләрчә кыйнап үтергәннәр. Их! Вакытсыз, бик вакытсыз киттең, дустым... Ә мин? Мин нинди хәлдә? Алар, ичмасам, Колчак тормасендә, дошман белән көрәшеп, шәһид киттеләр. Ә мин? Бу нинди хаксызлык? Кулымнан килгәнне эшләдем, хәтта газиз җанымны да кызганмадым. Кулыма мылтык алып сугыштым. Менә-менә дар агачына тартабыз дигәндә качтым. Мең бәла белән Акмәчеткә — үзбезнекеләр янына җиттем...

Ишектәге йозакның шалтыравы Сабирның уен бүлде. Камера ишеге ачылды. Кулларына мылтык тоткан ике кызылармеец камера эченә керделәр. Ишек төбендә — коридорда тагын икәү һәм надзиратель күренде. Надзиратель пышылдап, мөгаен, күрше камерадагы арестантлар ишетмәсен дип, ачулы тавыш белән боерды:

— Алып чыгыгыз!

Тар коридор, таш баскыч буенча тагын да түбәнрәк подвалга төшерделәр. Тәбәнәк, кечкенә бүлмә. Кырыйда өстәл. Өстәл артында хәрби киемнән өч кеше. Каршыда тимер ишек. Ишек өстенә фонарь эленгән. Аннан кызыл шәүлә төшә. «Мөгаен, әнә шул ишек артындагы подвалда атарлар»,— дип уйлады Сабир.

— Исем, фамилияң? Туган елың?

Өстәл артында трибунал председателе үзе. Сорауны ул бирә. «Соңгы тикшерү... нишләргә?»

— Тизрәк җавап бир! — Боз кебек салкын тавыш хәнҗәр булып кадалды.

— Иптәш председатель...

Сабир тагын ашыгып үзенең большевик булуын, Күкчәтау совдепында эшләвен сөйли башлады...

— Кем сезне иртәгә хәтле порукага ала ала?

Әйтерсең лә, башка күсәк белән суктылар. Сабир бөтенләй хәрәкәтсез калды: «Атарга хөкем ителгән «контрны» мена хәзер, үлем алдында кем соң порукага алсын? Кем, кем белә аның гонаһсыз булуын?» Тынлык. Яшәү белән үлемне хәл итүче фаҗигале тынлык. Кинәт аның өстенә боз ишелгәндәй булды — председатель соравын кабатлады.

— Бер көнгә, сез әйткәннәрне тикшергәнче, порукага алыр кешегез бармы?!

Сабир башын түбән иде.

— Мин! — диде кинәт ниндидер таныш түгел тавыш. Сабир өнемме, төшеммe дип тавыш килгән якка борылды. Үзен камерадан атарга алып чыккан конвоирларның берсе — озын буйлы,ябык кызылармеец бер адым алга атлады:— Бу кешене мин порукага алам, иптәш председатель!

Икенче көнне Сабир Ташкент урамында көтмәгәндә үзе белән Күкчәтау РСДРП(б) оешмасында бергә эшләгән Дойсәнбай Нысанбаевны очратты. Дойсәнбай хәзер Төркстан Совет Республикасы каршындагы ЧКның тикшерү комиссиясендә эшли икән. Менә шушы очраклы очрашу Сабир Шәриповны котылгысыз, нахак үлемнән алып калды...

Нәкъ менә шул көннәрдә Ташкентка Валериян Владимирович Куйбышев килә. Сабир аның белән очраша. (Алар, күреп булмаса да, Кәрим Сутюшев аркылы бер-берсен белә торган булганнар.) Һәм, Куйбышевның тапшыруы буенча, ул киредән Күкчәтау — Кызыл Яр — Омск ягына Колчак тылына разведкага китә.

Ниһаять, 1919 елның 12 ноябрендә Колчак гаскәрен тар-мар итеп, Тухачевскийның бишенче армиясе кызылармеецлары Күкчәтауга керәләр. Күкчәтауда тагын Совет хөкүмәте урнаша.

— 1918 елның декабрь башында,— ди озак еллар бирэдә яшәүче Хөсәен абый Куликов, ул көннәрне хәтерләп,— чатнама суык иде. Шулай да без, яшьләр, Хәлиулла бай өенә йөгерәбез. Аны Совет хөкүмәте конфисковать итеп, «Халык йорты» иткән иде. Күкчәтауның барлык татар-казакъ яшьләре шунда җыелдык. Зал шыгрым тулды. Алда өстәл. Аңа кызыл комач ябылган. Көтәбез. Нәрсә булыр икән?

Менә бер вакыт өстәл янына урта буйлы,ябык, кыска гына сакаллы, хәрби киемдәге бер кеше чыкты.

— Сабир абый Шәрипов менә шул инде,— диде минем яндагы бер егет. Мин аның турында ишетсәм дә, үзен күргәнем юк иде.

— Хөрмәтле иптәшләр! — дип ул сүз башлады...

Менә шул көнне Күкчәтауда беренче комсомол оешмасы барлыкка килде. Беренче булып Шәмәт Шаяхметов, Кәби Туленов, Банат Хәбибуллина, Кадыйр Усманов, Нәфисә Мифтәхетдинова һәм мин язылдык.

Икенче көнне Сабир ага комсомолларны үзенә, совдепка чакырып алып:

— Инде, иптәшләр, эшкә тотыныйк,— диде.

Без аптырап калдык. Нинди эш? Без нәрсә эшли алабыз соң?

— Иң элек оешманың җитәкчесен — секретарен сайлыйк. Аннан һәрберебезгә күтәрә алган кадәр җәмәгать эше йөклик. Каршылык юкмы?

— Секретарь итеп бездән олырак һәм бераз укыган — Атбасардан килгән егетне — Галимҗанны сайладык. Шәмәт белән Кадыйрга әдәбият сөючеләр түгәрәге оештыру эше тапшырылды. Нәфисә үзе теләп «Бетсен наданлык» оешмасын төзәргә һәм укытырга булды. Бәнат белән миңа китапханә эше йөкләнде: китап җыярга, шкаф табарга. Без шул көнне үк эшкә тотындык.

Минем күңелемдә иң тирән эз калдырган вакыйгаларның берсе — 1920 елның беренче январь көне булды. Бу көнне Күкчәтауда беренче тапкыр татарча концерт куелды. Без, комсомоллар:

**Булса байлар белән тик түрәләр**
**Аркабызда рәхәт күрәләр...—**

дигән җырны, ягъни «Марсельеза»ны һәм «Корбан булдыгыз»ны күмәкләп җырладык. Аннан төрле уеннар башланып китте. Бик кызык булды.

Озакламый Бәнат үзенең туганы Сибгат абзыйның өендә, халыктан җыелган китаплардан, хәзерчә әйткәндә, уку йорты ачып җибәрде. Мин аңа китапларны төпләргә ярдәм итә башладым. Һади абзый белән Нәфисә апа «Бетсен наданлык»тагы укыту эше белән генә канәгатьләнмичә, театр куярга җыена башладылар...

Озакламый Сабир Шәрипов Советларның Бөтенроссия съездына Күкчәтау өязеннән делегат булып сайланып Мәскәүгә китә.

...1921 ел, 16 февраль. Төн. Күктә — тулган ай һәм суыктан туңып, җемелдәп торган йолдызлар. Җир өсте — ап-ак. Күкчәтау билдән карда. Юан карагайлардан бурап салынган бер катлы, такта чатырлы өйләр, урам аркылы үркәчләнеп яткан көртләр салкын, күксел шәүләгә төренеп йокымсырыйлар. Шылт иткән бер тавыш юк. Этләр дә өрмиләр, күрәсең, туңып ояларына качканнар.

Көртләр биек, кайбер тыкрыкларда алар капка өстенә, хәтта өй түбәләренә хәтле күтәрелгән.

— Ярый әле бүген айлы төн, югыйсә,— дип әйтеп бетермәде, тыкрыктагы көртләрнең берсеннән күтәрелеп килгән кеше таеп егылды да түбән таба тәгәрәп китте. Көрт итәге почмактагы йортның коймасына килеп терәлгән икән. Кеше, шунда хәтле тәгәрәп килгәч, койма тактасына ябышып аягүрә басты. Ул бүреген, озын кара тунын бияләе белән аннан-моннан каккалады да, атлыйм дигән иде, тимер аяктагы бала сыман шуып китте. «Фу... менә сиңа, сакаллы башың белән шуып йөр... Пиманы киптерергә дә вакыт юк... Хәзер кайткач та мич өстенә куярга кирәк. Иртәгә якшәмбе, соңрак торырга булыр...» — Кеше, үз-үзе белән шулай сөйләшә-сөйләшә, койма буйлап барып тыкрыкның аръягына чыкты һәм түбәсеннән карга чумган бер өй янына килеп туктады. Өйнең ишеге подвал ишеге кебек әллә кайда түбәндә иде (ярый әле ишек тышка түгел, эчкә таба ачыла). «Иртәгә — эш җитәрлек. Келәткә хәтле юл ачарга, ә монда киңрәк баскыч эшләргә кирәк булыр... — Кеше тирә-якка карады: Күкчәтау йоклый... Кала читеннән күтәрелеп далага сузылган сөзәк таулар шәүләсе күренә... Әйе, кар яхшы яуды. Болай булса, быел иген яхшы уңар, ә икмәк кирәк, бик кирәк... Берсекөнгә Имәнтауга, Усманга барып киңәшмичә булмас... Молодец, «ата минишәр»,— ул бу кушаматны әйтүгә рәхәтләнеп елмайды,— тагын илле мең пот бодай әзерләгән. Аңа инде Петропавелга чыгарырга олаулар кирәк... Продкомиссиянең бүгенге Петроградка икмәк җибәрүне көчәйтү турындагы карарны да Имәнтаудагы коммунистларга таныштырырга кирәк булыр...»

Аннары ул бозланып каткан киез итекләре белән шуып төшеп, ике тапкыр ишеккә сукты. Бераздан эчтән хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Сабир, бу синме?

Урынга ятып, йокымсырап кына киткән иде Сабир, кемдер тәрәзәне шакый башлады.

— Кем ул? Кем кирәк?

Тәрәзә артыннан калын тавышлы бирәү:

— Шәрипов, тиз-тиз совдепка! — дип кычкырды.— Бик ашыгыч.

Сабир совдепка — базар мәйданындагы бер катлы яшел йортка — килеп җиткәндә, анда инде халык ыгы-зыгы килә иде. Атлы-җәяүле продотрядчылар. Күкчәтаудагы коммунистлар, комсомолецлар. Ни булды икән? Ул-бу турыда сорарга өлгермәде, почмактан бер-берсен таптагандай бар көченә чабып биш-алты пар ат күренде. Чаналарда — мылтыклы кешеләр. Атлар әле туктар-туктамастан, чаналардагы кешеләр сикереп төшә башладылар.

— Усман! — Сабир беренче чанадан сикереп төшкән кара тунлы, озын буйлы кешенең алдына килеп басты.— Бу синме? Ни булды?

— Восстание! — Усман Әбдерәшитов мылтыгын җиңел генә җилкәсенә элде дә сүзен дәвам итте.— Бөтен казачество күтәрелгән. Безгә чигенергә туры килде. Өч кешебез пленга эләкте, әйдә, председательгә керик. Барлык көчне җыярга кирәк. Алар инде Еленовкага якынлашалар.

Кибән астында көйрәп яткан ут гелт итеп кабынган кебек, бер төн эчендә Күкчәтау өязендәге барлык станицалардагы казаклар баш күтәрделәр. Икенче көнне инде Күкчәтау — аз санлы продотрядчылар, коммунистлар һәм ярлылардан оешырылган батальон белән генә сакланган шәһәр — камалу куркынычы астында калды. Чигенергә бары бер генә юл — Петропавел юлы гына ачык иде. Имәнтау, Чонлар, Зирәнде казакларына бу яктан Боровое, Шучи, Кутир-күл казаклары кушылып, Күкчәтауны дуга рәвешендә урап алдылар.

Ул арада Күкчәтауның үзендәге казаклар казармага һөҗүм башлады. Шулай итеп, совдепчылар Күкчәтауны калдырып, Петропавел ягына чигенергә мәҗбүр булдылар.

Бу восстание, ниһаять, 1921 елның яз ахырында, Үзәктән җибәрелгән Кызыл Армия частьлары ярдәме белән бастырылды. Күкчәтауда яңадан Совет хөкүмәте урнашты, Сабир Шәрипов яңадан казакъ-татар хезмәт ияләре арасында культура-мәгариф эшләрен җайга салып җибәрү эшенә керешә. Озакламый аны Атбасарга күчерделәр һәм Атбасар өязе Хезмәт Комитеты председателе итеп сайладылар.

1922 елда Сабир Акмулла каласына күчерелә. Башта ул губерна азык-төлек комиссары була, аннан 1924 елга хәтле губерна Башкарма Комитеты председателе булып эшли. Ул шул ук вакытта Казагыстан партия Үзәк Комитеты һәм Казагыстан хөкүмәте члены була.

1924 елны партия Үзәк Комитеты Сабир Шәриповны Мәскәүгә чакырта һәм аны ул чордагы иң җаваплы эшләрнең берсенә — Совет хөкүмәте нефтькә мохтаҗ вакытта — «Эмбонефть» трестына башлык итеп җибәрә.

Сабир өчен моңа хәтле таныш булмаган авыр, әмма мавыктыргыч, перспективалы эш башлана. Ул җимерелгән вышкаларны торгыза, кадрлар әзерли һәм алар белән бергә үзе дә укый, бара-тора нефть Сабир Шәриповның язмышында төп урынны ала. Аңа ул унбиш елдан артык гомерен бирә.

Гурьев партия Өлкә Комитеты Сабир Шәриповка биргән характеристикасында болай ди:

«Сабир Шәрипов «Эмбонефть»не аякка бастыруда зур хезмәт күрсәтү белән генә чикләнмәде, Комсары, Сагыз һәм башка җирләрдә яңа нефть чыганаклары ачты һәм гыйльми китаплар язды».

1933—1934 елларда Сабир Шәрипов Иранда Совет хөкүмәтенең сәүдә вәкиле булып хезмәт итә.

* * *

Сабир Шәрипов 1906—1907 елларда Атбасар өязендә писарь-тылмач булып эшләгән вакытта ук үзенең күргәннәрен яза башлый. Аннан соң туберкулез аны түшәккә сала. Ул елларны Акмулла губернасында гадәттән тыш хәл игълан ителә. Бу чорда халыкның аһ-зарын тасвирлый торган әсәрләрне бастырып чыгару турында уйларга да мөмкин булмый. Аннан соң аның басмаханәсе кайда? Шәрипов бит күбрәк казакъ телендә яза. Аннары 1916 ел вакыйгалары, революция, гражданнар сугышы, ачлык...

Менә шулай итеп Сабир Шәрипов үзенең күңеле, йөрәге тарткан бер хезмәттән — әдәбияттан бик күп еллар аерылып торырга мәҗбүр була. Әмма еллар күңел түрендә чаткыланып торган нурны сүндермиләр. Ниһаять, ул көннәр дә туа. 1924 елдан башлап Сабир Шәрипов, хуҗалык-партия эшләре белән бергәттән, каләм хезмәтенә дә күңел бирә.

— Без Досюрга («Эмбонефть»тә эшләгән вакытта) күчкәч, әти өй алдына кечкенә генә, тавык кетәге тикле генә алачык эшләде. Чөнки без торган өй бик кечкенә иде, ә без инде 4 бала үсә идек.

Билгеле, өйдә тыгын, ә әти, эштән кайткач, төн буена үзенең «кетәгендә» утыра, нәрсәдер яза иде. Минемчә, аның әсәрләренең күпчелеге менә шул алачыкта язылды,— ди Фәридә — Сабир аганың кызы үзенең истәлегендә. Ул — инженер-геолог, хәзер Мәскәүдә тора.

Иранда эшләгән еллар да эзсез калмый. Анда ул повестьлар, хикәяләр яза.

«Сабир Шәрипов,— ди Сабит Муканов 1937 елның 25 апрелендә, Казагыстан язучылар союзы эше турындагы докладында,— гаҗәп үзенчәлекле, талантлы язучы.

Аның әсәрләренең сюжеты кызыклы, мавыктыргыч, вакыйгаларга бай теле — матур, югары художестволы. Укучылар аны яратып, кызыгып укыйлар».

Казакъ халкы, Сабир Шәриповка зур ихтирам саклап, аның революциягә, Совет хөкүмәтенә булган хезмәтен һәм әдәби иҗадын югары бәяли.

Аның турында газета-журналларда мемуарлар басыла, радио һәм телевидение буенча чыгышлар оештырыла.

1959 елда Казагыстан дәүләт нәшрияты Сабир Шәриповның әсәрләрен ике томлык китап итеп бастырып чыгарды. Бу томнарга «Алтынбасар», «Бибулат», «Ләйлә» һәм башка повестьлары, хикәяләре кергән. Болардан башка 1924 елларда рус телендә басылган «Сәлия» романы игътибарга лаек.

Әдәби-художество әсәрләре белән бергәттән, Сабир ага гыйльми эзләнүләр белән дә шөгыльләнә. Шул эзләнүләрнең нәтиҗәсе булып 1924 елда казакъ телендә аның «Нефть» дигән гыйльми әсәре басыла.

«Сабирның тормышы һәм кызыклы һәм фаҗигале дастан. Аның турында мин әле тагын да язармын»,— ди үзенең «Тар, тайгак юл кичү» дигән китабында казакъның атаклы язучысы, революционеры Сәкин Сәйфуллин. Кызганычка каршы, ул дастан язылмады. Чөнки дусты Сабир кебек үк үзенең дә вакытсыз үлесен Сәкин алдан белмәде...

**Хатип Госман,**
филология фәннәре докторы, профессор

# ТАРИХИЛЫК ПРИНЦИБЫН ҮЗЛӘШТЕРҮ ЮЛЫНДА

## 1.

Бөек Октябрь Социалистик революциясе җиңеп чыгу белән татар совет әдәбиятының, бу яңа әдәбият турындагы фәннең, тәнкыйтьнең нигезен салу башланды. Бу эшкә, әдәби иҗат һәм әдәби тәнкыйть эшен социалистик революциягә кадәр үк җәеп җибәргән алдынгы язучылар белән бергә, шул ук социалистик революция таңында гына үсеп җиткән, әдәбият мәйданына яңа гына аяк баскан яки басарга җыенган яшь буын вәкилләре тотындылар. Алар арасында пролетариатның фәнни революцион тәгълиматын теге яки бу дәрәҗәдә үзләштерергә өлгергән әдипләр башта аз иде. Хәер, үзләштергәннәре дә күптәнге марксистлар түгел иделәр. 1905 елдан алып 1917 елгы революциягә кадәр заман эчендә иҗат иткән татар язучыларының бер өлешенә революцион демократлык хас булды. 1917 елгы революция вакыйгалары башланып киткәч, аларның аерата зирәк, халык массаларына аерата якын торганнары бик тизлек белән революцион демократизмнан югарыга атладылар, халыкның үз хәрәкәтләренә ачыктан-ачык кушылып, кыю һәм ихлас рәвештә большевиклар сафына таба юнәлделәр. Болар арасында без, иң мәшһүрләре итеп, Галимҗан Ибраһимов, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури кебек әдипләрне күрсәтә алабыз. Алар үзләренең социалистик идеал балкышында иҗат иткән яңа әсәрләре белән халык массаларын социалистик революциягә чакырдылар.

Империалистик сугыш елларында татар яшьләре массасы солдат хезмәтендә булды. Армия сафына эләкмәгәннәренең дә күп кенәсе, мохтаҗлык мәҗбүр итүе аркасында, заводларга, фабрикаларга китеп эшләде. Газап чигүләрдән гайре, монда алар билгеле иҗтимагый-политик мәктәп үттеләр: рус халкының революцион идеяләрен белделәр, рус хезмәт ияләре күтәргән хәрәкәтләргә кереп киттеләр. Мондагы яшьләрдә социалистик идеал иртәрәк ачыла башлады. Алар арасындагы талант ияләре социалистик чорга революцион көрәшнең үз эчендә килеп кереп, кулларына шунда каләм алдылар. Иҗатларын социалистик идеалны җырлаудан башладылар. Шамил Усманов шундыйлардан иде.

Шул рәвешле, социалистик революция җиңеп, пролетариат диктатурасы урнашкач, яңа туган күп милләтле совет әдәбиятының, теле ачылып, беренче сүзен әйтер чагында татар халкының да социалистик идеаллы беренче вәкилләре бар иде. Һәм чыннан да Бөек Октябрьның беренче туплары гөрелтесенә аларның да көчле авазлары кушылды. Бу безнең зур горурлыгыбыз.

Шунда да татар әдипләренең шактый

әлеше бу югарылыкка кинәт кенә күтәрелә алмады. Социалистик революциягә кадәр рус патшалары Россиядә иң реакцион иҗтимагый-политик стройны беркетеп тордылар. Татар халкы да моңардан гаять зур газап күрде. Аның тормышында да урта гасырчылык, дини хорафат, шәригать хакимлек итте, демократик иркенлекләр булмады. Ул чакта диннең хакимлек итүен, урта гасырчылык калдыкларының басымчаклыгын күздә тотып, В. И. Ленин болай диде: «Алыгыз динне яки хатын-кызның хокуксызлыгын яки рус булмаган милләтләрнең изелүен һәм хокукта тигез булмауларын. Болар барысы да буржуаз-демократик революция мәсьәләләре». Бөек юлбашчы бу мәсьәләләрнең хәтта иң алга киткән буржуаз дәүләтләрдә дә ахырына кадәр хәл ителмәвен аңлатты һәм: «Бездә болар Октябрь революциясенең закон чыгаруы белән ахырына кадәр хәл ителделәр»,— диде. Шунда ук Владимир Ильич буржуаз-демократик революция мәсьәләләрен социалистик революция юл уңаенда, узып барышлый, «ян яктагы эш» төсендә генә башкарып үтүен искәртте [1].

Революциягә кадәр күп кенә татар язучылары тирән нәфрәтләнү белән тәнкыйтьләп, фаш итеп килгән һәм бетерелүен таләп иткән урта гасырчылык күренешләре себереп ташланды, демократик таләпләр тулысынча гамәлгә ашты, *демократик идеал* тормышның гадәттәге чынлыгына әверелеп калды, ил халкы исә коммунистлар партиясе җитәкчелегендә, *коммунизм идеалына* карап, кешелекнең яңа эрасына аяк басты. Октябрь революциясе ташкынына крестьян хәрәкәтләре, милли азатлык һәм гомум демократик хәрәкәтләр эченнән килеп кергән әдипләр җитди мәсьәләгә килеп терәлделәр: я инде үтелгән революцион демократик таләпләр һәм демократик идеаллар дәрәҗәсендә торып калырга да, үзеңне иҗади кысырлыкка хөкем итәргә, яки ленинизм тәгълиматын үзләштерергә һәм коммунизм идеалын күрүгә ирешергә дә, талант көчеңне яңа тормыш төзү эшенә багышларга, халкыңнан аерылып калмыйча, тарихның алгы сафында килүчәккә юл ярырга. Татар әдипләренең иң зур күпчелеге шушы соңгы юлны сайлады.

Коммунистлар партиясе халык массаларын советча яңа тормыш төзү көрәшенә алып керде. Шушы практик эш барышында пролетар булмаган хезмәт иясе массаларда да социалистик аң, социалистик идеал яктырып үсә башлады. Революция ташкынына демократик теләкләрнең үтәлүен өмет итеп килеп кергән әдипләрдә дә социалистик аң, социалистик идеал шул ук шартларда ачылды. Моның мисалын К. Тинчурин, С. Сүнчәләй, Ф. Бурнаш, һ. Такташ кебек исемнәр белән күрсәтергә булыр иде. Алар революция тудырган яңа чынбарлыкны җырларга омтылдылар. Бу барыннан да элек яңа чынбарлыкны төзү өчен партия җитәкчелегендә барган көрәшкә ихлас күңелдән бирелеп катнашуны, вакыйгаларның закончалыкларын төшенүне сорый иде. Асылда бу марксизм-ленинизм дөньяга карашын, яңа сәнгать һәм әдәбиятның партиялелек принцибын үзләштерү дигән сүз иде. Соңрак алар, бик тирән һәм катлаулы төстә барган рухи яңару нәтиҗәсендә, марксистик-ленинчыл дөньяга караш белән коралланган һәм социалистик сәнгатьнең үзенчәлекләрен үзләштергән совет язучылары булып танылдылар да.

Татар әдәби тәнкыйтендә, мәсәлән, һади Такташ кебек әдипләр турында, социалистик революцияне аңлауга шактый озак килде, социалистик сәнгатьнең иҗат принципларын акрын үзләштерде, дигән фикерләр әйтелгәләде. Бу, безнеңчә, берьяклырак караш иде. Совет чынбарлыгына социалистик революция ташкыны белән килеп кергән яшьләр рухи яктан, бүтән заманнар белән чагыштырганда, тиз үстеләр. Моның шулай икәнен В. И. Ленин 1919 елда ук күрсәтеп үтте [1]. Бу табигый да иде. Ленинизм тәгълиматын халык массалары революция вакыйгалары барышында, практик эш эчендә өйрәнделәр. Монда фикер һәм гамәл бер-берсенә аерылгысыз бәйләнгән иде. Шуңа күрә дә мондый шартларда шәхеснең яңаруы тиз барды. Язучыларда да бу шулай булды. Тәнкыйтьчеләр, теге яки бу язучының иҗатын бәяләгәндә, аның үсеше акрын барды, дигәннәр икән, болай дию ул чакта, бигрәк тә 20 елларда һәм 30 еллар башында, татар марксистик тәнкыйтенең үзенең әле җитди кимчелекләре булуыннан килә иде. Яшь татар совет тәнкыйтьчеләре ленинизмның әдәбият революцион чынбарлыкны чагылдырырга, эшче һәм крестьяннарның революцион батырлыгын җырларга тиеш, дигән төп таләбен дөрес үзләштерсәләр дә, сәнгатьнең үзенә хас үзенчәлекләрен, аның иҗат ме-

[1] Ленин. Сочинения. Рус телендә 33 том 31—32 битләр.

[1] Карагыз: Ленин. Сочинения. Рус телендә. 29 том, 408—409 битләр.

тодын, иҗатта сәнгать осталыгы кебек мәсьәләләрне аңлауда һәм аңлатуда ялгышкалыйлар да иде әле. Бу исә сәнгатьнең хас үзенчәлегенә, сәнгать иҗаты процессының үзенчәлекле законнарын тиешле дәрәҗәдә тирән белмәүдән, художникның, марксистик-ленинчыл дөньяга карашны үзләштерүе өстенә, шул караш нигезендә, сәнгать осталыгына да өйрәнергә тиеш булуын искә алмаудан килә иде. Ачыграк әйткәндә, марксистик-ленинчыл эстетиканы, ягъни марксизмның сәнгать турындагы өйрәтмәсен тирән үзләштерү, сәнгать иҗатының катлаулы һәм нечкә мәсьәләләрен тикшергәндә аңардан иҗади файдалана белү җитенкерәми иде. Югыйсә, мәсәлән, Такташ дөньяга марксистик карашның нигезләрен егерменче елларның башларында ук инде аңлаган, аңа инанган, үзенең фәнни социалистик карашларын дәртләнеп үстерә, тирәнәйтә бара, әмма үз иҗатының яңа чорга килешле булган метод һәм формаларын табып, җитлектереп өлгермәгән, ул аларны зур активлык белән эзли, ялгышлар ясый, уңышларга ирешә, үз үсешенең, шулай ук яңа әдәбият үсешенең катлаулы каршылыкларын җиңә-җиңә югарыга юл яра иде. Шунда да аны пролетариат идеологиясеннән, социалистик революцияне аңлаудан ерак тора, дип катгый хөкем чыгаручылар табыла, аның хәлен аңлау һәм аңа ярдәм күрсәтү урынында кайчакта киресе эшләнә иде.

Татар әдәби тәнкыйтендәге, әдәбият фәнендәге мондый кимчелекләр соңрак, әлбәттә, бетерелде.

Татар әдәби тәнкыйтенең, әдәбият фәненең үсешен гел үз эчендә генә аерып карау дөрес булмас иде. Чөнки татар совет әдәбияты да, әдәбият фәне дә туганда ук күп милләтле социалистик әдәбиятның органик бер өлеше буларак дөньяга килде. Формалашу, үсү кыенлыкларын да ул ялгызы гына кичермәде, ялгызы гына җиңмәде. Маркс, Энгельс, Ленин тәгълиматы, алар биргән эстетика бөтен дөньяның революцион сәнгате, шулай булгач, һәр аерым халыкның социалистик сәнгате өчен уртак тәгълимат, уртак методологик өйрәтмә иде. Бу тәгълиматны аңлау, тормышта куллану, баету эшендә М. Горький, А. Луначарский кебек ленинчылар гаять зур эш эшләделәр. Илнең төрле милләт язучылары совет әдәбиятының формалашуы чорында ук һич тә үз милли хәзинәләре белән генә чикләнеп калмадылар, алар турыдан-туры Маркска, Энгельска, Ленинга мөрәҗәгать иттеләр, русның бөек социалистик сәнгать осталарыннан, сәнгать галимнәреннән ярдәм алдылар, алардан өйрәнделәр. Шушы хәл илнең һәр милләтендә, шул исәптән татар халкында да совет әдәбиятының, тәнкыйтенең, әдәбият фәненең формалашуын тизләтте, өлгергәнлек дәрәҗәсенә тиз күтәрде. Сәнгать иняләре, язучылар яңа сәнгатькә нигез салганда, аны үстереп алып киткәндә һәрвакыт бөек Ленинны остазлары, аталары итеп күрделәр. Һади Такташ капитализм чорында кыргыйлыкка, һәлакәткә хөкем ителгән авыл малаеның Бөек Октябрь аркасында азатлык алып, зур юлларга чыгуын җырлады, Ленинга булган рәхмәтен шушы герое авазыннан искиткеч матурлык, самимилек белән әйтеп бирде:

> Шулай, әткәй,
> Ленин юл күрсәтте
> Юлдан язар усал улыңа.
> Иптәшләрчә үткен каләм бирде:
> «Мә, яз инде».— диеп кулыма.

Бу герой бөтен халыкны, бөтен кешелекне бәхетле итәрдәй бөек эшләргә, иҗатта һәм фәндә күрелмәгән бөек ачышларга ашкына иде. Шагыйрь үзе шушы герой белән замандаш булуны, аның матурлыгын җырлый алуны үзенә бәхет санады, үзен өченче затка куеп: «Аны болай җырларга Ленин өйрәтте»,— диде.

## II

Ул еллардан соң ярты гасыр узды. Гомумән, совет әдәбиятының аерылгысыз бер өлеше буларак, татар әдәбияты да үзенең үсешендә гаять зур юл үтте. Аның да күчле талантлары бөтен ил, бөтен дөнья алдына чыктылар. Әдәбият белән бергә әдәбият фәне дә, әдәби тәнкыйть тә үсте, марксистик-ленинчыл эстетика белән коралланды. Моңа ирешү, әлбәттә, Маркс, Энгельс һәм Ленин хезмәтләрен гаять зур игътибар, рухлану һәм тырышлык белән өйрәнү, аларның өйрәтмәсе буенча эш итү аркасында булды. Хәзер даһилардан өйрәнү тагын да көчлерәк дәвам итә, һәм киләчәктә дә гел тирәнәя барыр. Чөнки аларның тәгълиматы, тормышның үзе шикелле, мәңге тере, мәңге үлемсез. Бу тәгълимат кешелекнең тарихи юлын яктыртып бару гына түгел, бәлки тарихи хәрәкәт тудырган яңалыклар белән үзен өзлексез баета да бара.

Марксистик-ленинчыл эстетика сәнгатьнең иҗтимагый кәрәштәге, шәхес тормышындагы ролен, шулай ук аның үзенчәлек-

ләрен тәшкил иткән нечкә сыйфатларын хисапсыз күп яклардан тирән итеп ача. Аны өйрәнү, үзләштерү һәм гамәлдә куллана белү җиңел түгел, ул һәр кешедән гомеренең иң кыйммәтле өлешен, хисләренең иң сафын, зиһененең иң үткен эшчәнлеген таләп итә. Татар совет әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйте өлкәсендә эшләргә теләгән кешеләр алдына да ул совет хөкүмәтенең беренче елларында ук шундый таләпләр куйды. Бу таләпләрне әдәбият-сәнгать кадрлары еллар буе өзлексез дәвам иткән хезмәтләре белән уңышлы үтәп килделәр, әдәбияттай гаять катлаулы һәм туктаусыз хәрәкәттәге күренешнең бик күп өлкәләрен, эчкәре кереп, яктырттылар, аңлаттылар, һәр өлкәнең үзенә хас алымнарын кулланып эш итәргә өйрәнделәр.

Марксистик-ленинчыл әдәбият фәненең үзәгендә торган методологик принципларның бик мөһимнәреннән берсе, һичшиксез, тарихилык. Бу принцип күп мәсьәләләрнең чын мәгънәсендә ачкычы хезмәтен үти. Аны үзләштермәдеңме, җитди мәсьәләләрнең берсенә дә якын килә алмыйсың.

Иң элек «тарихилык» (историзм) төшенчәсен ачыклап китик. Кайберәүләрнең моны, тарихи вакыйгаларны бәр-бер артлы күз алдына китерү, дип кенә аңлаулары ихтимал. Бу — берьяклы булыр иде. Без исә бу урында «тарихи» дигәннән «үсә, үзгәрә торган» диген мәгънәне күбрәк күз алдында тотабыз. Бу ноктадан алганда, һәр җанлы күренеш тарихи, чөнки ул катып калмаган, ул үсә, үзгәрә, үзгәргәндә дә теләсә ничек түгел, аның үзгәреше билгеле бер закончалык белән бара. Без әнә шул закончалыкны, аның хәрәкәтендәге төрле баскычларны белергә телибез, һәр баскычта нәрсә хаклы, нәрсә хаксыз икәнен ачыкларга, хаксызның юлын бүлдереп, хаклыга куәт бирергә ниятләнәбез.

Татар совет әдәбияты фәненә, әдәби тәнкыйтенә нигез салганда, егерменче елларның башларында, тарихилык принцибын үзләштерү иң үткен бурычлардан булып торды. Ул чакта культура мирасына нигилистик, вак буржуаз карашлар шактый таралган иде. В. И. Ленин үзенең чыгышларында, партиянең Үзәк Комитеты кабул иткән документларда бу карашларның бозык асылын фаш итте, аларны тар-мар китерде. Ул культура мирасына, үткән заман эшлеклеләренең эшчәнлегенә ничек бәя бирергә икәнен өйрәтте, эксплуататор сыйныфлар хакимлек иткән җәмгыятьтә бер милләттә ике милләт, бер милли культурада ике милли культура булуы турында тәгълимат бирде. Ул үзенең Лев Толстой турындагы хезмәтләрендә, Максим Горькийга язган хатларында әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен тикшерүнең даһиларча үрнәген күрсәтте.

Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти кебек әдипләр татар совет әдәбияты фәнендә Ленинчә тарихилык принцибын куллануда беренче елларда ук аерата күп һәм нәтиҗәле эш эшләделәр. Революциягә кадәрге татар әдәбиятының мирасын ленинчыл караштан бәяләп чыгу эшен алар башладылар. Бу юлда Г. Ибраһимов «Татар әдәбияты тарихының мөндәриҗәсен каян башларга» (1922), «Пролетариат әдәбияты турында» (1924), Г. Нигъмәти «Әдәбият мәйданында» (1925) кебек беренче зур хезмәтләрен бирделәр. Алар бу һәм башка хезмәтләрендә әдәбиятның сыйнфыйлыгын ачтылар, мирасны Ленин өйрәткәнчә эшчеләр сыйныфының социализм төзү максаты ноктасыннан үзләштерергә чакырдылар, әдәбиятта язучының чынбарлыкны «марксизм аркылы күреп тасвирлавын» алга сөрделәр. Алар шулай ук «футуризм», «имажинизм» кебек формалистик күренешләргә Ленин өйрәткәнчә кискен көрәш ачтылар, әдәбиятка килгән яшь буынның эстетик карашларын марксизм-ленинизм нигезендә формалаштыруга һәм үстерүгә күп көч куйдылар. Аларның бу хезмәте татар совет әдәбиятының үсешенә җитди уңай тәэсир ясады.

Шулай да бу эш җиңел генә бармады. Революциягә кадәрге татар әдәбиятының тарихи эчтәлеген һәм сәнгать нәфислеге ягыннан булган эстетик кыйммәтен билгеләүдә вульгар, дорфа һәм нигилистик концепцияләр шактый дәвамлы тәстә комачаулык тудырып килделәр. Пролеткультчылар, раппчылар, таппчылар революциягә кадәрге татар әдәбиятының эчтәлеге тулаем буржуаз, социализмга тулаем чит дип аңлаттылар. Монда да әдәбият фәненә, тәнкыйтьчеләргә үткәннән калган мирасны бәяләүдә тарихилык принцибы җитмәде, алар кешелекнең культурасы үсешендә өзлексезлек (преемственность) диган нәрсәне бөтенләй күздән төшерделәр.

Ф. Энгельс «Анти-Дюринг» әсәрендә, колбиләүчелекнең бөтендөнья культурасы өчен булган әһәмиятен аңлатып, болай диган иде: «Тик коллык кына игенчелек белән промышленность арасында киңрәк күләмдә хезмәт бүленеше үткәрү, һәм шуның нәтиҗәсендә борынгы грек дөньясы-

ның чәчәк атуы мөмкинлеген бирде. Коллыктан башка грек дәүләте, грек сәнгате һәм фәне була алмас иде, коллыктан башка Рим дә булмас иде. Ә Греция һәм Рим салган нигездән башка шулай ук хәзерге Европа да булмас иде». Безнең барлык экономик, политик һәм чаклый үсешебез, диде ул, шундый башлангыч шартлардан күтәрелеп чыкты ки, ул шартларда коллык гомум тарафыннан танылган кебек, шундый ук дәрәҗәдә зарури да иде. Бу мәгънәдә алганда безнең, антик коллыктан башка хәзерге заман социализмы да була алмас иде, дияргә хакыбыз бар»[1].

В. И. Ленин да шулай ук «марксизм... кешелек фикеренең һәм культурасының ике мең елдан артык үсешендә булган барлык кыйммәтле нәрсәләрне үзләштерде һәм эшләде»[2],— диде.

Күренә ки, борынгылыкта культура гаять тирән һәм кискен сыйнфый көрәш шартларында туган һәм үскән. Шуңа күрә ул үзе дә каршылыклы. Әмма бу котылгысыз да булган. Борынгылыкта җәмгыятьнең алга баруы, культураның үсүе өчен бүтән юл, бүтән шартлар була алмаган. Шуның белән бергә бу шартлар тарихта ике килми, кабатланмый торган булган. Сыйнфый көрәш үсә баруы нәтиҗәсендә бер формация җимерелгән, икенчесенә күчелгән, элекке формация беткән, ләкин аның заманында туган культура хәзинәләре яшәп калган. Культура үсешендә өзлексезлек (преемственность) барган. Безнең бурычыбыз элекке иҗтимагый формацияләр килүе-китүе барышында туып калган барлык культура мирасын өйрәнеп, бәяләп чыгу, андагы барлык прогрессив элементларны яңартып эшләү.

Барлык борынгы халыклар калдырган мирас байлыгы эчендә татар халкының борынгы бабалары калдырган өлеш тә бар. Ул да туып килгән социалистик культура карамагына күчәргә тиеш иде. Бу шулай эшләнде дә. Еллар барышында татар әдәбияты, татар теле, тарихы өлкәсендә дә марксистик яктан нык коралланган кадрлар үсте. Алар инде фән өлкәсендә байтак кына уңай казанышларга да ирештеләр. Кискен төстә торган бурычларның берсе — әдәбиятның тарихын төзү иде. Чөнки марксистик-ленинчыл методологик нигездә төзелгән тарих кына мирасның чын кыйммәтен ачачак, аның күләмен тәгәл билгеләячәк. Әлбәттә, әдәбиятның тарихын билгеләргә уйладыңмы, иң элек алдыңа бер сорау килеп баса: каян башлана? Татар әдәбиятының тарихын элек төрлечә башлап караулар булды. Кайберәүләр аны Орхон-Енисей язуларыннан ук башларга омтылыш ясадылар. Г. Ибраһимов моны кискен тәнкыйть итте. («Татар әдәбияты тарихының мөндәриҗәсен билгеләү мәсьәләсе». 1922 ел). Ул үзе татар әдәбиятының елга башын Идел буеннан эзләү ягында иде. Соңгы елларда бу фикер бәхәссез төс алды, әдәбиятны борынгы Болгардан башлау гадәткә керде. Әмма моның шулай икәнен марксистик-ленинчыл өйрәтмә ноктасыннан расларга, мәсьәләнең методологик нигезләрен билгеләргә кирәк иде. Бөек остазларыбызның тәгълиматы безгә бу юлда да җитәкче булды. Теге яки бу җәмгыятьтә язма культураның туу шартлары Маркс һәм Энгельс хезмәтләрендә тирән аңлатылган. Алар моның алгы шарты игенчелектән һөнәрчелекнең аерылып чыгуы, сәүдә барлыкка килү, һөнәрчелек-сәүдә шәһәрләренең тууы, шәһәрдә торып идарә итә торган дәүләт оешуы икәнен күрсәтәләр. Җәмгыять мондый хәлдә язусыз яши алмый. Язу барлыкка килә. Бу дәрәҗәгә ирешкән җәмгыять инде антагонистик сыйныфларга бүленгән. Хезмәт ияләрен эксплуатацияләү аркасында хаким сыйныфлар үзләре өчен культуралы көнкүреш шартлары тудыралар, физик хезмәт җәфасыннан азат яшиләр. Хезмәт игенчелек белән һөнәрчелек арасында бүленү белән генә калмый, физик хезмәт белән рухи хезмәт арасында да бүленеш барлыкка килә. Тормышы, хокуклары һәрьяктан тәэмин ителгән, үзе өчен буш вакыт булдырган хаким сыйныф кешеләре арасыннан укымышлылар, фән, сәнгать белән шөгыльләнүчеләр чыга. Алар алга киткән һәм үз илләре белән экономика, культура багланышларына кергән чит илләрнең культура һәм сәнгать казанышларын өйрәнәләр, аннан тәҗрибә, традиция алалар. Мондый шартларда шәһәр дәүләтнең политик, экономик үзәге генә булып калмый, ул шулай ук халыкның культура хәрәкәтен координацияли торган үзәккә дә әйләнә. Хәтәр хәлләр туып, шәһәр тормышы җимерелсә, ул координацияләгән, ул җитәкләгән культура да җимерелә, таркала, тик халыкның үз көраше белән шәһәр тормышын яңадан торгызуы гына культура хәрәкәтен яңадан ялгап, элекке традицияләрне яңадан терелтеп, үстереп җибәрә. Мондый хәлләр тарихта очрый,

[1] К. Маркс и Ф. Энгельс об искусстве. Рус телендә. 1957 ел. I том. 291 бит.
[2] Ленин, Сочинения. Рус телендә, 31 том, 292 бит.

Марксистик-ленинчыл өйрәтмә яктылыгында хөкем йөрткәндә, татар әдәбиятының борынгы чыганаклары бик төгәл булып ачылып китәләр дә. Безнең эраның беренче мең елы урталарында ук Идел буенда төрки телле халыклардан торган шәһәрләр барлыкка киләләр. Аларда төркичә чәй язуы гамәлдә йөргәнен совет фәне хәзер инде тулысынча раслады[1]. Шул ук беренче мең елның ахырларында Идел-Кама кушылган урында Болгар дәүләте барлыкка килә, шәһәрләр төзелә башлый[2]. Монда сугылган иң борынгы тәңкә 907 елга карый[3]. Тәңкәдә Болгар ханының исеме гарәп хәрефләре белән «Җәгъфәр бине Габдулла» дип язылган. (Ислам кабул иткән болгарлар чәй язуыннан гарәп язуына күчкән булырга тиешләр). 930 елларда Җәгъфәрнең улы Микаил суктырган тәңкәләрдә инде «Микаил бине Җәгъфәр» дию белән бергә «Бимәдинәте Болгар» дип тә язылган[4]. Ягъни «Болгар» туп-туры шәһәр дип аталган.

Әмма теге яки бу халыкның язу кулланa башлавы белән үк язма әдәбият үсеп китми әле. Моның өчен дәвамлы төстә өлгергән өстәмә шартлар кирәк. Шулай да Идел буенда монголлар басып алганчы ук (XIII йөз уртасына кадәр үк) төрки телдә язма әдәбият барлыкка килгән. Колгалинең «Кыйссаи Йосыф»ы шушында язылган булырга тиеш. Монголлар шәһәрләрне җимерәләр, талыйлар, халкын кыралар. Соңрак, чагыштырмача тынычлык урнашкач, 100 ел эчендә Идел буенда бай культуралы һөнәр-сәүдә шәһәрләре төзелә. Хәзер безнең кулда XIV йөз Идел буеның венецияле ике туган Франциск һәм Доминикан Пицигانолар 1367 елда сызган картасы, 1375 елда исеме билгесез кеше сызган картасы, шулай ук Венеция космографы Фра Мауре 1459 елда сызып тәмамлаган карталары бар. Боларда шул заман Идел буе төрки шәһәрләре аермачык билгеләп чыгылган[5]. Бу шәһәрләр Көнбатыш Европа, Азия, Урта Көнчыгыш һәм төньяк илләре белән җанлы экономик, сәүдә, культура бәйләнышларында яшәгәннәр. Котбыйның «Хөсрәү вә Ширин»е (1342 ел), Хорәзминең «Мәхәббәтнамә» (1353), Мәхмүт бине Галинең «Нәһҗел Фарадис» (1358 ел) әсәре, Сәйфи Сараи әсәрләре шушы заманда язылган.

Бу заман — феодализм заманы. Идел буенда ерткыч Алтын Урда ханнары хакимлек итә. Алар Идел буе төрки дөньясы, Рус иле халыкларын рәхимсез изәләр, талыйлар, җәберлиләр. Монда күтәрелгән шәһәрләр дә ханнар, килмешәкләр кулы белән төзелмәгән, аларны Идел буеннан, Хорезмнән, Рус иленнән куып китерелгән осталар, хезмәт ияләре, кол ителгән халык салган. Дөньяви китапларны да ханнар яки сугыш чукмарлары язмаган. Аларны укымышлылар дөньяга чыгарган. Шулай да китапларны бина салу белән бер дәрәҗәдә карап булмый: аларда язучыларның дөньяга карашлары, идеологияләре гәүдәләнгәнгә, аларны сыйнфый ноктадан карап аеру — беренче бурыч. Күп өлеше руханилар һәм ханнар хакимлеген яклап, ныгытып торган фикер ияләре тарафыннан төзелгәнгә, аларның кайберләрендә дини идеяләр, ерткычларны аклау кебек карашлар да гәүдәләнгән. Ләкин ул вакытта, хаким катлаулардан чыккан укымышлыларның кайберләре, фәннәрне өйрәнеп, әсәрләрендә ерткыч ханнарны хөкем иткәннәр. Шулай ук, беренсәрән генә булса да, укымышлылар, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр һ. б. шундый катлаулардан да каләм ияләре чыккалаган. Аларның прогрессив карашларны үзләштергәннәре үз әсәрләрен дөньяви, прогрессив юнәлештә иҗат иткәннәр.

Кыскасы, бездә борынгы культура казанышларын, тәнкыйть күзлегеннән үткәреп, марксистик-ленинчыл позициядән, революцион эшчеләр сыйныфының фәнни тәгълиматы таләпләре ноктасыннан карап өйрәнергә һәм үзләштерергә кирәк. Чөнки безнең борынгылыкны өйрәнүебез, аны белүебез борынгылык өчен түгел, бүгенгебез өчен, социалистик культураны үстерүебез өчен хезмәт итәргә тиеш. Маркс, Энгельс һәм Ленин хезмәтләре — бу юлда безгә иң ышанычлы, иң зур мәктәп.

Әдәбият фәнендә тарихилык принцибын үзләштереп җитмәгән заманда безгә культура яки әдәбият өлкәсендә булып үткән аерым тарихи шәхесләрне дөрес бәяләү дә кыен булды. Хәзер бу өлкәдә дә без В. И. Ленин өйрәтмәләрен үзләштердек, ул күрсәткәнчә, ышаныч белән эш итәбез. «Та-

---

[1] Кузнецов В. А. Надписи Хумаринского городища. «Советская археология» журналы. 1963 ел. 1 сан.

[2] X гасырда яшәгән гарәп галиме Максуди (вафаты 957 еллар тирәсендә) җир йөзенең ул вакытта мәгълүм булган илләрен 944 елда картага төшергән. Ул Болгар илен дә аерым атап күрсәткән. (Карагыз: Рихард Хенниг. Невидимые земли. М. 1963. Том IV. Стр. 129).

[3] Карагыз: С. Д. Янина. Новые данные о монетном чекане Волжской Болгарии. Куйбышевская археологическая экспедиция. IV том. Мәскәү. 1962 ел. 183 бит.

[4] Шунда ук. 191 бит.

[5] Бу карталарны карагыз: Труды Саратовской архивной комиссии. 1889 ел. II том. 1 һәм 2 чыгарылыш.

рих алдында күрсәткән хезмәтләр тарихи эшлеклеләрнең безнең заман таләпләре белән чагыштырганда нәрсәне б и р м ә ү л ә р е н ә карап билгеләнми, бәлки аларга кәтле килеп җиткәннәр белән чагыштырганда алар инде я ң а н ә р с ә б и р ү л ә р е н ә карап билгеләнә», — В. И. Ленин әнә шулай диде[1]. Шушы өйрәтмәне куллана белмәү үз вакытында бездә Г. Утыз-Имәни, Г. Кандалый, Ш. Мәрҗани, хәтта Ф. Әмирхан кебек фикер ияләренең, әдипләрнең хезмәтләрен билгеләүдә күп кенә буталчыклар тудырган иде. Бу шәхесләргә хәзер дөрес мөнәсәбәт ачыкланды. Шулай да бу юлда безнең күп эшлисебез, Маркс, Энгельс һәм Ленин хезмәтләренә әледәнәле кайтып өйрәнәсебез, тирәнгә керәсебез бар әле. Соңгы елларда бездә татарлардагы мәгариф тарихы буенча байтак бәхәсләр булды. Борынгы Идел буе төрки дөньясында игенчелек белән һөнәрчелек арасында хезмәт бүленеше барлыкка килү, сәүдә мөнәсәбәтләре туу, шәһәрләр төзелү һәм, ниһаять, шуларның мәҗбүр итүе, кушуы нәтиҗәсе буларак язу куллана башлау, Ленинча тарихилык ноктасыннан караганда, һичшиксез, прогрессив күренеш. Ләкин бу ганимәтнең үзенең каршылыклы яклары бар: язудан башлыча хезмәт ияләре түгел, эксплуататор хаким сыйныфлар файдаланган. Бу аларга барыннан да элек дәүләттәге иҗтимагый мөнәсәбәтләрне ныгыту һәм үстерү, аның идеологик әскормасына куәт бирү өчен кирәк булган. Табигый, бу эшне алар үз кулларына алганнар. IX—X гасырларда яшәгән атаклы гарәп галиме Ибн-Руст үзенең 903—912 еллар арасында язган хезмәтләрендә болай ди: «Аларның (болгарларның — Х. Г.) күпчелек өлеше ислам динен тота, һәм аларның авылларында мәэзиннәре, имамнары белән мәчетләре һәм башлангыч мәктәпләре бар»[2]. Мондагы «мәчет», «имам», «мәэзин» дигән сүзләр хәзерге заман кешесенең, әлбәттә, колагын яра. Әмма шуннан башлап, мең елга якын гомер дәвамында мәктәп-мәдрәсәләр булып килгән. Ләкин аларның эшчәнлеге дә каршылыклы: аларда тулаем алганда схоластика хакимлек иткән. Шулай да алар җәмгыятьнең дөньяви, тормыш өчен бик кирәкле ихтыяҗларына да хезмәт күрсәткәннәр. Шунысы булмаса, җәмгыять аларны мең елга якын, XX гасыр башына кадәр асрамаган булыр иде. Тарихилык ноктасыннан карасак, бу мәктәпләрдәге прогрессив элемент гомумән грамотага өйрәнүдән һәм филологик белемнәр бирүдән гыйбарәт булуын күрербез. Монда төрки тел белән бергә гарәп һәм фарси телләрен өйрәнү нык куелган булган. Моның да максаты шәкертләрне гарәп һәм фарси телендәге дини китапларны укырга өйрәтү булган. Ләкин шуны да истән чыгармаска кирәк: теге яки бу патша теге яки бу уку йортын, фән учагын үзенең халыкларны талау, изү көчен арттыру ниятендә ачса да, ул учакта күтәрелә башлаган фән, үзенең объектив асыл хасиятенә бинаэн, хәтта шул патшаларның үзләренә дошман көчләргә куәт бирә торган юнәлештә үсеп киткән. Тарихта моның мисаллары әллә никадәр. Схоластик мәктәпләрдә гарәп, фарси телләрен укытуның да шундый яклары булган. Чөнки бу телләрдә ислам тәгълиматы гына түгел, аңа каршы чын фән дә югары булган. Гарәпләр, фарсилар урта йөзләрдә бөтен дөнья фәненең алгы сафында булып, бөтен дөнья фәнен баетып, бер адым алга таба этәреп калдырганнар. Гарәп, фарсины белгән кеше дини китаплар гына түгел, Әл-Кыйнди (800—879), Фараби (870—950), Әбү Гали Сина (980—1037), Ибн Рушд Аверроэс (1126—1198) кебек прогрессив фикер ияләренең хезмәтләрен, Гомәр Хәйям, Рудаки, Фирдәүси, Низами, Сәгъди кебек даһиләрнең әсәрләрен укый алганнар. Бу прогрессив галим һәм әдипләрнең традицияләрен дәвам иттергән укымышлылар арасыннан алдынгы эшлеклеләр җитешкән.

Схоластик мәктәпләрдәге прогрессив элемент — филология фәне дидек. Татарларда XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында схоластик мәктәпләрне җимерү һәм ысулы җәдид (яңа методлы) мәктәпләргә күчү башланды. Яңа мәктәп тарафдарлары элекке мәдрәсәләрнең схоластикасын ташлап калдырдылар, әмма филологиясен үзләре белән алдылар, аны мәктәптәге дөньяви фәннәр рәтенә куйдылар. Яңа мәктәпләрдә гарәп, фарси телләрен укыту дәвам иттерелде. Әмма бу филологик цикл элекке хәлендә калдырылмады, баетылды: рус теле өстәлде. Социалистик революция җиңгәч, татар совет мәктәбен төзү башланды. Ысул җәдид мәктәпләре асрап килгән дин дәресләре, буржуаз әхлак нигезләре кебек нәрсәләр ташлап калдырылды, ләкин табигать-математика һәм филология циклын совет мәктәбе үзенә

[1] В. И. Ленин. Сочинения. Рус телендә. II том. 166 бит.
[2] Труды Куйбышевской археолог. экспедиции. 183 бит.

алды, аларны яңача корды. Филология циклы үстерелде: туган телне укыту чын фәнни нигездә куелды, рус телен өйрәнүгә игътибар артты, шуның белән бергә мәктәпкә Европа телләре дә килеп керделәр. Татар совет мәктәбе тик татар мәгарифе тәҗрибәсе нигезендә генә төзелдесә бик зур хата булыр иде. Ул татарның революциягә кадәрге мәктәбеннән кайбер уңай якларны гына алды, ә асылда исә татар совет мәктәбе, илдәге барлык мәктәпләр шикелле, бөтендөнья мәгариф эшенең прогрессив казанышлары нигезендә төзелде.

Шушы күзәтүдән культура өлкәсендәге өзлексезлек, аның тарихи үсештә нинди сыйфат сикерешләре ясавы, искергәнне ничек ташлап, яңаны ничек үстерә һәм үзләштерә баруы күренә, һәр баскычның, үз заманы тарихи зарурияты тудырганга күрә, үз заманы өчен «хаклы» булуы һәм, яңа зарурият тугач, аның «хаксыз»га әверелүе аңлашыла.

* * *

Илле ел эчендә татар әдәбияты һәм тел фәне искиткеч зур юл үтте. Бу өлкәдә хәзер безнең дөньяга марксистик-ленинчыл караш һәм методология белән нигезле коралланган һәм чын мәгънәсендә җитлеккән кадрларыбыз бар. СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты чыгарган «Татар совет әдәбияты тарихы» (Казан. 1960, Мәскәү. 1965), «Хәзерге татар әдәби теле» (Мәскәү. 1969), «Татарча-русча сүзлек» (Мәскәү. 1966), «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (Казан. 1969 ел) — шушындый коллектив фундаменталь хезмәтләр һәм шул ук институт һәм университетның аерым галимнәре язган монографик хезмәтләр татар филология фәненең хәзинәсенә генә түгел, бөтен Совет иле филологиясе хәзинәсенә дә кыйммәтле өлеш булып керделәр. Без болар өчен бөек Ленинга, Коммунистлар партиясенә һәм Совет хөкүмәтенә бурычлы. Хәзер безнең алдыбызда яңа гаять зур эшләр тора, без татар совет филологиясенең яңа күтәрелешенә ирешер өчен элеккедән дә күп өлеш катлаулы һәм киң, элеккедән күп өлеш күләмле һәм тирән мәсьәләләрне чишәргә керешергә тиешбез. Без моны, һичшиксез, булдырырбыз, әмма моның өчен бер нигез шарт бар: фәндә тарихи белән теоретик белемнәрне бер-берсеннән өзмичә, бергә ялгап алып барырга, тикшеренүләрдә марксистик-ленинчыл тарихилык принцибын барган саен тирәнрәк үзләштерергә, аны коммунистларча партиялелек, принципиальлек белән тормышка ашырырга тиешбез. Без тагын һәм тагын — һәркайчан зур ихлас белән остазларыбыздан тагын да тирәнрәк дәрес алырга, Маркстан, Энгельстан, Ленинннан өйрәнергә тиешбез.

Радик Сибәгатов

# ТӘРҖЕМӘГӘ ИКЕ КАРАШ

Рус теленнән татар теленә тәрҗемә гаять бай һәм күп яклы өлкә. Бездә кыска белдерүләрдән алып зур-зур әдәби әсәрләргә кадәрге барлык стильдәге язма төрләре, барлык жанрлар тәрҗемә ителә. Бу эш безнең газета-журнал редакцияләренең, китап нәшриятының көндәлек бурычына әйләнгән һәм басма продукциянең шактый зур өлешен тәшкил итә. Тәрҗемә әдәбият үсә, катлаулана барган саен, билгеле, аны гыйльми яктыртуга мохтаҗлык һәм игътибар да арта бара.

Теге яки бу тәрҗемәнең сыйфаты, ничек тәрҗемә итәргә «яравы», ә ничек «ярамавы» турында революциягә кадәрге матбугатта ук кайбер фикерләр әйтелгән иде. Ләкин бу эш бары тик совет чорында гына киң колач алды. Әһәмиятлерәк һәрбер тәрҗемәгә, бигрәк тә матур әдәбият тәрҗемәләренә, рецензияләр басу гадәткә кереп китте. Әлеге рецензияләрдә, теге яки бу тәрҗемәне бәяләү белән беррәттән, тәрҗемә хакында кайбер гомумирәк фикерләр дә әйтелде. Тора-бара тәрҗемәнең махсус проблемаларын күтәргән мәкаләләр күренде, тәрҗемә тарихына кагылышлы хезмәтләр язылды. Ниһаять, рус теленнән татар теленә тәрҗемә теориясе буенча китап — С. Фәйзуллинның «Ике тел хәзинәсе» (1964 ел) дөньяга чыкты.

Бездә әле тәрҗемә буенча тикшеренүләр тарихы артык зур түгел. Шулай да күп санлы мәкаләләрдә, рецензияләрдә, тәрҗемә ителгән аерым китапларга карата язылган кереш сүзләрдә һәм башка чыганакларда сибелеп яткан фикерләрне, тупланган тәҗрибәне, ничектер, гомумиләштерергә, тикшеренүләрдә өстенлек ала барган тенденцияләрне ачыкларга, бәяләргә тырышу, безнеңчә, бик вакытлы һәм кирәк эш. Аннары, башка телләрдә, бигрәк тә рус телендә, алып барылган тикшеренүләргә күз салып, уртак мәсьәләләрне — ә алар күп кенә — чагыштырыбрак күзәтү дә бик мөһим.

Сүзне шундый уртак күренешләрнең берсеннән башлыйк та. Соңгы елларга кадәр тәрҗемә буенча тикшеренүләр нигездә әдәбият белеме карамагында булды, аның бер тармагы итеп каралды. Бу бездә дә, руста да шулай иде. Моның дөреслеген раслау өчен шуны әйтү дә җитә: XVII гасырның азагыннан алып 1958 елның 1 январена кадәрге чорны үз эченә алган «Татар тел белеме библиографиясе»ндә тәрҗемә буенча нибары 12 хезмәт күрсәтелсә, 1917—1959 еллар өчен төзелгән «Әдәбият белеме библиографиясе»ндә тәрҗемә буенча 112 хезмәт теркәлгән.

Тәрҗемәне әдәбият белеменең бер тармагы итеп өйрәнүчеләр аның күп кенә мөһим принципларын күрсәттеләр һәм нигезләделәр. Алар, җыеп, гомумиләштереп алганда, түбәндәгеләр: тәрҗемәдә әсәрнең идеясен дөрес бирү; эчтәлек белән форманың диалектик бердәмлеген тәэмин итү;

милли колоритны, авторның индивидуаль стиль үзенчәлекләрен саклау; телнең сафлыгы; формализмга юл куймау һ. б.

Ләкин шундый сорау туа: тәрҗемәне әдәби-эстетик бурычлар җәһәтеннән өйрәнү тәрҗемә теориясе өчен бердәнбер юл була аламы? Һәм, гомумән, аны тагын ниндидер башка (әйтик, лингвистик) юнәлештә өйрәнүнең кирәге бармы? Әгәр булса, бу ике юнәлеш бер-берсе белән нинди бәйләнештә, нинди мөнәсәбәттә торырга тиеш? Бу мәсьәләләр беренче башлап рус матбугатында куелды һәм уңышлы хәл ителде. Монда бигрәк тә А. В. Федоровның (А. Федоров. Введение в теорию перевода.) хезмәте зур. Ул бик дөрес күрсәткәнчә, оригиналь әдәби әсәр иҗат итүдән аерым буларак, тәрҗемә эшендә тема һәм герой эзләү, сюжет-композиция кору кебек бурычлар куелмый. Тәрҗемәче иҗаты өчен бердәнбер һәм төп мәйдан — тел өстендә эшләү. Тәрҗемәче алдына куелган бурыч та тел чаралары белән хәл ителә. Шулай булгач, телдән-телгә тәрҗемә итү өчен генә түгел, ә бәлки бу эшнең теориясе өчен дә лингвистик нигезләрне, телләр арасындагы мөнәсәбәт закончалыкларын белү сорала. Тагын шуны әйтергә кирәк, әдәби юнәлешнең өйрәнү объектын матур әдәбият тәрҗемәләре белән, ә лингвистик юнәлешнекен фәнни, иҗтимагый-политик һәм башка тәрҗемәләр белән чикләргә ярамый. Чөнки, беренчедән, иҗтимагый-политик һәм фәнни сөйләмдә дә әдәби тасвирлау чаралары, күчмә мәгънәле сүзләр еш очрый. Икенчедән, барлык жанрлар, барлык сөйләм төрләре тел белеме (грамматика, лексикология, стилистика) кагыйдәләренә буйсына. Шулай итеп, тәрҗемә эшенең бер яктан, әдәбият белеменә, ә икенче яктан тел белеменә карагалыгы, шуңа күрә тикшеренүләрне дә ике юнәлештә алып барырга кирәклеге ачык аңлашылса кирәк. Дөрес, боларның берсе дә бүген генә уйлап чыгарылган нәрсәләр түгел. Гамәлдә андый ике юнәлеш, ике караш бар иде инде. Тик аларның берсе, әдәби-эстетик юнәлеш, өсенлек алган, ә икенчесе, лингвистик юнәлеш, бәяләп җиткерелми иде...

Татар теленең, әдәбиятының һәм, гомумән, тормышының милли үзенчәлекле үсеш шартлары тәрҗемәчеләр алдына да үзенә аерым башка бурычлар куйды һәм аларны конкрет хәл итүне таләп итте. Революциядән соң, тәрҗемә киң колач алган бер вакытта, халык аңламый торган гарәп-фарсы сүзләреннән арыну һәм алар урынына үз сүзләребезне куллану (үз телебездә эквивалент табу) бурычы куелгач, тәрҗемә эшенең бик авыр хәлдә калганлыгы аңлашыла. Искелектән котылырга кирәклеге ачык, ә яңалык әле урнашмаган. Менә шундый шартларда рус теленнән татар теленә тулы сыйфатлы тәрҗемә итү мөмкинлекләре чикләнгән дип карачылар булды.

Алдан ук искәрмә ясап, шуны әйтергә кирәк, бу мәсьәләдә без тарихи һәм сыйнфый караштан торырга тиешбез. Югыйсә, үз заманында кайбер буржуаз тәнкыйтьчеләр дә «...безнең әдәби телебез юктыр... урам телләре илә Толстойны, Золяны, Гюгоны тәрҗемә итеп булмый», — дип яза торганнар иде. Билгеле, буржуаз тәнкыйтьчеләрнең максаты ачык. Бу «тәнкыйть» — рус буржуазиясенең великодержавный шовинизмына авазадаш нәрсә, татар телен бәяләргә теләмәү. Революциядән соң, тел-әдәбият үсешенең яңа шартларында, әйтик, В. И. Ленин әсәрләрен тәрҗемә итә башлагач та, «бездә сүз җитмәве» турында чыгышлар булды. Ләкин бу бөтенләй икенче нәрсә.

Бу чорда рус теленнән татар теленә тәрҗемә итүчеләр алдында торган кыенлыклар һәм бурычлар, безнең тәрҗемә практикасын гомумиләштергән беренче гыйльми карашлар В. И. Ленин әсәрләрен татар телендә чыгару өчен төзелгән комиссия члennары тарафыннан әйтелде. Комиссия членнары, татар матбугаты, татар теле өчен мондый тәрҗемәләрнең яңарак эш булуын, русчадагы мәгънәләрне әйтеп бирергә бездә «сүз җитмәвен» күрсәтеп, иң элек «атамалар ясау» яки «читтән алу» мәсьәләсен куялар. «Моның аркасында тәрҗемәче тәрҗемәче генә булып кала алмый, бер дәрәҗәгә кадәрле тел төзүче булырга» мәҗбүр, дип язалар алар. Бу бөтен тәрҗемәгә, шул исәптән матур әдәбият тәрҗемәләренә дә, хас бурыч дип исәпләнә.

Комиссия кузгаткан икенче мәсьәлә тәрҗемәнең мәгънәви һәм әдәби төгәллегенә кагыла. Авторлар татар телен «ярлы» дип карасалар да, тәрҗемәдә төп фикерне саклау белән генә чикләнмичә, «шул фикернең аерым тармакларын, аерым төсмерләрен дә бирү» бурычын куялар.

Комиссия членнары язган мәкаләдә шулай ук тәрҗемәнең грамматик ягына кагылган мәсьәләләр дә бар. Аерым алганда, анда болай диелә: «Җөмләләрдәге сүз тәртибе, җөмләнең төзелеше оригиналдагы рәвештә бирелүе шарт кылына. Бу, әлбәт-

тә, төп теләк, ләкин һәммә урында моны тулы көенчә үткәрү мөмкин түгел. Җаена карап, моңардан читенергә туры килгән чаклар да була: байтак урыннарда Ленинның күп катлаулы бер җөмләсе тышкы төзелеш буенча бөтенләй үзгәртелеп, татарча да аңлашылырлык чыксын өчен, бик күп кыска җөмләләргә бүләргә, сүз тезмәләрен алмаштырырга мәҗбүр булына...»

Күрәбез, тәрҗемә мәсьәләләренең куелышында заманга хас чикләнгәнлек («тел төзү», «сүз тәртибен, җөмлә төзелешен оригиналдагыга туры китерү» кебек моментлар) тә бар, хәтта күпмедер дәрәҗәдә формализм ягына авышлык сизелеп тора. Ләкин кабатлап әйтәбез, бу — башлыча мәсьәләләрнең куелышында гына. Аларны практик рәвештә хәл итә башлагач, авторлар нигездә дөрес позициягә күчәләр. Әйтик, «тел төзү», «сүз ясау» болай карағанда ятрак нәрсә, андый эшнең формализмга китерүе дә бик мөмкин. Ләкин комиссия, шуны аңлап, бер яктан, яңалык белән артык мавыкмаска, ә икенче яктан, традициядән бөтенләй аерылмаска кирәклеген күрсәтә. Шулай ук грамматик форма белән эчтәлек арасында мөнәсәбәт дөрес (эчтәлек файдасына) хәл ителә. Мәсәлән, «җөмлә төзелешенең оригиналдагыча бирелүе шарт» диген һәм ике телнең ике системага каравын исәпкә алмый торган положение куелу белән бер үк вакытта, моның гамәлдә барып чыкмавы да раслана.

Революциядән соң, тәрҗемәнең авырлыгы турында күп язылса да, оригиналына тулысынча туры килә торган (адекват) тәрҗемә мәсьәләсе әллә ни зур бәхәс чыгармады. Фикер аерымлыклары, күбесенчә, бу максатка ирешү юлларын — төп принципларны билгеләүдә күренде. «Россиядә профессиональ хәрәкәт тарихы» дигән китапның татарча тәрҗемәсе чыккач, «Безнең юл» журналының 1926 елгы 5—6 саннарында «Тәрҗемәне яхшырту турында» исемле бер рецензия басыла. Авторы — Г. Хәбиб. Ул анда тәрҗемә практикасында кулланылган өч төрле принципны күрсәтә һәм аларның һәрберсенә үзенчә бәя бирә:

«1) Төп язучының аерым-аерым сүзләрен җәяләр эчендә алып, сүзгә-сүз тәрҗемә итү. Тешкә йомшаграк бер сүз чыкса, шул уңайдан файдаланып, битләрчә сүз буткасы пешерү... Бу юл — дини эчтәлекле китапларны тәрҗемә итүдә йөртелә торган ташландык бер юл.

2) Төп оригиналдагы сүзләрнең турыдан-туры лөгать мәгънәләрен саклап, җөмләне җөмләләп тәрҗемә итү. Бу да мактаулы юл түгел, аңлануны авырайта торган юл...

3) Халыкчыл уйлап, шул халыкның сүз сөрешенә, җөмлә төзелешенә туры китереп тәрҗемә итү ...Берничә җөмләне бер генәгә калдырырга; читләтеп әйтелгән сүзләрне турылап, турылап әйтелгән сүзләрне читләтеп әйтергә мөмкин. Монда иң төп язучының әйтергә теләгән нәрсәсен тулы рәвештә бирүне генә күздә тотарга. Минем үземчә, тәрҗемәдә иң туры һәм файдалы юл шушы соңгысы булырга тиеш».

Заманы өчен, һичшиксез, файдалы фикерләр болар. Ләкин бүгенге көндә аларны саф алтын итеп кабул итеп булмый. Беренче пунктта, гомуми контексттан аңлашылуынча, сүз хәзерге фәндә ирекле тәрҗемә дип йөртелә торган алым турында бара. Ләкин автор шушында ук 20 елларның икенче яртысында һәм 30 елларның башындагы аңлатмалы тәрҗемәләрне дә («аерым-аерым сүзләрен җәя эчендә алып») һәм формаль тәрҗемәләрне дә («сүзгә-сүз») характерлый торган төшенчәләр куллана. Икенче пунктта, оригиналның «һәр сүзе каршысына татарчадан бер сүз туры китереп», ягъни сүзне-сүзгә күчерүне, формализмны инкарь итү белән бергә, берминди дәлилсез, җөмләне җөмләгә тәрҗемә итү дә яраксыз дип карала. Өченче пунктта күрсәтелгән юл без хуплый торган адекват тәрҗемәгә якын. Ләкин монда да «берничә җөмләне бергә генә калдырып» тәрҗемә итүне яклап, оригиналның синтаксисын җимерү үзмаксатка әйләндерелә.

Егерменче елларның азагына кадәр бездә иҗтимагый-политик, фәнни-популяр тәрҗемәләр өстенлек алып килгәнлектән, тикшеренүләр дә еш кына шундый (матур әдәбият әсәре булмаган) тәрҗемәләргә нигезләнә торган булды. Әдәби-эстетик проблемалар алгы планда тормаганга, бу төр тәрҗемәләрдә сүз күбрәк тел белеме җирлегендә барды.

Тәрҗемәдә очрый торган төрле-төрле күренешләрне кайсы яклап бәяләргә кирәклекнең ачык булмавы кайбер очракларда бик үк конкрет булмаган нәтиҗәләргә дә китерде. Мәсәлән, язучы Г. Кутуй үзенең «Тәрҗемә әдәбият турында»гы мәкаләсендә[1] тәрҗемәнең төп принципларыннан бер-

[1] X ел эчендә татар матур әдәбияты. Татиздат. Казан. 1930 ел.

сә итеп «тәрҗемәнең оригиналга җавап бирерлек дәрәҗәдә дөрес» булырга тиешлеген күрсәтте. Лакин, билгеле булуынча, тәрҗемәдә «дөреслек» киң мәгънәле төшенчә. Аны безнең бүгенге караш буенча, һич югында, өч яктан бәяләргә була. Беренчедән, төп фикер бирелеше; икенчедән, образ, тойгы, милли колорит күчерелеше; өченчедән, формаль (әйтик, синтаксик) эквивалентлык ягыннан.

Бу «дөреслек» төшенчәсен ачыклау, конкретлаштыру һәм тулыландыруда Ибраһим Газиның хезмәте зур. «Совет әдәбияты» журналының 1936 елгы 3 санында «Тәрҗемә принциплары турында» исеме белән басылган мәкаләсендә ул, мәсәлән, матур әдәбият тәрҗемәсен күздә тотып, болай язды: «Әгәр шигырьнең эчтәлеген дә, форма элементларын да бөтен тулылыгы белән татарчалаштырып булмый икән, шигырьдә беренче чиратта эчтәлек һәм шагыйрьнең социаль йөзен характерлый торган элементлар тулы чагылырга тиеш... Проза тәрҗемәсендә дә шушы ук принциплар нигез итеп алыналар». «Тәрҗемә адекват булырга тиеш дибез,— дип дәвам итә ул.— Адекват дигәч тә, бөтен кире әтерләре дә оригиналдагыча булсын дигән сүз түгел, әлбәттә».

Ибраһим Газиның әдәби тәрҗемәдә адекватлыкны бәяли торган критерийлары түбәндәгечә: мәгълүм бер эпоха өчен характерлы әсәрне тәрҗемә иткәндә шул эпоханы билгели торган бөтен үзенчәлекләр, шул эпохага гына хас моментлар тулы көенчә тәрҗемәгә күчәргә тиеш, шунсыз ул әсәрнең тарихи кыйммәте юкка чыгачак; әсәрнең эчтәлеге, идеясе тулы, дөрес алынырга тиеш; әсәрдәге образлар — типларның мәгънәләрен дөрес аңлап, тулы һәм дөрес гәүдәләндерергә кирәк; заманның лексика үзенчәлеге сакланырга тиеш. И. Гази әсәрдә бу элементларның бер-берсеннән аерым бирелмәвенә, аларны аерым йөртүнең бик шартлылыгына да игътибар итә. «Әсәрнең идеясе образ аркылы һәм шул образны билгели торган художество үзенчәлекләре аркылы бирелә,— ди ул.— образ үзе дә әсәрнең идеясен тулы чагылдыру өчен генә хезмәт итә».

Форма белән эчтәлек арасындагы мөнәсәбәткә дөрес караш булдыру өчен матур әдәбият тәрҗемәләре уңайлы материал булды: эчтәлекнең уртак, ә формаль элементларың, нигездә, һәр тел өчен аерым, үзенчәлекле булуы исбат ителде, лексик, грамматик, стилистик мәсьәләләрнең беркайчан да игътибардан читтә кала алмавы күренде. Тәрҗемә турындагы сүзгә телчеләрнең кушылуы да шуның бер дәлиле инде. «Совет әдәбияты» журналының 1935 елгы 12 санында Л. Җәлəйнең «Сурәтләү чарасы булучылыкта: җөмләләрнең аерымланган кисәкләре» исемле мәкаләсе басылды. Әлеге мәкаләдә автор әдәби-эстетик мәсьәләләр белән лингвистик мәсьәләләрнең тыгыз бәйләнгәнлеген исбат итте. Телнең «реаль аң» булуын киң итеп аңларга һәм «эчтәлекнең тулы чагылуында форманың никадәр роль уйнаганлыгын тирәннән төшенергә, ә моның өчен кайсы гына тел белән эш курсә, шушы телдәге барлык алымнар — типик «норма», «система» хәленә килгән алымнар белән таныш булырга һәм аларны үз урыннарында кулланә белергә кирәк»,— дип язды ул. Шул чорда «чишелми килгән бер момент» итеп, Л. Җәләй «рус телендә чагылган нечкәлекләрне татар теле синтаксисы чаралары аша тулысынча чагылдыру мәсьәләсен» куйды. Ул, сурәтләү чарасы буларак, аерымланган кисәкләрнең ролен, аларның стилистик аерымлыкларын күрсәтте.

Әйтеп үткәнебезчә, тәрҗемәне теоретик өйрәнү практика белән тыгыз бәйләнештә барды. Әйтик, соңгы вакытка кадәр очрый торган иреккле һәм бигрәк тә механик тәрҗемәләр теоретик сөйләшү өчен җитди сәбәп булды. Ибраһим Гази язганча, «ирекле тәрҗемәче, үзенең автор түгеллеген онытып, җөмләләрне, абзацларны төшереп калдыра, кирәк дип тапканда, үзеннән өстәп җибәрә» торган булса, формаль, механик яки сүзгә-сүз тәрҗемә белән мавыгучылар, «татар синтаксисының рус синтаксисыннан принципиаль рәвештә аерылуын белмичә, җөмләнең фикерне аңлату өчен бер форма гына икәнен төшенмичә, оригиналның формасына табыныдылар»[1]. Шушы ук уңай белән С. Фәйзуллин үзенең «Әдәби тәрҗемә һәм тел культурасы» (1951 ел) дигән мәкаләсендә: «Безнең тәрҗемәләрнең төп кимчелеге — телнең грамматик төзелеше белән хисаплашмауда», дип язды[2]. Сүзләрне дөрес тәрҗемә итү белән бергә, ул аларны җөмләләр, фразалар итеп бәйләүдәге авырлыкны, бу эшнең әһәмиятен һәм, нихаять, формализмның менә шунда башлануын күрсәтте. Синтаксиска игътибар җитмәү аркасында, безнең күп кенә тәр-

---

[1] «Совет әдәбияты» журналы, 1952 ел, 4 сан.
[2] «Совет әдәбияты» журналы, 1951 ел, 3 сан.

җемәләр тезек бер бина булудан бигрәк, аерым-аерым кирпечләрнең тәртипсез өеме булып калалар, диде ул.

Шул рәвешчә, соңгы вакытка кадәр диярлек тәрҗемәне өйрәнү, нигездә, әдәбият белеме карамагында калса да, тәрҗемәчеләр, язучылар, әдәбият белгечләре һәм хәтта тел белгечләре үзләре дә, башлыча, тәрҗемәнең әдәби-эстетик мәсьәләләре белән шөгыльләнсәләр дә, әледәнәле аның конкрет лингвистик мәсьәләләрен дә кузгатып тордылар. Тәрҗемә буенча тикшеренүләрдәге лингвистик аспект көчәя, киңәя барды. Тәрҗемәдә форма белән эчтәлек арасындагы гомуми мөнәсәбәтне ачыклау белән бергә, аның конкрет күренешләрен өйрәнүгә игътибар артты. М. Зәкиев «Совет әдәбияты» (1952 ел) журналында басылган «Тынычлыкның ялкынлы көрәшчесе», «Классик әсәрнең тәрҗемәсе» (А. Фадеевның «Тар-мар» романының тәрҗемәсе» турында. 1953 ел һ. б.) кебек мәкаләләрендә «русча җөмләләрне татарчага әйләндергәндә, артык сузып, сүзләр өстәп, мәгънәне сыекландыру», «грамматик формаларны дөрес кулланмау» очракларын күрсәтте. Ул, аерым алганда, конкрет мисаллар белән атрибутив сүз тезмәләренең тәрҗемәсенә тукталды. М. Әмирнең ике телдәге килешләр арасындагы мөнәсәбәткә кагылышлы фикерләре кызыклы. «Тәрҗемә — иҗат эше» дигән мәкаләсендә ул болай яза: «Рус телендә булган алты падеж урынына татар телендә дә алты килеш булса да, русчадагы падежлар бездәге килешләр белән тәңгәл килеп бетмиләр... Русча текстта родительный падежда килгән сүзләрне, баш ватып тормыйча, ның-нең кушымчасы белән, винительный падежда килгән сүзләрне ны-не кушымчалары белән генә тәрҗемә итәргә ашыгу характерындагы ялгышлар бар». С. Әдһәмова «Әдәби тәрҗемә турында берничә сүз» (1953 ел) дигән мәкаләсендә, грамматик терминнар кулланмыйча, үзара «с» союзы белән, творительный падежда бәйләнгән ике исемнең татар телендә бирелешен яктырта [1].

1962 елның көзендә һәм 1963 елның кышында «Социалистик Татарстан» газетасы үткәргән дискуссия рус теленнән татар теленә тәрҗемә принципларының эшләнешенә бер йомгак булды. Күп мәсьәләләр рус һәм татар тел-әдәбият белеме, гомуми тәрҗемә теориясе казанышлары, тел турындагы марксистик-ленинчыл тәгълимат нигезендә уңышлы хәл ителде. Дискуссиянең кайбер нәтиҗәләрен түбәндәгечә йомгаклап була: тәрҗемә объектив процесс, ул катгый закончалыкларга таяна; аны өйрәнүне һәм, гомумән, тәрҗемә теориясен эшләүне я әдәби-эстетик, я лингвистик аспект белән чикләп булмый. Дискуссиядә катнашучылар тәрҗемә эшенең бердәй әһәмиятле өч этаптан торуына игътибар иттеләр: а) оригиналның эчтәлеген, идея-художество үзенчәлеген дөрес аңлау; б) сүз сайлау; монда, контекст, ситуация таләбе белән исәпләшмичә, формализмга, калькаларны чамасыз куллануга, «тәрҗемә жаргоны» тудыруга юл куймау; в) тәрҗемәдә иң авыры — җөмлә төзү; монда ике телнең синтаксик берәмлекләре арасындагы мәгънәви, формаль мөнәсәбәтне күз алдында ачык тотарга кирәк.

Татар матбугатында тәрҗемә турында күп кенә языла. Һәрбер мәкаләдә диярлек аны мөмкин кадәр киңрәк, тулырак бәяләргә омтылыш ясала; бер үк вакытта әдәби-эстетик, стилистик, лексик, грамматик мәсьәләләр куела. Моны, бер яктан, уңай күренеш, предметның катлаулылыгын аңлау, дип карамыйча булмый. Ләкин, икенче яктан, мондый «синтетик мәкаләләрнең» ниндидер гыйльми системага, теоретик бөтенлеккә дәгъва итә алмауларын да әйтергә кирәк. Бу, гамәлдә, фәнни абстракциягә зур әһәмият бирмичә, тәрҗемәне табигый катлаулылыгында берьюлы чагылдырырга тырышу нәтиҗәсе. Әйтик, тәрҗемәче-практик бер үк вакытта лингвистик мәсьәләләрне дә, әдәби иҗат мәсьәләләрен дә хәл итә: сүз сайлый, аларны үзара бәйли, җөмлә төзи; эмоциональ оттенокларны, образ элементларын телдән-телгә күчерә. Ул боларның бөтенесен берьюлы эшли, аның өчен боларны аеруга мохтаҗлык юк. Ә теориядә эш башкача: предметның теге яки бу ягына игътибарны көчәйтү, аны башкалардан аеру юлы белән генә гыйльми тулылыкка, объективлыкка ирешергә мөмкин. Бу юлда зур адым ясаучыларның беренчесе С. Фәйзуллин булды. Ул үзенең «Ике тел хәзинәсе» дигән хезмәтендә, тәрҗемә мәсьәләләрен лингвистик планда куеп, аның төп принципларын һәм кайбер аерым мәсьәләләрен яктыртты.

Китапта «Алынмалар», «Сүз һәм аның мәгънә күләме турында» кебек тәрҗемәнең лексика өлкәсенә караган бүлекләр бар. Бер бүлек («Тезмә — җөмлә — кон-

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1958 ел. 5 сан.

текст») грамматик мәсьәләләргә багышланган. «Тәрҗемәче аерым сүзләрне түгел, бәлки җөмләләрне тәрҗемә итә. Җөмлә контекст эчендә тәрҗемә ителә. Тәрҗемәнең дөрес булуы өчен һәр аерым җөмләнең үзалдына дөрес булуы гына җитми, җөмләләрнең үзара бәйләнешен дә дөрес бирергә кирәк»,— дип яза С. Фәйзуллин. Шул рәвешчә, һәрбер синтаксик берәмлекне башкалары белән тыгыз бердәмлектә карап, ул сүз тезмәсендә сүзләрнең бәйләнеше, урыны, тәрҗемәдә ия белән хәбәр, кайбер иярчен җөмләләрнең, әйләнмәләрнең бирелеше һ. б. мәсьәләгә ачыклык кертте. «Дөрес булсын, матур булсын» дигән бүлектә тәҗрибәле тәрҗемәченең стиль мәсьәләләренә карашы чагылган. Матбугатта бәяләнгәнчә, С. Фәйзуллинның бу китабы тәрҗемә теориясе тарихында зур әһәмиятле хезмәт булды. Безнең фикеребезчә, хәзер татар тел-әдәбият фәнендә тәрҗемә теориясенең гомуми контурлары сызылды. Инде аның конкрет тармакларын җентекләү башланыр дип көтәргә кирәк.

Шуны әйтмичә булмый, тәрҗемә буенча тикшеренүләрнең әһәмияте тәрҗемәче-практиклар өчен фәнни юл күрсәтү белән чикләнми. Аның әдәби-эстетик аспектын алганда, ул әдәби-эстетик категорияләрнең телара мөнәсәбәтен ачыклап, ахыр чиктә, халыкларның тел-әдәбият иҗатын якынайтуга, милли культураларны якынайтуга хезмәт итә. Ә инде тәрҗемәне лингвистик аспектта өйрәнүгә килгәндә, ул телләрнең уртак һәм аерым үзенчәлекләрен күрү өчен әһәмиятле һәм үз телебезне, башкалар белән чагыштырып, тулырак һәм дөресрәк аңларга ярдәм итә. Менә шуңа күрә тәрҗемәне теоретик өйрәнү юнәлешләре, аның тарихи үсеш тенденцияләре бик мөһим, кызыклы проблема булып тора.

# ХЫЯЛ ДӨНЬЯСЫНДА

Әллә фантастика яратучылар күбәйде, әллә инде фантаст язучылар ишәйде, соңгы дәверләр дөнья әдәбиятында фантастика жанры торган саен киңрәк мәйданнар яулый. Кайчандыр бөек фантаст Жюль Верннык хыялында гына туган «наутилус» хәзер океан төпләрен айкый. Циолковский хыялы тудырган кораблар галәм киңлекләрен гизә. Бер карасаң, хәзер тормышта хыялга урын да юк сыман. Азимов, Ефремов, Стругацкийлар кебек бүгенге көн фантастлары үзләренең берсеннән-берсе кызыклырак әсәрләре белән безне катлаулы рухи кичерешләр, тирән фәлсәфи фикерләр өлкәсенә алып керәләр.

Ә менә үзебезнең татар әдәбиятында фантастика жанры булганмы? Шушы популяр жанрда эшләүчеләр кемнәр алар? Юк һәм бөтенләй булмаган дисәк, дөрес үк булмас. Классик язучыларыбызның «Сәмруг кош», «Гарәфә кич төшемдә», «Фәтхулла хәзрәт», «Рөстәм мажаралары» кебек әсәрләр фантастика жанрының гүзәл үрнәкләре белән бер рәттә торырлык. Әмма бүгенге язучыларыбыз арасыннан, бер-ике авторның Айга, галәмгә очу турындагы сәхнә әсәрен һәм хикәясен, шулай ук М. Харисовның «Фаҗигале планетага сәяхәт» исемле повестен исәпләмәгәндә, бу өлкәдә актив эшләүчеләр күренми диярлек. Әйе, юк дәрәҗәсендә аз бездә фантастлар! Шулай да, үзебезнең арада яшәп, тырышып эшләп ятучы бердәнбер фантаст язучыбыз бар. Ул — Адлер Тимергалин.

1960 елда аның «Пәһлеван кабере», 1965 елда «Ике хикәя, бер хыял», 1967 елда «Ерак планетада» исемле китаплары чыккан иде һәм менә күптән түгел генә «Мәңгелек хатирәләр»[1] исемле яңа җыентыгы дөнья күрде.

«Мәңгелек хатирәләр» повестен «Яшь ленинчы» газетасында басылган чагында ук белә идем. Китаптан тагын бер кат укыдым һәм үкенмәдем.

«— Алло! Синме, Гаяз? Сәлам!

— Юк,— дидем мин, Нуровны танып алгач, һәм тавышымны үзгәрткән булдым.— Юк, Гаяз әле генә эш белән чыгып китте. Тиз генә кайтмастыр...

— Шаяртма, туган! Тыңла әле...

— Ярый, тыңлыйм... Сәлам,— дидем мин, котылыр әмәл юклыгын аңлагач.— Әйдә, тасма телеңне эшкә җик. Сибә башла...

— Гаяз, синең унбиш көн вакытың булырмы? Әйтик, берсекөннән үк бушый алырсыңмы?

Мин былтыр да, Нуров сүзен тыңлап, атна-ун көн ялымның үтеп киткәнен сизми дә калган идем, шуны искә төшереп:

— Буш вакытым юк, инженер,— дип җавап бирдем...— Беренчедән, аспирантымның диссертация яклыйсы бар...

Телефонда көлүгә охшаш тавыш ишетелде.

— Икенчедән, чираттагы конференциягә әзерләнергә кирәк. Өченчедән...

— Гаяз, борчак сипмә! Беренчедән, аспирантың яклаган инде. Мин белештем. Шулаймы?

— Шулай дип... бик үк алай түгел...

— Икенчедән, конференция дигәне кыш көне буласы. Шулаймы?

— Шулай, инженер, шулай хәерсез! — дидем мин ачу белән.— Шулай, шымчы!..

— Өченчедән, килештек!..

Телефон трубкасы шарт-шорт итте. Мәсьәлә хәл ителде.

Димәк, унбиш минуттан монда Нуров абзаң үзе килеп җитәчәк дигән сүз иде бу».

Повесть әнә шулай җиңел һәм мавыктыргыч төстә башланып китә. Вакыйгалар, хыяллар дулкыны сине бөтереп ала да әсәрнең соңгы битенә кадәр ычкындырмый тота. Балалар өчен генә түгел, өлкәннәр тарафыннан да рәхәтләнеп укырлык повесть ул.

Кайчандыр Җиргә космик кунаклар килгән булган. Һәм алар безгә, Җир кешеләренә, зур бүләк калдырганнар. Ләкин бүләкне мәгарә эченә, бернинди шартлаткыч белән дә җимереп булмый торган калын стена артына яшереп киткәннәр. Чөнки җирдә әле сугышлар бара. Кешелек әле мәкерне, явызлыкны йөгәнләп җиткермәгән. Әгәр космик кунаклар калдырган өлеге бүләк явызлар кулына төшсә, Җирне фаҗигага китә. «Мәңгелек хатирәләр» повестендагы инженер Нуров белән Гаяз менә шул серне чишәләр.

Повестьнең эчтәлеген болай кыска-кыска һәм өстән генә сөйләгәч, кайберәүләрнең аны сугышка каршы язылган әсәр дип уйлаулары мөмкин. Ләкин авторның төп максаты мәгарәгә яшерелгән космик сер тирәсендә барган мажаралар турында сөйләү түгел. Монда сүз хәтер турында бара. Автор кеше хәтеренең мөмкинчелекләре, хәтернең нәселдән нәселгә күчүе, хәтер аша мәгълүматларның буыннан-буынга тапшырылу ихтималы турында кызыклы әсәр язган.

[1] А. Тимергалин. Мәңгелек хатирәләр. Казан. 1969 ел.

Повестьның төп геройларыннан Нуров образын автор аз сүзләр һәм отышлы сурәтләү чаралары ярдәмендә җанлы, тулы итеп күрсәткән. Безнең алда үткен сүзле, җитез, кызу табигатьле яшь галим. Вакытывакыты белән бала-чага сыман беркатлы, шаян булуы белән ул мәхәббәт казана. Һәм повестьны укып бетергәч тә, бу күңелле, хыялый галим белән аерылышасы килми.

Күрәсең, автор моны күңеле белән үзе дә сизгәндер. Без Нуров белән тагын берничә хикәядә очрашабыз. Дөрес, ул хикәяләр әлеге повестьның дәвамы түгел. Алар мөстәкыйль әсәрләр.

Адлер Тимергалин укучының игътибарын коры маҗаралар белән генә җәлеп итәргә җыенмый. Ул гаять кызыклы, галимнәр пәрә-пәрә килеп бәхәсләшә торган проблемаларны алып, аларны үзенчә чишә.

Галәм чиксез. Анда өзлексез хәрәкәт, утлы гарасатлар бара, фән аңлатып бирә алмаслык серләр тулып ята. Космоста кеше акылына бәйләнмәгән фаҗигаләр мизгел саен кабатланып тора. Галактикаларның чәчелүе, җыелуы, җисемнәрнең туңуы яки шартлавы аркасында нинди генә җәмгыятьләр юкка чыкмый торгандыр! «Космик кыш килгәндә» хикәясендә Адлер кызыклы, мавыктыргыч итеп, менә шул хакта сөйли. Хикәядә сурәтләнгән галимнәр шул җимерелүләргә, гарасатларга каршы тора алырлык яңа матдә уйлап табалар. Кешелекне алда гарасатлар, бәхетсезлек көтми, кешелек фаҗигагә таба бармый. Әгәр фаҗига кешелеккә таба үзе килә икән, кешеләр аны җиңәргә әзер булырга тиеш! Әсәрнең төп идеясе әнә шул.

Адлер юморист та. Җор тел белән язылган, көлкеле хикәяләр бу китапта байтак. «Сынау», «Узыш», «Кибернетик кәмит», «Угры», «Тәмугта бер көн»...

Соңгы хикәядән бер фрагмент китерик. Лирик герой теге дөньяга китә... Һәм ул анда зур шәхесләр белән очраша:

— Сез кем буласыз соң? — дип сорадым мин аңардан.

— Мин ерырак гасырдан, унберенчедән үк,— дип җавап бирде ул, каләмен колак артына кыстырып,— Гомәр Хәйям дигән гонаһкярмын. Ишеткәнең бар идеме?

— Бар, әлбәттә! Без сезнең шигырьләрне бик яратып укыйбыз. Ничек әле:

Адәмнәрне җанлы итеп ясадың син,
Инде аны үтереп-җимереп ятасың син:
Бу ижатың начар булса, кем гаепле?
Яхшы булса, нигә аны ватасың син?!

— Менә шушы сөальләрем коткарды да инде мине,— диде Гомәр Хәйям, көлеп.— Югыйсә үземне, мөнда тотмыйча, турыдан-туры җәһәннәмгә озатачаклар иде.

— Ничек?

— Тәңре менә ничәмә-ничә гасырлар инде җавап эзли, әмма тапмый... Безнең мөнда үз кагыйдәләребез бар. Логиклар җәмгыятенә мөрәҗәгать итәрбез, анда без алланы төп башына утырта торган сораулар әзерләүче акыл ияләрен сайлап куйдык. Ялгышмасам, кайсыдыр: «Үзең күтәрә алмаслык таш ясый аласыңмы?» дип аллаһы тәгаләне кәкре каенга терәткән иде. Менә шушындый баш катыргыч сораулар кирәк... Сезнең чорның да шуңа охшаган берәр җәүһәре юкмы соң?

— Бар! — дидем мин, куанып.— Бар, Гомәр бабай!

— Яле, я, тыңлап карыйк,— диде шагыйрь.

— Аллаһы тәгаләнең кодрәте шулхәтле киң, аның табигатьтә булмаска да кулыннан килә...

Җыентыктагы хикәяләр бер-берләреннән нык аерылсалар да, аларның сюжет, тема корылышлары төрлесеннән төрлечә булса да, Адлерның барлык хикәяләре өчен дә хас уртак яклар да бар. Барыннан да элек аларны проблемалар уртаклыгы берләштерә. Аның күпчелек хикәяләрендә кеше һәм табигать көчләре арасындагы мөнәсәбәт сурәтләнә. Автор кешеләрнең табигать көчләреннән өстен булуларын күрсәтә. Шуның белән бергә, Адлер бүгенге көнкүреш мәсьәләләреннән дә ерак китми.

«Малай» хикәясе, мәсәлән, хыялга корылган булса да, бүгенге көн өчен мөһим булган мәсьәләне кузгата.

Бәләкәй генә бер малай фикер йөртүе, белеме белән үз яшьтәшләрен генә түгел, хәтта укытучысын да узып китә. Шахмат тактасына карамыйча әтисен ота. Кинокитапларның башын белү белән азагы ничек бетәчәген алдан ук әйтеп бирә. Хәтта кайсы футбол командаларының отасын, кайсыларының оттырасын да алдан белеп тора. Яшьтәшләре дә, олылар да аның гадәти малай түгеллеген беләләр һәм аңа кырын карый башлыйлар, сәер бала итеп күрәләр. Һәм аны врач дәвалый башлый. Янәсе, аның нервлары какшаган. Нәтиҗәдә ул яшьтәшләре сыман гап-гади бала булып кала. Укуы да хәрти генә. Башкалар сыман сугыша да башлаган. Шулай уртача гына бер кеше булып китә бу.

«Ә психиатор, еш кына, баланы ныклап тикшермәгәнлегенә үкенеп: «Мин феномен яныннан узып китмәдемме икән?» — дип уйлый. Мин дә аның фикеренә кушылам»,— дип тәмамлана хикәя.

Биредә фантазиядән бигрәк, чып-чын проблема, бүгенге көннең актуаль мәсьәләсе кузгатылган. Адлер тормыштагы мөһим проблеманы тотып алган да әдәби әсәр язган. Монда инде, әйткәнемчә, хыялдан битәр, тормыш бимазалары чагылган.

«Мәңгелек хатирәләр» китабы бер Тимергалинның гына түгел, ә 1969 елгы әдәбиятыбызның да уңышлы әсәрләреннән.

А. Тимергалин дүрт китап авторы. Бердәнбер фантаст һәм аның исеме, китаплары бүгенге көнгә кадәр телгә алынмавын тәнкыйтьче дусларның игътибарсызлыгы дип аңларга кирәктер! Форсаттан файдаланып, шуны да әйтергә кирәк, аның бу китабындагы күп кенә хикәяләре вакытлы матбугат битләрендә чыгарга тулы хокуклылар. «Аш төрләндерү өчен» генә түгел, газета-журнал битләрен бизәп торырлыклары да күп. Һәм алар, һичшиксез, үз укучыларын тапкан булырлар иде.

РОБЕРТ БАТУЛЛИН.

# ТУГАН ЯГЫБЫЗНЫҢ ЕРАК ҮТКӘНЕ

Мәскәүнең «Наука» нәшриятында тарих фәннәре докторы, профессор Альфред Халиковның «Урта Иделнең борынгы тарихы» дигән монографиясе басылып чыкты. 25 табак күләмендәге бу калын китап безнең якларда яшәгән халыкларның борынгы тимер чорына кадәр булган тарихын тикшерүгә багышланган. Моңа кадәр фән безнең төбәкнең ул чоры турында бик аз белә иде. Бу хезмәтнең матбугатта басылып чыгуы, егерме ел буена төрле экспедицияләрдә катнашып, автор тарафыннан кирәк кадәр фәнни материал тупланганнан соң гына мөмкин булды. Аннан соң китапта шактый күп санлы музей коллекцияләре, моңарчы язылган әдәбият, шулай ук этнография, лингвистика, палеоботаника, палеозоология, геология һәм бу тема естендә эшләүгә азмы-күпме катнашы булган башка фәннәр тарафыннан тупланган материал файдаланылган. Автор үзенең монографиясендә Идел буе халыклары формалашуының башлангыч процессларын эзлекле күзәтүне төп максат итеп куйган. Әлеге хезмәтендә ул Урта Идел территориясендә кешеләр урта палеолит чорында, ягъни моннан 50 мең еллар чамасы элек килеп чыккан дип билгели. Дөрес, ул чорга караган тарихи табылдыклар артык күп түгел, ләкин табылган кадәресе турында археологларның күпчелеге уртак фикердә. Безнең төбәктә мезолит, икенче сүзләр белән әйткәндә, урта таш дәвереннән (безнең эрага кадәр 8—5 меңенче еллар) калган табылдыклар күбрәк. Бу чорда җәя һәм ук кулланыла башлый. Сүз уңаенда шуны да әйтеп үтәргә кирәк, бу чорда кораллар һәм көнкүреш кирәк-яраклары ясау өчен чакматаш төп чимал булып хезмәт иткән. Урыннарда казулар алып барганда, пычакка охшашлы әйберләргә, пәкеләр һәм башка төрле предметларга тап буласың. А. Халиков урта таш дәвер чорына караган табылдыкларга төпле анализ ясый, аларның периодларын һәм даталарын билгели.

Китапның яңа таш гасыр турындагы бүлекләре дә укучыда зур кызыксыну уята. Бу чор ташны эшкәртүнең яңа ысуллары киң таралу белән характерлана. Хәзерге көндә Урта Идел буенда бу чордан калган 250 дән артык әйбер табылды. Аларның күбесе хәзерге Татарстан территориясенә туры килә. Китапта чакматаштан эшләнгән әйберләргә (пәкеләр, балталар, уклар, өтергеләр) һәм яңа таш гасырда кулланууда булган балчык савытларга тулы анализ ясала. Автор ул савытларга гаҗәеп матур бизәкләр төшерелгән булуын әйтә.

А. Халиков тарафыннан тупланган материаллар яңа таш гасыр чорында кешеләрнең нигездә балык тоту һәм аучылык белән шөгыльләнүләре турында фикер йөртергә тулы нигез бирә. Тормыш-көнкүрештәге бу үсеш утрак тормышка күчүне якынайта. Яңа таш чоры казылмаларында еш кына җир өй урыннары очрый. Экспедицияләрдә тупланган материалга ясалган анализ яңа таш чорында Урта Идел буенда яшәүче халыкларга югары Идел һәм Урал буенда яшәүчеләрнең йогынтысы булуын раслый.

Китапның металл чорына багышланган бүлекләре дә зур кызыксыну белән укыла. Безнең эрага кадәр 3 меңенче елның икенче яртысында безнең якта яшәүчеләр беренче мәртәбә металл әйберләр һәм аларны ясау ысуллары белән танышалар. Ләкин шулай да корал һәм хезмәт кирәк-яраклары хәзерләүдә төп материал буларак таш кулланыла. Халиков үзенең бу хезмәтендә бронза чорында Урта Идел буенда яшәгән халыкның составы үзгәрүгә дә игътибар итә.

Безнең эрага кадәр 2 меңенче елда терлекчелек белән көн күрүче халыклар, явымтөшемнең кимүе сәбәпле, төньяктагырак районнарга күченәләр. Күчеп килүчеләр бу төбәктәге халыкны бәлки терлекчелек һөнәре, шулай ук металл әйберләр ясауның прогрессиврак ысуллары белән таныштырганнардыр. Ләкин алар җирле халыкның үзенә хас юл белән үсешенә комачаулык итмиләр.

Бронза чорында яшәгән җирле халыкларны археологлар Казан тирәсе культурасына кертәләр һәм аларны күп санлы каберлекләр буенча өйрәнәләр. Археологларга Ананьина иселе белән билгеле булган культураны шул халыклар калдыралар. Ананьина авылы Татарстан АССРның хәзерге Алабуга районы территориясендә урнашкан булган. Ананьина культурасы ыруглары угро-финнарның: мариларның, удмуртларның һәм комиларның борынгы бабалары булып исәпләнә.

Китапның соңгы бүлекләрендә автор укучыны Урта Идел буенда яшәгән халыкларның тормыш-көнкүреше һәм үзара мөнәсәбәтләре белән таныштыра.

Китап бик бай иллюстрациядә чыккан. Ул тарихчылар, студентлар һәм туган якны өйрәнүчеләр өчен ифрат файдалы хезмәт булачак.

Автор безне якын киләчәктә үзенең яңа кызыклы хезмәте — туган ягыбызның икенче чордагы тарихы, шул җөмләдән, Идел болгарлары һәм Казан татарлары тарихы белән таныштырыр дип ышанабыз.

**П. Н. СТАРОСТИН,**
**археолог, тарих фәннәре кандидаты.**

# БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**Әдип һәм галим.**
**КОЛЛЕКТИВ ҖЫЕНТЫК. Казан. 1969 ел**

Мәгълүм булганча, узган елның декабрь аенда талантлы драматург һәм шагыйребез, күренекле әдәбият галиме һәм фольклорчыбыз, Татарстанның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты Нәкый ага Исәнбәткә 70 яшь тулды. Танылган әдипнең иҗат бәйрәмен республикабыз җәмәгатьчелеге гаять тантаналы шартларда, зурлап билгеләп үтте. Алдыбыздагы коллектив җыентык та әнә шул вакыйга уңае белән чыгарылган. «Әдип һәм галим» дип исемләнгән бу китапка Нәкый аганың тормыш һәм иҗат юлына багышланган мәкаләләр, күренекле шагыйрьләребезнең аның хакындагы шигырьләре тупланган. Андагы һәр материалдан Нәкый Исәнбәтнең иҗатын ихтирам итү һәм зурлау, аның үзенә һәм хезмәтләренә тирән хөрмәт белән карау сизелеп тора. Аларның барысына да хас төп сыйфат әнә шул.

Җыентык филология фәннәре докторы, профессор Мөхәммәт Гайнуллинның «Олы каләмдәшебез турында» дигән җыйнак кына мәкаләсе белән ачыла. Мәкаләдә Н. Исәнбәтнең күп кырлы иҗат эшчәнлегенә гомуми күзәтү ясала, аның мәдәниятебез үсешенә зур казаныш булып кергән хезмәтләренә югары бәя бирелә. М. Гайнуллин башлаган сүзне Ә. Фәйзи, С. Хәким, М. Кәрим, А. Шамовлар дәвам итә — кем шигырь, кем ихлас күңелдән әйтелгән җылы сүз белән.

Җыентыкның йөзен билгеләп торган фәнни мәкаләләр арасыннан филология фәннәре кандидаты Фатих Урманчеевның «Исәнбәт һәм татар халык иҗаты» исемле хезмәте аеруча уңай тәэсир калдыра. Исеменнән үк күренгәнчә, ул Нәкый аганың фольклор фәненә керткән казанышларын ачыклауга багышланган. Ф. Урманчеев халык авыз иҗатының һәр тармагында (балалар фольклоры, табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр, мифләр һ. б.) Н. Исәнбәт башкарган эшләрне санап чыга, беләп һәм фәнни тирән итеп, аның бу өлкәдәге бөтен эшчәнлеген тикшерә.

Филология фәннәре кандидаты Фоат Ганиевның «Әдипнең татар тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеге» дип исемләнгән мәкаләсе дә нигездә әйбәт язылган. Ул Нәкый аганың тел белеменә караган барлык хезмәтләре белән таныштырып чыга, аларга шактый тулы һәм төпле анализ ясый.

Н. Исәнбәт үткен комедияләр, тирән дулкынландырырлык драмалар, җанны тетрәтерлек трагедияләр авторы да. Драматургның трагедия жанрындагы әсәрләре турында Һәнүз Мәхмүтовның «Нәкый Исәнбәт трагедияләре» дигән мәкаләсендә сөйләнә. Мәкалә авторы Н. Исәнбәтнең «Спартак», «Мәрьям», «Муса Җәлил» кебек трагедияләрен тикшерә, драматургның бу өлкәдәге эшчәнлегенә гомуми күзәтү ясый.

Ахырдан Гөлсем Исәнбәт һәм Әбрар Кәримуллиннар тарафыннан бик этрафлы һәм тулы итеп эшләнгән библиографик белешмә бирелгән. Җыентыкны филология фәннәре кандидаты Хәсән Гобәйдуллин төзегән, редакторы шагыйрь Мәхмүт Хөсәен.

**В. МАНАСЫПОВ. Не хочу быть Наполеоном. Рус телендә. Хикәяләр һәм фельетоннар. Мәскәү. 1969 ел**

Сатира һәм юмор әдәбияты белән кызыксынып барган укучыларга Вахит Монасыйпов исеме таныш булырга тиеш. Ул әдәбиятның шул өлкәсендә аеруча күп һәм нәтиҗәле эшләп килүче язучыларыбызның берсе. Үзе эшләгән «Чаян» журналында һәм республикабызның башка газета-журналларында әледән-әле аның хикәя, фельетоннары басылып килә, Татарстан китап нәшриятында җыентыклары чыгып тора.

1969 ел ахырында исә Вахит Монасыйпов әсәрләрен, 225 000 данә тираж белән, Мәскәүнең «Правда» нәшрияты аерым китап итеп чыгарды. «Крокодил китапханәсе» сериясендә чыккан бу җыентыкка язучының өч дистәдән артык хикәясе һәм фельетоны кергән. Үзенең ул әсәрләрендә В. Монасыйпов безнең тормышта очраган аерым кимчелек һәм җитешсезлекләрне тәнкыйтьли, кешеләр арасындагы начар гадәтләрдән көлә. Бюрократлар һәм ялагайлар, күз буяучылар һәм дәүләт милкен әрәм-шәрәм итүчеләр, һәртөрле принципсыз һәм мәнсез адәм имгәкләре аның геройлары. Кеше күзенә ташланмыйчарак, качып-посып яшәргә яраткан әнә шул адәм актыкларын язучы көн яктысына тартып чыгара, аларның битлекләрен ертып ташлап, хурлык баганасына тери.

Тема-проблемалары һәм геройлары төрле-төрле булган кебек, китаптагы әсәрләрнең әдәби кыйммәте дә төрлесенеке төрле дәрәҗәдә. Арада шактый тапталган һәм кабатланган күренешләргә багышланганнары бар. Бүгенге көн күзлегеннән карaганда, аерым хикәя һәм фельетонларының актуальлеге, оригинальлеге кими төшкән. Кайбер әсәрләрендә автор тормыштагы яңь-

сез күренешләрне, кешеләр арасындагы начар гадәтләрне коры теркәү, кәгазьгә төшерү белән генә чикләнә. Таркаурак язылганнары, төп фикере һәм идеясе аңлашылып бетмәгәннәре дә очрый. Әмма ни генә булмасын, эшләнеп бетмәгән, кимчелекле әсәрләр никадәр генә очрамасын, җыентыктагы күпчелек хикәя һәм фельетоннар чын мәгънәсендә әдәби әсәр дәрәҗәсенә күтәрелгән. Арадан «Наполеон булырга теләмим», «Юбилярның сәламәтлеге өчен», «Эссе июнь», «Тәртип урнаштырды», «Яулык», «Коткаручы», «Тарихи козгын» кебекләре аеруча уңай тәэсир калдыра. Үзенең иң уңышлы әсәрләрендә Вахит Монасыйпов конкрет тормыш фактларыннан зур гомумиләштерүләр ясауга, кешеләр арасындагы начар гадәтләрне типиклаштырып, әдәби типлар иҗат итү дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Һәм җыентыкның йөзен нәкъ менә шул уңышлы хикәя һәм фельетоннар билгеләп дә.

**Ф. МАНСУРОВ. Хәерле юл. Повесть һәм хикәяләр. Казан. 1969 ел**

Яшь прозаик Фәнил Мансуров әдәби иҗат юлындагы тәүге адымнарын тугандаш Башкортстан туфрагында атлый. «Хәерле юл» аның Казанга күчеп килгәч чыгарган беренче җыентыгы. Китапка язучының «Хәерле юл» исемле повесте һәм 4—5 хикәясе кертелгән.

Ф. Мансуровның бу җыентыктагы барлык әсәрләре диярлек кырыс табигатьле Себер, андагы кешеләр, аларның тормышлары турында. Үзенең повесть һәм хикәяләрендә ул андагы бай нефть ятмаларын үзләштерүче кыю йөрәкле кешеләргә дан җырлый, тайга урманнарына нефть промышленносте алып килгән үзгәреш-яңарышларны сурәтли. «Хәерле юл» шул темага багышланган әсәрләрнең иң житди һәм күләмлесе. Кырыс тайга шартларында эшләүче нефть промышленносте эшчеләре турындагы бу повестьның күп өлешен Идел буе егете Сабир белән Себер кызы Бибинур арасындагы мәхәббәт хисләрен, аларның үзара мөнәсәбәтләрен тасвирлаган битләр алып тора. Ышандырып житкермәгән аерым урыннары булуга да карамастан, әсәрнең ул урыннары болай ярыйсы гына тәэсир калдыра.

Әлеге повестенда булсын, хикәяләрендә булсын, Ф. Мансуров очсыз-кырыйсыз тайга урманнарын, аларның кырыс һәм мәһабәт матурлыгын сурәтләүгә күп урын бирә. Дөресен әйтергә кирәк, тайга урманнарын, андагы кош-кортларны, җәнлекләрне, аларның гадәтләрен һәм кыланышларын ул шактый белеп, яратып тасвирлый. Аның әсәрләрен укыганда шул яклардагы табигатьнең күркәм матурлыгын, үзгә бер сулышын тойгандай буласың. Гомумән, табигать күренешләре, җәнлекләр һәм хайваннар турында язу авторга җиңелрәк бирелә шикелле. Җыентыктагы «Тайга законы» дип исемләнгән хикәяне укыганнан соң моңа тагын бер кабат ышанасың. Сильна исемле манси кызының беренче мәхәббәт һәм яшьлек хисләрен сурәтләүгә багышланган «Болан мөгезе» исемле хикәя дә җылы гына тәэсир калдыра.

Ф. Мансуров үз әсәрләренең телен эшкәртүгә житди караган. Аның повесте да, хикәяләре дә төзек, җиңел әдәби тел белән язылган.

Әбрар Кәримуллин

# ТОРМЫШКА АШМАГАН ПРОЕКТЛАР

*Татарча газета-журналлар чыгару өчен көрәш сәхифәләреннән*

Россиядәге төрки халыклар арасында китап басу эшенә иң башлап Идел буе татарлары (1800), аннары әзербәйҗаннар керештеләр (1831). Газета-журнал чыгару эшен башлап җибәрү исә әзербәйҗаннар өлешенә туры килде: 1875 нче елның 22 июлендә Баку шәһәрендә Хәсәнбәк Мәликов тарафыннан оештырылган «Игенче» исемендәге газетаның беренче саны дөньяга чыкты. Татар телендә вакытлы матбугат 1905 елгы рус буржуаз-демократик революциясе нәтиҗәсендә генә барлыкка килде.

Матбагачылык эшенә шулай алдан керешүләренә карамастан, татарча газета һәм журналлар ни өчен бик соңга калып чыкты соң?

Кайбер басма чыганаклар һәм бигрәк тә моңа кадәр билгеле булмаган архив материаллары бу сорауга җавап табарга ярдәм итәләр.

## *Иван Запольский проекты*

Татар телендә газета чыгару мәсьәләсе беренче тапкыр 1808 елда ук көн тәртибенә куелган булган. ТАССР Үзәк дәүләт архивында саклана торган бу документларга заманында Казан университетының тарихын язган профессор Н. П. Загоскин да кагылып үткән [1]. Аннан соң бу факт татар әдәбияты тарихы буенча хезмәтләрдә дә искә алынып килә, әмма татарча газета чыгару проектының ни өчен тормышка ашмый калуы турында берни дә әйтелгәне юк әле.

Казан университетын патша хөкүмәте үзенең колониаль изү политикасын үткәрү, аллавытлар властен ныгыту өчен ышанычлы кадрлар хәзерләү максаты белән ачкан иде. Университетның прогрессив карашлы рус галимнәре хөкүмәт куйган рамкаларда гына калырга теләмәгән, фән, культураны алга җибәрү, җирле халыкларның мәгърифәтен үстерү өчен дә көрәшкән. Әнә шундыйларның берсе физика-математика профессоры Иван Ипатович Запольский булган.

Ул 1808 елда гимназия директоры һәм университет ректоры вазифаларын үтәүче профессор И. Ф. Яковкинга Казанда университет каршында рус һәм татар телләрендә «Казан хәбәрләре» исеме белән газета чыгарырга теләге булуын белдерә һәм аңа

---

[1] Н. П. Загоскин. История имп. Казанского университета... том II. Казань. 1903 год. Рус телендә. 285—286 битләр.

шушы газетаның проектын төзеп бирә. Яковкин Запольскийның бу проектын кабул күреп ала һәм аны Казан уку округы попечителе Румовскийга тапшыра. Румовский, университет каршында газета чыгару югары начальствога, ягъни Мәгариф һәм Эчке эшләр министрлыгы түрәләренә ошамас дип куркып, бу тәкъдимне кире кага. Попечительнең риза булмавын белгәннән соң да Запольский аптырап калмый, Казан гражданский губернаторы Б. А. Мансуровка мөрәҗәгать итеп карый. Губернатор бу тәкъдимне хуплап каршы ала. 1808 елның 22 декабрендә, Казанда рус һәм татар телләрендә газета чыгарырга рөхсәт сорап, Эчке эшләр министры А. Б. Куракинга зур хат яза. Мансуров үзенең Куракинга язган хатында Казанда бу газеталарны чыгарырга яныл йөрүче кадрлар да, полиграфия мөмкинлекләре дә булуын әйтә. Казанда цензура булуы да газетаны чыгару эшен җиңеләйтәчәген, аны чыгару буенча эшләячәк кешеләр өстеннән үзенең җитәкчелек итәчәген, алар өчен үзе җавап бирәчәген ышандыра.

Бу мәсьәләне үзе генә дә хәл итәргә хакы булуга карамастан, Куракин халык мәгарифе министры Разумовский белән киңәшергә кирәк таба. Соңгысы исә бу турыда яңадан попечительгә мөрәҗәгать итә, аның фикерен сорый. Куракинга язган җавабында, попечитель Румовский сүзләренә таянып, Разумовский газетаның татар телендә басылуына каршы фикер белән чыга һәм моны университет типографиясендә гарәп шрифтлары аз булу белән аңлатырга тырыша.

Башта ук Запольский проектына каршы чыккан Румовский, аның губернаторга мөрәҗәгать итүенә һәм газета чыгару мәсьәләсенең башкалага ук җитүенә ачуы килеп, Казанда газета чыгарырга рөхсәт биргән очракта да бу эшкә Запольскийны катнаштырмаска дип яза. Ул моны Запольскийның университетта эшләве белән аңлатырга тырыша.

Куракиннан шушы җавапны алган Мансуров, аның приказ формасында булуына карамастан, үзенең беренче тәкъдимен яклап яңадан Куракинга мөрәҗәгать итә. Газетаны татар телендә дә чыгару кирәклеген яклый, гарәп хәрефләрен үз хисабына хәзерләтәчәген, Запольскийның университетта эшләве газета чыгаруда катнашуына комачаулык итмәячәген күрсәтә, татар телендә газеталар чыгару проектын Казан татарларының шатланып каршы алулары, аны чыгару өчен үз эшен яхшы белгән кешеләр булуы турында да яза[1].

Куракин Мансуровның бу үтенечен Министрлар Советы җыелышына куя. 1809 елның 26 маенда Казанда ике телдә газета чыгару өчен рөхсәт бирелә. Куракинга бу мәсьәләне үзе үк хәл итә алуы турында кисәтү ясала. Ләкин Министрлар Советы Румовскийның газета чыгаруда Запольский катнашмаска тиеш дигән таләбен дә кабул итә. Шуның нәтиҗәсендә, рөхсәт бирелгәннән соң да, газета ике ел буена чыкмый кила. Ниһаять, аның беренче саны 1811 елның 19 апрелендә дөнья күрә. «Казанские известия» исеме белән чыга башлаган бу басма орган Казанда беренче, Россия провинцияләрендә чыга башлаган өченче газета була.

Проектны күтәргән Запольскийга бу эштә катнашырга рөхсәт ителмәгәч, газетаны татар телендә дә чыгарырга кирәк дип тырышып йөрүче кеше калмый. Мансуров вакытында бу тәкъдимне яклап чыккан булса да, күрәсең, Запольскийдан башка аны татар телендә чыгарырга батырчылык итмәгән. Губернатор кебек зур рәсми кеше булуы, бу тәкъдимгә Куракинның башта каршы килүен дә искә алгандыр дип уйларга мөмкин.

Татар телендә газета чыгару фикере университет профессоры башына тиктомалдан гына килмәгән. Ул бу турыда татар халкының алдынгы карашлы вәкилләре белән сөйләшкән, алар арасында тулы теләктәшлек тапкан булырга кирәк. Моның шулай булуын Мансуровның Куракинга язган хаты да раслый. «Казанда татар китаплары басу тәҗрибәсеннән һәм Казанда газета чыгару проектын шәһәрнең **мөселман халкы күп тапкырлар** (Мансуров разрядкасы) хуплап чыгулары»[2]на басым ясап күрсәтүе нәкъ шул турыда сөйли.

---

[1] Биредә сүзнең Ибраһим Хәлфин турында булуы мөмкин. Ул вакытта рус телендәге барлык документлар татарчага аның тарафыннан тәрҗемә ителгәннәр. Татар телендә газета чыгару хакында Запольскийның И. Хәлфин белән дә киңәшкән булуы бар.

[2] Н. П. Загоскин. Күрсәтелгән хезмәт, 290 бит.

Аннан соң, Запольский газета чыгарудан азмы-күпме файда алуны да күздә тоткан булырга кирәк, заманы өчен шактый зур материаль чыгым сорый торган бу эшкә татарлар белән киңәш итми, газетаны халык арасында тарату хакында алардан ышанычлы гарантия алмый торып керешә алмаган булыр иде.

## *Маркел Никольский проекты*

Запольскийдан соң озак тормыйча, татар телендә газета чыгару өчен тагын бер омтылыш ясала. 1834 елгы бу проект турында инде фәндә билгеле булганлыктан[1], монда без аның турында берничә генә сүз әйтү белән чикләнәбез. «Бәхрел әхбәр» (Хәбәрләр диңгезе) исеме белән чыгарырга уйланган бу газетаның башлап йөрүчесе Маркел Григорьевич Никольский була. Казан университетының математика профессоры Г. Б. Никольскийның улы Маркел 1833 елда университетның Шәрык бүлеген уңышлы тәмамлаган яшь галим. Ул, зур эрудицияле, киң белемле кеше булып, татар, төрек, гарәп, фарсы әдәбияты һәм телләрен дә яхшы белгән. Гимназиядә укыган вакытта ул татарлар белән аралашкан, татар халык җырларын, әкиятләрен, мәкаль һәм әйтемнәрен җыю белән дә шөгыльләнгән. Ул татар халкының тырышлыгын, аң-белемгә сусавын тирән тойган. Маркел татар телендә газета чыгаруның төп максаты итеп халыкка аң-белем җиткерү, мәгърифәт тарату, татар һәм рус халыкларының үзара якынлашуына хезмәт итү бурычын куя.

Газетаның программасы һәм беренче саны өчен хәзерләнгән материаллар белән танышкан профессор А. Казембек бу турыда: «Кем тарафыннан гына булмасын, татар телендә газета чыгару татарларның мәгърифәте өчен генә түгел, промышленность һәм сәүдә өчен дә зур файда китерәчәк. Бигрәк тә Казанда, аны чыгару өчен кирәкле барлык мөмкинлекләр бар җирдә, татар телендә газета чыгару кирәк кенә түгел, зарури эш тә»[2],— ди һәм Казан уку округы попечителенә мөрәҗәгать итә.

Румовскийдан аермалы буларак, бу вакытта попечитель булып эшләгән М. Н. Мусин-Пушкин бу тәкъдимне кире какмый һәм материалларны хәл итү өчен Эчке эшләр министрына җибәрә. Корбут һәм башка тарихчылар бу газетаның ни өчен дөньяга чыкмый калуы турында бер сүз дә әйтмиләр. Мусин-Пушкин хаты артыннан Эчке эшләр министрына Никольскийның кем булуы турында характеристика соратуы һәм әле генә Шәрык бүлегенә эшкә алынган Никольскийның Астраханьга тәрҗемәче итеп тиз генә җибәрелүе патша хөкүмәтенең бу мәсьәләгә ничек каравын ачык күрсәтә...

## *Петр Пашино проекты*

Татар телендә беренче журнал чыгарырга йөргән Петр Пашино эшчәнлеге турында матбугатта ике хезмәт басылып чыкты[3].

Никольский кебек үк, ул да Казан университетының Шәрык бүлегендә укыган, 1855 елда бу разряд Петербургка күчү сәбәпле, аны башкалада тәмамлаган. Казанда вакытта ук әдәби һәм фәнни эшләр белән шөгыльләнә башлаган бу яшь галим эзләнүләрен Петербургта да дәвам итә. Пашино Чит ил эшләре министрлыгында зур гына урында эшли башлый, әмма «Земля и воля» исемле революцион оешма белән элемтәдә торуын сылтау итеп, бераздан эшеннән алына.

1864 елның 2 маенда Петербург цензура комитетына «Файда» исеме белән татар телендә журнал чыгарырга рөхсәт сорап язган гаризасыннан күренгәнчә, ул вакытта Пашино Азия департаментына татар теле тәрҗемәчесе булып эшкә урнашуга ирешкән була. Петр Пашино шулай ук татар тормышын, аның культурасын яхшы белгән,

---

[1] М. Корбут. Проект первой татарской газеты. «Вестник научного общества Татароведения» журналы. 5 сан. 1926 ел. 106—131 битләр; Васильев. XIX йөзнең 40 елларында татарча газета чыгару проекты. «Безнең юл» журналы. 1926 ел. 3 сан. 17 бит.

[2] Татарстан Дәүләт архивы. 92 фонд. 3 тасвирлама. 556 эш. 8 бит.

[3] Е. И. Чернышев. К истории татарской печати в России. Проект татарского журнала «Файда». Труды общества изучения Татарстана. Рус телендә. Казан. 1930 ел. I том. 129—134 битләр; Е. Г. Бушканец. О попытке издания татарского журнала «Файда» в 1864 году. «Из истории Татарии» исемле җыентык. 1965 ел. 291—296 битләр.

Татар тарихы, халык иҗаты буенча ул җыйган материалларның күбесе, патша цензурасы куйган киртәләр аркасында, матбугатка чыга алмый калган [1].

Е. И. Чернышевның күрсәтелгән хезмәтендә Пашино татар телендә «Файда» исемле журнал чыгаруны «татарларны Россия сәүдә-промышленность капиталына буйсындыру, вак халыкларны изүдә патша хөкүмәтенә хезмәт итү йөзеннән» эшләде дип языла. Әмма журнал проектында очрый торган: «Русларның интересларын яклау, хөкүмәтнең эшчәнлеге турында дөрес информация бирү» шикелле юллар белән танышкач, боларның рөхсәт алуны җиңеләйтү өчен генә язылганлыгы аңлашыла.

Пашиноның революцион-демократик орган булган «Современник» журналына язышуын, Н. В. Шелгунов, агалы-энеле Василий һәм Николай Курочкиннар белән таныш булуын, Н. Г. Чернышевский, Н. А. Добролюбов кебек кешеләр белән аралашуын искә алсак, Чернышевның Пашинога биргән бәясенең нигезсез булуы күренә. Без бу хакта профессор Е. Г. Бушканец фикерләренә тулысынча кушылабыз. Әгәр Пашино чыгарырга йөргән журнал патша хөкүмәте интересларын яклау максатыннан оештырылса, ни өчен Эчке эшләр министры аны чыгарырга рөхсәт бирмәгән соң? Пашиноның татарча журнал чыгарырга йөрүе, безнеңчә, прогрессив карашлы рус кешеләренең изелгән халыкларны яклап чыгуының матур бер үрнәге.

## *Владимир Курочкин проекты*

Моңарчы галимнәргә билгеле булмаган, Ленинградтагы СССР Дәүләт тарих архивында табылган яңа документлар П. Пашино проектын тирәнрәк аңларга ярдәм итәләр. Шулардан берсен без монда татарчага тәрҗемә итеп китерәбез:

«МАТБУГАТ ЭШЛӘРЕ ҮЗӘК ИДАРӘСЕНӘ
АРМИЯ КАПИТАНЫ ВЛАДИМИР СТЕПАНОВИЧ КУРОЧКИННАН

ҮТЕНЕЧ

**Россиянең Европа өлешенең көнчыгышындагы губерналарда татарлар сан ягыннан руслардан күбрәк. Аларның һәр яңа эшкә тиз керешергә торулары, булдыклылыклары һәм кулларында шактый капитал туплаулары аркасында тире эшкәртү, сабын ясау, поташ, терлек мае эретү һәм башка заводларның күп өлеше хәзерге көндә татар заводчылары кулында. Бу заводлар чыгара торган продуктлар илебезнең бөтен почмакларына гына түгел, зур күләмнәрдә чит илләргә дә чыгарыла. Шуның өстенә, бу якларда, бигрәк тә безнең белән чиктәш мөстәкыйль татар ханлыклары [мөселман илләре — Ә. К.], дала халыклары, Кытай татарлары [мөселманнары — Ә. К.] белән сәүдә эше дә безнең татар капиталистлары кулында.**

**Урта Азия белән күрше безнең губерналар арасында промышленность һәм сәүдә эшләренең уңышлы үсеше өчен, татар халкының грамоталылыгын күтәрергә шартлар булдыру, һичшиксез, гаять зур әһәмияткә ия. Бигрәк тә җир эшкәртү, промышленность, сәүдә эшләре буенча махсус белем тарату беренче урында тора. Рус телен белмәүләре аркасында бу мәсьәләләргә караган нәрсәләрне алар белә алудан мәхрүмнәр.**

**Туган Ватанымның, шул исәптән, үзебезнең башка халыкларыбызның алга баруында булган бөтен көчем һәм мөмкинлекләрем белән һәм материаль средстволарым булуымнан чыгып, күрсәтелгән өлкәдә туган бушлыкны тутыру һәм татарлар арасында мәгърифәт таратуга ярдәм итү йөзеннән моның өчен татар телендә махсус журнал чыгарырга кирәк дигән карарга килдем.**

**Менә шушы максатлардан чыгып миңа татар телендә «Файда» [Польза] исемендә газета чыгарырга хокук бирү өчен Матбугат эшләре Үзәк идарәсенең [эчке эшләр министры каршында — Ә. К.] ходатайство итүен үтенеп сорыйм.**

**Газета түбәндәге программа белән чыгарылачак:**

---

[1] «Биржевые ведомости». 1881 ел. 187 сан. 2 бит.

Сәүдә, промышленность, авыл хуҗалыгына караган җитәкче-кулланма мәкаләләр.

II

Эчке хәбәрләр. Галиҗәнап приказлары, хөкүмәт карарлары, күрсәтмәләре һ. б.

III

Чит ил хәбәрләре. Бу тема буенча газета редакциясе «Северная почта» [газетасындагы — Ә. К.] материалларына таяначак.

IV

Төрлесеннән. Авыл хуҗалыгы, завод, фабрика производствосының төрле өлкәләренә караган мәкаләләр; сәүдә, биржа эшләре турында һ. б. кирәкле мәгълүматлар.

V

Фельетон. Этнография буенча мәкаләләр, тарихи очерклар, кыска хикәяләр һәм.

VI

Филология. Бу рубрика астында мәкаль-әйтемнәр, легендалар, төрле филологик тикшеренүләр басу күздә тотыла.

Декабрь (көне күрсәтелми) — 1865 ел.

Капитан Владимир Степанович Курочкин (имзасы)

Тору урыным:

Московской части [г. Санкт-Петербурга — Ә. К.], квартал по фонтанке, у Семеновского моста, в доме Баронессы Вульф, № 90, кв. 3»[1].


Бу үтенеч тә, Пашинонынкы кебек, Эчке эшләр министры тарафыннан кире кагыла.

Владимир Степанович Курочкин кем булган соң? Аның бертуганнары Василий һәм Николай Степанович Курочкиннар — 1861 елдан бирле «Земля и воля» исемле яшерен революцион оешмада торган күренекле разночинец шагыйрьләр. Герцен һәм Огарев белән элемтәдә булулары өчен полициянең яшерен күзәтүе астында торганнар. Александр II гә һөҗүм булгач, аларның икесен дә Петропавел крепостена япканнар. Николай Курочкин — Н. Г. Чернышевскийның көрәштәше һәм аның эшен дәвам иттерүче революцион-демократ, Чокан Вәлихановның якын дусты. Владимир Курочкин Урта Азиядә армиядә хезмәт иткәндә, күрәсең, Чокан Вәлиханов белән танышкан һәм, Чокан Петербургка килгәч, аның белән Василийны да таныштырган булса кирәк.

Владимир, һичшиксез, туганы Василий белән Николайның фикердәше булган. 1864 елда Пашинога татарча журнал чыгарырга рөхсәт ителмәгәч, Владимир Курочкинның шул ук «Файда» исеме белән татарча газета чыгарырга рөхсәт сорап Матбугат эшләре Үзәк идарәсенә мөрәҗәгать итүе алар арасында элемтә барлыгы, бергәләп эшләү турында сөйли. Бу алар чыгарырга уйлаган газета-журналның бер исемдә булуы белән генә түгел, төзегән программаларының тулысынча диярлек тәңгәл килүендә дә чагылган.

Дөрес, Пашино белән Курочкин программаларының бу органнарны чыгару максатын бәян иткән кереш өлешендә аерма шактый зур күренә. Мәсәлән, Курочкинныкындагы «татар халкының грамоталылыгын күтәрергә шартлар булдыру», тормыш өчен файдалы белем тарату кирәклеген ассызымлап күрсәтү Пашинонынкында булмавына карамастан, программаларның берлеге аларның икесенең дә бер максаттан чыгып эш

[1] Документның төп нөсхәсе Ленинградтагы СССР Дәүләт тарих архивында (776 фонд. 3 тасвирлама. 181 эш. 1—2 битләр) саклана.



13 ДЕК. 65.

Въ Главное Управленіе по дѣламъ печати.

Арміи Капитана Владиміра Степановича Курочкина

Прошеніе

Татарское населеніе восточныхъ губерній Европейской Россіи, далеко превышающее численностію русское населеніе, по духу предпріимчивости и вслѣдствіе накопленія въ его рукахъ большихъ капиталовъ употребляетъ всю свою дѣятельность на заводскую и фабричную промышленность, такъ что въ настоящее время большая часть кожевенныхъ, мыловаренныхъ, салотопенныхъ, поташныхъ и другихъ заводовъ принадлежатъ заводчикамъ изъ татаръ. Продукты, получаемые съ такихъ заводовъ составляютъ не только предметъ повсемѣстнаго внутренняго потребленія, но въ большомъ количествѣ отпускаются за границу. Кромѣ того вся торговля этого края, особенно съ сопредѣльными намъ независимыми татарскими ханствами, степью и Китайскою Татаріею также находится въ рукахъ нашихъ татарскихъ капиталистовъ. Несомнѣнно, что для успѣшнаго хода промышленныхъ и торговыхъ дѣлъ нашихъ пограничныхъ съ среднею Азіею губерній весьма важно возвышеніе уровня образованія татарскаго народа, а прежде

*Курочкин гаризасының фотокучермәсе.*

итүләрен күрсәтә. Пашино программасында Курочкинның V һәм VI пунктлары юк, аның VI бүлеге «Төрлесеннән. Беллетристика һәм беренче бүлектә күрсәтелмәгән темалар буенча кызыклы хәбәрләр» дигән юллары нигездә Курочкинның күрсәтелгән пунктларына якын тора.

Владимир Курочкинның татарча газета чыгарырга рөхсәт сорап керүе дә Василий һәм Николай киңәше буенча эшләнгән булуы мөмкин[1]. Бу өлкәдә тикшерүләр алып барылса, Н. Г. Чернышевский һәм аның көрәштәшләренең изелгән халыклар турында кайгыртулары, аларны революцион хәрәкәткә тарту өчен конкрет эш алып барулары турында документлар да табылуы ихтимал. Бәлки, мондый эзләнүләр нәтиҗәсендә, шул вакытта Петербургта эшләгән Х. Фәезханов кебек татар галимнәренең революцион-демократлар белән таныш, һәрхәлдә, хәбәрдәш булуын да ачыклап булыр иде[2].


---

[1] Николай Курочкинның Н. Г. Чернышевский көрәштәше булуын искә алсак, аның туганы Владимирның бу газетаны чыгару өчен йөрүе абыйсына татарлар арасында революцион-демократик идеяләрне пропагандалауда ярдәм итү йөзеннән булуы да мөмкин. Шуның өстенә Н. Г. Чернышевскийның татар халкының хәлен яхшы белүе, татар телен һәм тарихын өйрәнүе дә күп нәрсәләр турында уйландыра.

[2] Бу очракта Х. Фәезхановның Чокан Вәлиханов белән дуслыгы, хат алышып торуын да онытмаска кирәк. Чоканның Николай Курочкин белән дус булуы моның өчен нигез барлыгы турында сөйли булса кирәк.

1860 елларда Казан татарлары үзләре дә газета чыгарырга йөргәнлекне күрсәтә торган хәбәрләр бар. Х. Фәезханов Казан татарларыннан ике-өч кешенең, компания төзеп, газета чыгарырга рөхсәт сорап йөрүләрен телгә алып үтә [1]. Бу газетаны кемнәр чыгарырга йөрүе безгә билгеле түгел, бу турыда Ленинград һәм Казан архивларында





10 Сентября 1874 3/X.

Его Сиятельству
Господину Управляющему Министерствомъ Внутреннихъ Дѣлъ Дѣйствительному Тайному Совѣтнику и Кавалеру Князю Алексѣю Борисовичу Лобанову Ростовскому.

[illegible]

Станціоннаго Смотрителя при С-Петербургскомъ Почтамтѣ Тачитьдинъ Кутлуярова

Прошеніе.

Желая въ какой бы то нибыло мѣрѣ быть полезнымъ отечеству и своимъ единовѣрцамъ магометанамъ въ особенности въ настоящее время, когда каждый изъ насъ магометанъ чувствуетъ потребность образованія и сознаніе правъ своихъ Руского Гражданства, желая по возможности силъ моихъ удовлетворить желанія и стремленія единовѣрцевъ магометанъ путемъ развитія между ними научнаго самообразованія, основаннаго на нравственныхъ началахъ и полезныхъ знаніяхъ посредствомъ общедоступнаго ихъ изложенія на татарскомъ языкѣ. И почему имѣю честь

*Котлыяров гаризасының фотокүчермәсе.*

[1] Шул хактагы документ белән безне М. Госманов таныштырды.

әлегә документлар табылмады. Татар кешесе газета чыгарырга рөхсәт сорап язган үтенечләрнең иң элгәреләреннән берсе 1871 елга карый. Бу документ культурабыз тарихы өчен кыйммәтле булганлыктан, аның бер өлешен монда татарча китерәбез:

«ЭЧКЕ ЭШЛӘР МИНИСТРЫ, ТУЛЫ СТАТСКИЙ СОВЕТНИК ҺӘМ КАВАЛЕР КНЯЗЬ ГАЛИҖӘНАП АЛЕКСАНДР БОРИСОВИЧ ЛОБАНОВ-РОСТОВСКИЙ ӘФӘНДЕГӘ
САНКТ-ПЕТЕРБУРГ ПОЧТАМТЫ СТАНЦИЯ КАРАУЧЫСЫ
ТАҖЕТДИН КОТЛЫЯРОВТАН

ҮТЕНЕЧ

Бигрәк тә хәзер, һәр мөселман кешесе аң-белемен үстерү мохтаҗлыгын һәм Россия гражданины итеп үзенең хокукларын аңлау кирәклеген тирән таныган заманда, Ватаныма, бигрәк тә диндәш мөселманнарга азмы-күпме файда китерү максатыннан чыгып, аларның фәнни аң-белемнәрен үстерүгә теләк һәм омтылышларын әхлакый башлангычларга нигезләнгән файдалы белем тарату өчен татар телендә халыкка аңлаешлы гади телдә язылган газета чыгару аркылы, үземнең көчемнән килгән барлык мөмкинлекләр белән ярдәм итәргә телим.

Һәм шуннан чыгып, цензура карамагы астында Санкт-Петербургта, 1875 елдан башлап, татар телендә, түбәндәге программа белән газета чыгарырга Сез Галиҗәнаплэрнең мәрхәмәтчелегенә түбәнчелек белән баш иеп, Сезнең хокукыгызда булган рөхсәтегезне бирүегезне үтенәм.

Сез Галиҗәнаплэр!

Газетаның максаты: әхлакый нигезләргә һәм файдалы белемнәргә нигезләнгән башлангыч аң-белем тарату аркылы хәзерге заман акыл һәм мәгърифәт үсешенә комачаулаучы җитешсезлекләргә каршы көрәшү.

Беренче чиратта:

— Хәзерге көнгә чаклы корьән хафизлар эшчәнлеге аркасында туган төрле хорафатларны, ялган карашларны, халыкның аң-белем үсүенә киртә булган корылмаларны җимерү;

— Мин чыгарачак газетада Россия, рус авыл хуҗалыгы, терлекчелеге, урманчылыгы һәм рус фәненең башка шундый өлкәләрдә ирешкән уңышлары турында киң мәгълүмат бирү;

— Мөселманнар арасында сәүдә һәм промышленность үсүенә ярдәм итү йөзеннән, фабрика-завод эшләрен оештыру мәсьәләләре турында төрле өлкәләрдән мәгълүматлар бирү;

— Медицина буенча аң-белем тарату. Чөнки мөселманнар арасында төрле һәм күп авырулар очрый, халыкта тәэлми торган авырулар җен-пәриләр бозуыннан килә дигән ышанулар яши.

Гомумән алганда, газетаның максаты: хәзерге көнгә чаклы караңгылыкта адашып йөрүче халыкка мәгърифәт таратуда бөтен юллар белән хезмәт итү.

Сез Галиҗәнаплэр!

— Минем бу яңа һәм файдалы эшне башлауда, Россия дәүләте халыклары мәгърифәте һәм тормышын яхшыртуда Сез Галиҗәнаплэрнең киң күңелле йөрәгенә шул кадәр якын мөкатдәс бу файдалы эштә, бу үтенечемне бөек мәрхәмәтегездән читтә калдырмавыгызны бик зур түбәнчелек белән үтенеп-үтенеп сорыйм.

Сез Галиҗәнап, күп гасырлар буенча караңгылыкта яшәүче татар халкының мәгърифәтен һәм аң-белемен үстерүдә иң көчле корал булачак һәм булырга тиешле үз басма органы бу газетаны ачарга рөхсәт биреп Россия дәүләтендә яшәүче барлык мөселманнарның Сез мәңгелек ихтирам һәм хөрмәтләрен яулаячаксыз.

Сез Галиҗәнапләрнең һәр сүзен үтәргә торучы хезмәтчегез:

Таҗетдин Котлыяров (имзасы)

Сентябрьнең 9 ычы көне.
1871 ел.
Тору урыным: Санкт-Петербург Почтамт бинасының 11 квартирасында» [1].

---

[1] Документның төп нөсхәсе Ленинградтагы СССР Дәүләт архивында (776 фонд. 5 тасвирлама. 100 эш. 1—2 битләр) саклана.

«МАТБУГАТ ЭШЛӘРЕ ҮЗӘК ИДАРӘСЕНӘ
САНКТ-ПЕТЕРБУРГ ПОЧТАМТЫ СТАНЦИЯ КАРАУЧЫСЫ
ТАҖЕТДИН КОТЛЫЯРОВТАН

ҮТЕНЕЧ

**Цензура карамагы астында Санкт-Петербургта 1875 елдан башлап татар телендә «Мөхбир» (ягъни Вестник) исеме астында атнага бер, җомга көнендә газета чыгарырга миңа рөхсәт бирүегезне сорап Матбугат эшләре Үзәк идарәсенең мәрхәмәтле начальствосына түбәнчелек белән мөрәҗәгать итәргә батырчылык итәм.**

**Газетаның программасы түбәндәгечә:**

**I**

**Авыл хуҗалыгы, һөнәрчелек, сәүдә эшләре.**

**II**

**Төрлеләр. Дәүләт карарлары һәм күрсәтмәләре, фән, сәнгать, промышленность яңалыклары.**

**III**

**Һәр кешегә кирәк дәрәҗәдә педагогика һәм гигиена буенча мәгълүмат.**

**IV**

**Сәяхәтләр.**

**V**

**Повестьлар, шигырьләр, мәзәкләр, мәкаль-әйтемнәр.**

**VI**

**Мөселман һәм башка халыкларның гаилә һәм иҗтимагый тормышы буенча мәгълүматлар.**

**VII**

**Чит ил хәбәрләре, тәрҗемәләр, чит җирләрдә булган кызыклы хәлләр турында күзәтүләр.**

**VIII**

**Фельетон.**

**IX**

**Лөгать.**

**X**

**Белдерүләр.**

**Газета, мөселман законы буенча үткәрелә торган ике бәйрәмнән кала, атнага бер тапкыр, җомга көнне аерым номер булып бер басма табак күләмендә басылачак.**

**Газета Император академиясенең Васильев атавы, 9 линия, 10 йортта урнашкан типографиясендә басылачак.**

**Почта аркылы җибәрү шарты белән генә чыгарылачак газетага Россиянең теләсә кайсы шәһәрендә язылу бәясе:**

Елга — 8 сум
$^1/_2$ елга — 5 сум

Чит илләрдә язылучылар өчен (елына) — 16 сум.

Шушы үтенеч белән Санкт-Петербург Почтамты экзекуторлык[1] бүлегенең № 6 — минем шәхесемне раслаучы таныклама да китерелә.

Матбугат эшләре Үзәк идарәсеннән күрсәтелгән журналны чыгарырга тиешле күрсәтмә һәм бу турыда кабул ителгән тәртип буенча миңа шәһадәтнамә бирүегезне һәм шулай ук бу турыда минем эш урыным — Санкт-Петербург Почтамтының корреспонденцияләрне тәртипкә салу һәм тарату Экспедициясенә хәбәр итүегезне түбәнчелек белән үтенеп сорыйм.

Газетаның нашире һәм җаваплы редакторы вазифасын үз өстемә алу белән матбугат турындагы бөтен законнарны үтәргә сүз бирәм.

Сентябрь.— (көне күрсәтелмәгән)
1874 ел.

Санкт-Петербург Почтамты станция караучысы:
Таҗетдин Котлыяров.
(имзасы)»[2]

«ЭЧКЕ ЭШЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ
МАТБУГАТ ЭШЛӘРЕ ҮЗӘК
ИДАРӘСЕ
25 сентябрь 1874 ел.
№ 4697

ЭЧКЕ ЭШЛӘР МИНИСТРЫНА[3]

Санкт-Петербург Почтамтының Станция караучысы Таҗетдин Котлыяров 1875 елдан башлап Санкт-Петербургта, үз редакциясендә «Мөхбир» (Вестник) исеме астында, татар телендә газета чыгарырга рөхсәт сорап Матбугат эшләре Үзәк идарәсенә мөрәҗәгать итте.

Ул шундый ук үтенеч белән 1872 елда ук Матбугат эшләре Үзәк идарәсенә мөрәҗәгать иткән булса да, аның үтенече «Махсус әдәби органнар ачарга рөхсәт бирү Империя составына кергән төрле вак милләтләрнең үзбаш яшәвенә ярдәм итәчәк, бу исә хөкүмәтнең күз алдында тоткан планнарына туры килми»,— дип Матбугат эшләре Үзәк идарәсе доклады буенча Эчке эшләр министры тарафыннан ул вакытта да кире кагылган иде.

Менә шуңа нигезләнеп Матбугат эшләре Үзәк идарәсе сораучының бу үтенечен бу юлы да кире кагарга мөмкин дип саный, һәм бу турыда шушы фикерен Сез Галиҗәнапләр карамагына җиткерәм.

(Матбугат эшләре Үзәк идарәсе председателе, Статс секретарь — Логинов (имзасы)»[4].

Беренче үтенечнең астына «1871 елның 9 сентябрь көнне» дип куелган, аның 1874 ел булуы да мөмкин. Һәрхәлдә, 7 биттә күрсәтелгән сүзләрдән Таҗетдин Котлыяровның шундый ук үтенеч белән 1872 елда ук рәсми органнарга мөрәҗәгать итүе күренә[5].

Котлыяровның беренче үтенече, инстанцияне читләтеп үтеп, турыдан-туры эчке эшләр министрына җибәрелгәнлеге өчен кире кайтарыла. Шуннан соң ул яңадан якындагы инстанциягә — Матбугат эшләре Үзәк идарәсенә мөрәҗәгать итеп карый. Рөхсәт итмәскә дигән җавап бу юлы министрның үзе тарафыннан түгел, Үзәк идарә исеменнән җиткерелә.

Котлыяров программасын тәфсыйллап тикшереп тормыйча, без монда бары берничә моментка гына тукталып үтәбез. Шунысы игътибарга лаек: XIX гасырның соңгы чирегендә, хәтта XX йөз башында татар телендә газета-журналлар чыгарырга сорап язган үтенечләрдә газетада мөселман дине, аның кануннары турында да язылачагы әйтелә. Котлыяров исә, киресенчә, газетаны халык аңын томалап килүче дин әһелләр-

---


[1] Экзекутор — хуҗалык бүлегендә эшләүче.

[2] Ленинградтагы СССР Дәүләт архивында (776 фонд. 5 тасвирлама. 100 эш. 3—4 битләр) саклана.

[3] Хатның бу каралама вариантында Эчке эшләр министрына дигән багышламасы күрсәтелмәгән.

[4] Ленинградтагы СССР Дәүләт архивында саклана. (776 фонд. 5 тасвирлама. 100 эш. 7 бит).

[5] Яңа табылган документлар (776 фонд. 5 тасвирлама. 168 эш. 1—7 битләр). Котлыяров һәм Бекбулатовларның 1872 елның 10 декабрендә ук шундый үтенеч белән керүләрен раслый.



М.В.Д.

Главное Управленіе по дѣламъ печати.

25 Сентября 1874 г.

№ 4617

... 25 Сен/74

Станціонный смотритель при С.Петербургскомъ Почтамтѣ, Тажитдинъ Кутлуяровъ, обратился въ Главное Управленіе по дѣламъ печати съ прошеніемъ о разрѣшеніи ему издавать въ С.Петербургѣ, съ 1875 года, подъ его редакторствомъ, еженедѣльную газету на татарскомъ языкѣ, подъ названіемъ «Шундаларъ» (Вѣстникъ).

Проситель уже обращался съ таковымъ же ходатайствомъ въ Главное Управленіе по дѣламъ печати въ 1872 году и ходатайство это было тогда отклонено Г. Министромъ Внутреннихъ Дѣлъ, по докладу Главнаго Управленія о несоотвѣтствіи съ видами правительства

*Матбугат эшләре Үзәк идарәсенең Эчке эшләр министрына язган хаты*

рена каршы көрәшү өчен чыгарырга йөрүен ассызыклап күрсәтә. Аның программасы Владимир Курочкинныкыннан да киңрәк, күпкырлы һәм энциклопедик характерда. Бу документлардан Таҗетдин Котлыяровның чын мәгънәсендә зур эрудицияле, киң карашлы фикер иясе булуы күренә. Без әле аның биографиясен, нинди эшләр башкаруын ачып бирә торган документларга юлыкмадык. Табылган документлар аның Петербургтагы Үзәк Почтамтта эчке корреспонденцияне кабул итү, тәртипкә салу һәм тарату бүлеге башлыгы булып эшләвен раслыйлар. Россия Фәннәр академиясе белән сөйләшеп, проектлаштырган газетасын академия типографиясендә бастырырга килешүе аның рус галимнәре белән таныш булуы турында сөйли.

Котлыяров үтенече дә Эчке эшләр министры тарафыннан: «Махсус әдәби органнар ачарга рөхсәт бирү Империя составына керган төрле вак милләтләрнең үзбаш яшәвенә китерәчәк, бу исә хөкүмәтнең күз алдында торган планнарына туры килми»,— дип кире кагыла.

Патша хөкүмәтенең шундый каты каршылык белән татар телендә газета-журнал чыгарырга йөз ел буе диярлек рөхсәт бирми килүен нәрсә белән аңлатырга мөмкин соң? Әлбәттә, аның нигезендә царизмның милли колониаль изү, халыкларны наданлык-

та, караңгылыкта тоту политикасы ята. Ләкин болай дип әйту генә мәсьәләне ачып бетерми әле. Әгәр милли телләрдә газета-журналлар чыгару «вак милләтләрнең үз-баш яшәвенә ярдәм итәчәк» булгач, ни өчен царизм әрмән, еврей, грузин, молдован, литва, латыш, поляк, эстон, фин телләрендә вакытлы матбугат ачуга каршы килмәгән соң? Бу — царизмның христиан булмаган халыкларны тагын да катырак изүе, көчләп чукындыру политикасына нигезләнгән.

Әле бу момент кына рус самодержавиесенең татарларга карата аерата мәрхәмәтсезлеген тулысынча ачып бетерми. Югыйсә, ни өчен патша хөкүмәте 1830 елда Тифлиста казна хисабына мөселман динендәге фарсы халкы телендә «Фарсийские ведомости» дигән газета чыгара башлады һәм 1832 елдан аны татар телендә «Кавказның бу тарафының хәбәрләре» исеме белән 1840 елларда да бастырып килә, 1875 елда үзбәк һәм рус телләрендә «Туркестанская туземная газета», аннан казакъ һәм рус телләрендә «Акмолинские областные ведомости» дигән газеталар чыгарырга керешә. Ул гына да түгел, шул ук мөселман халыклары булган әзербәйҗаннарга 1875 елда «Игенче», 1885 елда кырым татарларына «Тәрҗеман» газетасы басарга рөхсәт бирә.

Бу мәсьәләгә ачыклык кертү өчен, Кавказ наместнигы барон Розенның 1831 елда Эчке эшләр министрына җибәргән бер хатына мөрәҗәгать итик. Бу хатта фарсы телен белүче кешеләр аз булу сәбәпле, Тифлиста фарсы телендә чыгып килгән газетаның туктaлуы, аны татар (әзербәйҗан — Ә. К.) телендә чыгара башлау кирәклеге аңлатылган. Розен казна хисабына «татар» телендә газета чыгару Россия составына яңа кергән халыкларны газета аша Россия тормышы, рус гореф-гадәтләре белән якынрак таныштырырга ярдәм итәчәк, шуның белән күрше мөстәкыйль мөселман илләре алдында Россияне бу халыклар алдында кайгыртучы дәүләт итеп күрсәтәчәк, моның исә файдасы Россия өчен аз түгел, ди. Министр да бу фикерне тулысынча яклап чыга.

Менә бу юллардан татарларга ни өчен вакытлы матбугат ачарга рөхсәт бирелми килүенә җавап та табып була. XIX гасырда инде хөкүмәт Идел буен Россия дәүләте тарафыннан күптән үзләштерелгән өлкә дип карый, шуңа күрә андагы халыкларның, бигрәк тә мөселман халкы булган татарларның, теләге белән азмы-күпме хисаплашу кирәксез нәрсә дип саный. Царизмның татарларга карата аерата рәхимсезлеге менә шуңа нигезләнгән иде. Без бу нәрсәне вакытлы матбугат ачу өчен алып барган көрәштә генә түгел, татарча китап басу эшендә дә, мәктәп-мәдрәсәләргә карата царизмның тоткан политикасында да ачык күрәбез. Бу экономика өлкәсендә дә шулай булды.

Менә бу фактлар белән танышкач, ни өчен патша хөкүмәте 1809 елда Казанда татар телендә газета чыгарырга рөхсәт биргән соң, дигән сорау да туа. Күрәсең, монда газета чыгаруны сорап патшаның үз чиновнигы — Казан губернаторы үзе мөрәҗәгать итүе һәм ул тәкъдимне тырышып яклавы ярдәм иткән булырга тиеш. Архив документлары күрсәткәнчә, Казан губернаторлары арасында бу беренче һәм соңгы факт булды.

1809 елда рөхсәт бирелүнең икенче ягы да бар. Бу әле патша самодержавиесенең Урта Азиягә үтеп керүгә керешкән чоры гына иде. Патша хөкүмәте үзенең бу политикасында татарлардан киң файдаланды. Тылмачлар булып кына түгел, казакъ җирләрендәге төрле официаль урыннарда күп кенә татар кадрлары эшләп килде. Урта Азия белән Россия сәүдәсе дә бу вакытта нигездә татарлар кулында иде. Менә шуңа күрә XIX йөзнең беренче чирегендә патша хөкүмәте татарларның интересы белән азмы-күпме исәпләшергә мәҗбүр булган, алар белән исәпләшмәүнең көнчыгыш политикасын үткәрүгә комачаулаячагын аңлаган. Ә инде Урта Азиядә үзенең позицияләрен ныгыткач, ул алар белән исәпләшүне кирәк тапмаган.

Менә шуның өчен ул 1809 елда бу мәсьәләгә бер төрле, ә инде 1834 елдан соң икенче төрле карый башлаган. Моның шулай икәнен царизмның бу чорда Урта Азия һәм Кавказ мөселман халыкларына карата икенче төрлерәк политика алып баруын да күрсәтә. Менә шуның өчен дә царизмның колониаль-милли изү политикасының төрле халыкларга карата төрлечә булуын дифференцияләмичә карау аркасында күп кенә сораулар әлегә хәтле җавапсыз кала килде. Мәсәлән, Россиядәге күп кенә халыклар ни өчен XIX йөздә үк вакытлы матбугат ачканнар, ни өчен кайбер халыкларга Европа һәм рус культурасы, фәне, алдынгы иҗтимагый фикере белән танышу өчен мөмкинлекләр күбрәк булган, ни өчен татарлар арасында мөселман диненең йогынтысы шактый көчле булган?

Үзләренә вакытлы матбугат ачарга, аның аркылы Европа, рус культурасы белән халыкны таныштырырга рөхсәт бирелмәү Идел буена Төркиядән, гарәп илләреннән газета-журналлар алып кайтуның көчәюенә китергән. Халыкның күпчелеге, рус телен белмәве аркасында, рус вакытлы матбугатын укый алмаган. Инде XIX йөздә дә татарда Шәрык культурасына кыйбла тоту көчле булган икән, газета-журнал ачарга рөхсәт бирмәве белән царизм үзе үк моңа сәбәпче булган.

Иван Ипатович Запольский, Маркел Григорьевич Никольский, Петр Пашино, Владимир Курочкин кебек алдынгы рус укымышлыларының халыклар төрмәсе булган патша Россиясендә изелгән милләтләрне яклап чыгуы, башкарган эшләре күп нәрсә турында сөйли. Рус милләте Победоносцев, Ильминскийлардан гына тормады, милләтнең чын рухын чагылдырган Чернышевский, Курочкин кебекләр дә аз түгел иде.

Хәзер аз гына хыялга урын биреп карыйк. Әгәр рус халкының искә алган алдынгы карашлы шушы бер генә вәкиле татар телендә газета яки журнал ача алуга ирешкән булса, ул безгә нәрсәләр китергән булыр иде? Беренчедән, ул татар тормышына алдынгы рус культурасы, рус революцион-иҗтимагый фикеренең йогынтысы киңрәк үтү өчен юл ачар иде. Бу исә халыкның мәгърифәте үсүен активлаштырыр, ислам йогынтысыннан тизрәк аерылырга ярдәм итәр иде. Татар галимнәреннән Каюм Насыйри, Х. Фәезханов, Гали Мәхмүдов кебекләрнең эшчәнлеге моны тулысынча раслый. Алар рус телен, әдәбиятын, фәнен үзләштереп кенә калмадылар, аның белән халыкны да таныштырып килделәр һәм бу өлкәдә татар мәгърифәтен Европа һәм рус культурасы казанышлары белән баетуга зур өлеш керттеләр. Әгәр дә ул чорда татарча вакытлы матбугат ачарга рөхсәт ителгән булса, күпме әдәбият, тарих, халык иҗаты әсәрләре теркәлеп калыр иде, күпме яңа язучылар, мәгърифәтчеләр, галимнәр җитешкән булыр иде! Татар халкының Европа һәм рус культурасы казанышларына омтылышы никадәрле тизрәк тормышка ашар иде. Кызганычка каршы, тормыштагы бу алдынгы омтылышлар бик соңгарып кына гамәлгә аша алдылар. 1905 елга хәтле кара көчләрнең карашы һәм эшләре өстенлек алып килде. Шундыйларның иң эреләреннән берсе — миссионер Ильминскийның «Рус культурасында тәрбияләнгән, рус телен белүче татарга караганда фанатик татар патша хөкүмәте өчен күп мәртәбә файдалы»[1] дигән сүзе үзе генә дә күп нәрсәгә шаһитлек бирә. Менә шуңа күрә дә без XIX йөздә үк халкыбызның азатлыгы, тигез хокукы, культурасы өчен көрәшкән алдынгы рус галимнәренең хезмәтләрен тирән ихтирам белән искә алырга тиешбез.

---

[1] Н. И. Ильминский. Письма Николая Ивановича... Победоносцеву. Рус телендә, Казан. 1895 ел. 175 бит.

**Ильтани Илялова**

# ЯҢА ҮРЛӘРГӘ КАРАП

*«Казан утлары» журналының 1965 елгы ноябрь санында театр белгече Ильтани Илялованың Татар академия театры турындагы бер мәкаләсе басылган иде. Театрның киләчәк язмышы өчен тирәнтен борчылып язылган ул мәкалә дөньяга чыкканнан бирле биш еллап гомер узды.*

*Редакция биш ел элек башлаган сүзгә яңадан әйләнеп кайтырга, дәресрәге, аны дәвам итәргә булды. Узган биш ел вакыт эчендә нәрсә дә булса үзгәргәнме, үзгәрсә, нәрсә үзгәргән, кайсы якка үзгәргән? Гомумән, республикабызның үзәк театры бүген нинди хәлдә? Шул сорауларга җавап язуын үтенеп, без кабат сәнгать фәннәре кандидаты И. Илялова̃га мөрәҗәгать иттек.*

1965 елдан соң Академия театры тормышында байтак үзгәрешләр булып узды. Һәм, бәхеткә каршы, аларның күбесе асылда татар театр сәнгатен алга, яңа үрләргә илткән файдалы үзгәрешләр булды.

1966 елда театр, ниһаять, баш режиссерга тиеште. Бу эшкә театр институты тәмамлаган Марсел Сәлимҗанов куелды. Әлеге тәвәккәл адым урынлы булды. Шуннан бер ел алдан театрның директоры итеп Рәшидә Җиһаншина шикелле нык куллы, энергияле оештыручыны да куюу театрның бөтен тормышына: репертуар сайлауга һәм актерларның иҗади үсүенә, режиссурага һәм спектакльләрнең гомуми культурасы күтәрелүгә уңай йогынты ясады.

Иҗат оешмасы тормышындагы һәр чорның үзенә генә хас аерымлыклары, үзенчәлекле яклары була. Татар академия театры тормышындагы хәзерге этапны эзләнүләр чоры дип атарга булыр иде. Бу нәрсә пьесалар сайлауда һәм аларны сәхнәгә куюда, шулай ук актерларны төрле пландагы рольләрдә сынап карауда сизелә. Әйтик, В. Минкинаның бер кичне Мелитаны, ә икенче көнне аңа капма-каршы характердагы Гыйльменисаны, Ф. Халитовның рәттән Прибытковны һәм Сәгдетдинне, Ф. Ильскаяның әле Глафираны, әле Фатима Сабрины, Ә. Шакировның исә әле Айдынны, әле Анджелоны уйнаулары тикмәгә генә түгелдер, билгеле. Мондый мисалларны тагын да дәвам итәргә мөмкин булыр иде, чөнки бу татар театрының һәр артистына кагыла торган нәрсә.

Узган мәкаләдә без театрны репертуар ярлылыгы өчен дә гаепләгән идек. Һәм ул чагында хәл, чыннан да, шулайрак иде. Хәзер исә бу мәсьәләдә дә алга китеш бар. Соңгы 5 сезонда сәхнәгә утызлап яңа спектакль чыгарылган. Шуларның 18-е татар драматургларының әсәрләре, калганнары — тәрҗемә пьесалар. Тамашачы афишаларда төрле-төрле язучыларның исем-фамилияләрен укый алды: В. Шекспир һәм Н. Исәнбәт, Х. Вахит һәм Ч. Айтматов, Т. Гыйззәт һәм М. Байҗиев, Т. Миннуллин һәм Э. де Филиппо, А. Островский һәм А. Гыйләҗев, Фигейредо һәм Ю. Әминов һ. б., һ. б... Авторлары төрле булган кебек үк, ул спектакльләрдә тасвирланган чорлар, вакыйгалар

һәм персонажлар да төрле-төрле. Элегрәк төрле жанрдагы, төрле пландагы әсәрләр дә еш кына, бер анадан туган игезәкләр сыман, берсе икенчесенә охшаш итеп сәхнәләштерелгән булсалар, бүген андый бертөслелектән дә котылып барабыз шикелле. Әйтик, «Миркәй белән Айсылу» спектакле «Кол»га охшамаган кебек, «Гүзәлем Әсәл», «Соңгы корбан» һәм «Шамил Усманов» спектакльләре арасында да уртаклык юк диярлек. Мин юри драма жанрына караган мисаллар китердем. Чөнки бу төр әсәрләрне берсе икенчесен кабатламаслык итеп сәхнәгә кую аеруча кыен эш. Әмма режиссерлар (М. Сәлимҗанов, П. Исәнбәт, Т. Ходжаев, М. Новохижин) бер үк жанрның төрле якларын, төрле-төрле төсмерләрен (халык драмасы, лирико-трагик драма, психологик драма һ. б.) тапканнар. Шул ук вакытта тирән психологизм барлык спектакльләрнең дә аерылмас бер сыйфаты булып тора.

Төрле пьесаларда төрле проблемаларны хәл итү өчен режиссерлар төрле сурәтләү чараларыннан файдаланганнар. Ул әсәрләрнең берсендә тормыш контраст сурәтләр, икенчеләрендә ягымлы, нәфис бизәкләр, өченчеләрендә исә куе-куе буяулар ярдәмендә тасвирланган. Билгеле булганча, тормышны сурәтләү алымы, авторның чынбарлыкка образлы карашы теге яки бу жанрның асылын тәшкил итә дә инде. Пьесаны пьесадан, жанрны жанрдан нәрсә аера? Барыннан да элек мәгълүм бер конкрет тарихи шартлар. Алар һәр жанрда, һәр әсәрдә үзенә бертөрле. Режиссерның осталыгы шуларны күрә белүгә кайтып кала. Миңа калса, безнең режиссура хәзер әнә шуңа өйрәнеп килә. Ә бу, үз чиратында, академия театры спектакльләрендәге бертөслелекне, чырайсызлыкны нык киметте, нәтиҗәдә чын сәнгать әсәрләренең саны бермә-бер диярлек артты. Әгәр соңгы елларның күп спектакльләре аншлаг белән бара, тамаша залы тулы була икән, бу очраклы хәл түгел, әлбәттә.

Уебызча, театр тагын бер мөһим мәсьәләне хәл итеп килә. Бераүгә дә сер түгел: бездә татар тамашачысы тәрҗемә әсәрләргә йөрми, дигән караш яшәп килде, һәм аның әле дә бетеп җиткәне юк. Тәрҗемә әсәрләрен актив төстә сәхнәгә куя башлап, театр җитәкчелеге моның киресен раслады — тамашачы андый спектакльләргә дә атлыгып йөри икән. Тик бер шарт белән, әгәр әйбәт куелган булсалар.

Татар академия театры үсешендәге уңай традицияләр хакында сүз алып барганда, без аның реаль җирлеген, ышандырырлык мисалларын күздә тотып фикер йөртәбез. Коллектив куйган 30 лап спектакльнең кимендә 10 нан артыгын чын сәнгать әсәрләре рәтенә кертергә мөмкин. Ә 4—5 сезонга 10 ннан артык яхшы, кызыклы спектакль куелган икән — бу инде аз түгел. Өстәвенә ул спектакльләрнең һәрберсе үзенә бер төрле, берсе икенчесен кабатламый. Һәр әсәрне куйганда, театр теге яки бу иҗади мәсьәләләрне хәл итәргә, бүгенге көн, бүгенге тормыш өчен мөһим проблемаларны чишәргә тырышкан.

Сүзне Х. Вахитның «Күк капусы ачылса» комедиясеннән башлыйк. Бу әсәрне сәхнәгә куйганда театр коллективы, бүгенге тормыш материалларына нигезләнеп, рәхәтләнеп көләрлек, яшәү дәрте бөркелеп торган күңелле һәм җиңел водевиль тудырырга омтылган. Мондый әсәр актерлар өчен, аларга үз сәләтләренең яңа якларын күрсәтү өчен дә кирәк иде. Кайберәүләр водевильне трагедия белән чагыштырганда түбән жанрга санап, аңа кимсетеп карасалар да, ул осталыкка өйрәнү өчен менә дигән мәктәп, ә театр сәнгатенең аеруча катлаулы бер төре булып тора. Менә иң авторитетлы сәхнә остасы Станиславский фикереннән мисал: «Водевиль үзенә бер ниндидер «шартлы» нәрсә, шуңа күрә аны теләсә ничек сәхнәләштерергә мөмкин, логика һәм психология кануннары белән хисаплашып торуның һич хаҗәте юк, дип уйлау гадәткә кергән,— дип яза ул.— Хәлбуки, водевиль дөньясы — чынчыннан реаль дөнья, тик анда гадәттән тыш хәлләр генә адым саен очрап тора... Водевильнең персонажлары искиткеч гади һәм тормышчан кешеләр. Аларның үзенчәлеге шунда, алар һәрнәрсәгә бик тиз ышаналар. Водевиль персонажы үзенә бер дөнья белән яши, үзенең уй-хисләрен ул сүз һәм хәрәкәтләр белән генә түгел, ә җыр һәм бию аша да белдерә. Музыка, җыр һәм бию элементлары күп булуга карамастан, водевиль — һәрвакыт реаль сәнгать. Театр сәнгатен стильләштерүчеләр раслаганча, бу аның «шартлылыгы» түгел, ә поэзиясе... Бу авыр жанр: водевильдә тормыш чынлыгы һәм хисләр сафлыгы, усал сатира һәм көн кадагына сугу, нәфислек һәм шигърият, музыкальлек һәм ритмлык бергә йөри. Яшь актер өчен бу менә дигән өйрәнү мәктәбе».

«Күк капусы ачылса» водевилендә дә оста табылган детальләр һәм көтелмәгән ситуацияләр, көр күңеллелек һәм юмор күп, характерлы образлар шактый. Анда Г. Камалова, Н. Гайнуллин, Г. Надрюков кебек артистлар үзләренең бөтенләй көтелмәгән, яңа яклары белән ачылалар. Бөтен спектакльдән ниндидер бер җиңеллек, шатлык хисе, яктылык һәм күтәренке рух бөркелеп тора. Һәм, сүз дә юк, бу әсәрне сәхнәгә кую коллектив өчен зарури бер адым, аның палитрасындагы буяулар һәм төсләрне тагын да төрлеләндерү өчен үтә кирәк бер эш иде.

«Миркәй белән Айсылу» һәм «Шамил Усманов» драмаларын сәхнәләштергәндә исә театр бөтенләй башка мәсьәләләрне хәл итә. Аларның икесен дә сәхнәгә бер үк кеше (Марсел Сәлимҗанов) куя һәм үзе өчен үтә мөһим саналган мәсьәләне чишәргә — күп кеше катнашкан массовый күренешләр аша дулкынландырырлык бөтен бер сәхнә әсәре тудырырга омтыла. Кем дә инкарь итмәс: сүзсез рольләр башкаручы актерлар массасыннан һәрберсенең үз эчке дөньясы, тормыш юлы һәм характеры булган җанлы кешеләр тудыру теләсә нинди режиссер кулыннан килә торган эш түгел. Бу авыр мәсьәләне беренче тапкыр уңышлы хәл иткән кеше К. Станиславский булды. Аның бу эшен шәкертләре А. Попов һәм М. Кнебель дәвам итте. Сәлимҗановны исә Алексей Дмитриевич Попов укыта. Сәлимҗанов рус театрын үзгәртеп коручы Станиславский тәгълиматының әнә шул ягын аеруча яхшы үзләштергән. Югарыда исемнәре аталган әсәрләргә шушы позициядән чыгып якын килсәк, аларны бергә йөртү һич тә гаҗәп тоелмаячак. Тегесенең дә, бусының да үзәгендә — халык образы. Тик берсендә революциягә кадәрге, икенчесендә революция елларындагы татар халкы гәүдәләндерелә. Тегесендә дә, бусында да мәсьәләләрне халык хәл итә.

Бер караганда, революциягә кадәрге авылга багышланган, шәригатьнең рәхимсез кануннары һәм шуларга сукырларча иярүчеләр хакында сөйли торган әсәрдә бүгенге көн өчен кызыклы нинди әйбер булырга мөмкин, дип уйлыйсың. Әмма режиссер хезмәтенең кыйммәте дә шунда: ул спектакльне тирән драматизм белән сугарган, массовый күренешләрдә катнашучы сүзсез персонажларның образлары аша дини-хорафатлардан, кыргый гореф-гадәтләрдән котылып җитмәгән халык массаларының трагик хәлен күрсәтә алган. Академия театрының бу спектакле әнә шуңа күрә халыкның драматик язмышы турындагы тирән сәнгать әсәре буларак кабул ителә. Анда деспотлык морале, сыйнфый хорафатлар белән каршылыкка кергән яшьләрнең мәхәббәт тарихы, татар сәхнәсендә төрле вариантларда күп тапкырлар уйналган фаҗигале мәхәббәт бөтенләй яңа яктан ачыла.

...Караңгы залда салмак, моңлы көй яңгырый. Акрын гына пәрдә ачыла. Бөтен сәхнәне иңләп алган очсыз-кырыйсыз күк йөзе. Шул зәңгәр киңлекнең ямен җибәреп, ярым җимерек бәләкәй йортлар тезелеп киткән, алар кайдадыр аста, чокыр төбендә булып күренәләр. Башта әсәр салмак эпик темпта, акрын гына башланып китә. Әмма, зина кылуда нахакка гаепләп, ике яшь йөрәккә яла ягу моментыннан соң спектакль искиткеч киеренке, шомлы тон ала һәм ахырга кадәр шулай дәвам итә.

Мәчет алды. Авылның бөтен халкы шунда җыелган. Ике «җинаятьчене» хөкем итәләр. Аерым кешеләрне исәпләмәгәндә, аларның барысы да әлеге егет белән кыз турында алдан ук начар фикердә. Режиссер карап торышка бертөсле күренгән шул массаны төркемнәргә аерган, массовый күренештәге һәр кешегә индивидуаль характер сыйфатлары, үзенчәлекле гадәтләр бирә алган. Әлеге хәлне бертөрле бәяләүчеләр дә, вакыйгага карата һәркемнең үз мөнәсәбәте бар. Биредә без традицион массовканы түгел, ә шәригать кануннарына сукырларча ияреп бик нык алданган җанлы халык вәкилләрен күрәбез. Режиссер сиземләве нәтиҗәсендә, гомуми бурычлардан чыгып, әлеге күренешләрдә катнашкан һәр персонажга ачык, конкрет бурыч йөкләнгән һәм сүзсез персонажлар чын тере кеше булып күренәләр. Халык ураган түгәрәк эчендә мыскыллап-кыйнап эштән чыгарылган Миркәй белән Айсылу басып тора. Кемдер бераү, шаярган булып, Айсылуны чеметеп ала; шар күзле, чытык йөзле икенче бер фанатик, балта белән чабып үтерергә кирәк үзләрен, дип акыра; өченче бераү күңеленнән яшьләрне кызгана да, тик мулладан, диннән өркү аны да башкаларга кушылырга мәҗбүр итә; хатын-кызларның кайберләре нәфрәтләнгән булып кыланалар һәм туктаусыз чәрелдиләр, икенчеләре (андыйлар азчылык) кызны җәлли... Бәхетсез хәлгә тарган яшьләрне ачыктан-ачык якларга кодрәте җиткән кеше бөтен-

ләй юк диярлек. Тулаем алганда, безнең алда муллага ышанган гавам. Хәзер алар «эшкә» тотыначак. Йөгереп бау һәм корым китереп җиткерәләр, егет белән кызны бер-берсенә бәйлиләр, йөзләренә корым сөртәләр һәм, өстерәп диярлек, урам буйлап йөртергә алып китәләр. Алар артыннан халык кузгала: акырыш, сүгенү, сызгыру, каһәрләү, мәсхәрәләү. Хурлыктан, куркудан бүртенгән йөз белән ертык киемле Айсылу сөйрәлә, кыйналып, яраланып беткән Миркәй аңа булышмакчы була. Ләкин булдыра алмый. Аның йөзен, башын, бөтен гәүдәсен дөмбәсли башлыйлар. Мәхшәр, тәмуг...

...«Шамил Усманов» спектаклендә инде башка халык һәм башка тема белән очрашабыз. Монда сүз элек караңгылыкта изелеп яшәгән массаларның рухи үсеше, революция эше өчен актив көрәш юлына басуы турында бара. Әмма режиссерның төп максаты—алдагы спектакльдәге кебек үк, халык драмасын күрсәтү. Кыенлыгы, зур тәҗрибә һәм культура таләп итүе ягыннан, күп кеше катнашкан күренешләрне кую һәрвакыт режиссер осталыгына имтихан булып саналды һәм санала. Ул зур массаларны композицион яктан оештыра белүне, тулы әсәр белән аның аерым кисәкләрен бәйләүне, ягъни күп кеше катнашкан күренешләрнең идея юнәлешен ача белүне таләп итә. Театрның бу спектакле, андагы массовый күренешләр, персонажлар характерлары массаларда революцион аңның ничек туу процессын күрсәтүгә хезмәт итә.

Беренче пәрдәне күз алдына китерик. Мәчет алды тәртипсез, төрле киемдәге, төрле яшьтәге кешеләр белән тулган. Анда гармунга типтереп биюче сәләмә киемле, әрсез һәм үткен яшьләр дә, нәрсә әләксә шуны кигән сабыр холыклы намаз картлары да һәм кадровый хәрбиләр дә бар. Беренче карашка искиткеч тәртипсезлек хөкем сөрә кебек. Әмма бу буталчыклыкның үз мәгънәсе бар. Хәзергә монда һәркемнең үз тормышы, һәркем үзе тиеш тапкан эш белән мәшгуль. Яшь-җилбәзәк ишек алдын тутырып, мәш килеп бии, кемдер киемнәрен ямап утыра, өченче берәүләр көмит карый. Һәркемнең үз характеры, үз холкы: уен-көлке яратучылар һәм җәнҗал чыгаручылар да, булдыклы һәм җитди кешеләр дә бар. Чегән таборын хәтерләткән шушы чуар төркем ирекле татар батальоны дип йөртелә, ул әле яңарак оешкан һәм иртәгә Дутов бандаларына каршы сугышка чыгып китәргә тиеш.

«Миркәй белән Айсылу»дагы кебек үк, монда да режиссер һәр персонажның үз йөзен, биографиясен һәм характерын тапкан. Алар төрле юллар белән революциягә килгәннәр, менә бу батальонга язылганнар һәм тирә-юньдәге вакыйгаларга да төрлечә карыйлар. Һәрберсенең элек үз тормышы һәм язмышы булган. Вакытлар узу белән аларның аңы үсәчәк, алардан менә дигән көрәшчеләр чыгачак. Хәзергә исә һәммәсе диярлек үзенчә анархистлык, үзенчә тәртипсезлек белән аерылып тора.

Берәүләрен үгетләп, икенчеләрен төрткәләп, көч-хәл белән Мәхмүт Урманаев аларны стройга тезә. Өзлексез сөйләшәләр, хәрби командаларны аңлый алмый аптырыйлар. Азап белән тезелеп беткәндә генә манарадан азан тавышы ишетелә. Берничә кадровой солдаттан башкалары, бернигә карамый винтовкаларын ташлап, мәчеткә намаз укырга йөгерәләр. Ә бераздан, берни булмагандай, урыннарына кире кайталар. Менә шушы чуар, таркау толпадан сугышчан батальон оештырырга кирәк. Батальон тормышыннан алынган аерым моментлар мисалында режиссер бу кешеләрнең яңадан тууларын, аларда ил, революция язмышы өчен җаваплылык хисе үсүен күрсәтә алган.

Алдагы икенче-өченче күренешләрдә үк кемнең кем булуы ачыла башлый. Казакъ далаларындагы ниндидер бер станциягә туктауга, батальонга паровозга ягу өчен утын җыярга кушыла. Берәүләр эшли, икенчеләре тик тора. Кемдер базардан халат алып кайткан, үз тирәсенә халыкны җыеп шул хакта сөйли. Сүз арты сүз китә. Җылы якларны һәм йөзем җимешен сагынучылар табыла. Ташкентка китәргә теләүчеләрдән аерым группа оеша. Колакны ярырлык шау-шу, ызгыш-талаш башлана. Зур булмаган бер төркем, батальоннан аерылып, бөтенләй китеп бара. Күренештән күренешкә, пәрдәдән пәрдәгә без революция эшенә турылыклы калган солдатларның эчтән һәм тыштан ничек үзгәрүләрен күреп-сизеп торабыз. Әлеге чуар, төрлетөрле халык өйрәнеләп Кызыл гвардиянең сугышчан батальонына әйләнә, соңыннан Кызыл Армиянең интернациональ полкына килеп кушыла.

Бүген, Совет дәүләте төзелүгә илле елдан артык вакыт узганнан соң, драмада тасвирланган вакыйгалар ерак үткән булып тоела. Ә хәрби, тарихи темага караган

спектакльдә халык катнашкан күренешләрне чишүне, беренче чиратта, әлеге вакыйгаларда халыкның нинди роль уйнавын ачыклаудан, герой һәм массалар арасындагы мөнәсәбәтләрне ачудан башларга кирәк. Чөнки бөтен спектакльнең идея-сәнгатьчә яңгырашы шушы мәсьәләне ничек чишүгә бәйле. М. Сәлимҗанов куйган спектакльдә исә кеше һәм ил язмышы бер-береннән аерылгысыз.

Күп халык катнашкан күренешләр белән бергә, әсәрдә аерым шәхесләр язмышына багышланган моментлар да байтак. Монда Хәйрүш (Н. Гайнуллин) һәм Таҗетдин (Ф. Кульбарисов) кебек яшәүнең мәгънәсе хакында фәлсәфә корырга яраткан эпизодик образлар да, Ф. Халитов тарафыннан гаять оста иҗат ителгән Сәгдетдин карт та, ниһаять, Усманов (Н. Дунаев), Кәриб (Ә. Шакиров), Каюм (И. Багманов), Урманаев (Н. Әюпов) кебек төп каһарманнар бар. Халык күп катнашкан массовый күренешләрне оста эшләү белән бергә, персонажларның психологик характерларын ачуда М. Сәлимҗанов иҗатына хас тагын бер мөһим сыйфат күренә. Соңгысы М. Байҗиевның өч кенә катнашучысы булган «Хуш, Назлыгөл» исемле тирән психологик драмасын куйганда аеруча калку булып күренә. Үз геройларының эчке дөньяларына үтеп керү, әлеге өч кешенең темпераментлы, кайнар бәхәсе аша режиссер һәм актерлар тормышның, яшәүнең мәгънәсе, явызлык һәм гаделлек турындагы тирән фәлсәфи мәсьәләләрне чишәләр.

Соңгы елларда куелган иң уңышлы спектакльләрдән «Гүзәлем Әсәл»дә дә шушы ук мәсьәлә күтәрелә. Бу спектакль хакында күп сөйләнде, күп язылды. Билгеле булганча, бу спектакль өчен, режиссерга, художникка һәм дүрт актерга Тукай премиясе лауреатлары дигән мактаулы исем бирелде. Аның театр тормышында уңай якка борылыш турында сөйли торган беренче карлыгач булуы бәхәссез. Ул тагын бер ягы белән мөһим: анда ике яшь актер үз талантларының яңа яклары белән ачылдылар. Сүз Н. Гәрәева һәм Р. Таҗетдиновлар хакында бара. Аларның уены бөтен спектакльдә һәм үзләренең шәхси иҗатларында зур казаныш булды. Бу уңыш театрдагы яшь көчләрнең мөмкинлекләре зур булуын аеруча ышандырырлык һәм ачык итеп күрсәтте. Соңгы вакытта яшьләрнең репертуарга һаман саен активрак кертелүе очраклы күренеш түгел, билгеле. «Хуш, Назлыгөл»нең бөтен башкаручылары яшьләр. Р. Таҗетдинов һәм Н. Дунаевлар өчен бу спектакль әллә ни ачыш булмады, ә менә Г. Исәнгулованың Назлыгөле аның алга үсешендә зур адым итеп саналырга лаек. Нәкъ менә шушы әсәрдә ул үз иҗатының бөтенләй яңа якларын күрсәтә алды.

Мәсьәләгә шушы яктан якын килгәндә, Шекспирның берничә ел элек куелып, җәмәгатьчелек арасында күп шау-шу кузгаткан «Чамасына күрә чарасы» исемле (режиссер П. Исәнбәт) әсәре дә билгеле бер игътибарга лаек. Бу әсәргә бер генә ноктадан карап якын килү дөрес булмас иде. Спектакль турында чыннан да бәхәсләшергә мөмкин. Инде байтак еллар театрның бөек инглиз драматургы мирасына мөрәҗәгать иткәне юк иде. Шуңа күрә, бу факт үзе генә дә хуплауга лаек. Әсәрне сәхнәләштерү ахыргача уңышлы эшләнгән дип буламы? Юк, булмый. «Чамасына күрә чарасы» Шекспирның иң катлаулы пьесаларыннан. Ул искиткеч чуалчык һәм эзлексез драма. Анда бик әкәмәт төстә трагедия белән фарс, тирән фәлсәфи фикер белән гротеск, тупас көлү һәм сүгенү белән шигърият аралаша. Шекспир иҗатын өйрәнүче инглиз галимнәренең берсе үз вакытында бу әсәр турында хәтта: «Пьесаның һәм комик, һәм трагик яклары бертигез дәрәҗәдә биздерерлек, беренчесе — чирканыч, икенчесе — куркыныч»,— дип язган. Татар театры куйган спектакльгә шулай ук бөтенлек җитми. Әсәрнең комик ягы артык күпертелгән, һәм ул пьесаның башка якларын басып киткән иде. Әмма, ни генә булмасын, бу спектакльне бөтенләй яраксызга чыгарып сызып ташлыйсы килми. Спектакльнең кайбер уңай яклары, барыннан да бигрәк, яшьләр иҗат иткән кызыклы гына образлары бар иде. Шакировның Анджелосы, Шәрәфиевнең Герцогы, Гәрәеваның Изабелласы әнә шундыйлар. Шекспир драматургиясе белән очрашу әлеге артистларның киләчәк иҗаты өчен, һичшиксез, уңай роль уйнады.

Әзербәйҗан драматургы Җаббарлының «Айдын» әсәре дә тулысынча диярлек яшьләр көче белән сәхнәгә чыгарылды. Бу спектакльнең режиссеры А. Казимов үзе дә яшь, Ленинград театр институтын яңа гына тәмамлап кайткан иде.

Театрдагы яшьләрнең актив рәвештә алгы планга чыгулары тагын бер яктан

әһәмиятле. Аларның күбесе чын мәгънәсендә заманча һәм мәдәни булган олы һәм урта буын актерлары белән янәшә уйнау бәхетенә иреште.

Актер сәнгате һәрвакыт тамашачыга исәпләнгән була. Артист аерым шәхескә түгел, җәмагатьчелеккә мөрәҗәгать итә — бу актер сәнгатенең төп мөһим ягы. Тамаша залына, халык белән бергә, көн үзәгендә торган мәсьәлә дә килеп керә, ул театрга үз таләпләрен куя, бүгенге мәсьәләләргә җавап бирүне сорый. Шуңа да театр сәнгатенең бөтен тарихы буенча замандашлары аңламый һәм бәяләми калдырып та, соңгы буыннар тарафыннан даһига саналган бер генә артист та булмаган. Чөнки артист сәнгате искиткеч заманча сәнгать. Бу театр сәнгатенең үзенчәлеге белән бәйле күренеш, театр һәрчак тере кеше белән эш итеп, тамашачы белән күзгә-күз карап сөйләшә. Ә тамашачыны, ерак үткәндәге вакыйгалардан бигрәк, бүгенге көн мәсьәләләре күбрәк кызыксындыра. Актер үзен сәхнәгә чыгарган буын яшәгән чакта күренеп, тиешле бәясен алып калырга тиеш. Аның киләчәге — аның бүгенгесе. Нәкъ менә бүгенге кешеләр өчен генә иҗат итeлә, «һәр кич туып, һәр кич юкка чыга» торган сәнгать булганы өчен дә, аның бүгенге конкрет тормыш белән бәйләнеше искиткеч тыгыз.

Шуңа да безнең көннәрдә бөтен дөнья театр сәнгатендә заманча уйнау сәләте, бүгенге актер турында өзлексез бәхәсләр, фикер алышулар бара. Ул бәхәсләрнең булуы бик табигый күренеш, чөнки реалистик сәнгать яңа эчтәлек салып куя торган әзер формалар белән эш итми, үзе тасвирлый торган чор, чынбарлык тәэсирендә өзлексез үзгәреп тора торган тере организм. Ялган романтик пафос, ялган тәэсирләнү — бүгенге актер өчен ят нәрсә. Бүгенге актер тыштан тотнаклы. Әнә шул тышкы тыйнаклык артына чын темперамент һәм кайнар хис яшерелгән. Заманчалык, заманча актер уены турында академия театрында да күп уйланалар. Һәм без олы буыннан булсын, яшьләр арасыннан булсын чын мәгънәсендә заманча саналырлык әллә ничә исем турында әйтә алыр идек.

Башка күп кенә сәхнә әсәрләре белән бергә, «Айдын» спектакле дә нәкъ шул ягыннан аерылып тора. Әмма әзербәйҗан классигының бу әсәрен сәхнәгә куюдан икенче бер мөһим моментны да билгеләп үтәсе килә. Сүз мелодраматик жанрда язылган әсәрне заманча укый белү турында бара.

Җаббарлы пьесасы — катлаулы һәм ярыйсы ук куркыныч әсәр. Жанры буенча ул типик мелодрама, шуңа күрә режиссер аннан ике яшь йөрәкнең бәхетсез мәхәббәт язмышы турында сөйли торган гадәти мелодраматик спектакль эшләсә дә, берни әйтә алмас идең.

Режиссер башка юлдан киткән. Ул әсәрнең социаль ягына басым ясый. Нәтиҗәдә байлыкның кешеләрне гариплэндергеч көч булуын күрсәтү спектакльнең төп темасына әйләнә. Айдын белән Гөлтекинне ахыр чиктә нәкъ менә акча хәрап итә. Шуңа күрә режиссер да, артистлар да байлык, акча турында сүз барган күренешләргә аеруча нык басым ясыйлар. А. Казимов тапкан сүзсез күренешләр, персонажларның йөреш-килбәте дә шул ук фикергә буйсындырылган.

Менә миллионер Дәүләтбай малае һәм полицейский очрашалар. Әлеге бер сүз әйтелмәгән. Әмма полицейскийның аңа бик ярарга тырышып честь бирүеннән, э тегесенең горур һәм боеручан төстә баш кагуыннан ук аларның җәмгыятьтә тоткан урыннарын, капиталның һәм мөлкәтнең көчен аңлыйсың. Мондый күренешләр спектакльдә аз түгел.

Режиссер тарафыннан эшләнгән пролог һәм эпилог та әсәрнең гомуми яңгырашын көчәйтә төшә. Драматургик чыганактан аермалы буларак, режиссер әсәрдәге вакыйгалар агышын 1915—1917 еллар белән чикли. Спектакль башланганда сәхнә артында әлеге цифрлар күрсәтелә.

...Моңлы озын көй, әзербәйҗан халык көе яңгырый. Акрын гына пәрдә ачыла, тамашачы каршында иске Баку шәһәренең бер почмагы. Бер йортның биек стенасын һәм шуның янәшәсендәге баскычны сурәтләү аша, художник тауга таба күтәрелүче тар урамнар иллюзиясен бирә алган. Менә шушы тар урамда, таш баскычта шаулашып торучы халык. Мондый башлангыч безне шунда ук темпераментлы, гөр килеп торган шәрык шәһәре атмосферасына алып керә. Шуңа күрә төп геройларның язмышы да тормыштан аерым булып тоелмый.

Спектакльнең чишелеше дә аның гомуми пафосына бәйләнгән. Өч пәрдәдә дә декорация ике катлы итеп эшләнгән, аста Айдынның караңгы, салкын бүлмәсе, өстә казино, анда күз камашырлык якты, анда музыка, анда байлар типтерә. Һәм менә 1917 ел җитә, өске каттагылар куркып, каушап кала. Хәзер Айдыннар, аскы каттагылар көне килә. Соңгы сүзне элек аскы катта булганнар, халык әйтергә тиеш.

...Водевиль, психологик һәм халык драмасы, мелодрама — академия сәхнәсендә барган спектакльләр әнә ничек төрле-төрле. Шуннан формалар төрлелеге, сәхнә әсәрләренең күптөрлелеге, шуннан аларның кызыксыну уятулары килеп чыга. Тагын шул кадәресен шатланып әйтергә кирәк, күпчелек очракларда безнең спектакльләрнең формасы һәм эчтәлеге бер-беренә бик яхшы ярашлы булдылар.

Театрның иң кызык спектакльләреннән саналган «Кол» шуның матур үрнәге була ала. Ул, шулай ук, трагедия жанрын үзләштерүдә бер баскыч булып та тора. Театр гадәттә куеп килгән әсәрләрдән «Кол» үзенең стиле, рухы, жанры белән үк аерылып тора. Бу әсәрдә безнең актерлар күрергә гадәтләнгән тормыш-көнкүреш бөтенләй юк. Биредә сентиментальлек юк, җыр юк. Ул колның рәхимсез язмышы хакында кырыс тонда сөйли торган әсәр.

П. Исәнбәт куйган спектакльдә гади көнкүреш вакыйгаларына бөтенләй урын да юк, анда соң чиктә шартлы декорацияләр — ярым түгәрәк станок, бөтен сәхнәгә өч шәм. Режиссер игътибар үзәгенә актерны куярга теләгән.

Башка күп кенә постановкалардан аермалы буларак, татар академия театрының «Кол»ы соң чиктә эмоциональ, темпераментлы, кайнар рухлы булып чыкты. Биредә хисләр ташкыны, кайнар канлы кешеләр күрәшә. Һәм Эзопның азатлык өчен кайнар көрәше бөтен спектакльне чын мәгънәсендә заманча иткән.

Артистларга бу җиңел бирелмәгәндер, чөнки алар мондый пьесаларда уйнарга гадәтләнмәгән иде әле. Дөресен әйтергә кирәк, үз есләренә төшкән бурычны бу юлы алар уңышлы үтәгәннәр. Бу, беренче чиратта, Эзоп ролен башкарган Р. Таҗетдиновка карый.

Академия театры тормышындагы уңышлы күренешләрнең берсе тагын шунда: театр режиссура мәсьәләсендә дә бертөрлелектән котылып килә. Узган биш сезонда Г. Камал театрында читтән чакырылган өч режиссер — Т. Ходжаев, А. Казимов, М. Новохижин — спектакль куйды. Билгеле, төрле режиссерлар белән очрашып, артистлар үз уеннары, үз иҗатлары өчен күп нәрсә алалар. Әйтик, Н. Гәрәева Әсәл ролен башкарганнан соң гына Гөлтикинне, ә Ш. Әсфәндиярова үзенең Тугинасын Хәдичәдән соң гына уйный алды. Андый мисаллар бик күп. Шулар өстенә, театр эшкә бөтен бер труппаларны чакыра башлады. «Гүзәлем Әсәл»дә, «Соңгы корбан»ны куйганда шулай булды: режиссердан тыш, Кече театрының күренекле художнигы Ф. Волков чакырылды. «Айдын» спектаклен режиссер А. Казимов, художник М. Сагиян, композитор Ф. Әмиров куйды. Өчесе дә Бакудан. Мондый алым спектакльләрнең культура дәрәҗәсен дә күтәрә. Сүз дә юк, мәсәлән, Ф. Волков кебек танылган, тәҗрибәле художник безгә күп нәрсә бирде.

Г. Камал театрындагы тенденцияләр турында сөйләгәндә, аларга хас төп линиягә — коллективның бәхәссез үсүенә, алар башкарган эшнең уңай якларына тукталасы килде. Чөнки бүгенге академия театрының йөзен нәкъ әнә шул сыйфатлар билгели. Шулай да, халык әйтмешли, барысы да ал да гөл генә түгел. Театр куйган ике дистәдән артык спектакль арасында урта куллары, хәтта начарлары, кирәксезләре очрый.

Кайберәүләр театрда комедияләр белән мавыгу тенденциясенең көчәюен күрсәтәләр, мисалга «Кыю кызлар», «Американ», «Илһамия» кебек әсәрләрне китерәләр. Әмма исәпли башлагач, комедияләрнең алай күп булмавын күрәсең. Исемнәре саналган 30 лап яңа әсәр арасында 7—8 генә комедия булды. Бу, бәлки, артык күп түгелдер.

Сүз дә юк, театр өзлексез эзләнә, репертуарны киңәйтү, әсәрләрнең географиясен, иҗади горизонтларын киңәйтү өчен тырыша. Режиссерлар яңа формалар эзлиләр. Ниһаять, актерлар эзләнә. Беренче планга яшьләрнең күтәрелүе характерлы. Театрга тамашачының актив йөри башлавы куандыра һәм тагын да җаваплырак эшләргә мәҗбүр итә.

**Сәлам Алишев,**
тарих фәннәре кандидаты

# КРЕСТЬЯННАР СУГЫШЫНДА ТАТАРЛАР

Россиядә феодализм строеның җимерелү чорында дүрт мәртәбә крестьяннар сугышы булып уза. Алар тарихта Болотников восстаниесе (1606—1607 еллар), Разин восстаниесе (1667—1671), Булавин (1707—1709) һәм Пугачев восстаниесе (1773—1775) буларак билгеле. Шуларның зурларыннан саналган Степан Разин восстаниесе узганга быел 300 ел тулды.

Моннан 300 ел элек бабаларыбыз — рус, татар, чуваш, мордва, мари һ. б. милләт крестьяннары — кулларына корал алып, җирбиләүчеләргә, милли-колониаль изү политикасы үткәргән администрациягә каршы гражданнар сугышы башлап җибәрделәр.

Аның иң көчле, кызган, күп халыкны үз эченә алган вакыты һәм урыны 1670 елда Идел буенда була. Разин восстаниесен өйрәнү өчен, бигрәк тә аңа татарларның кушылуы турында, материаллар күп сакланмаган. Аларның табылган өлеше 3 томлык документлар җыентыгында 1954—1962 елларда басылып чыкты.

Совет тарихчылары 1667—1671 ел крестьяннар сугышы буенча тирән һәм киң эзләнүләр, тикшеренүләр алып баралар. Шулай да, С. П. Порфирьевның революциягә кадәр язылган «Разинщина в Казанском крае», 1923 елда «Безнең юл» журналында Г. Гобәйдуллинның «Стенька Разин һәм татар крестьяннары» мәкаләләрен һәм «Татарстан АССР тарихы» китапларында Степан Разин җитәкчелегендә крестьяннар сугышы турында булган бүлекчәне исәпкә алмасак, татарларның восстаниедә катнашулары хакында махсус киң тарихи тикшерену булганы юк әле.

Төрки кабиләләрдән оешкан төрле халыкларны европалылар һәм руслар электән үк инде татар дип йөрткәннәр. Мисал өчен Түбән Идел буенда ул вакытта күчеп йөргән татарларны алырга була. Астрахань татарларын элек ногай татарлары дигәннәр. XVII—XVIII гасырларда алар Кундроу, Юрт, Едисан, Буджак һ. б. вак төркемнәргә

бүленеп бетәләр. Разин восстаниесе турындагы документларда телгә алына торган Юрт (юртовские) татарлары һәм морзалары XVII гасырда көчмә феодализмның патриархаль ыруг мөнәсәбәтләре белән бәйләнгән чорын кичерәләр. Алар восстаниеда катнашмыйлар. Рус хөкүмәтеннән куркалар һәм аңар ярдәм итәргә тырышалар. Мәсәлән, Маркашев дигән морзаның тол калган хатыны белән мәлае Мостафа, Разин атаманы Щелудякны тотып биргән өчен, патшадан жалование сорап яза. Астрахань татарларының бер өлеше Степан Разинга каршы сугышучы хөкүмәт гаскәрләре составында да була[1].

Едисан һәм Ямбулат татарлары восстание вакытында Астраханьнан качкан рус дворяннарын үзләрендә яшерәләр һәм Мәскәүгә озаталар. Хөкүмәт файдасына шуның кебек башка эшләр эшлиләр. Касим ханы (курчак патшалыгы) Василий Арсланович шундый ук позициядә була. Ул үзенең коралландырган сотнясын восстаниечеләргә каршы җибәрә. Халык арасында хөкүмәт файдасына агитация алып бару, восстаниечеләрнең торышын тикшерү, разведка ясау өчен татар морзаларыннан Буршич Бубеков, Степан Толкачев, Курмыш абыз[2] һәм монах Аврам Агапов җибәрелә. Мөселман һәм христиан руханиларыннан Курмыш абыз белән монах Агаповның, морзалар белән бергәләп, восстаниегә күтәрелгән халыкка каршы чыгулары ул чор өчен бик характерлы күренеш. Ул вакытта Урта Идел буе татар җәмгыятенең сыйнфи социаль аерымлануын ачык күрсәтә. Эксплуататор сыйныф вәкилләре булган бу кешеләргә баш күтәргән крестьяннарның мөнәсәбәте ачык була: яңа чукынган морза Толкачевны дүрт кисәккә (башта аяк-кулларын, аннан башын) чабып, калган икесенең башларын кисеп үтерәләр. Касим морзалары белән беррәттән, Казан татарлары һәм мишәрләрнең бер өлеш йомышлылары да баш күтәргән халыкка каршы көрәш алып бара. Ә икенче бер өлеше восстаниедә актив катнаша.

Йомышлы һәм ясаклы Казан татарларының крестьяннар сугышында катнашулары Идел буеның башка халыклары белән чагыштырганда катлаулырак күренеш. Бу аларның социаль-экономик хәленнән һәм патша хөкүмәтенең милли-колониаль изү политикасы үткәрүеннән килеп чыга.

Рус хөкүмәте яклы булган татар морзаларының бер өлеше, Казан алынганнан соң, Россиянең төрле өлкәләренә, шулар рәтеннән — Арзамас, Темников, Керенск, Воронеж, Ломовск, Алатырь, Касим, Козьмодемьянск һ. б. өязләргә күчереп утыртылалар. Аларга хәрби хезмәтләре өчен җир участоклары һәм крестьяннар бирелә.

XVI гасыр ахырына кадәр крепостной крестьяннарга хуҗа булу алпавытның кайсы милләттән булуына бәйләнмәгән, рус алпавыты кулында татар, татар морзаларында рус крепостной крестьяннары булган. 1593 елда татар бистәсендә чиркәү салырга, мәчетләрне җимереп бетерергә һәм рус кешеләренә «татарларда торуны» тыярга дип патша указы чыгарыла. XVII гасыр башында башланган крестьяннар сугышы һәм аңардан курыккан хөкүмәтнең соңыннан бераз саграк социаль политика үткәрүе нәтиҗәсендә, бу указ бик акрынлык белән тормышка ашырыла. Әмма 1620—1630 елларда татарларны руслаштыру һәм милли чикләүләр тагын да көчәеп китә. 1633 елдан башлап Казан татарларына металл эшкәртү һәм корал ясау, алар белән сәүдә итү тыела. 1649 елгы Собор уложениесе буенча, татар йомышлыларына һәм морзаларына рус крестьяннарын крепостнойлыкта тоту кабат тыела. Чукынган морзалар гына крестьяннарын һәм җирләрен үз кулларында калдыра алганнар.

1660 елда моңа кадәр яшәп килгән тарханлык (феодаль иммунитет яки феодаль хуҗалыкның кагылгысыз булуы, һәртөрле салымнардан азат ителү) бетерелә. Бу татар феодалларының өстенлек алган өлеше бетерелә дигән сүз. Татар морзаларына булган мөнәсәбәтнең үзгәрүен тагын шуннан да күрергә мөмкин: 1613 елда Романовны патша итеп сайлау соборында татар морзаларына катнашырга рөхсәт ителә һәм патша сайлау актына 8 татар морзасы да кул куя, ә 1649 ел законнар җыентыгы — «Уложение» — төзү соборына татар феодалларының берсе дә кертелми.

Менә ни өчен ислам динендә калган татар җир биләүчеләренең бер өлеше хөкүмәткә оппозициядә була һәм алар XVII гасыр крестьяннар сугышына да катнашалар.

---

[1] Степан Разин җитәкчелегендә крестьяннар сугышы. Рус телендә. М. 1957. I т., II т., III т.

[2] Абыз дип татарларның укымышлы кешеләрен олылаганнар.

Татарның түбән сыйныфы тагын да ачулы булган. Бер өлеш крестьяннар алпавытлар кулында крепостной хәлдә булса, ясаклы крестьяннарның җирләрен исә һәртөрле юллар белән алпавыт, монастырь һәм гаскәриләр тартып алганнар. Моның өстенә татар крестьяннары башкаларга караганда да күбрәк төрле салымнар түләргә тиеш булалар. Элек татар крестьяннары эшкәрткән җирләр авыллары белән рус алпавытлары һәм монастырьлар кулына күчә бару процессы түбәндәге саннарда күренә. Поместье җирләре гасыр башындагыга караганда ике мәртәбә арта. Казан өязендә генә дә 1646 елда 334 рус алпавыты була, Казан һәм Зөя өязләрендәге 50 авыл архиерей һәм монастырьлар кулына күчә.

Крестьяннарны гомуми изүнең көчәюе XVII гасырда бөтен Россия эчке базары барлыкка килү белән дә бәйле. Товар-сәүдә мөнәсәбәтләре үсү белән, феодалларның шәфкатьсезлеге дә арта бара. Товар булдыру өчен акча, акча булдыру өчен крестьян хезмәте кирәк. Крестьян хезмәтен эксплуатацияләү турыдан-туры алпавытлар тарафыннан да һәм алар файдасына эшләгән дәүләт тарафыннан да алып барыла. Әнә шул эксплуатация лагерена каршы Россиянең күп милләтле крестьяннар сыйныфы күтәрелә. Алар XVII гасыр дәвамында сыйнфый көрәшне туктатмыйлар, ә 1670 елда аның иң югары ноктасы булган крестьяннар сугышы башланып китә.

Татар крестьяннары бу сугышта башка халык крестьяннары белән бергә, кулгакул тотынышып көрәшәләр. Бу турыда төрле документлар ачык сөйли. Хөкүмәт гаскәрләре башлыгы Ю. Барятинский үзәккә җибәргән рапортында «казаклар, татарлар, чувашлар, черемислар (мари) һәм мордва караклары бергә җыйналып сугышталар»,— дип яза, икенче бер документта «карак татарлар һәм чувашлар байларны үтереп бетерергә уйладылар»,— диелә, һәм мондый язмалар күп документларда күренә. Идел буе халыклары, Степан Разин хәрәкәте турында ишетү белән үк, баш күтәрәләр. Моның өчен сигнал гына кирәк була. Мәсәлән, 1668 елның апрель аенда Пенза өязендә баш күтәрүчеләрнең бер отряды — «15 кеше, күбесе татар»,— хәрәкәт итә. Мондый отрядлар башка урыннарда да аерым алпавытларга каршы да, хөкүмәт гаскәрләренә каршы да көрәш алып баралар. «Шул ук 1668 елның май аенда,— дип күрсәтелә тагын бер язмада — башкортлар һәм татарлар күбәүләп җыелып Инсар шәһәренә сугыш белән киттеләр».

Крестьяннар хәрәкәтенең төп лозунглары «Җир һәм ирек» була. Алар, үзләрен изүче җирле администрациягә һәм алпавытларга каршы көрәшеп, бөтен крестьяннар сугышына антифеодаль характер бирәләр. Сугышның мондый характерын төрле вакытта язылган документлар раслый.

Кайбер крестьяннар Степан Разин Астраханьда вакытта ук аның отрядына кушылалар. Шундыйлардан Чаллы крестьяны Савка Онуфриевны күрсәтергә була. Ул 1662 елда Чаллы крепостен татар-башкорт отряды җимергәч, җиде ел Казанда төрле хезмәттә, бер ел Спасс монастыренда бобыль булып тора һәм Разин восстаниесе турында ишеткәч, бурлак булып яллanып, восстаниенең үзәге булган Царицын һәм Астраханьга барып җитә, актив көрәшүчеләрнең берсе буларак, казаклар арасында есаул булып сайлана [1].

Үзләренең морзаларына каршы көрәшне Кадом өязендә алпавыт Сафәр Ишмуратов авылы — Курмай крестьяннарының чыгышы ачык күрсәтә. Алар үченнән исән калган Кильмәш Агишев үз крестьяннары өстеннән жалоба биреп, «Курмаево Починки авылы крестьяннары минем йортымны җимерделәр, барлык милкәтемне таладылар, бер туганымның улын — Айдаш Мустаевны үтерделәр»,— дип яза [2]. Крестьяннарның баш күтәреп чыгулары турында шулай ук Касим ханы Василий Арсланович, татар морзасы князь Яков Енгалычев һ. б. өяз морзаларының кайберләре тарафыннан хөкүмәткә бирелгән жалобаларында языла.

Идел буе халыкларының восстаниегә бердәм кушылуы Степан Тимофеевич Разинның Урта Идел буена, Мәскәүгә юнәлү өчен, Сембер шәһәренә килүе вакытында, 1670 елның җәй айларында башлана һәм ул 1671 елгача дәвам итә. Сембергә таба

---

[1] Степан Разин җитәкчелегендә крестьяннар сугышы. Рус телендә. I т. М. 1954. 269 бит.

[2] Шунда ук. III том. М. 274 бит.

юнәлгәндә һәм Сембернең үзеннән Степан Разин Казан татарларына берничә мәртәбә хатлар җибәрә һәм аларны восстаниегә кушылырга чакыра. Рус булмаган халыкларны восстаниегә күтәрү эшендә Степан Разинның якын ярдәмчеләреннән Хәсән Карачуринның роле зур була. Степан Разин Сембер шәһәренә килеп җиткәч, Кадом өязе йомышлы татары Хәсән Айбулат улы Карачурин татар, рус, мордва крестьяннарыннан отряд оештырып, аңа барып кушыла. Ул заманнан калган документлар Хәсәнне төрле милләт крестьяннарының атаманы, көчле энергияле җитәкче итеп сурәтлиләр. Ул, казак, рус, мордва атаманнары белән бергә, алпавытлар властена каршы зур көрәш юлына баса.

Степан Разин, җәзалап сорау алганда: «Хәсән мине Казан ягына барырга өндәде, баш күтәрүчеләр һөҗүм иткәндә, Казан татарлары тик ятмаслар, дип чакырды»,— дигән[1]. Димәк, Хәсән Казанны азат итәргә тырышкан.

Хәсән Айбулат улы Карачурин, Степан Разин әйтүенә караганда, озын буйлы, кара сакаллы, яңагында чабылган яра эзе булган. Бу яра эзе кайдан килгән? Бәлки ул моңа кадәрге восстаниеләрнең берсендә катнашкан һәм шул вакыт җәрәхәт алгандыр? Мондый вакыйгалар ул вакыт еш булган. Мәсәлән, князь Иван Дусай улы Енгалычев 1662 елда Мәскәүдә булган восстаниегә — «бакыр бунтына» катнаша. Шуның өчен аны кыйнап Псковка сөргәннәр. Сөрген срогын тутырып кайткач, ул Темников өязендәге утарында яши. «Степан Разин восстаниесенә катнашканы өчен аның җирләрен миңа бирегез»,— дип, аның күршесендәге алпавыт Слепцов Енгалычев өстеннән жалоба яза. Карачуринның да шундый ук язмышка дучар булуы мөмкин.

Хәсән Карачурин Степан Разинның якын көрәштәше, баш күтәрүчеләрнең зур атаманы була. Хәсәннең Разин исеменнән Казан татарларына мөрәҗәгать итүе дә бу хакта сөйли.

Разинның «прелестные письма»лары, восстаниегә чакырып язган хатлары татарлар арасында да бик күп тарала. Ләкин аларның сакланып калган кадәресе бары алты гына. Шуларның берсе татар телендә. Аның авторы — Хәсән Айбулат улы Карачурин. «Олуг чирүдән[2], Степан Тимофеевичтан, мәгълүм булсын,— диелгән ул хатта,— сезки Казан бистәсе мөселманнарына һәм мәчет башы абызларга барча әһеле исламга һәм фәкыйрь вә колларга мәрхәмәт итүче Икшей муллага һәм Мамай муллага һәм Ханыш мирзага вә Москов мирзага, вә барча абызларга, вә барча бистә һәм өяз мөселманнарына Степан Тимофеевичтан... сәлам. Сәлам соңында, бездән хәл-әхвәл сорасагыз, без сәламәтбез һәм сездә сәг булгай идегез. Сүземез шулдыр: тәңре, пәйгамбәр һәм патша, вә гаскәр өчен сез безнең белән бергә булгай идегез. Әгәр бергә булмасагыз, соңра безгә үпкәләмәгез. Тәңре шаһиттер, кем сезгә бер төрле дә начарлык булмас, вә без сезнең өчен тырышабыз. Янә мәгълүм булгай иде: мин, Хәсән Айбулат углы, Степан Тимофеевич ягында һәм безгә бу хакта ышаныгыз. Мин, Хәсән, бу тугрыда сезгә нәсихәт әйтәм. Әгәр миңа инансагыз начар булмас. Барчаңыздан үтенәм. Кем ходайга безнең өчен дога кылыңыз, бездән сезгә сәлам. Бу язуга мөһеремне бастым»[3].

Мондый хатлар Иделнең тау ягында да, сул якта, болын ягында яшәүче татарлар арасында да киң таралганнар. Моңа төрле дәлилләр бар. Мәсәлән, бер документта Каратай авылыннан Иштирәк абызның болын ягы татарларына язган хаты турында сөйләнә. Иштирәк абыз үзенең иптәшләрен — татарларны, чувашларны үзара атышмаска, Иделнең ике як «морзалары — татарлары һәм чувашлары бер-бер булып» Степан Разинга кушылырга үгетли һәм шул турыда русча, татарча хатларны юкә каерысына төреп, ком өстенә куеп калдыра.

Димәк, восстаниегә кушылырга чакырып хат белән халыкка мөрәҗәгать итүчеләр бер Карачурин гына булмаган. Карачурин язган хатның күчермәсе сакланып калган, ә башкалар безгә кадәр килеп җитмәгәннәр.

---

[1] Степан Разинның допроста сөйләгән сүзләренә 3 кенә күрсәтү бар: 1) туганын асканы өчен боярларны күрә алмавы, 2) сөрелгән патриарх Никон турында һәм 3) Хәсән Карачурин хакында.

[2] Чирү — гаскәр башлыгы.

[3] Русчадан текстның тәрҗемәсен Г. Газиз эшләгән. «Безнең юл». 1923. № 8—9. 31 бит. Хатның татарча тексты (төп нөсхә) сакланмаган.

Карачурин, әлбәттә, агитация эше белән генә шөгыльләнеп калмаган. Ул, отряд оештырып, Разин белән бергә, патша гаскәрләренә каршы Сембер тирәсендә сугыш алып барган. Сембер янында Разин гаскәрләре җиңелеп, Донга чигенгәч тә Хәсән көрәшне дәвам иттергән. Корсуньда ул тагын зур отряд оештырган. Ул отряд татар, чуваш, мордва һәм рус крестьяннарыннан торган, анда баш күтәрүчеләрнең саны 6 мең кешедән гыйбарәт булган. Ләкин 24 октябрьда бу отряд Барятинский командалык иткән хөкүмәт гаскәрләре тарафыннан таркатылган. Шулай да Барятинский бу сугыштан соң Саранскига таба бара алмыйча, ярдәм килүен көтәргә мәҗбүр булган. Димәк, Карачурин отряды хөкүмәт гаскәрләрен шактый зәгыйфьләндергән һәм ул крестьяннар белән яңа очрашулардан курыккан.

1670 елның ноябрь ахырында Усть-Урень бистәсе янында Дон казагы Ромашка һәм Хәсән Карачурин командалыгында 15 меңлек баш күтәрүчеләр гаскәре тупланган. Документта күрсәтелгәнчә, монда «Самара, Саратау, Саранск, Пенза, Алатырь, Курмыш һ. б.» өязләрдән төрле милләт крестьяннары җыелган булган. Хөкүмәт гаскәрләре белән сугыш вакытында крестьяннар бу юлы да җиңелгәннәр, ә батыр атаман «Мурзакайко» яраланган[1]. Ләкин 7 декабрьда ул, Алексей Савельев белән бергә, тагын зур гаскәр җыеп, Алатырьга таба, хөкүмәт гаскәренә каршы юнәлә. Алар 8 декабрьга 20 меңлек крестьян армиясе җыялар. Шул ук көндә Ю. Долгорукий куп астындагы армия белән көчле сугыш иртәдән кичкә кадәр дәвам итә.

Ю. Долгорукий патшага язган хатында: «Без 68 әләм, 20 туп кулга төшердек, бихисап күп восстаниечеләрне кырдык, качучыларны 25 чакрым буена куып, барысын туракладык»,— дип яза. Крестьяннарның җитәкчеләре Савельев Пенза ягына таба кача, «Асан Айбулатов сын Карачурин» мордва авылы Костяшевога яшеренә. Ләкин озакламый, декабрьның икенче яртысында, аны стрелецлар башлыгы Колобов Ю. Долгорукийга тотып китерә. Ю. Долгорукий: ...Мин аны четвертовать[2] итәргә куштым»,— дип, патшага хәбәр итә.

Ләкин соңрак табылган материаллар икенче төрле дә сөйлиләр. Имеш, Степан Разинның сорау вакытында сөйләгәннәреннән соң, Хәсәнне эзләргә Мәскәүдән шымчы Алексей Лукин җибәрелгән булган. Хәсән аңардан качкан һәм каядыр китеп югалган. 1693 елда да аның кайдалыгы билгеле түгел, дигән сүз бар. Безнеңчә, беренче мәгълүматлар дөрес булырга тиеш. 1693 елда Хәсән турында хәбәр бирүчеләргә ул мәгълүматлар, мөгаен, билгеле булмагандыр.

Шул уңайдан әйтергә кирәк, Хәсән Карачурин турында булган мәгълүматларның төп өлеше аның улы Әнәс аркасында сакланып калган.

Хәсән китеп югалгач, аның җирләре Мәскәү стрелецлары башлыгы Гермоген Вешняковка бирелә. Хәсәннең семьясы да тарала. Ата-аналары үлгәч, яшь малай Әнәсне Вешняков үзенә алып чукындыра. Инде үсеп җиткәч, 1693 елда, Әнәс, әтисенең восстаниегә катнашканын инкарь итеп, «Аның җирләрен дөрес алмаганнар, аларны миңа кайтарыгыз»,— дип, дәгъва кузгата.

Әнә шул дәгъваны кире кагу өчен һәм Гермогенның оныгы Александр Вешняксены яклау өчен Карачуринның восстаниегә катнашуы турында документаль материал җыела һәм алар Казан сарае приказының Керенск воеводасы Чубаревка бирелгән грамотасында язылып калалар. Әлбәттә, Әнәс Карачуринның дәгъвасы кире кагыла...

* * *

Татар крестьяннары башка отрядларда да булып, төрле җирдә, бигрәк тә Иделнең тау ягында, хөкүмәт гаскәрләренә каршы көрәш алып барганнар. Мәсәлән, Сура елгасы буенда татар, чуваш, мари, мордва крестьяннарының 15 мең кешелек отряды Цивильскидан 7 чакрымда лагерь булып урнаша һәм шәһәрне камап ала. Шәһәрне хөкүмәт гаскәрләре берничә айдан соң гына баш күтәрүчеләр камавыннан коткаралар.

---

[1] Хәсән Карачурин ул вакыт рус документларында Осай, Асан, Анай, Акай, Мурзакай, Мурзакайко дип төрлечә йөртелгән.

[2] Четвертовать — баштан уң кулын, аннан сул кулын, аякларын һәм башын кисү.

Восстаниечеләрнең татарлардан һәм чувашлардан торган бер отряды «Зөя татарларының баш кешесе, татарин Алмакай» җитәкчелегендә була. Ул Цивильскины алырга баруы турында әйтеп манифест-өндәмәләр тарата һәм барлык крестьяннарны үзенә кушылырга чакыра.

Сакланып калган документларда икенче бер отряд турында мондый мәгълүматлар бар: «Казаклар белән бергә Керенскига Каргалы татарлары килде, алар байларны, крестьяннары булган морзаларны талап йөрделәр. Каргалының баш кешесе татарин Чапкун һәм Дарузай абыз балалары, Бабич алар белән җитәкчелек иттеләр».

Ә Темников шәһәре абызы Исмаил Исяшев үзенең утызлап иптәше белән (Ишелей Ертышев, Шимай Ишелеев, Санбай Елмасов һ. б.) алпавытларга каршы сугышып йөри. Шунысы характерлы: бу отрядта рус крепостной крестьяннары да була. Алар барысы да хөкүмәт гаскәрләре тарафыннан куып таратылалар, ә фамилияләре күрсәтелгәннәре әсир итеп алыналар. Темников өязендә восстаниегә шулай ук морза князь Дусай Булаев та катнаша.

Ә 1671 елның гыйнварында Цивиль өязендә татарлардан, чувашлардан һәм марилардан төзелгән отрядларда өч-дүрт мең кеше булып, аларның атаманнары Яндри авылыннан Изелбай, Милшейка, Сурбеево авылыннан Токтамыш, Аслип Айдуганов, Чемей Чювков, Нурусово авылыннан Изелбай, Кибәкче авылыннан Чурабай Чуракин һ. б. булган. Бу отрядларның бер өлеше Алатырьга һөҗүм итә. Алатырь янында көчле сугыш була.

Документлар күрсәткәнчә, төрле халык крестьяннарының баш күтәреп чыгуы Иделнең уң як яр буенда көчле була, ә сул як ярда, Казан өязенең үзендә, восстание күтәрүче крестьяннарның актив хәрәкәте турында документлар юк. Ләкин шуны истә тотарга кирәк, беренчедән, крестьяннар хөкүмәт җәза отрядларының, аерым чиновникларның кәгазьләрен кулга төшерсәләр, яндыра торган булганнар. Икенчедән, Казан шәһәренең өяз өчен генә түгел, ә бәлки, бөтен Идел буенда баш күтәрүчеләргә каршы көрәшнең төп үзәк пункты булуы да роль уйнагандыр.

Патша хөкүмәте С. Разинның беренче күтәрелеп чыгу вакытында ук әле аңа каршы төрле хәрби чаралар күрә.

1670 елның җәендә, С. Разин гаскәрләре Идел буйлап үзәккә таба юнәлгәч, хөкүмәт баш күтәрүчеләргә каршы князь Урусов командалыгында армия җибәрә. Шул ук вакытта князь Ю. Барятинский Казанга килә. Тиздән Казан восстаниегә каршы көрәшнең төп үзәгенә әверелә. Мәскәү белән ике арада элемтәне баш күтәрүчеләрнең төрле отрядлары Идел буенда Нижний Новгород тирәсендә өзәләр. Нык крепосте булган, зур гарнизонлы дворяннар Казаны үз көчләре белән Разинга каршы торырга тиеш була. Князь Барятинский Казаннан Сембергә барганда крестьян отрядларын туплардан атып тарката, тотылганнарын аса, кисә. Ул 20 сентябрьдә Коланга авылы янында казак, татар, чуваш, мари, мордвалардан торган 3000 кешелек атлы һәм җәяүле отряд белән сугыш булуы, тотылган 67 кешене астыруы турында яза. 23 сентябрьдә Карлы буенда (Буа янында) баш күтәрүчеләрнең икенчеләре белән көчле сугыш булып, әсир төшкән 18 крестьян асып үтерелә. 24 сентябрьдә Барятинский Кырыксадак авылы янында татар, чуваш, мари казаклары отрядын тар-мар итә һәм шул сугышлар аркасында көчсезләнеп, 1 октябрьдә генә Сембер шәһәре янына килеп җитә. Казаннан Сембергә барып җиткәнче, ул восстаниечеләр отрядлары белән 12 мәртәбә сугыша. С. Разин, 3 октябрьдә җиңелеп, Донга китеп барса да, Казан тирәсендә крестьяннар сугышы тукталмый. Баш күтәрүчеләр декабрь аенда Зөя һәм Тәтеш тирәсендә күп булып тупланалар. Декабрь башында Тәтешкә һөҗүм итеп, алар андагы администрацияне кырып бетерәләр. Чути авылы янында да хөкүмәт гаскәрләре белән көчле сугыш була.

Югарыда төрле халык крестьяннарының Цивиль янында алып барган көрәше турында әйткән идек. Шундый ук хәлләр Тау ягындагы башка өязләрдә дә күп була.

Ләкин торган саен көчәя барган хөкүмәт гаскәрләре, восстаниечеләрнең төрле отрядларын тарката барып, 1671 елның язында крестьяннар сугышын бастыралар. Восстаниегә кушылган крестьяннардан һәм йомышлылардан дворяннарның үч алуы башлана. Әгәр восстаниене бастыруда төп көч булып регуляр гаскәр торса, баш күтәрүчеләрне эзәрлекләү һәм җәзалауны дворяннарның җәза отрядлары башкара.

«Толубай Еникеевның җалобасы буенча аның крестьяны Денис Григорьев асып үтерелде».

«Азеева авылы татары Максим Кондратьев, рус крестьяннары Данила һәм Ивашка белән бергә, Лачиновларның җалобасы буенча асып үтерелде».

«Муралей морза Теребердеев крестьяны Левка Гурьев чыбыркы белән кыйналды һәм аның сул кулының бармагы чабып өзелде».

Мондыйларның исемлеген күп китерергә мөмкин булыр иде. Ләкин китерелгән хәтлесе дә, восстание җиңелгәч, крестьяннардан үч алу картинасын шактый тулы ачып бирә.

Татар йомышлыларының восстаниегә кушылганнары юкка чыгарыла, җирләре тартып алына һәм алпавытларга бүлеп бирелә. Алпавытлар үзләре дә, күбрәк җир эләктереп калу өчен, алар өстеннән җалобалар яудыралар.

Хезмәт иясе крестьяннарның язмышы, әлбәттә, тагын да аянычрак булган: аларны төркеме-төркеме белән асканнар, авыллары белән яндырганнар. 1671 елның апрелендә Дондагы бай казак старшиналары төрле милләт крестьяннарының атаклы юлбашчысы С. Разинны тотып Мәскәүгә бирәләр. Ул, искиткеч каты җәзалардан соң, шул ук елның 6 июнендә Кызыл мәйданда үтерелә.

Восстание төрле милләт крестьяннарын берләштерә. Бу көрәштә крестьяннар таркаулык, караңгылык эчендә яшәү, төп максатларны аңламау, шәһәр эшчеләре кебек союзниклары булмау нәтиҗәсендә җиңелсәләр дә, алар арасында сыйнфый бердәмлек, дуслык ныгый. Шуңардан курыккан патша хөкүмәте ясаклы крестьяннар җирен тартып алу фактларын кыскартырга, башка милләт халыкларын ачуландырмаска тырыша башлый. Ләкин урындагы администрация һәм дворяннар халыкны изү чараларын көчәйтү ягын гына карыйлар. Феодаль-колониаль изүнең йомшармавы татар һәм башкорт крестьяннарының 1673 елда яңадан дәһшәтле восстание башлавына сәбәп була.

# ПИРАМИДАЛАР ИЛЕНДӘ

Без күрергә күптән хыялланган Мисыр җирендә.

Укый-яза белә торган һәр кеше Мисыр тарихы белән азмы-күпме дәрәҗәдә таныш. Борынгы Мисырның куәте, аның тарихи истәлекләре һәркемне кызыксындыра. Берләшкән Гарәп Республикасы — борынгы тарихы белән дан казанган Мисыр гына түгел, ул гарәп көнчыгышының, мөселман культурасының үзәге дә. Хәзерге вакытта да Мисыр көнчыгышта әһәмиятле урын тота, андагы политика Якын һәм Урта Көнчыгышка билгеле йогынты ясый.

Халыкара аэропортта автобуска утырып, отельгә урнашу өчен, Каһирәгә юнәлдек. Вакыт төнге сәгать бер булуга карамастан, урамда җиңел машиналар чаба, велосипедлы кешеләр, йөк төялгән ишәкләр, җиргә тия язган голәбияләрен җилфердәтеп, баш түбәсенә йөк күтәреп баручы җәяүлеләр күренеп кала. Тиздән сәхәр вакыты җитә, кибетләрне ачарга әзерләк бара.

Рамсес II нче урамының ике ягында да зур реклама щитлары тезелеп киткән. Аларга бормалы-сырмалы гарәп хәрефләре белән «Стелла сырасын эчегез!», «Мисыр сигаретларын тартыгыз!», «Безнең фирма тукымалары һәркемне бизи»,— дип язылган һәм ике катлы йорт биеклегендә коньяк шешәсе ясап куелган. Ураза дип тормый реклама, мөселманнарга коньяктан да авыз итәргә куша!

Каһирә турысында Нил, тармакларга бүленеп, күп кенә утраулар хасил иткән. Шәһәр шул утрауларга урнашкан. Без торачак «Гомәр Хәйям» отеле Гезира утравында икән. Каһирәнең яшеллеккә күмелгән өлеше бу. Пальмалар, магнолия, эвкалипт, Мисыр акациясе, кып-кызыл чәчәкле олеандра, хуш исле розалар шәһәргә ямь биреп тора. Кайбер агачларны гаҗәп матур чәчәк атучы үрмәле гөлләр чолгап алган. Әйтерсең, зур агачлар чәчәк аткан.

Әкияттәгечә матур Гезира паркына 1952 елга кадәр инглизләр хуҗа булган, хәтта анда Мисырның премьер-министры да керә алмаган.

Мисырда безнең беренче танышкан кешебез Әхмәд Сәед әфәнде булды. Ул безгә хезмәт күрсәтүче туристик фирма вәкиле икән. Ачык йөзле, аз сүзле бу чибәр гарәп безнең Мисыр буйлап сәяхәтебез белән җитәкчелек итте.

Отельдә безне әйбәт каршы алдылар, яхшы җиһазландырылган номерларга урнаштырдылар. Иртәгесен совет илчелегендә булдык. Аннары Каһирә буйлап сәяхәт башланды. Каһирәдә безнең гидыбыз рус хатыны Клеопатра Андреевна булды. Ул Прагада туган, аңа ике тулганда әти-әнисе Каһирәгә күчеп килгәннәр. Африка кояшы үзенекен иткән, аны гарәп хатыннарыннан аера алмассың. Аны Каһирәнең иң яхшы гиды диләр. Дөрес булырга тиеш бу сүз. Мисыр халкының борынгы һәм хәзерге тормышы, соңгы елларда булган политик һәм социаль үзгәрешләр турында бер гид та Клеопатра Андреевна кебек тулы итеп сөйләмәде. Совет туристлары белән бик яратып эшлим, ди ул. Советлар Союзына бару — аның бик зур хыялы.

— СССРдагы тормыш турында ишеткәннәремне, укыганнарымны үз күзләрем белән күрәсем килә! — ди.

Каһирә белән беренче очрашуда ук аның архитектурасының чуарлыгы күзгә ташлана. Борынгы мәчетнең мәһабәт, озын манаралары яңа салынган небоскреблар биеклегенә җитәргә тырыша сыман. Шәһәрнең иске кварталларындагы тар, кәкре урамнар яңа, киң магистральләргә килеп тоташа. Урта гасыр мөселман архитектурасы

белән салынган йорт янәшәсендә көнбатышның модерн стилендә төзелгән бина. Монда Европа, Азия, Африка архитектура стильләре бергә очрашып, һәрберсе үзенең үзенчәлеген саклый, милли колорит, интернациональ универсализм хасил итә. Чит ил йогынтысына, мөселман булмаган халыклар культурасына, башка милләт кешеләренә Мисырда элек тә ят итеп карамаганнар. Бүгенге Мисыр гарәпләренең формалашуында күп халыклар — эфиоплылар, ливиялеләр, греклар, фарсылар, төрекләр, Кавказ һәм Урта Азия халыклары, хәтта кыпчаклар да күренекле урын тоткан. Шунлыктан мисырлылар тышкы кыяфәтләре, үз-үзләрен тотышлары ягыннан да төрлесе төрлечә. Гарәпләрнең милли киеме булган галәбия (озын күлмәк) киеп йөрүчеләр белән бер рәттән европача киенеп йөрүчеләр дә бик күп. Шәһәр яшьләре күбесенчә европача киенә. Хатын-кызлар урамнарда сирәк очрый. Ислам шәригате буенча, алар урамда кара күлмәк һәм кара шәл ябынып йөрергә тиеш. Әмма Мисыр хатын-кызлары пәрәнҗә бөркәнмиләр — бит каплау гадәте монда борынгыдан ук булмаган. Хатын-кызлар ил тормышында аз катнашалар. Барлык эштә: трамвайда кондуктор да, ресторанда савыт-саба юучы да, телефонистлар да, вокзалларда кассирлар да — ирләр. Эшләүче хатын-кызлар да очрый, ләкин әле алар аз. Хелуан шәһәрендәге текстиль комбинатында 16 мең кеше эшли. Шуның нибары 300 е генә хатын-кыз. Безнең СССРда хатын-кызларның җәмгыятьтә тоткан урыны турында сөйләвебез гарәпләрне бик нык гаҗәпләндерде.

Мең еллар буена яшәп килгән шәригать кануннары хатын-кызны гаилә колына әйләндергән, илнең иҗтимагый тормышыннан читләштергән. Ләкин замана үзенекен итә. Озын кара күлмәк киеп, кара шәлгә уранып баручы гарәп хатыны белән янәшә мини юбка кигән яки киеменнән чыга язган гарәп кызлары да очрый. Барда яки кафеда сигарет тартып, тезләрен ялтыратып утыручы (әлбәттә, буржуаз «алтын яшьләр»дән) кызлар да күренгәли.

Дүрт миллион ярым халкы булган Каһирә шәһәрендә автомашиналар хәрәкәте бик көчле, ул куркыныч ташкынны хәтерләтә. Машиналарның я музыкаль, я берәр җәнлек тавышына охшаган, я куркыныч булып ишетелгән гудоклары шәһәр халкын кисәтеп тора. Ләкин урам кагыйдәләре тегәл үтәлми. Кеше таптау еш була. Гарәпләр андый очракта артык шаккатмыйлар: «Алла биргән, алла үзе алган»,— гына диләр.

Каһирә — Берләшкән Гарәп Республикасының гына түгел, бөтен гарәп көнчыгышының культура үзәге. Анда гарәп илләрендәге иң бай китапханәләр, музейләр, кинотеатрлар, киностудияләр, театраль һәм музыкаль коллективлар тупланган. Күп кенә югары уку йортлары, шул исәптән өч университет бар. Аларның иң зурысында — Каһирә университетында 33 000 студент укый, 2000 укытучы эшли. Анда Мисыр тарихы укытуга, Мисырда һәм башка гарәп илләрендә милли азатлык көрәше тарихы, Июль революциясе тарихы, «гарәп социализмын» өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Студентлар Бөек Октябрь Социалистик революциясе һәм СССР тарихы белән дә нык кызыксыналар.

Әль-Обера мәйданында — 1869 елда (Суэц каналы ачылган көнде) ачылган опера театры. Хәзер анда, совет белгечләре җитәкчелегендә, хореография училищесы эшли.

Каһирәнең үзенчәлекле шәһәр икәне адым саен күренә. Без анда мөселман календаренең рамазан аенда — ураза вакытында булдык. Феллахтан (крестьян) алып академикка кадәр аллага ышаналар. Диннең власте көчле әле анда. Кичке сәгать биштә, авыз ачар вакытны белдереп, Әль-Әзһәр мәчете янында туп атып җибәрә, Каһирәдәге 300 мәчетнең манараларында төрле төсләге утлар кабына һәм алардан мәзиннең ахшам әйткән тавышы яңгырый. Манараларның күбесенә мәзин урынына репродуктор куелган. Авыз ачканнан башлап, радио, телевидение аллаһы тәгаләгә хезмәткә күчә. Моңарчы шау-гөр килеп торган шәһәр урамнары беразга бушап кала. Урам пешекчеләре бу вакытта үзләренең ризыкларын әзерләп өлгертәләр, урамдагы халыкның күбесе кайда туры килсә — шунда утырып ашый. Диннең власте никадәр генә көчле булса да, ул да заманга яраклашырга тырыша. Шәригать буенча рамазан аенда һәртөрле күңел ачу, җыр, музыка тыела. Ләкин хәзер моңа игътибар ителми икән. Ахшамнан соң кинотеатрларга, концерт залларына керермен дип уйлама: алар шыгрым тулы. Радио, телевидение уразага багышланган ике-өч сәгатьлек музыкаль программа тапшыралар.

Ләкин без үзебез ашый торган ресторапнарда кайбер гарәпләрнең көндезге ашка да йөрүләрен күреп, болар ничек ураза тотмый икән, дип гаҗәпләнә идек. Аның сере бар икән: ислам дине буенча сәүдә һәм башка эш белән йөрүче мосафирга ураза тотмаска мөмкин һәм үз машиналары булган кешеләр бик ансат кына «мосафирга» әйләнәләр икән. «Аллаһе тәгалә» дигәнең бай кешенең хәленә керә белә шул!

Каһирәгә быел 1000 яшь тулды. Бу шәһәр тарихи истәлекләргә гаҗәп бай. Каһирәнең Гиза районындагы борынгы пирамидалар һәркемне шаккатыра. Пирамидалар шәһәргә бик якын. Аларга менә дигән асфальт юл илтсә дә, теләге булган туристларны дөяләргә атландырып алып баралар. Без дә дөягә атланып бардык. Дөяне җитәкләп яннан гарәп бара, ул бераз барган саен сиңа борылып: «Бахшиш» [1],— дип куя.

Менә мәктәп дәресләкләреннән һәркемгә билгеле Хуфу (Хеопс) пирамидасы. Моннан 5000 ел элек төзелгән бу пирамида үзенең төзелеше белән дә, зурлыгы белән дә гаҗәпкә калдыра. Аның биеклеге 147 метр. Пирамиданы 100 мең кеше 30 ел эшләгән. Һәркайсы ике ярым тонна авырлыктагы 2 миллион 300 мең таш шомартылып, измәсез салынган.

Пирамиданың эченә дә кердек. Ул ялгыз кеше чыга алмаслык лабиринтлардан тора. Уртада зур күмү залы. Зал уртасында фиргавен мумиясе салынган саркофаг куелган булган. Пирамида эченә куйганчы, фиргавеннең мәетен аерым эремәгә салып 70 көн тотканнар, ул анда мумиягә әйләнгән. Аннары мумияне пирамидага күчергәннәр. Мумия белән бергә пирамидага фиргавеннең исән вакытта файдаланган барлык әйберләрен куйганнар, анда бик күп алтын булган, ләкин ул алтыннарны инде күптән урлап бетергәннәр.

Хуфу пирамидасы белән янәшә — Хафра (Хефрен) пирамидасы, аныкы 137 метр биеклектә. Пирамидалар борынгы кешеләргә бик зур тәэсир ясаганнардыр, әлбәттә. Ләкин бу таш таулар борынгы Мисыр халкына бик кыйммәткә төшкән. Хуфу пирамидасын төзү халыкның ачуын шул кадәр кузгаткан — пирамидада ул алты гына көн яткан. Җиденче көнне восстание күтәреп, халык аның байлыгын талаган, ә Хуфуның мумиясен пирамидадан чыгарып ташлаган.

Гиза пирамидалары белән янәшә борынгы Мисыр сәнгатенең гүзәл үрнәге — гигант Сфинкс урнашкан. Ул Сфинкс — кеше башлы арслан — фиргавен властеның көчен гәүдәләндергән. Борынгы Мисырда сфинкслар һәр храмда, һәр сарай алдында булган. Әмма Гизадагы сфинкс үзенең зурлыгы белән барысын да узган. Ул тоташ бер кыядан чокып ясалган, биеклеге 20 метр. Сфинкс тарихчылар өчен бер табышмак әле. Кайчан төзелгән ул, кемне гәүдәләндерә? Күп галимнәр аның йөзе Хафрага охшаган диләр. Бик мөмкин. Фиргавен Хафра аны, ихтимал, үз көчен күрсәтү өчен эшләткәндер. Ләкин без сфинксны Хафра истәлеге итеп түгел, аны эшләгән исемсез осталарга мәңгелек бөек һәйкәл буларак кабул итәбез. Күпне күргән Мисыр җиренең шаһиты булып, ул Каһирәгә бик горур карап тора. Мисырның бөтен тарихы диярлек аның күз алдында үткән.

Каһирәнең тирә-ягында гына түгел, шәһәрнең үз эчендә дә тарихи истәлекләр бик күп. Менә без Нил аркылы салынган «26 июль күпере» буйлап барабыз. 1952 елгы революция хөрмәтенә шулай аталган ул. Аннан ерак та түгел Касран-Нил күпере. Аны чыккач, шул исемдәге урам. Бу урамда бөтен дөнья египтологларын үзенә тарткан атаклы борынгы Мисыр музее урнашкан. Аның 100 дән артык залында борынгы Мисырның бәя биреп бетермәслек гүзәл тарихи истәлекләре саклана. Хуфуның, Хафраның, хатын патша Хатшепсутның, Тутмос III нең моннан 35—40 гасырлар элек эшләнгән скульптуралары хәзерге художникларны да сокландыра. Менә атаклы фиргавен Эхнатонның зирәк акыллы хатыны Нефертити бюсты. Ул әле дә бөтен дөньяда чибәрлек эталоны булып тора. Фиргавен килене Неферт скульптурасы кеше тәне төсендәге граниттан эшләнгән. Күзләре зәңгәр кварциттан, күз алмасы, кашлары кара таштан инкрустацияләп ясалган. Неферт музейга килүчеләргә елмая, күзләрен уйната кебек.

1920 елда тарихчылар өчен көтелмәгән ачыш ясала: археологлар моннан 33 гасыр элек яшәгән фиргавен Тутанхамон гробницасын табалар. Аның ишегендәге печате дә ватылмаган була. Ул зур гробница берничә залдан тора. Аларда Тутанхамонның ал-

---

[1] Чәйлек акча бир дигән мәгънәдә.

тыннан эшләнгән киемнәре, хезмәтчеләре аны күтәреп ялга алып чыга торган зиннәтле носилкалар, караватлар һәм бик күп башка хәзинәләр була.

Тутанхамонның мумиясе берсе эчендә икенчесе куелган сигез саркофаг эчендә булып, сигезенчесе 400 килограмм саф алтыннан эшләнгән.

Ислам сәнгате музеенда бөтен мөселман дөньясыннан сәнгать үрнәкләре, киемсалым, савыт-саба, тукыма, бизәнү әйберләре, архитектура үрнәкләре, шәмаилләр, китап-кульъязмалар саклана.

Тиз йөрешле поезд безне Мисырның көньягына — Луксор шәһәренә алып бара. Тимер юл Нил үзәнлеге буенча салынган. Нил — Мисыр халкын су белән тәэмин итүче, иген кырларын сугаручы бердәнбер елга. Бөтен чәчүлек җирләр диярлек Нил үзәнлегендә. Авыл кешесе буларак, авыл хуҗалыгында эшләүче буларак, мин Мисырның авыл хуҗалыгы белән аеруча кызыксындым. Крестьянның тормышы бик авыр шул әле анда. Иң кыены — су булдыру. Сугармасаң берни дә үсми. Каһирәдә инде алты ел, Асуанда егерме ел буена яңгыр яуганы юк, диләр. Авыллар бик ярлы. Ишек һәм тәрәзәсенә камыш чыпта асылган балчык өйләр күп. Крестьян сата торган продукция дә арзан. Бер кило апельсин ни бары бер трамвай билеты бәясе тора.

Мисыр җирләренең дүрт проценты гына эшкәртелә, җан башына 0,13 гектар гына җир туры килә. Җирдән өч мәртәбә уңыш алынса да, халыкны авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итү — Мисыр хөкүмәте өчен зур проблема. Насер житәкчелегендәге хөкүмәт илдә авыл хуҗалыгы кооперативлары төзүгә зур игътибар бирә. Хәзерге көндә ике миллион фәллахны берләштергән кырык мең кооператив төзелгән. Боларда бераз тракторлар да күренгәли. Ләкин күбесенчә эш кул көче белән башкарыла.

Луксор — борынгы Мисыр истәлекләренә бай шәһәр. Мисырлылар үзләре: «Луксорда булмаган кеше — Мисырны күрмәгән!» диләр.

Луксор шәһәре янында борынгы заманның бөек яулап алучысы Рамсес II нченең 19 метрлы гигант статуясы тора. 97 яшькә кадәр яшәгән, 100 хатыны, 174 баласы булган һәм 67 ел идарә иткән фиргавеннең гранит сыны бу...

Асуан — 150 мең кеше яши торган тузанлы гына шәһәр. Ул 20—25 елга бер генә яңгыр ява торган комлы-ташлы Нубия чүле белән Нил үзәнлеге арасына урнашкан. Шәһәрдән егерме километрда Советлар Союзының техник һәм материаль ярдәме белән плотина эшләнә. Ул цемент кулланмыйча, граниттан төзелә. Хәзер Берләшкән Гарәп Республикасында елга ике миллиард киловатт электр энергиясе эшләнә, ә Асуан ГЭСы елга 10 миллиард киловатт бирәчәк. Сугарулы җирләр 30 процентка артачак. Тиздән Асуан ГЭСы бөтен көченә эшли башлаячак. Унике турбинаның тугызы эшкә җигелгән инде.

Совет кешеләренә Мисырда зур хөрмәт белән карыйлар, ә Асуанда бу бигрәк тә сизелә. Күп кенә гарәпләр аз-маз русча да сөйли башлаган инде. Мисырның шәһәр урамнарында безне: «Руси добри», «Спасибо», «Хорошо, руси — садыйк», дип килеп кулларыбызны кысучылар бик күп булды.

Мисырда туристлар күп, ләкин совет кешеләрен тиз таныйлар. Моның сәбәбен безгә гарәпләр болай аңлатты: безнең кешеләрнең аларга мөнәсәбәте һәм үзләрен тотулары гади, табигый икән. Ә капиталистик дөньядан килгән бай туристлар гарәпләргә түбәнсетеп карыйлар.

Казан күренешләре төшерелгән открыткалар, татарча граммпластинкалар гарәпләргә бик ошады. Ә Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестеның гарәпчә тәрҗемәсе иң кадерле сувенир булды. Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк, безнең Казанда яхшы сувенирлар аз әле.

Мисырда балалар гаҗәп кызыксынучан. Алар туристлар белән бик тиз аралашып китәләр. Безгә Хургада шәһәрчегендә Яхъя Мостафа исемле гарәп малае аеруча нык ияләште. Ул алтынчы класста укый, һәрнәрсә белән кызыксынучан. (Мисырда балалар алты яшьтән укый башлыйлар, башлангыч мәктәптә алты, ә барлыгы уникe ел укырга кирәк.) Бер көнне ул безгә Израил самолетларының шәһәргә бомбалар ташлавы турында сөйләде. Яхъя сөйли, ә үзенең күзләрендә яшь. Шул сугыш вакытында әтисе үлгән, ә бер елдан соң әнисе авырып үлгән. Яхъя сеңелесе һәм бер энесе белән ятим

калган. Ул хәзер әтисенең энесе Абду семьясында яши, ә Абдуның үзенең дә биш баласы бар. Яхъяның сеңелесе икенче туганнарында яши, ә энесенең кайда икәнлеген ул белми. Мин аның укуы белән кызыксындым. Ул дәреслекләрен алып килеп күрсәтте. Мин аңа Ленин рәсеме төшкән значок бүләк иткәч:

— Ленин миндә бераү бар иде, аны миңа суфити сәих (совет туристы) бүләк итте. Ленин балаларны бик яраткан, ятим балалар турында кайгырткан, безгә бу турыда мөгаллимебез сөйләде,— диде.

Әйе, чүлдә комга күмелеп утырган кечкенә гарәп шәһәрчегендә дә беләләр Ленинны!

Беркөн шулай, Кызыл диңгезнең матурлыгына сокланып, яр буенда утырабыз. Яхъя да безнең янда. Көн үзәгендә кинәт кенә самолетлар гөрелтесе ишетелде. Яхъя сагая төште, безгә елышты. Күп тә үтмәде, аткан тавышлар яңгырады. Шунда Яхъя бик курыкты һәм:

— Качыгыз! Алар балаларга да аталар,— дип куйды.

Без соңыннан гына белдек: Израиль самолетлары Хургада өстенә килгән булган. Ә Берләшкән Гарәп Республикасы зениткалары ата башлагач, качканнар.

Безнең Мисыр буйлап сәяхәтебез Александрия шәһәрендә тәмамланды. Александрия (аны гарәпләр Искәндәрия дип йөртәләр) моннан 2300 ел элек Александр Македонский тарафыннан салына башлаган. Ул буйга егерме алты, иңгә егерме километрга сузылган бик матур шәһәр. Александрия — Мисырның диңгез капкасы. Бу шәһәрнең урамнары туры, матур, кибетләре бик бай. Анда гарәпләр белән бергә греклар, итальяннар, әрмәннәр һәм башка халыклар яши. Башыннан ахырына кадәр төренгән бәдәви хатыны белән чалмалы, голәбияле гарәпне дә, муенына тәре таккан христиан дин башлыгын да, иң соңгы мода белән киенгән кызларны да очратасың анда.

Мисыр шәһәрендә тормыш бик иртә, кояш чыкканда ук башлана. Эшчеләр завод-фабрикаларга ашыгалар. Базарлар ачыла. «Йокыдан намаз яхшы» дип, мөэзиннәр манарадан иртәнге намазга чакыра. Ләкин мәчетләрдә кеше кичен генә күп була. Мәчеткә йөреп кенә тамак туйдырып булмый шул! Эшләп тә көнне көнгә ялгавы җиңел түгел әле Мисыр халкына. Халыкның тормышын җиңеләйтү өчен күп кенә чаралар күрелсә дә, гасырлар буе колониализм изүе астында яшәгән илнең халкына ашарлык икмәк табу шактый кыенга туры килә.

Эшчеләр яши торган кварталларда кичке сәгать сигезләрдә тынлык урнаша. Эшче халыкның авыр тормыш иртәсе кояшның беренче нурлары белән башлана бит. Ә бай кварталларга урнашкан Сөләйман паша Кәсер-ан-Нил, Әл-Эзбикиа урамнарында, киресенчә, кичен халык бик күбәя, әйтерсең, бөтен шәһәр шунда җыела. Төн уртасына кадәр кибетләр эшли, тротуарлар җиләк-җимеш сатучы, кырык тартмачы, урам пешекчеләре белән шыгрым булып тора.

...Израиль агрессиясе илдә зур кыенлык тудырган. Ләкин утыз ике миллионлы Мисыр халкы гаделлек җиңәчәгенә, якын киләчәктә тынычлык урнашуга нык ышана. Әлбәттә, аларның өмете акланыр, чөнки гаделлек алар ягында.

**ГАБДЕЛБӘР ФӘЙЗРАХМАНОВ,**
Арча районының Куйбышев исемендәге
колхоз председателе.

# КЕРӘШЕН ЙОЛАЛАРЫ

*1968 елның җәй айларында Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты Татарстанның Чаллы, Әлмәт һәм Минзәлә районнарына диалектологик экспедиция оештырды. Экспедиция вакытында, әлеге районнарда яшәгән керәшен татарларының тел үзенчәлекләрен өйрәнү белән бергә, аларның тарихы, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре һәм җырларына да игътибар иттек.*

*Мәгълүм булганча, бу районнарда яшәгән татарлар XVI—XVII гасырларда ук христианлаштырылган булган һәм күп еллар буе халыкның төп массасыннан аерылып яшәгән. Бәлки, нәкъ менә шуңа күрәдер дә аларда мәҗүсилек белән бәйле йолалар күбрәк сакланып калган. Керәшеннәр арасында, мәсәлән, кешене төрле бала-казалардан коткара торган, авырулардан дәвалый торган серле сүзләр, «тел» белүчеләр күп булган. Аларның байтагы буыннан-буынга күчә-күчә безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.*

*Әлеге районнарда яшәгән халыкның элекке рухи тормышын чагылдыру ягыннан кызыклы материал булуларын искә алып, ул йола һәм гадәтләрнең кайберләре белән журнал укучыларын да таныштырып узмакчы булабыз.*

*Текстлар әдәби орфография белән бирелә. Аларның транскрипция белән язылган вариантлары һәм магнитофон язмалары институтның тел секторы фондында саклана.*

*Ф. ӘХМЕТОВА.*

I

## Ут теле

Ут атасы күк була.
Ут анасы соры була.
Утның кызы кызыл була.
Кызына калгач кызу була.
Ут, уйнама, уйнама,
Уйнамыйк, көлмиек,
Бергә гомер итмиек.

---

Әлеге сүзләрне әйтеп, ут чыккан җирдән өч тапкыр әйләнеп уза торган булганнар. Шулай үткәч, янәсе, ут сүнәргә тиеш була.

## Кан теле

Кызыл инә, кызыл җеп,
Кызлар җое җөйлием.
Бакыр инә, бакыр җеп,
Бакыр җое җөйлием.
Тимер инә, тимер җеп,
Тимер җое җөйлием.

Икенче варианты:

Ак таш агарып ята,
Кук таш кугәреп ята,
Кара таш кан тарта.

---

Кешенең берәр җире киселеп, кан ага башлаганда әйтелгән. Шуны өч мәртәбә әйтеп төкерсәң, кан, туктый имеш.

## Бүсер теле

Шүри бүсер, шүри бүсер,
Шүри бүсер, карт бүсер,
Карт булсаң да, ят бүсер.
Пичкә салдым дүрт икмәк,
Дүрт икмәк пичкә ябышып катадыр,
Шулай ябышып ят бүсер,
Пычак белән суярмын,
Чалгы белән кыярмын.

---

Эчтәлегенә караганда, бүсер белән авырган кешене дәвалаганда кулланылган булырга тиеш.

## Җил теле

Җилдән тисәң — җилгә кит,
Җирдән тисәң — җиргә кит,
Җиде юл чаты.

---

Чир җил белән тиде дип уйлаганда, әлеге сүзләрне әйтеп, колмак очыртканнар.

## Елан теле

Кара елан, чык елан,
Җептән нәзек калырсың.
Соры елан, чык елан,
Җептән нәзек калырсың.
Бакыр елан, чык елан,
Җептән нәзек калырсың.

---

Елан чакса, ул урынны әлеге сүзләрне әйтеп әйрән белән сыпыралар.

II

## Кырау куу

Яз көне кырау төшә торган вакытта яшьләр, иске чабаталар алып, басуга чыкканнар. Анда, бер-берсенә чабата атышып, шаярышып, «кырауның атасын-анасын куабыз» дип, кычкырып такыр басу ягына таба йөгерешкәннәр. Янәсе, кырауны такыр басуга куганнар.

Соңыннан әлеге иске чабаталарны өеп яндырганнар һәм, авылга кайтып, мунча төннекләрен чөеп йөрткәннәр. Бу хәл яктырганчы дәвам иткән. Шуннан соң хурланып кырау төшми башлый, янәсе.

# КАЗАНДА БЕРЕНЧЕ ТАТАР СПЕКТАКЛЬЛӘРЕ

Кешенең гомерендә озакка, хәтта бөтен гомерендә онытылмаслык истәлекле көннәре була. 1906 елның 22 декабре — минем гомеремдәге шундый көннәрнең берсе. Ул көнне Казанда татар телендә беренче спектакль куелды.

Куелды дип әйтүе генә ансат. Шактый мәшәкатьле һәм читен эш булды ул. Без, берничә кеше, 1906 елның ноябрь башларында Гариф Габитов (интеллигент-демократ) квартирына җыелдык һәм оештыру комиссиясе сайладык. Ул комиссиягә киләсе җыелышка кадәр пьесалар — бер драма, бер комедия сайлау, бина мәсьәләсен хәл итү эшен һәм башка шундый эшләрне тапшырдык. Икенче җыелышта комиссия сайлап алган «Кызганыч бала»[1] дигән драманы һәм «Гыйшык бәласе»[2] дигән комедияне тикшердек. Алар икесе дә шунда ук безгә ошады һәм без үзара рольләрне дә бүлештек, эшкә дә тотындык. Язучылардан Галиәстар Камал, Фатих Әмирхан, Г. Коләхметов, Сәгыйт Рәмиев, Габдулла Тукай безне бу эшкә рухландырып тордылар.

Репетицияләр ясар өчен хәзерге Большая Красная урамындагы приказчиклар союзының бинасы билгеләнгән иде. Соңыннан безгә спектакльне дә шунда куярга туры килде. Әмма аны куйганчы шактый мәшәкать булды әле. Тиешле органнардан спектакльне куяр өчен рөхсәт алырга кирәк иде. Аның өчен куелачак пьесаларның русча кыскача эчтәлеген, җаваплы оештыручының һәм спектакльдә катнашачак артистларның биографияләрен язып бирергә һәм спектакльне куюдан нинди максат күздә тотылуына аңлатма сорадылар. Шуларны тиз генә эшләп биргәч, ниһаять, спектакльне куярга рөхсәт бирелде. Аннары афишалар бастыру да шактый озакка сузылды. Аларны спектакль башланыр алдыннан гына урам витриналарына ябыштырдылар. Ярый әле газеталарда бер-ике көн элегрәк игълан басылып чыккан иде. Шулай да халык ишеткән иде булса кирәк, спектакль көнне касса янында бик күп кеше җыелды. Шау-шу күтәрелде, чөнки спектакль куелачак зал кечкенә булганлыктан, керергә теләүчеләрнең барысына да билет сатып булмый иде.

Спектакль без көткәннән дә зуррак уңыш китерде. Тамашачылар безне көчле алкышлап, кабат-кабат сәхнәгә чакырдылар. Бу хәл безне бик рухландырды. Икенче көнне, спектакль куючыларга рәхмәт белдереп, газеталар редакцияләренә бик күп хатлар килгән иде. Билетлар җитешмәгәнлектән, спектакльне күрә алмый калган кешеләр аны яңадан зуррак бинада куюны сорап язганнар иде. Аларның үтенечен искә алып, 22 декабрьда «Яңа клуб» бинасында (Б. Лядская урамында) спектакльне яңадан куярга булдык һәм, беренче спектакльнең уңышыннан рухланып, шунда ук икенче спектакльгә әзерләнә башладык. Бу юлы да каршылыклар күп булды. Татар хатын-кызларының да, пәрәнҗәсез генә спектакльгә килеп, ирләр белән бер залда утырулары турында белеп калган бөтен «Печән базары» купкан иде. Реакцион сәүдәгәрләр һәм кайбер мөселман руханилары, татар телендәге спектакльне икенче тапкыр күрсәтергә юл куймауны, рөхсәт бирелмәвен таләп итеп, полиция башлыгына делегация җибәргәннәр.

Бәхеткә каршы, ул делегация соңга калган. Алар полициягә барганда спектакль куюга рөхсәт язуы безнең оештыручыларыбызның кулында иде инде. Шуннан соң артык зур гауга булмады. Күрәсең, начальство үз карарын үзгәртергә

[1] Нәмык Камал әсәре.
[2] Нәмык Камал әсәре.

теләмәгәндер. Сәүдәгәрләрнең шулай ду кубып йөрүләре бер яктан безнең эчне пошырса да, икенче яктан аның файдасы да булды. Шул хәлләрдән соң халык театр белән аеруча нык кызыксына башлады. Спектакльне карарга дип шәһәр халкы гына түгел, хәтта якын-тирә авыллардан да бик күп кеше килгән иде. Тик, билетлар ала алмау аркасында, бу юлы да күп кеше карый алмыйча калды.

Тамашачылар залы шыгрым тулы. Менә соңгы звонок. Тынлык. Бөтен тамашачылар да сәхнәгә текәлгәннәр. Кереш сүзне шагыйрь Сәгыйт Рәмиев әйтте. Ул үзенең нотыгында, туган телдәге спектакльнең халкыбыз өчен әһәмиятле булуын һәм бу спектакльгә татар халкы тарихында беренче тапкыр яшь татар хатын-кызлары катнашуларын әйтеп, беренче тапкыр театрга килгән татар хатын-кызларын котлады. Тамашачылар аның чыгышыннан соң бик озак кул чаптылар. Аннары спектакль башланды. Тамашачылар артистларны тын да алмыйча тыңладылар. Спектакль тәмамлангач, тагын кул чабулар башланды. Сәхнә чәчәкләр белән тулды.

Ләкин безнең бу куанычыбыз озакка бармады. Печән базары элементларының, шайка оештырып, безгә, Казан шәһәренең Болак аръягында яшәүчеләргә, һөҗүм итәргә әзерләнүләре турында ишеткәч, күңелебез сүрелде. Башта кайберләребез бу хәбәрне буш сүз дип, аңа әллә ни игътибар итмәгән иде.

Спектакль тәмамланып, без гримнарны юып киенгән арада халык таралып беткән һәм вакыт бик соң иде инде. Клубтан чыккач, без, бер тирәдәрәк торучылар, барыбыз да бергә кайтырга булдык. Шәһәрнең үзәк өлешендә торучылар безгә тыныч йокы теләп хушлаштылар. Без буш урам буйлап ары атладык. Ләкин теге иптәшләребездән аерылып аз гына баргач, каршыбызга бер төркем кеше килеп чыкты да безне чолгап алдылар. Димәк, безне кисәтеп куюлары юкка гына булмаган икән. Арабызда булган хатын-кызларыбыз да шактый борчыла башладылар, без дә шүрләбрәк калган идек. Ләкин шулчак безгә ярдәм килде. Бөтенләй таныш булмаган бер төркем егетләр янныбызга килделәр дә, теге шайканы өркетеп җибәреп, безне квартирларыбызга тикле озатып куйдылар. Юлда тагын шунысы да мәгълүм булды. Печән базары әһелләре безгә Болак күпере төбендә һөҗүм итәргә тиеш булганнар икән. Күпер төбендә чыннан да байтак кына шикле кеше тора иде. Ләкин безнең бик күп икәнлегебезне күреп булса кирәк, бәйләнмәделәр. Шулай итеп, бернинди дә бәла-каза булмады.

Казанда татар телендә куелган беренче һәм аннан соң спектакльләрдә кемнәр катнашты соң? Алар, билгеле, профессиональ артистлар түгел, бәлки һәвәскәрләр иде. Инде мин аларның барысының да исемнәрен хәтерләмим. Хәтеремдә калганнары түбәндәгеләр:

1. Әминә Ибраһим кызы Терегулова — Петербургтагы хатын-кызлар югары курслары курсисткасы (студенткасы), соңыннан атаклы профессор мәрхүм Әбүбәкер Терегуловның хатыны.

2. Суфия Коләхметова — Казан хатын-кызлар югары курслары курсисткасы, соңыннан врач.

3. Шәмсекамәр Коләхметова[1] — медицина хезмәткәре.

4. Рәбига Габитова — Казан югары хатын-кызлар курсы курсисткасы.

5. Зәйнәб Терегулова.

6. Гайшә Багданова — гимназистка, соңыннан теш врачы.

7. Шакир Мөхәммәдьяров — укытучы һәм матбугат хезмәткәре.

8. Гимад Нугайбеков — матбугат хезмәткәре.

9. Сәйфелмөлек Гализов — Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте.

10. Әкрәм Кайбышев — укытучылар әзерләү мәктәбе укучысы...

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, спектакльләрдә катнашучыларның күбесе афишаларда чын фамилияләрен куймыйча, псевдонимнарын гына яздыра иделәр. Чөнки ул елларда хөкүмәт мәктәпләрендә укучыларга җәмәгать эшләренә катнашырга, төрле чыгышлар ясарга рөхсәт ителми иде. Минем үземә дә төрле спектакльләрдә һәм рольләрдә «Хайбушев», «Әкрәмов» һәм башка төрле псевдонимнар белән чыгышлар ясарга туры килде.

ӘКРӘМ КАЙБЫШЕВ

---

[1] Суфия да, Шәмсекамәр дә язучы Гафур Коләхметовның сеңелләре.

## Заһирә Гомәрова



### Нигә Вәли тиз үсми

Әй үстеләр арышлар,
Вәлине дә уздылар.
Аның битен кытыклап,
Башакларын суздылар.

Вәли нигә тиз үсми? —
Ни җавап табыйк моңар?
Арышлар,— ди әбисе,—
Яңгырдан курыкмыйлар.

Вәли яңгырга чыдый,
Тиз үсеп булмасмы,— ди,—
Күк күкрәп эшне боза...
Вәли өенә сыза.

### Күңелем

Нинди данлы Ботвинник.
Без аңа да мат бирдек.
Без ул, мин генә түгел,
Аның белән ярышта
Катнашты минем күңел.

Җиңәсең бик теләсәң:
Отылды бит Петросян.
Тик
Откан мин генә түгел,—
Аның белән ярышта
Катнашты минем күңел.



Уйныйм мин Самат белән,
Һөҗүм итәм ат белән,
Ул куркыта мат белән...

Җиңүләр җиңел түгел,
Җиңелми минем күңел,
Чемпион минем күңел.

## Чыланудан качалар



Күл буенда бакалар
Чумалар да калкалар;
Очып килде бер чыпчык,
Әй чыркылдый:
чырк-чырк-чырк!
— Ник анда шаулашасыз?
Ни өчен даулашасыз?
Ә бакалар: — бак,— диләр,—
Күнгә карап бак,— диләр,—
Яңгыр булачак,— диләр,—
Безнең сүзләр хак,— диләр,—
Безнең сүзләр чын,— диләр,—
Син дә суга чум,— диләр.
Чумалар да калкалар.
Менә нинди бакалар.
И гаҗәпләнде чыпчык:
— Чыланасыз бит —
чык-чык-чык!
Тамчы төшкәч башына,
Посты үзе дә шунда
Яшел яфрак астына.

## Укып бир



Әбекәем килсәнә,
Күзлегеңне кисәнә.
Язу язып утырдым,
Дәфтәремне тутырдым.
«Мин зул!» диеп йөрсәм дә,
Инде яза белсәм дә,
Укый белмим мин әле
Әби, укып бир әле.

## Табышмак

Кабара да кабара,
Аның саен агара.
Мич эчендә кызара,
Тәмле исләр чыгара.

Мичтән алгач мактыйлар,
Унган, диләр, ах, диләр;
Ул барында һәркемнең
Күңелләре шат, диләр.

Кисәләр дә: ак, диләр,
Мактыйлар да мактыйлар,
Ул булганда, мул булганда
Тормышлар гөрләп бара —
Нәрсә ул, әйтеп кара?

**Радик Фәизов**

# МОГҖИЗА



Төн урталары булгандыр, Ренат кисәк йокысыннан уянып китте. Янәшәдәге карават буш, хатыны Сания әле дә урынында түгел иде. Ренат аптырый төшеп залга чыкты. Кухняда ут яна, ачык ишектән залга яктылык төшкән. Сания диванда бала имезеп утыра иде. Ренат, сак кына басып, аның янына ук килде, шыпырт кына дәште. Ләкин Сания селкенмәде дә. Ул, тулы беләкләре белән баланың ялан гәүдәсен кочаклап, башын диван артына терәгән килеш утыра бирде. Ренат иелеп аның йөзенә карады. Бала сулык-сулык имә, ә ана көндез эшләп арган сәламәт кешеләр йокысы белән һичбер хәбәрсез йоклый иде! Менә баланың аягы салынып төште. Ана, тирән йокыда көе, нәкъ уяу кеше җитезлеге белән бу аякны уңайлап куйды.

Ренат Саниянең мәрмәрдән уелгандай ак, хәрәкәтсез йөзенә хәйран калып карап торды. Һәм кинәт үзен гаепле итеп сизгәндәй булды. Бу хис һаман көчәя барды, бу хис күңелен биләп алды. «Могҗиза...» — дип уйлады ул һәм, көтелмәгәндә башына килгән уйлардан арынырга теләп, кухняга чыгып утырды. Папирос кабызып җибәрде.

Ә кухня ялт иткән: анда бер генә чүп әсәре дә, бер генә юылмый калган савыт та юк. Чиста тәлинкәләр матур итеп өелгән, кашыклар, чәнечкеләр барысы да үз урынында. Аның көндез салып куйган ак күлмәге юылган, кипкән һәм үтүкләнгән. Хәтта тәмәке көле савытына кадәр чистартып куелган.

«Чынлап та могҗиза бит. Кай арада барысына да җитешә икән бу Сания? Исәпләп карасаң, бу тәлинкәләрне, кашыкларны һәрберсен юарга, корытып сөртергә генә дә күпме вакыт китә торгандыр. Ә бу күлмәкне юарга һәм үтүкләргә... Кухня идәнен, залны, йокы бүлмәсен юарга... Бала карарга, иртә-кич ашарга әзерләргә... Боларга күпме энергия сарыф итәргә кирәк икән?!» — дип уйлады Ренат. Ул йорттагы башка мәшәкатьләрне, азык кибетенә йөрүләрне хисапка салды, шулар өстенә хатынының көндез балалар бакчасында эшләп үткәргән җиде сәгатен китереп куйды. Аның маңгаена тир бәреп чыкты. Бер кешенең көн саен шул кадәр энергия сарыф итүенә һич ышанасы килмәде. «Могҗиза, могҗиза бу!» — дип кабатлады ул.

Ә бит шушы ук йортта ул да яши. Эше дә авыр түгел: бүлек мөдире. Эштән ул көн саен диярлек сәгать ярымга соңгарып кайта. Ул кайтышка ваннага кайнар су агызылган, чиста сөлге эленгән, ишек янына йомшак туфлиләр куелган була. Ваннадан чыгышка кайнар аш,

лимон туралган чәй әзер. Тамак туйгач, ул диванга килеп утыра, кызын — әле яше дә тулмаган нәнине алдына ала. Әмма нәнинең телевизорда гаме юк: әтисенең борынына ябыша, колакларын йолкый, күзләрен кармалый. Аны тиз арада әнисенә бирергә туры килә.

Ул телевизор карый. Программаны ошатмаса, китаплар, газеталар укыштыра. Ләкин диванда аның тик гәүдәсе утыра. Ә күңеле, уй-фикерләре бик еракта: футболчылар яисә хоккей уйнаучылар арасында, илнең төрле почмакларында, хәтта чит илләрдә йөри. Шул ук вакытта ул краннан су аккан, савыт-саба шалтыраган тавышларны ишетә. Борынына кызган үтүк исе, сабын исе бәрелә. Ара-тирә сабый көйсезләнеп, әнисеннән нәрсәдер таләп итә. Шулай итеп, Сания даими рәвештә нәрсә белән булса да мәшгуль була. Ул гүяки үзенә аерым бер тормыш белән яши. Ә Ренат бу тормышны бары тик тоя гына. Ул аның вак-төяген күрми. Бу тормыш аның аңына, тышта искән җил тавышыдай, кагылып кына уза. Ә инде гәүдәсенә рәхәт талгынлык җәелгәч, ул һәркөн чиста җәймә өстенә ята. Һәрвакыт чиста юрган ябына. Ә Саниянең эше һаман да бетми әле. Ренат йокы аралаш та аның кухняда нидер юганын, кырганын ишетә.

Менә шулай үтә гомерләре. Сания зарланмый, семьяда татулык.

...Ренат шактый уйланып утырды. Аның күңелен үзен Сания алдында гаепле итеп тою хисе кимерә иде. Юк, болай яшәргә ярамый... Ахырда ул, баягыча ук, сак кына басып, тагын хатыны янына килде. Аның кулыннан баланы алып, караватка салырга теләде. Ләкин, ул балага кулын тидерүгә, ана шунда ук күзен ачты.

— Ай, синме бу? Ник йокламыйсың?

— Баланы алып салмакчы идем...

— Син салып йокламый ул,— диде Сания. Һәм, дөрестән дә, әнисе куеныннан аерылган бала күзләрен уа, еларга әзерләнә иде. Аны яңадан әнисе кулына бирергә туры килде.

— Сания, мине иртәгә иртәрәк уят әле,— диде Ренат.

— Юләрләнмә, төн пәрие кебек йөреп, нинди иртәрәк ул тагын,— диде хатыны.

— Юк, син уята күр, зинһар,— дип кабатлады Ренат.

Ләкин хатыны дәшмәде. Ул тагын башын диван артына терәп, тынып калды. Чөнки әле нәни бала сулык-сулык имә, әле нәни бала тирән йокыга китмәгән иде.

# КҮГӘРЧЕН ФАЗЫЛ

Чакырган жиргә бар, куган җирдән кит, дигәннәр борынгылар. Хәзер заманалар үзгәрде, бу әйтем дә искерә бара, күрәсең. Һәрхәлдә, безнең Фазыл агай бу кисәтүнең нәкъ киресен эшли башлады.

Заман үзгәрде димәктән, авыл халкына әллә ни булды. Берсеннән-берсе үчеккәндәй, шыңгырдатып алтышар почмаклы йортлар салалар. Егетләре солдатка бармас борын өйләнеп җибәрә, дан итеп туен ясый. Ул кунак-муйнак уйнауны әйтеп тә торасы юк инде. Баеды халык, вәт нәрсә. Гөрләтеп мәҗлесләр үткәрүне чүпкә дә санамый.

Ә Фазыл агайның әкәмәт гадәтенә килсәк, ул менә шул мәҗлесләргә дәшкәнне көтеп-нитеп тормый. Юк-бар йомышын таба да мәҗлес башында гына килә дә керә. Кергәч, билгеле, урыны табыла. Урын табылгач, утырырга туры килә. Моның өчен берәүнең дә Фазылга җәйсыз сүз ишеттергәне юк. Ник дигәндә, Фазыл егет чактан ук җырга, шаян такмаклар әйтергә, мәҗлес халкының күңелен табарга мәчтер кеше. Ул кунаклар арасында җырлап, гөрләп кенә утыра. Шуна күрә күгәрчен Фазыл диләр дә аны.

Фазыл агай кыстатмый, халык сорагач, җырлый. Ә җырлагач, билгеле инде, тамак та чылатырга кирәк. Шулай җырлый-гөрли утыра торгач, кунаклар тарала башлый. Ә бу чакта Фазыл агайның кызып кына килгән, дәрте яңа кузгалган вакыты була әле. Инде өй тәмам бушап калгач та, ул хуҗаның үзенә, хатынына, туган-тумачаларына атап, берәрне әйтеп маташа әле. Хуҗаның инде бай-бай итәргә дә вакыт икәнен төрттерүен дә колакка элми. Кыскасы, аны өенә җитәкләп кайтарып куярга туры килә.

Әле беркөн клубта зур җыелыш булды. Колхозчылар барысы да килгән, район вәкиле дә бар иде. Шунда президиум сайлаганда, кайсыдыр Фазыл агайның да исемен кычкырды. Халык сорагач, ул каршы түгел инде, батыраеп сәхнәгә атлады. Әмма, бөтен авылдашлары каршына күтәрелгәч, шактый ук каушый калды тагын. Бригадир Харисның киң аркасы артына посып утыру ягын чамалады. Кичә ул югары оч егете Хәмбәл туена юлыккан, башы да бик авырта иде.

Председатель Ханнан җәйләп кына речь сөйләде, ә Фазыл агай тәмләп кенә черем итте. Күзләрен йомуга, каршына тагын кичәге мәҗлес килде. Яшьләр үбештеләр, чәркәләр күтәрелде, тальян моңнары сызылды. Менә бер заман бөтен мәҗлес ду купты. «Фазыл абый җырласын!», «Фазыл абый, берне әйтеп бир әле!» дигән сүзләр ишетелде. Фазыл агай исә, тамагын кырып, әзерләнә калды.

Нәкъ шул мәлдә Ханнанның рече иң кызык төшенә җиткән: ул авылда быел гына ничә кешенең яңа йорт торгызып чыкканын санарга керешкән иде. Ул кинәт тертелеп калды. Хәтере ялгышып, күзләрен түшәмгә текәде.

— Моны Фазыл төп-төгәл әйтер! — диде кемдер.

— Фазыл туган!

— Фазыл абый, әйтеп бир әле! — дигән сүзләр ишетелде.

— Ә? Мин хәзер... хәзер...— диде Фазыл һәм, урындык артыннан башын да күтәрмәстән, клуб залын яңгыратып «Алмагачы» көенә җырлап та җибәрде.

## Әхсән Баянов

### Үкенечкә

«Әй, тал нечкә, тал нечкә,
Талдыйн билләрең нечкә»,—
Дип зифа буеңны җырлау
Булды ла үкенечкә.

Үргә күп укталдым —
Кәрҗин чыкмый бер талдыйн.
Хәзер үзем, миңгә бөгелеп,
Җырның җыртыгын саныйм.

Сүзләреңә түз генә —
Көнгә түгел бер генә.
Нечкә таллар эләккәннән
Үзәк ныграк өзелә.

### Мәхәббәт корбаны

— Җаным-бәгырем, чиксез сиңа мәхәббәтем,
Шуннан күбен сиңа ходай күрсәтмәсен.
Дүрт стенам җайлылыгы кирәк түгел,
Ваннакаем җылылыгы кирәк түгел,
Карьерамның гүзәллеге кирәк түгел,
Бичәкәйнең йөз аллыгы кирәк түгел;
Өемдәге гарнитурлар булсын фида,
Гардеробым, кәстүмнәрем калсын шунда —
Калсын шунда гомер җыйган бар нигъмәтем.
Булган чакта сиңа олуг мәхәббәтем,
Китәр идем төренмичә толыпка мин,
Китәр идем җир читенә, котыпка мин!

— Китик, җаным, китик, булгач андый дәртең,
Чын гыйшыкка дөрес бәя бирер һәркем.

— Рөхсәт итәр микән ләкин... ничек әйтим...
Профсоюз комитеты? Һәм бүтән кем...
Итәр бәлкем?!
Ә?

## Әтәчләр сугыша

Буләсе йортмы бар,
Чортмы бар, югыйсә?
Утарда йон оча —
Әтәчләр сугыша.

Ун тамчы кан тамсын
Бер бөртек җим өчен —
Җәл түгел! Янәсе
Егетлек күренсен!

Әтәчлек әүвәлдә
Дефицит саналган.
Иблисләр аркылы
Әфьюн күк таралган.

Чишмәдән һәркемгә
тамчылап бүленгән.
Әтәчләр сизгәнче...
Кешеләр йөгергән.

Таң атса, көн туса,
Әтәчләр сугыша.
Мәңгелек түреннән
Карт иблис күз кыса.

Утарда йон оча,
Йон оча.

## Баганалар

Г. Латыйпка няру

Кайсы шәп, син үзең чамала,
Дөньяда күп була багана.
Күрдем мин төрлесен
аларның —
Кыскасын, озынын, юанын.

Кайберсе сураеп күренә
Юлның нәкъ уртасы-түрендә.
Бәрелеп ватылса арбалар,
Көпчәкләр арбасыз чабалар.

Кучәрне яңарту бик рәхәт,
Күңелдә төзәлми җәрәхәт.
Кирәкми алама багана
Сиңа дә, миңа дә, аңа да.

Була тик аларның шундые —
Йөрәккә дәрт бирә ел буе.
Күтәрә күперне, өйләрне —
Бөгелми, сыгылмый билләре.

Яшәргә өйрәтеп ирләрне,
Утыра бизәп ил-көннәрне.
Кирәк бу, кирәк бу багана
Сиңа дә,
Миңа дә,
Аңа да.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

### КАДЕРЛЕ ОБРАЗ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Соңгы ике елда Казан шәһәрендәге иҗат хезмәткәрләренең фәнни-теоретик семинары эшләп килде. Партиянең Казан шәһәр комитеты тарафыннан оештырылган бу семинарның шушы елның 16 апрелендә соңгы дәресе булды. Бу дәрес «Әдәбиятта һәм сәнгатьтә юлбашчы образы» дигән темага багышланган иде. Семинарда катнашкан язучылар, композиторлар, рәссамнар, артистлар алдында Казан сәхнәсендә В. И. Ленин образын тудыручылар: Татарстан АССРның халык артистлары Габдулла Шамуков, Шәүкәт Биктимиров, артист В. Остропольский чыгыш ясадылар, кадерле образны иҗат итү белән бәйле хисләре турында сөйләделәр.

СССРның халык артисты, композитор Нәҗип Җиһанов музыка өлкәсендә Ленин темасын иҗат иткәндәге уңышлар һәм бу өлкәдә алда торган бурычлар турында сөйләде. Танылган художник Лотфулла Фәттахов Ленин образын иҗат итүдә рәссамнарыбыз ирешкән казанышлар турында сүз алып барды. Филология фәннәре кандидатлары Азат Әхмәдуллин, Илбарис Надиров һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин татар әдәбиятында һәм халык иҗатында Ильич образының ничек гәүдәләндерелгәнлеге турында сөйләделәр. Һәм бу өлкәдәге аерым актуаль проблемаларга тукталдылар.

### МАТБУГАТ КӨНЕНӘ БАГЫШЛАП

5 майда Г. Тукай исемендәге клубта матбугат көненә багышланган тантаналы җыелыш булды. Матбугат көне турындагы докладны Татарстан АССР журналистлары союзы идарәсе председателе Ш. Х. Хаммәтов сөйләде. Ул җыелышта Татарстан АССР Министрлар Советы каршындагы матбугат идарәсе начальнигы В. П. Федоров һәм КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Н. А. Андриянов иптәшләр дә чыгыш ясап, журналистларны, полиграфия работникларын матбугат көне белән тәбрик иттеләр һәм аларга эшләрендә уңышлар теләделәр.

Тантаналы җыелышка катнашучылар, Америка һәм Сайгон интервентларының нейтраль Камбоджа җирләренә бәреп керүен нәфрәт белән гаепләп, бердәм рәвештә резолюция кабул иттеләр.

### ПРОЗА СЕКЦИЯСЕНДӘ

14 майда ТАССР язучылар союзы каршындагы проза секциясенең чираттагы утырышы үткәрелде. Аяз Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын» исемле яңа романы (бу әсәр «Казан утлары»ның 1969 елгы 10—12 һәм бу елгы 1 нче саннарында басылган иде) турында фикер алышуга багышланган ул утырышта язучылардан Гариф Ахунов, Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир, Шәйхи Маннур, Нурихан Фәттах һәм әдәбият белгече, филология фәннәре кандидаты Рифхат Свиригин чыгыш ясап, әсәргә карата үзләренең фикерләрен әйттеләр. Иң алдан чыгыш ясаган Г. Ахунов «Урамнар артында яшел болын»ның бүгенге заманның иң алгы сызыгыннан торып язылуын, әсәрдә актуаль проблемалар күтәрелүен билгеләп үтте. Ул үзенә аеруча әсәрнең авыл тормышын сурәтләгән бүлекләре ошаганлыгын, ә шәһәр тормышын сурәтләгәндә авторның урыны-урыны белән ашыгыбрак эш иткәнлеген дә искәртте.

А. Гыйләҗевнең бу әсәре турында сөйләгән барлык язучылар да әсәргә нигездә уңай бәя бирделәр.

### ФОТОКҮРГӘЗМӘ

Татарстан АССРның 50 еллыгына багышлап, республика журналистлар союзы һәм дәүләт музее «Туган ягым Татарстан» исемле фотокүргәзмә оештырдылар. Республикабызның табигатен, атаклы кешеләрен, промышленностен, авыл хуҗалыгын һәм куль-

турасын чагылдыруга багышланган бу күргәзмәдә, яна рәсемнәр белән берраттан, Октябрь революциясе, гражданнар сугышы, Ватан сугышы ветераннары, хезмәт фронты эшчеләренең шәхси альбомнарыннан алынган уникаль фоторәсемнәр дә куелган иде.

### ДУСЛЫК КИТАБЫ

Әле шушы көннәрдә генә Пермь китап нәшрияты «Четыре ветра» исемле яңа китап басып чыгарды. Рус телендә басылган бу китапка башкорт, коми-пермяк, татар һәм удмурт шагыйрьләренең шигырьләре тупланган. Татар шагыйрьләренең әсәрләре басылган бүлектә республикабыз шагыйрьләреннән Нури Арсланов, Әхсән Баянов, Шәүкәт Галиев, Зәки Нури, Нәби Дәүли, Хисам Камалов, Зөлфәт, Сажидә Сөләйманова, Сибгат Хәким, Ренат Харисов, Марс Шабаев һәм Илдар Юзеевларның берәр бәйләм шигырьләре урнаштырылган. Идел буе халыклары дуслыгын чагылдырган бу җыентыктагы рәсемнәрне художник М. В. Тарасова эшләгән.

### ҮЗЕШЧӘННӘР КҮРГӘЗМӘСЕ

Шушы елның апрель аенда Казандагы художниклар йортында В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан АССРның төзелүенә 50 ел тулуга багышлап, республикабыз үзешчән художниклары әсәрләренең күргәзмәсе үткәрелде. Анда 65 үзешчән рәсамның 320 хезмәте куелган иде. Ул күргәзмәдә В. И. Ленин образын тасвирлаган әсәрләрдән тыш, сынлы сәнгать, скульптура, графика һәм көнкүреш-бизәү сәнгате әсәрләре дә күрсәтелде.

### ЛАЕКЛЫ БҮЛӘК

Менә берничә ел инде Азнакай районында чыга торган «Маяк» газетасы журналистлары эшче һәм авыл хәбәрчеләре белән даими рәвештә актив эшләп килләр. Редакция сотрудникларының тырышлыгы нәтиҗәсендә районда эшче һәм авыл хәбәрчеләренең сафлары елдан ел арта бара. Мөһим хуҗалык-политик мәсьәләләрне хәл итүдә дә «Маяк» газетасы район партия оешмасына зур ярдәм күрсәтә.

Матбугат көне алдыннан газета адресына Мәскәүдән, СССР журналистлар Союзы идарәсеннән шатлыклы хәбәр килде. Анда эшче һәм авыл хәбәрчеләре арасында масса эшен яхшы оештырганы өчен, «Маяк» редакциясе коллективына Мария Ильинична Ульянова исемендәге бүләк һәм II дәрәҗә диплом бирелгәнлеге турында әйтелгән.

### ЮБИЛЕЙ ПОЧЕТ ГРАМОТАСЫ

Театр сәнгате өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры РСФСР Верховный Советы Президиумы, РСФСР Министрлар Советы һәм ВЦСПСның В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән булдырылган Ленин юбилее Почет грамотасы белән бүләкләнде.

Китап басуда ирешкән уңышлары өчен Татарстан китап нәшриятына да Ленин юбилее Почет Грамотасы бирелде.

### ЯЗУЧЫЛАР — САЙЛАУЛАРДА

Шушы елның 14 июнендә үткәрелгән СССРның сигезенче чакырылыш Верховный Советына сайлауларга әзерлек барышында шагыйрь Зәки Нури республика сайлау комиссиясенең рәисе булып эшләде.

* * *

Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Ибраһим Зариф улы Мингазиев (Ибраһим Гази) 638 нче Бөгелмә сайлау округыннан СССРның сигезенче чакырылыш Верховный Советының Милләтләр советына депутат итеп сайланды.

### БЕЛЕШМӘЛЕКНЕҢ ЯҢА БАСМАСЫ

Татарстан китап нәшрияты әле шушы көннәрдә генә «Писатели Советского Татарстана» («Совет Татарстаны язучылары») исемле библиографик белешмәлекнең тулыландырылган яңа басмасын бастырып чыгарды. Библиограф Әсия Гыйниятуллина тарафыннан төзелгән һәм 220 әдип турында зур гына мәгълүмат тупланган бу белешмәлекнең киләчәктә татарча басмасын чыгару да күздә тотыла.

### ШАГЫЙРЬ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

Латвиядәге Даугавпилс шәһәре тирәсендә сугыш елларында фашистлар хәрби әсирләр өчен лагерь корганнар һәм шунда күп кенә совет сугышчыларын әсирлектә тотканнар. 1942 елның август — сентябрь айларын-

да патриот шагыйребез Муса Җәлил дә шул лагерьда тоткында булган. Шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын яхшы белүче, аның турында күп кенә очерклар, мәкаләләр язган әдибебез Рафаэль Мостафин май аенда Латвиягә барып, заманында Муса Җәлил тоткынлыкта булган әлеге Даугавпилс тирәсендәге лагерь урыннарын карап һәм, җирле халыктан сорашып, шактый кызыклы материаллар туплап кайтты.

## БӨТЕНСОЮЗ КИҢӘШМӘСЕ

Май аенда Мәскәү шәһәрендә хәрби-патриотик темага язучы әдипләрнең Бөтенсоюз киңәшмәсе үткәрелде. Ул киңәшмәдә Татарстан язучыларыннан Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов һәм Тихон Журавлев иптәшләр катнашты.

* * *

13—14 май көннәрендә Куйбышев шәһәрендә хәрби-патриотик һәм гражданлык оборонасы темасын яктыртучы әдипләрнең, журналистларның, кино, телевидение, радио, газета һәм журнал редакцияләре хезмәткәрләренең җыелышы булды. Егерме алты өлкә һәм автономияле республика вәкилләре катнашында үткәрелгән ул җыелышка Татарстан язучылары союзыннан язучы Самат Шакир да барды.



РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН



ЮРИЙ ФЕДОТОВ

# ҖӘЛИЛ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

## МУСА ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАРСТАН КОМСОМОЛЫ ПРЕМИЯЛӘРЕ КОМИТЕТЫНДА

Җәлил исемендәге Татарстан комсомолы премияләре комитеты 1970 елда премияләр бирү турында карар кабул итте.

Әдәбият өлкәсендә: шагыйрь **Равил Габдрахман улы Фәйзуллинга** — 1969 елда чыккан «Мәрмәр» исемле шигырьләр җыентыгы өчен.

Театр сәнгате өлкәсендә: Качалов исемендәге Зур драма театры артисты **Юрий Степанович Федотовка** — А. Штейнның «Көчле яңгырлар арасында», М. Горькийның «Зыковлар», Брагинскийның һәм Рязановның «Бер яңа ел төнендә» спектакльләрендә Иван, Михаил, Лукашин рольләрен башкарганы өчен.

*Хөрмәтле иптәш!*

«Казан утлары» журналына язылу дәвам итә.

Әгәр Сез алдагы айлар өчен журналга язылмый калган булсагыз, һәр айның 20 сенә кадәр язылa аласыз.

Журналга Советлар Союзының барлык почта бүлекләрендә язылырга мөмкин.

Аның өчен, журналның 73210 номерлы индексын әйтеп, аена 50 тиен исәбеннән акча түләү җитә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ